50 ел

# Казан утлары

5

МАЙ-1972

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**5**

МАЙ
1972


## Бу санда

БИШЬЕЛЛЫК АДЫМНАРЫ


Ф. ТАБЕЕВ. Алга барышлый . . . . . . . . . 3


«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 50 ЕЛ


КПССның Татарстан өлкә комитеты котлавы . . 15
СССР Язучылар союзы идарәсе секретариаты котлавы . . . . . . . . . . . . . . . 15
РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретариаты котлавы . . . . . . . . . . . . . . . 16
Киләчәккә карап. Баш мәкалә . . . . . . . . 17


ҺӘР ШАГЫЙРЬДӘН БЕР ШИГЫРЬ


С. ХӘКИМ. Үткәнемә, узганыма бүген... . . . 22
Ш. МАННУР. Әйтче тагын... . . . . . . . . 22
Г. АФЗАЛ. Хәерле юл . . . . . . . . . . . 24
Ш ГАЛИЕВ. Яңгыр ява... . . . . . . . . . 25
З. НУРИ. Яза авыл, яза диңгез . . . . . . . 26
С. БАТТАЛ. Владивостокта татар җырлары . . . 27
ЗӨЛФӘТ. Сайрамас идеммени! . . . . . . . 28
Г. РӘХИМ. Арадашчы . . . . . . . . . . . 29

Ш. БИКЧУРИН. Каты токым. Роман . . . . . . 30


ҺӘР ШАГЫЙРЬДӘН БЕР ШИГЫРЬ


Х. ТУФАН. Кайтмый калган дуска . . . . . . 56
Ә. ИСХАК. Рәхмәт җыры . . . . . . . . . . 58
Ә. РӘШИТОВ. Россия . . . . . . . . . . . 60
Ә. БАЯНОВ. Хаталарым . . . . . . . . . . 61
М. ӘГЪЛӘМОВ. «Хәерле юл сүзгә» . . . . . . 62
Г. ЛАТЫЙП. Нинчәнче тапкыр... . . . . . . . 63

М. РӘФЫЙКОВ. Рәхмич. Йомышчы Әбүбәкер. Хикәяләр . . . . . . . . . . . . . . . 64
Ү. САТТАРОВ. Кызым хикәяләре . . . . . . . 75


ҺӘР ШАГЫЙРЬДӘН БЕР ШИГЫРЬ


Н. АРСЛАНОВ. Кайтмый калмый . . . . . . . 79
И. ЮЗЕЕВ. Ни язар тимерче . . . . . . . . 80
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Әгәр дә мин... . . . . . . . 80
Р. ХАРИС. Чаллыда уйлану . . . . . . . . 81
Р. ГАТАУЛЛИН. Сүнмәс утлар белән . . . . . 82
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Эх, сабый чакларымда да... . 83

Ф. МАНСУРОВ. Яктытауда бүз тургайлар. Повесть. 84



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## БЕЗНЕҢ АНКЕТА


З. НУРИ. Журнал өчен, журнал белән . . . . 127
М. ӘМИР. Зур байлыгыбыз . . . . . . . . . 128
А. ШАМОВ. Журналның бер нөсхәсе . . . . . 129
Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Журналның үз архивын булдырыйк . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Үткән юлы зур, киләчәк юлы якты . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Журнал миңа — мин журналга. 134
Ф. ХӨСНИ. Аның яктысында... . . . . . . . 134
Ә. МАЛИКОВ. Сихотэ-Алин таулары аша . . . 135
Ә. ЕНИКИ. «Безнең юл» — «Казан утлары» . . . 136
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Поэзия мәктәбе . . . . . 137
Р. ИШМОРАТ. Ярату хисләре белән . . . . . . 138
Э. КАСЫЙМОВ. Яшьнәп-күкрәп яшә! . . . . . 138
А. РАСИХ. Әдәбият мәйданына юл ачучы . . . 139
Б. КАМАЛОВ. Остаз, арадашчы, дус . . . . . 140
Г. АФЗАЛ. Журнал миңа нәрсә бирде . . . . . 141


## ИСТӘЛЕКЛӘР


Г. ИДЕЛЛЕ. Ул елларда . . . . . . . . . . . 142


## ОЧЕРКЛАР


И. ИШМОРАТОВ. Давыл алдыннан . . . . . . . 152
М. ЗАРИПОВ. Тылсымлы нур . . . . . . . . . 158


## СӘНГАТЬ


Х. КУМЫСНИКОВ. Тыйнак кеше, сәләтле артист . 164


## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Р. МОСТАФИН. Укучы һәм язучы . . . . . . . 169
Т. МИҢНУЛЛИН. Без «театр» уйныйбызмы! . . . 175


## КИТАП КҮЗӘТҮ


Г. РАМАЗАНОВ. Заман рухында . . . . . . . . 179


## БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ


Х. ХАЛИКОВ. Яңгыр хәбәрчеләре. Шигырьләр . 182


## ЮМОР-САТИРА


Р. ИСАЕВ. Күрәзәче. Перекур. Хикәяләр . . . . 184
Г. ЛАДОНЩИКОВ. Кысыр хәсрәт. Эпиграммалар . 186
«Чаян» котлавы. . . . . . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 188

Аккошлар. Ноталы җыр. Ф. ӘХМӘТОВ көе, Р. ФӘЙЗУЛЛИН җыры . . . . . . . . . . 192



Баш редактор: Гариф Ахунов.

Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Техник редакторы Р. Нәбиуллина.
Корректорлары Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева

Производствога бирелде 11/II-1972 ел. Басарга кул куелды 3/IV-1972 ел. ПФ 09013. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87396 экз. Заказ Г-103. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1972 ел.

**Фикрәт Табеев,**

КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре

# АЛГА БАРЫШЛЫЙ

Яңа, тугызынчы бишьеллыкның икенче елы бара. Ул олы бәйрәмгә — Совет Социалистик Республикалар Союзы төзелүенең ярты гасырлык юбилеена хәзерлек шартларында уза. Илебез халыклары бу зур бәйрәмне хезмәттә һәм иҗатта яңа уңышлар белән каршыларга җыеналар.

Хаклы рәвештә горурлана алабыз: без дәүләтебезнең ярты гасырлык бәйрәмен совет кешеләренең какшамас бердәмлеге нығыган шартларда, марксизм-ленинизмның җиңелмәс байрагы астында берләшкән төрле милләт һәм халыкларның җимерелмәс дуслыгы нығыган шартларда билгеләп узачакбыз. Без горурлана алабыз: партиябез В. И. Ленинның милли политика өлкәсендәге төп васыятен тормышка ашырды, бездә пролетар интернационализм идеяләре рухында тәрбияләнгән совет халкы оешты.

Татарстан хезмәт ияләре СССРның 50 еллыгын аеруча зур горурлык белән каршылыйлар. Чөнки Совет Татарстаны Ленинның турыдан-туры катнашы белән, аның җитәкчелегендә төзелә. һәм Совет власте яшәгән ярты гасыр вакыт эчендә республикабыз узган юл ленинчыл милли политиканың гүзәл тантанасы турында сөйли. Без массаларның культура дәрәҗәсе күтәрелүне яки өлкәнең иксез-чиксез табигый байлыкларын үзләштерүне, заманча промышленность булдыруны яки авыл хуҗалыгында коллектив производствога күчүне алабызмы, бу эшләрнең һәммәсендә, иҗтимагый тормышның башка сфераларындагы кебек үк, татар халкы илебез халыкларының, беренче чиратта рус халкының, зур ярдәменә һәм булышлыгына таянды. Шуя ук вакытта, Союзда иң югары үсешкә ирешкән республикаларның берсе буларак, Татарстан үзе дә башка халыкларга ярдәм итеп килә, шул юл белән коммунизм төзү эшенә өлеш кертә, Советлар Союзындагы барлык халыкларның дуслыгын һәм интернациональ хезмәттәшлеген нығыта.

Борынгы дәверләрдән башлап безнең көннәргә кадәр бабаларыбыз меңнәрчә еллык катлаулы юл узган. Мең ел һәм 50 ел. Гасырлар биеклегеннән торып карaганда, соңгысы диңгездән бер тамчы кебек кенә. Әмма Совет власте шартларында узган шул 50 ел безнең өлкәне танымаслык итеп үзгәртте.

Казан губернасының революциягә кадәрге хәленә күз салыйк. Ул Россиянең иң артта калган бер аграр почмагы иде. Промышленность юк дәрәҗәсендә. Кустары-

чылык характерындагы вак предприятиеләр һәм башлангыч хәлендәге машина төзелеше — бар булганы әнә шул. Казан губернасының экономикасы нинди кызганыч хәлдә булуын күрсәтү өчен, бер генә факт китерик. 1909 елда Казанда промышленность күргәзмәсе оештырыла. Күргәзмәгә килүчеләрнең берсе теләкләр дәфтәренә шундый сүзләр язып китә: «Әгәр бу күргәзмә күпмедер дәрәҗәдә игътибарга лаек икән, бары артталыкны күрсәтүе ягыннан гына лаек була ала». Бик гыйбрәтле сүзләр... Губерна грамоталылык дәрәҗәсе буенча да арттагы урыннарның берсендә торган.

Бәхеткә каршы, боларның һәммәсе ерак үткәндә калды. Октябрь революциясенең саф җилләре татар халкын милли изелүдән, хокуксызлыктан һәм хәерчелектән коткарды, аны якты, бәхетле тормыш юлына чыгарды. Татарстан бүген алдынгы промышленность һәм авыл хуҗалыгы республикасына, югары үсешкә ирешкән фән һәм культура республикасына әйләнде.

Әле Совет властеның беренче елларында, 1919 елда ук, В. И. Ленин тәкъдиме белән Казан губернасына беренче геологик экспедиция җибәрелә. Аннан бирле ярты гасырлап вакыт узды. Һәм менә Татарстан чынлап та фонтан һәм вышкалар иленә әйләнде. Нефть промышленносте үсешендә күрелмәгән темплар белән эшләү Татарстанны тиз арада нефть җитештерүче иң эре районнар сафына чыгарды.

Татарстанның энергетика базасы үсешенә күз ташлап алу да кызыксыз булмас. Әгәр элек бездә промышленностьның бу тармагы бөтенләй булмаса, хәзер республика җан башына электр энергиясе җитештерү буенча Япония, ФРГ, Бельгия, Франция, Италия, Австрия кебек илләрне узып китте. Казан, Түбән Кама, Зәй һәм Урыссудагы электр станцияләре бер ел эчендә генә дә 12 миллиард киловатт-сәгать электр энергиясе җитештерәләр. Бу — революциягә кадәр бөтен Россиядә җитештерелгән электр энергиясеннән 6 тапкыр күбрәк.

Промышленность һәм авыл хуҗалыгында да, фән һәм культура өлкәсендә дә, кешеләребезнең көндәлек тормышында да шул ук хәл. 50 ел — ул үсеш еллары, алдагы грандиоз эшләр өчен куәтле база булдыру еллары. Сигезенче бишьеллык әнә шул базаны, коммунизмның материаль-техник базасын, төзү һәм ныгытуның бер этабы булды.

Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXIV съезды сигезенче бишьеллык планнарының үтәлешенә йомгак ясады, XXIII съезддан соңгы вакыт эчендә булып узган мөһим хәлләргә һәм вакыйгаларга төпле бәя бирде, совет җәмгыятенең алга таба үсеш юлларын билгеләде.

Илнең экономик куәте арту, совет кешеләренең материаль хәле тагын да яхшыру, эшчеләрнең һәм колхозчыларның белем-культура дәрәҗәсе сизелерлек үсү безнең республикадагы экономик һәм социаль мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеген дә шактый җиңеләйтте.

Узган бишьеллык вакыйгаларына борылып караганда, без, барыннан да элек, батыр нефтьчеләребезгә мактау сүзләре әйтергә тиешле. Нефтьнең халык хуҗалыгындагы әһәмияте әйтеп бетергесез. Шуңа да нефть промышленностен алга таба үстерү һәм камилләштерү юлындагы һәр яңа адым хуплап каршы алына, мөһим бер вакыйга итеп карала. Узган бишьеллыкта Татарстан нефтьчеләре андый адымнарны күп ясадылар. Республиканың нефть промыселлары яңа техника һәм технологияне, хезмәтне һәм производствоны оештыруның алдынгы ысулларын сынау буенча гигант лабораториягә әйләнде, аларда йөзләрчә фәнни-техник мәсьәләләр эшкәртелде. Буровойларда, нефть промыселларында, төзелеш мәйданнарында, лабораторияләрдә бүгенге тормыш көн тәртибенә куйган теләсә нинди катлаулы мәсьәләләрне иҗади хәл итәргә сәләтле белгечләр, эшчеләр һәм галимнәр үсте.

Сигезенче бишьеллык дәвамында республика нефтьчеләре илгә 100 миллион тонна «кара алтын» бирү өчен көрәшеп эшләделәр. Һәм ул көн килде. 1970 елның 30 декабрендә бер ел эчендә Татарстанның нефть ятмаларыннан 100 миллионынчы тонна сыек ягулык чыгарылды. Илнең нефть промышленносте тарихында бер елда бер районда моның кадәр нефть чыгарылганы юк иде әле. КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы Татарстан хезмәт ияләренә җибәргән тәбрик хатларында бу зур казанышка югары бәя бирделәр: «Татарстан нефтьчеләре,— диелә бу хатта,—

табигый байлыкларны тизрәк үзләштерү өчен актив көрәш алып баралар, күп кенә катлаулы мәсьәләләрне иҗади рухта кыю чишеп, алар нефть чыгаруның югары темпларына ирештеләр, илнең энергетика-ягулык базасын ныгытуга зур өлеш керттеләр».

Узган ел Татарстан нефтьчеләренең тырышлыгы белән тарихка тагын бер истәлекле дата теркәлде. 1971 елның 14 маенда Татарстан җиреннән, нефть чыгарыла башлаганнан бирле, миллиард тонна нефть алынды. Миллиард тонна нефть... Илнең иң зур нефть районы Бакуга шул хәтле нефть чыгару өчен 100 еллап вакыт кирәк булган, Татарстан нефтьчеләре аны егерме биш ел вакыт эчендә бирделәр.

Партиянең XXIV съезды республикабыз нефтьчеләре алдына катлаулы яңа бурыч куйды: без бишьеллык буена нефть чыгаруның хәзерге дәрәҗәсен киметмәскә тиеш. Бу катлаулы, әмма үтәлерлек бурыч. Яңа бишьеллыкның беренче елында 101 миллион 143 мең тонна «кара алтын» алуга ирешү шул турыда сөйли.

Узган бишьеллыкта безнең республика илнең химия һәм нефть химиясе промышленностен үстерүгә зур өлеш кертте. Химия продукциясе җитештерү ике тапкырдан артыграк үсте. Хәзер без — халык хуҗалыгына бик тә кирәкле булган полиэфирлар, техник фотопленкалар, модификаторлар, аерым төр дарулар җитештерүче бердәнбер республика. Химия лабораторияләре өчен югары температурага түзем пыяладан ясала торган приборларның, фотография желатинының бөтен күләме, кино һәм фотопленкаларның яртысы, Советлар Союзында җитештерелә торган полиэтиленның өчтән бере бездә эшләнә. Тугызынчы бишьеллык химия һәм нефть химиясе промышленностен кызу темплар белән үстерүне күздә тота. һәм бишьеллык планнарын уңышлы хәл итүдә безнең республикага зур бурычлар йөкләнә. Чөнки бездә яңа төзелә торган нефть химиясе комбинатларына кирәкле арзанлы чимал запаслары күп. 1971—75 еллар эчендә Татарстандагы химия продукциясенең күләме 2,6 мәртәбә артачак. Үсеш нигездә яңа предприятиеләр төзү, эшли торганнарын киңәйтү һәм үзгәртеп кору хисабына тормышка ашырылырга тиеш.

Татарстанда нефть химиясен алга таба үстерүдә хәлиткеч рольне сигезенче бишьеллыкта сафка баскан Түбән Кама нефть химиясе комбинаты уйнаячак. Химия фәне һәм химия техникасының иң алдынгы казанышлары, нефть химиясен үстерүдәге иң яңа техник алымнар, кыйммәтле дөньякүләм тәҗрибә, эре промышленность комплекслары төзүнең алдынгы тенденцияләре — бу комбинатның техник проектында шуларның һәммәсе чагылыш тапты. Бу бишьеллыкта Түбән Камада автомашина шиннары җитештерә торган зур завод сафка басарга тиеш, башта ул «Жигули» маркалы җиңел автомобильләрне тәэмин итәчәк, ә 1974 елдан КамАЗда эшләнгән йөк машиналарына хезмәт күрсәтүгә күчә. Республиканың иң карт шәһәрләренең берсе Менделеевск да, Түбән Кама һәм Чаллы кебек үк, гигант төзелеш мәйданына әйләнәчәк. Анда катлаулы минераль ашламалар җитештерә торган Яңа Менделеевск заводы төзелә башлый. Ул үзе җитештергән ашламалар белән бер Татарстанны гына түгел, ә бөтен Идел буе игенчеләрен тәэмин итәчәк.

Химия, халык хуҗалыгының бөтен өлкәләренә, кеше тормышының барлык сфераларына үтеп кереп, промышленностьтагы иң алдынгы тармакларның берсенә әйләнде. Менә ни өчен партиябезнең XXIV съезды химия промышленностен үстерүгә шундый зур игътибар бирде, менә ни өчен яңа бишьеллыкта без бу өлкәдә икеләтә энергия белән эшләргә җыенабыз.

Әле совет дәүләте яши башлаган беренче елларда ук В. И. Ленин: «Яңа социалистик стройның җиңеп чыгуы өчен бер генә юл бар — ул илнең хуҗалыгын яңа техник базага күчерү юлы»,— дигән иде.

«Кемдә иң яхшы техника, оешканлык, дисциплина һәм иң шәп машиналар — шул өстен чыгачак»,— диде ул. В. И. Ленин күрсәткән юлдан барып, кыска гына вакыт эчендә совет дәүләте промышленностьта, авыл хуҗалыгында, транспортта һәм халык хуҗалыгының башка тармакларында техник прогрессның нигезе булган беренче класслы машина төзелешен булдырды.

Бу өлкәдә безнең республикабыз зур уңышларга иреште. Артык зур булмаган вакыт эчендә ул артта калган аграр районнан илебездәге машина төзелешенең эре үзәгенә әйләнде. Бүген индустриаль Татарстан җитештергән самолетлар һәм дви-

гательләр, суыткыч машиналар һәм җылылык үлчәү приборлары, манометрлар һәм регуляторлар, сәгатьләр һәм кинокамералар бөтен илгә билгеле.

Узган бишьеллыкта бездә машина төзелеше һәм металл эшкәртүче тармаклар аеруча кызу темплар белән үсте. Бу өлкәләрдә җитештерү күләме 2,5 мәртәбәгә артты. Шунысы игътибарга лаек, үсешнең дүрттән өч өлеше хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү хисабына туры килә. Республика промышленностеның бер генә тармагында да мондый темпларның булганы юк әле.

Мондый үсешкә без ничек ирештек соң? Бездә машина төзелешенең производство-техник базасы шактый киңәйде, фәнни-тикшеренү һәм проект-конструкторлык оешмалары үсте һәм ныгыды, барлык станоклар яңартылды. Шуларның һәммәсе яңа продукцияләр үзләштерүне тизләтергә, сыйфатны яхшыртырга һәм машина төзелеше предприятиеләрендә эшләнгән әйберләрнең хезмәт срогын озайтырга мөмкинлек бирде.

Без горурланып әйтә алабыз, Татарстанның машина төзелеше предприятиеләрендә җитештерелгән дистәләрчә товарлар Дәүләтнең сыйфат билгесенә лаек булды. Моңа без меңнәрчә кешеләрнең продукциянең сыйфатын яхшырту, аның ныклыгын һәм хезмәт итү срогын арттыру өчен үз-үзләрен аямыйча көрәшүләре нәтиҗәсендә ирештек.

Узган бишьеллыкның тагын бер характерлы үзенчәлеге шунда: машина төзүчеләр технологияне камилләштерү өлкәсендәге алдынгы алымнарны бөтен фронт белән куллана башладылар, техник прогресс белән фәнни идарә итү һәм фәнни-техник прогнозлаштыру проблемаларын чишүгә тәмам якынлаштылар, фәнни прогресс өлкәсендәге башка төрле яңалыкларны кыюрак куллана башладылар.

Республикада промышленностьның яңа тармагы — автомобиль төзелеше туып килә. Чаллы җирендә партия ихтыяры белән илебез индустриясенең яңа гиганты — Кама автомобиль заводы барлыкка килә. Ул мәсьәләгә аерым тукталырга кирәк.

Партия һәм хөкүмәтебезнең Татарстанда гигант автомобиль заводы төзү турындагы карарын республиканың партия оешмалары һәм барлык хезмәт ияләре кайнар рәвештә хуплап каршыладылар. Менә ике ел ярым инде автогигант комплексы объектларында төзүчеләрнең һәм монтажчыларның ныклы коллективын туплау, аларның хезмәт һәм тормыш шартларын яхшырту буенча зур эш алып барыла. Илнең бөтен почмакларында берсеннән-берсе зуррак яңа төзелешләр бара, шуңа күрә хәзер бездә төзелешләрнең колачы һәм күләме белән кемне дә булса шаккаттыру шактый кыен эш. Шулай да борынгы елга ярларында үсеп килгән КамАЗ үзенең күләме, колачы һәм темплары белән хәтта бүгенге иң зур төзелешләрдә булган кешеләрне дә таң калдыра.

Чагыштырып карау өчен кайбер саннар китерик. 1970 елда төзүчеләр коллективы 72 миллион 300 мең сумлык төзү-монтаж эшләре башкардылар. 1971 елда бу сан 224 миллион 800 мең сумга җитте, ягъни өч тапкырдан артыграк үсте. Әгәр 1970 елның январенда СССР Энергетика һәм электростанцияләр министрлыгының Чаллыда 9 меңләп төзүче һәм монтажчылар коллективы булса, 1972 елның январенда аларның саны 38 мең кешегә җитте. Хәзер КамАЗ объектларын төзүдә барлыгы 60 меңләп кеше эшли.

Чынлап уйласаң, биредә индустриянең әр-яңа бер үзәге төзелә, киләчәктә ул республикабыз промышленностен тагын да гармоник төстә һәм экономик яктан күбрәк файда китерерлек итеп үстерергә мөмкинлек бирәчәк.

Производствоны бер үзәккә туплау һәм техник дәрәҗәсе ягыннан Кама автомобиль заводы илебездәге иң эре автомобиль төзелеше предприятиесе булачак. Ул елына 150 мең данә авыр йөк машинасы, 250 мең данә дизель двигательләре эшләп чыгарачак. Специальләшкән алты заводтан гыйбарәт бу грандиоз комплекс кою эшләре, кайнар һәм салкын штамповкалар, автомобильләр җыю эшләре башкарачак, рамалар һәм кабиналар, дизель двигательләре, транспорт өчен кирәкле күп кенә башка җиһазлар җитештерәчәк.

КамАЗны төзү фән һәм техниканың соңгы сүзе буенча алып барыла: илебез автомобиль төзелешендәге иң яңа алымнарыннан берсе — эре корпуслар төзү алымы башлап шушында кулланыла. 1 миллион 225 мең квадрат метр зурлыгындагы мәй-

данны күз алдына китереп карагыз. Төзелеп яткан заводның дүрт цехы гына да шуның кадәр мәйданны билиячәк. Мондый зур корпуслар салу җиһазларны урнаштыру, заманча технологик линияләр төзү, транспорт, җылыту һәм вентиляция мәсьәләләрен һәм бүгенге промышленность предприятиеләрендәге башка күп кенә мөһим мәсьәләләрне иң рациональ юл белән хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Тагын шуны өстәргә кирәк, автомобиль комплексы составында иң яңа җиһазлар белән коралланган лабораторияләр, инженерлык, электрон-хисаплау үзәкләре төзеләчәк, бу анда теләсә нинди катлаулылыктагы тәҗрибәләр, фәнни тикшеренүләр алып барырга мөмкин булачак дигән сүз.

Төзүчеләрнең ике ел ярым вакыт эчендәге героик хезмәте Кама ярларын танымаслык итеп үзгәртте. Төзелеш индустриясе һәм производство базаларының күп кенә объектларын төзү тәгәлләнде, бетон юллар, тимер юл магистральләре салынды, дистәләрчә күп катлы яңа йортлар үсеп чыкты, балалар учреждениеләре, мәктәпләр, кибетләр файдалануга тапшырылды, яңа кинотеатрлар, эстрада мәйданнары ачылды.

КамАЗ — иң яңа, иң куәтле техника өстенлек иткән гади бер төзелеш мәйданы гына түгел, ул күп милләтле совет халкының характер көче ныгый һәм чыныга торган плацдарм да. Энтузиазм колачы һәм эшләүчеләрнең интернациональ составы ягыннан аны Днепрогэс яки Магнитка, Беломорканал яки Комсомольск, Братск яки Усть-Илим белән генә чагыштырырга мөмкин. КамАЗны бөтен ил төзи. Данлы зур эшләре белән төзүчеләрнең бүгенге буынын тарихка кертеп калдыру өчен, бирегә Чувашстан һәм Башкортстаннан, Украина һәм Белоруссиядән, Мәскәү һәм Ленинградтан, Төньяктан һәм Ерак Көнчыгыштан меңнәрчә егетләр, кызлар килде. Кама буйларында ВЛКСМ Үзәк Комитетының 500 кешелек интернациональ бригадасы эшли.

Автогигант төзүдә республикабыз хезмәт ияләре аеруча актив катнаша. 1970 елда КамАЗга республиканың төрле районнарыннан меңнәрчә эшчеләр килде. Узган ел Казан предприятиеләре генә дә төзелешкә мең кешелек комсомол отряды озаттылар. Татарстан колхоз-совхозларыннан 2000 кеше автозавод төзүчеләргә ярдәм итә.

Бүгенге картадан КамАЗ заказларын үтәмәгән яки Чаллыга эшелоннар озатмаган, кыскасы, теге яки бу формада әлеге төзелештә катнашмаган нинди дә булса шәһәр табу читен.

Кама автомобиль заводын төзүчеләргә культура хезмәте күрсәтүгә дә зур игътибар бирелә. Төзелеш башланганнан бирле анда 500 дән артык концерт куелып, аларны 100 меңнән артык тамашачы карады. КамАЗ төзүчеләре янында Татарстанның барлык күренекле сәнгать осталары булып кайтты. Анда шулай ук Мәскәү һәм Ленинград артистлары, Бурятия һәм Грузия, Советлар Союзындагы күп кенә башка республикаларның, өлкә һәм шәһәрләрнең сәнгать коллективлары чыгыш ясады.

Яңа бишьеллык планнарын вакытыннан алда югары сыйфатлы итеп үтәү өчен башланган социалистик ярыш көннән-көн киңрәк колач ала бара. Ярыш барышында производство алдынгыларының яңадан-яңа башлангычлары туып тора.

«Бишьеллыкны дүрт елда», «Ике кеше өч кеше өчен», «Смена заданиеңне үтәмичә эш урыныңнан китмә» — төзүчеләр коллективы хәзер әнә шундый лозунг һәм өндәмәләр белән рухланып эшли.

КамАЗ төзелә, КамАЗ бишьеллыкның яңа геройларын тудыра. Монтажчылар бригадиры, КПССның Татарстан өлкә комитеты члены Виктор Филимонов, ТАССРның атказанган төзүчеләре Люция Шәмсетдинова һәм Галина Филяшина, ташчылар бригадиры Георг Геворгян һәм балта осталары бригадиры Николай Плевин, КПССның XXIV съезды делегаты, механизатор Харис Гыйбазов һәм тырыш хезмәтләре белән «КамАЗ» маркалы беренче машинаның эшләнеп бетү көнен якынайтучы башка бик күпләрнең исемнәре бөтен республикага билгеле.

1972 ел — КамАЗ төзелешендәге хәлиткеч ел. Төзүчеләр ремонт-инструменталь заводны сафка кертергә, күпчелек корпусларда монтаж эшләрен тәгалләргә, 340 мең квадрат метр торак мәйданы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын файдалануга тапшырырга, шәһәр трамваеның беренче чиратын эшләтә башларга тиешләр.

КамАЗның беренче чиратын ходка җибәрү төзүчеләр коллективының 1972 елда ничек эшләвенә бәйләнгән.

Кама автомобиль заводын сафка кертү белән илнең промышленность күләмендә Татарстан промышленносте тоткан урын нык күтәреләчәк һәм республикабыз Советлар Союзының индустриаль яктан иң көчле районнарының берсенә әйләнәчәк.

Татарстан индустриясенең куәтле үсеше электр энергиясен җитештерүне бик нык арттыру бурычын көн тәртибенә куйды. Яңа бишьеллык бу яктан да истәлекле булды. Электр станцияләре һәм электр челтәрләре төзү, аларны яңа җиһазлар, автоматлаштыру һәм телемеханика чаралары белән тәэмин итү темплары фантастик адымнар белән үсте. Бишьеллык эчендә республика электр станцияләренең куәте тагын 1 миллион 80 мең киловаттка артты. Әгәр Татарстан төзелгәннән бирле узган 48 ел вакыт эчендә республикабыз электр станцияләрендә куәте 1 миллион 630 мең киловаттлык генераторлар хәрәкәткә китерелүен исәпкә алсак, бу бик зур сан. Электр энергиясен эшләп чыгаруның мондый үсеше асылда Зәй ГРЭСын, Түбән Кама ГЭСын, Казандагы өченче ТЭЦны сафка кертү белән тәэмин ителде. Хәзер Татарстанда 6 электр станциясе эшли, узган бишьеллыкта алар электр энергиясе белән Татарстанның үз ихтыяҗларын гына канәгатьләндереп калмадылар, җитештерелгән энергиянең дүрттән бер өлеше күрше республикаларга һәм өлкәләргә дә бирелде.

Энергетиканы кызу темплар белән үстерү яңа бишьеллыкта да дәвам итәчәк. Бишьеллык ахырына электр станцияләренең куәте 1 миллион 380 мең киловаттка артырга тиеш.

Узган бишьеллыкта авыл хуҗалыгының барлык тармакларында ирешкән югары казанышлар партиябезнең бу өлкәдә дә нәтиҗәле эшчәнлек күрсәтүен әйтеп тора. Республикада авыл хуҗалыгына капитал салулар елдан-ел үсә бара. Узган бишьеллыкта аларның гомуми күләме 841 миллион сумга җитте, бу аннан алдагы бишьеллык белән чагыштырганда ике тапкыр артыграк дигән сүз. Капитал салуларның шундый үсеше колхоз һәм совхозларның экономик хәлен бик нык яхшыртырга, авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүне һәм хәзерләүне шактый арттырырга мөмкинлек бирде.

Биш ел эчендә республикада авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүнең еллык күләме 785 миллион сумга җитте, бу алдагы бишьеллыклардан 29 процентка артыграк. Бу вакыт эчендә бөртекле культураларның уңышы 4,9 центнерга артты, без хәзер һәр гектар җирдән уртача 14,3 центнер уңыш алабыз. Авыл хуҗалыгы культураларының башка төрләреннән уңыш алу да шактый күтәрелде.

Шуңа нигезләнеп, без терлекчелекне үстерүдә хәлиткеч уңышларга ирештек, ит җитештерүнең еллык күләме 38 процентка, сөт — 40, йомырка — 56, йон җитештерү 8 процентка артты. Бу саннарга анализ ясаганда, бер мөһим хәл игътибарны җәлеп итә: авыл хуҗалыгы продукцияләре җитештерүнең тулаем күләме нигездә уңышны күтәрү, терлекчелекнең продуктлылыгын арттыру хисабына үсте.

Шул ук вакытта, дәүләтнең зур ярдәме аркасында, авыл хуҗалыгын электр энергиясе белән тәэмин итү ике тапкыр диярлек артты. Республика хуҗалыкларында тракторлар паркының гомуми куәте бер ярым мәртәбә көчәйде, комбайннар паркы тулысынча яңартылды, электр энергиясе куллану 1,7 мәртәбә үсте. Бишьеллык ахырына Татарстан колхозлары һәм совхозлары тулысынча электрлаштырылды.

Колхозларда һәм совхозларда җирне эшкәртүне камилләштерү буенча байтак чаралар күрелде, туфракның уңдырышлылыгын күтәрү, орлыкчылыкның сыйфатын яхшырту, ашламаларны рациональ файдалану һәм бүгенге фәннең, алдынгы практиканың башка казанышларын үзләштерү буенча байтак эш башкарылды. Нәтиҗәләре күз алдында: Татарстанда бөртекле һәм кузаклы культураларның уңышы елдан-ел үсә бара. 1966—70 елларда елына уртача 3,4 миллион тонна икмәк үстерелеп килендә, бу — алдагы бишьеллыктагыдан 1 миллион тоннага артыграк.

Терлекчелек өлкәсендәге уңышларыбыз продуктлылыкны күтәрү һәм терлекләрнең баш санын арттыру хисабына барды. Терлек азыгы базасын ныгыту белән бергә,

без нәсел эшен яхшырттык, терлекләрне асрау һәм ашату мәсьәләләрен камилләштердек.

Авыл хуҗалыгы производствосының төп тармакларында ирешелгән казанышлар колхоз һәм совхозларның экономикасын, аларның материаль хәлен ныгытты, бишьеллыкның соңгы елында республика колхозлары 40 миллион сум күләмендә саф табыш алдылар.

Бишьеллыкның нәтиҗәләренә йомгак ясап карау шуны күрсәтә: бездә авыл хуҗалыгы алдына куелган мәсьәләләрне уңышлы хәл итәрлек көчләр бар. Ә куелган мәсьәләләр шактый катлаулы һәм зур.

Иген уңышын үстерү, элекке кебек үк, төп мәсьәлә булып кала. Яңа бишьеллыкта Татарстан үз алдына бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 20—21 центнер уңыш алу һәм ашлыкның тулай җыемын 5 миллион тоннага җиткерү бурычы куйды.

Без яңа бишьеллыкта терлекчелек продуктлары җитештерү һәм хәзерләүне 43 процентка арттырырга тиешбез. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә яңа бишьеллык куйган зур бурычларны уңышлы хәл итү колхоз һәм совхозларның материаль-техник базасын ныгытуга, аларны көчле техника белән коралландыруга бәйле. Биш ел эчендә республиканың трактор паркы 20 процентка, комбайннар паркы 1,5 мәртәбә, автомобильләр паркы 1,6 мәртәбә артачак. Электр энергиясе куллану ике мәртәбә күбәя.

Авылда төзелеш эшләренә зур игътибар бирeләчәк, төзелешкә капитал салулар ике мәртәбә үсә. Республикада күп кенә уникаль терлекчелек биналары һәм хуҗалык объектлары салыначак. Алар арасында һәркайсы 30 гектарлык Казан һәм Чаллы теплица комбинатлары, тулысынча механикалаштырылганнан соң 250 шәр мең тавык асраячак Түбән Кама һәм Чаллы кошчылык комбинатлары, күп кенә башка объектлар бар.

Күрәсез, тугызынчы бишьеллыкта да авыл хуҗалыгы халык хуҗалыгының бөтен үсеш темпына, совет халкының материаль һәм культура дәрәҗәсен тагын да күтәрүгә зур йогынты ясаячак, бишьеллык план көн тәртибенә куйган күп кенә бурычларның ничек хәл ителүе авыл хуҗалыгының уңышлы үсүенә бәйләнгән.

Кешеләрнең махсус белемнәре, профессиональ хәзерлеге, гомуми культурасы шактый дәрәҗәдә аларның материаль һәм рухи ихтыяҗларын ничек канәгатьләндерүгә бәйләнгән. Шуңа күрә тугызынчы бишьеллыкта партия бу өлкәгә зур игътибар бирәчәк.

«Бишьеллыкның төп бурычы,— диде Л. И. Брежнев КПСС Үзәк Комитетының отчет докладында,— социалистик җитештерүне кызу темплар белән үстерү, аның нәтиҗәлелеген күтәрү, фән-техника прогрессы һәм хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү нигезендә халыкның материаль тормыш һәм культура дәрәҗәсен шактый күтәрүне тәэмин итүдән гыйбарәт».

Узган бишьеллыкта безнең республикада эшчеләрнең айлык хезмәт хакы уртача 26 процентка, ә колхозларда кешенең бер көнлек хезмәтенә түләү 46 процентка артты. Магазиннар, җәмәгать туклануы предприятиеләре челтәре шактый киңәйде, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү көчәйтелде. Республикада күп кенә рестораннар, кафелар, гостиницалар, мастерскойлар, көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатлары төзелде.

Шәһәрдә һәм авылда торак төзелешенең гигант программасы тормышка ашырыла. Илдәге капитал салуларның өчтән бере торак йортлар төзүгә, шәһәрләрне, поселокларны, авылларны төзекләндерүгә тотыла.

Узган бишьеллыкта Татарстанда капитал салымнар хисабына гына да өч миллион ярымнан артык торак мәйданы төзелде. Җәмәгать куллану фондларыннан материаль һәм культура байлыклары бүлү торган саен зурая бара, түләүсез уку, медицина ярдәме күрсәтү, санаторийларга һәм ял йортларына бушлай яки льготалы путевкалар бирү, социаль тәэминатның башка төрләре җәмәгать куллану фондлары хисабына тормышка ашырыла. Узган бишьеллыкта бу чыганак буенча түләүләр 33 процент тәшкил итте. Бу әлеге статья буенча хөкүмәт һәр кешегә елына 190 сум акча тоткан дигән сүз. Узган бишьеллык дәвамында республиканың санаторийларында, ял йортларында, дәүләт һәм профсоюзлар карамагындагы пансионатларда һәм профилакторийларда 640 меңнән артык хезмәт иясе ял итте һәм дәваланды,

Коммунистлар партиясе алга таба да һәр совет кешесе материаль яктан һәм культура ягыннан әйбәтрәк яшәсен дип кайгыртачак. Нәкъ менә шул максатны тормышка ашыру өчен ул яңадан-яңа мөмкинлекләр эзли, халык хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү юлларын эзли, иҗтимагый җитештерүнең эффектлылыгын арттырырга хезмәт итәрлек яңа алымнар эзли.

Коммунизм төзү кебек мөһим эштә халык хуҗалыгындагы белгечләрнең роле зур. Хәзер республикада югары һәм махсус урта белемле 170 мең белгеч эшли. Промышленность предприятиеләре, төзелеш оешмалары, колхоз һәм совхоз җитәкчеләренең иң зур күпчелеге үз профильләре буенча тиешле дәрәҗәдә белем алган кешеләр. Шунысы мөһим, соңгы ун ел эчендә Татарстанда югары һәм урта белемле кешеләр саны ике тапкырга артты, башлангыч белемле кешеләр исә 3 мәртәбәгә кимеде.

Яңа бишьеллык башланганга ел ярым вакыт узды. Узган чор турында нәрсә сөйләргә мөмкин? Бишьеллык торган саен кызурак темплар ала бара. 1971 елда илебез яхшы старт алды. КПССның XXIV съезды эшләгән грандиоз программа буенча җәмгыятьнең социаль-экономик үсешен тормышка ашыру өчен ныклы база булдырылды. Социалистик производство үсендә дәвам итә, аның нәтиҗәлелеге күтәрелде, фәнни-техник прогресс кызуланды. Халыкның тормышын яхшырту буенча билгеләнгән чаралар тулысынча үтәлде.

Бишьеллыкның беренче ел планын уңышлы үтәү өчен социалистик ярыш җәелдереп, Татарстан хезмәт ияләре яңа хезмәт уңышлары яуладылар. Промышленность продукциясенең иң мөһим төрләре буенча җитештерү һәм реализацияләүнең 1971 елгы планы срогыннан алда — 27 декабрьга үтәлде. Авыл хуҗалыгының материаль-техник базасын ныгыту дәвам итә. Капитал төзелеш өлкәсендә яңа адымнар ясалды: 70 тән артык промышленность объекты сафка кертелде, 1970 ел белән чагыштырганда торак төзелешенә капитал салулар 58 процентка артты.

Узган ел республика хезмәт ияләренең материаль һәм культура дәрәҗәсен күтәрү буенча күп кенә чаралар күрелде. Эшчеләрнең айлык эш хакы уртача 3,5 процентка үсте, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү артты, халык мәгарифе өлкәсендә, фән һәм культура үсешендә яңа уңышларга ирешелде. 1972 елның һәр көне совет кешеләренең мактаулы хезмәтләре турында яңа хәбәрләр китереп тора. Безнең республиканың данлы эшчеләр сыйныфы, колхозчы крестьяннары һәм интеллигенция вәкилләре ышанычлы адымнар белән партия күрсәткән юлдан коммунизм төзүнең яңа үрләренә атлыйлар.

Бишьеллыкның икенче елына аяк басканда Татарстанның промышленность, төзелеш, транспорт коллективлары, фән, культура учреждениеләре, колхозлары һәм совхозлары 1972 ел заданиеләрен һәм 9 бишьеллыкны вакытыннан элек үтәү буенча яңа йөкләмәләр алдылар. Болар һәммәсе республикабыз хезмәт ияләренең сигезенче бишьеллык чорында һәм яңа бишьеллыкның беренче елында ирешелгән казанышларны тагын да үстерергә һәм ныгытырга әзер торулары турында сөйли. Бишьеллык планны 1975 елның 5 декабрена үтәргә, 1972 елда планнан тыш 80 миллион сумлык продукция җитештерергә. Безнең яңа йөкләмәләребез әнә шундый.

Барлык коллективларда социалистик йөкләмәләрнең зур күтәренкелек белән кабул ителүе, республика хезмәт ияләренең аларны тормышка ашыру эшенә зур энтузиазм белән тотынулары партия планнары, XXIV съезд карарлары уңышлы тестә үтәләр, дигән ышаныч уяталар.

Безнең горурланырлык эшләребез күп. Әмма коммунистларга, совет кешеләренә алга карап яшәү, өзлексез эзләнү хас. Менә шуңа күрә дә республика хезмәтчәннәре төп игътибарларын хәл ителмәгән мәсьәләләргә, эшләнергә тиешле эшләргә юнәлтергә тиешләр. Ирешелгәннәр белән тынычланып калу, бер урында таптану безнең өчен ят нәрсә.

Партиябез коммунистик төзелешнең барлык этапларында совет кешеләренең дөньяга карашын формалаштыруда, аларның рухи культурасын, әхлак йөзләрен тәрбияләүдә мөһим фактларның берсе булган әдәбият һәм сәнгатькә һәрвакыт зур игътибар биреп килде.

Безнең җәмгыять коммунизм төзү юлыннан алга таба барган саен, әдәбият һәм сәнгатьнең роле үсә бара. Партиянең XXIV съездында ясаган докладында Л. И. Бреж-

нев: «Әдәбиятның һәм сәнгатьнең нәтиҗәле үсеше барлык союздаш республикаларда, СССР халыкларының уннарча телләрендә, күп төрле гүзәл милли формаларда бару факты зур канәгатьләнү тудыра»,— диде.

Узган бишьеллыкта республика хезмәт ияләрен коммунизм идеяләре рухында тәрбияләүдә Татарстанның әдәбият һәм сәнгать әһелләре зур эш башкардылар. Язучылар, рәссамнар, композиторлар, театр һәм кино хезмәткәрләре күп кенә яңа әсәрләр иҗат иттеләр. Аларның күпчелеге, югары сәнгатьчә һәм талантлы итеп, реализм һәм югары партиялелек позицияләрендә торып, заманның хезмәт сулышын, безнең халыкның революцион үткәнен чагылдыралар, ул әсәрләр кешеләрдә илгә мәхәббәт, халыкка һәм коммунистлар партиясенә тугрылык кебек иң матур сыйфатлар тәрбиялиләр. Әдәбият, сәнгать осталарының иң яхшы әсәрләре хаклы рәвештә бөтенсоюз аренасына чыкты, күп милләтле совет культурасын үстерүгә лаеклы өлеш кертте. Алар тагын бер мәртәбә социалистик реализм, халыкчанлык һәм партиялелек принципларына таянып иҗат итүче сәнгать көчләребезнең халыкка турылыклы булуларын раcладылар.

Бу чорда Татарстан язучылары В. И. Ленинның якты истәлегенә, героик сугыш елларына, совет кешеләренең бүгенге тормышына багышланган күп кенә повестьлар, романнар иҗат иттеләр. Сибгат Хәкимнең шигъри җыентыклары зур яңгыраш алды, В. И. Ленинга багышланган шигырь-поэмалары өчен аңа М. Горький исемендәге премия бирелде. И. Юзеев һәм Р. Фәйзуллин иҗатлары М. Җәлил премиясенә лаек булды. И. Гази, Г. Бәширов, Х. Туфан, Н. Арсланов, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмов, З. Нури, А. Расих һәм башкаларның яңа әсәрләре басылып чыкты.

Сигезенче бишьеллык хезмәт темасына багышланган яңа китаплар бирде. Алар арасында Г. Ахуновның Татарстан нефтьчеләре турындагы «Хуҗалар» романы, Э. Касыймовның химиклар тормышын сурәтләгән «Томан аша» романы, Ә. Баяновның КамАЗ төзүчеләр тормышыннан алып язылган «Ут һәм Су» романы, М. Хәбибуллин белән Ф. Хөснинең бүгенге авыл кешеләренә багышланган «Икмәк кадере» һәм «Мәйдан» исемле повестьлары, Г. Паушкинның автозавод төзүчеләр турындагы очерклары һәм башка әсәрләр бар.

Татар язучыларының яңа әсәрләре турында сөйләгәндә, тагын шуны истән чыгармаска кирәк: ул әсәрләрнең күбесе башлап «Казан утлары» журналы битләрендә дөнья күрде. Республиканың язучылары һәм шагыйрьләре өчен үзенә бер мәктәп булып саналган бу журнал менә ярты гасыр инде татар совет әдәбиятының үсешенә зур өлеш кертеп килә.

Татар совет әдәбиятының тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге шунда, ул СССРдагы башка халыкларның әдәбиятларыннан аерылган хәлдә үсми. Бишьеллык дәвамында Татарстан китап нәшрияты, «Дуслык букеты» сериясендә, тугандаш халыкларның иң яхшы шагыйрьләре белән таныштырып барды. Үз чиратында татар язучыларының әсәрләре Мәскәүнең үзәк нәшриятларында китап булып чыга, союздаш һәм автономияле республикаларның журнал һәм альманахларында басыла.

Узган бишьеллыкта татар совет музыка сәнгате дә өлгерү һәм яңару чоры кичерде. Ул үзенең тематикасын шактый киңәйтте, жанр һәм стиль алымнарын баетты. Хәзер бездә музыка сәнгатенең бөтен форма һәм жанрлары үстерелә. Халыкның музыкаль культурасы югары булуны раслый торган симфоник музыканың үсеше — шуның бер мисалы. Узган бишьеллык күп кенә эре симфоник әсәрләр туу белән характерлы. Алар арасында Н. Җиһановның Дәүләт премиясенә лаек булган Икенче симфониясе, А. Монасыйпов белән Ф. Әхмәтовның симфоник поэмалары, М. Яруллинның Р. Харисов сүзләренә язылган «Кеше» ораториясе бар. Р. Яхин, Р. Еникеев, Җ. Фәйзи, А. Ключарев, З. Хабибуллин дистәләрчә яңа җырлар иҗат иттеләр.

Бу елларда сынлы сәнгать югары үсешкә иреште. Татарстан рәссамнары «Зур Идел» исемле зона күргәзмәләрендә, бөтенроссия һәм бөтенсоюз күләмендәге вернисажларда, «Сатира тынычлык өчен көрәштә» исемле халыкара күргәзмәдә, 16 автономияле республиканың Мәскәү шәһәрендә уздырылган күргәзмәсендә уңышлы чыгыш ясадылар. Х. Якуповның «Пролог» картинасы, Н. Кузнецовның индустриаль пейзажлары, Б. Урманче һәм В. Маликовның скульптор портретлары, Н. Язынин һәм

Б. Карамышевның график эшләре, Л. Фәттахоvның кызыклы полотнолары бу чордагы зур иҗат казанышы булып тора.

Бишьеллык дәвамында республиканың театрлары һәм башка сәнгать коллективлары нәтиҗәле эш күрсәттеләр. Театрларның репертуары төрләнәнде, сәхнәгә күп кенә яңа әсәрләр куелды, кызыклы образлар иҗат ителде. Драматургия өлкәсендә Т. Миңнуллин, Ш. Хөсәенов, А. Гыйләҗев, Ю. Әминов һәм башкаларның аеруча актив эшләүләрен билгеләп үтәсе килә. Татарстан театрларының репертуары В. И. Ленинга багышланган яңа әсәрләр белән тулыланды. Татар дәүләт академия театрында Н. Погодинның «Каһарманнар» («Өченче патетик»), В. Качалов исемендәге Зур драма театрында А. Штейнның «Көчле яңгырлар арасында» исемле драмалары куелды. М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры Ф. Яруллинның «Шүрәле» балетының һәм Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясенең яңа постановкаларын күрсәтте. Ә. Бакировның «Су анасы» балетын, Н. Җиһановның «Ике легенда» балетын да тамашачылар җылы каршылады.

Татарстан АССРның Дәүләт симфоник оркестры күптән түгел генә оешты. Хәзер аны киң илебезнең бөтен почмакларында беләләр. Милли эстрада концертлары һәркайда зур уңыш белән уза. Мәскәү һәм Татарстан иҗат эшчеләренең уртак тырышлыгы белән Татарстанның 50 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә милли цирк эшли башлады, хәзер труппа Советлар Союзы шәһәрләре буйлап гастрольдә йөри.

Бишьеллыклар чорында Казан кинохроника студиясе кызыклы гына фильмнар эшләде. Анда эшләнгән документаль фильмнар төрле конкурс һәм күргәзмәләрдә дипломнар белән бүләкләнде, ә «Ленин Казанда» исемле фильм чит илләрдә уздырыла торган Ленин фестивальләрендә күрсәтелә. Сигезенче бишьеллык әдәбият-сәнгать әһелләренең иҗтимагый активлыклары арту белән дә характерлы. Язучылар, рәссамнар, композиторлар, артистлар тамашачылар белән очрашып тордылар, конференцияләрдә катнаштылар, авыл һәм шәһәр хезмәт ияләре алдында иҗат отчетлары белән чыктылар. Бездә хәзер язучылар, сәнгать осталары чыгыш ясамаган район юк. Узган ел ахырында Татарстан сәнгать осталарының һәм язучыларның зур бер төркеме КамАЗда булып кайтты.

Соңгы елларда безнең республиканың культура бәйләнешләре шактый киңәйде. Музыкаль фестивальләр, күп кенә республикаларның культура көннәре һәм культура атналыклары, күп шәһәрләрнең театр һәм музыкаль коллективлары бездә нинди уңыш белән узганын һәркем хәтерлидер. Үз чиратында безнең республиканың язучылары, рәссамнары, композиторлары һәм артистлары үзләренең иҗади казанышларын илнең төрле районнарында, шул исәптән башкалабыз Мәскәүдә күрсәттеләр. Бу әйбәт традиция һәм аны дәвам иттерергә кирәк.

Бу еллар эчендә иҗат союзлары, аерым авторлар һәм коллективлар көче белән иҗат ителгән әсәрләр безнең культура өлкәсендә бишьеллыктан-бишьеллыкка ничек үсүебез, ничек күтәрелүебезне ышандырырлык итеп сөйли. Ләкин болары узылган этап. Алда яңа бурычлар тора. Бүгенге көндә сәнгать осталарының төп бурычы коммунизм төзүче яңа кеше формалаштыруда актив катнашудан гыйбарәт. Совет сәнгате җәмгыять үсешендәге төп тенденцияләрне һәрвакыт сизгер тоя барды, партия һәм халык тормышындагы мөһим вакыйгаларның асыл мәгънәсен сәнгатьчә тирән, ышандырырлык итеп күрсәтә барды. Аның көче дә шунда. һәм бүген дә безнең язучылар, рәссамнар, композиторлар, театр һәм кино хезмәткәрләре алдында, КПССның XXIV съезды сәнгать кешеләре каршына куйган мәсьәләләрне хәл итү, сәнгать чаралары ярдәмендә коммунистик төзелешнең хәзерге этабына хас үзенчәлекләрне чагылдыру, бүгенге көн геройларын күрсәтү бурычы тора.

Халык иҗат интеллигенциясеннән безнең дәвернең зурлыгын күрсәтә, республика кешеләренең тормышындагы төрле сфераларны тирәнтен һәм һәрьяклап иңләрлек яңа, тормышчан әсәрләр көтә. Бу мәсьәләгә аеруча нык басым ясарга кирәк, безнең язучылар һәм сәнгать осталары нефтьчеләр һәм химиклар, төзүчеләр һәм авыл хезмәтчәннәре алдында бурычлы әле. Бүген исә, моңарчы беркайчан булмаганча, әдәбиятчыларның һәм сәнгать осталарының, иҗат союзларының хезмәт темасына, эшче сыйныфының тормышына һәм көрәшенә, бүгенге авылның көндәлек хезмәтенә, колхозчыларның тормыш укладында барган бөтен үзгәрешләргә, совет

интеллигенциясенең эшчәнлегенә аерата игътибарлы булулары сорала. Яңа бишьеллык безгә союз күләмендә яңгырарлык яңа әсәрләр бирергә тиеш. Бары шундый әсәрләр генә милли планда да җуелмас кыйммәткә ия булачак, чөнки союз күләмендә яңгыраш алган һәр сәнгать әсәре һәрвакыт милли була, хәлбуки, һәр милли әсәр союз күләмендә яңгырый алмаска мөмкин.

Совет җәмгыятенең рухи тормышында, яңа кеше тәрбияләүдә әдәбиятның һәм сәнгатьнең ролен күтәрү турындагы мәсьәләне әдәбият-сәнгать тәнкыйте алдында торган бурычлардан аерып карарга ярамый. Тәнкыйтьнең дәрәҗәсен күтәрү — сәнгатьнең уңышлы үсеген тәэмин итә торган төп шарт. Иҗат процессының аерылмас, органик бер өлеше буларак, ул әлеге процессның нәтиҗәләрен, халыкның эстетик зәвыкларын формалаштыруга актив йогынты ясарга тиеш. Шуңа күрә партиянең XXIV съездында һәм КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында бу өлкәдәге аеруча җитди җитешсезлекләр һәм кимчелекләр генә күрсәтелеп калмады, аның мөһим бурычлары да формалаштырылды, тәнкыйтьне үстерергә, аның марксистик-ленинчыл нигезен ныгытырга тиешле конкрет чаралар да билгеләнде.

Безнең иҗат союзларының һәм сәнгать оешмаларының мөмкинлеге зур. Яңа бишьеллыкта без әдәбиятчылардан һәм сәнгать осталарыннан иҗат өлкәсендә, хезмәт ияләренә эстетик һәм әдәби тәрбия бирү мәсьәләсендә күбрәк нәрсә көтәргә хаклы.

Соңгы еллар республикабыз өчен фәннең тагын да үсүе җәһәтеннән караганда да истәлекле булды. Татарстанның зур фәнни потенциалы галимнәребезгә математика, механика һәм астрономия, физика һәм химия, биология һәм геология, химия технологиясе һәм машина төзелеше, автоматика, экономиканың иң мөһим өлкәләрендә гыйльми тикшеренүләр алып барырга мөмкинлек бирә.

Республиканың 11 вузында һәм 55 фәнни-тикшеренү институтында 12 мең фәнни хезмәткәр эшли. Алар арасында бер академик, СССР Фәннәр академиясенең берничә член-корреспонденты, ике меңнән артык фән докторы һәм кандидаты бар.

Фәнни-техник революциянең бүгенге этабы өчен фән белән производствоның якыная баруы хас. Зур фәнни проблемаларны чишү производствоның яңа процессларын барлыкка китерде, традицион процессларны камилләштерергә ярдәм итте, промышленностьның бөтенләй яңа тармакларын тудырды.

ТатНИИ галимнәренең тикшеренүләре, мәсәлән, бөтен ил күләмендә иң арзанлы нефть чыгарырга һәм миллиардларча сум дәүләт акчасын янга калдырырга мөмкинлек бирде. Казанда фосфор-органик кушылмалар химиясе туу фармакологиянең интенсив үсүенә китерде. Биологик эзләнүләрнең нәтиҗәләре авыл хуҗалыгы производствосының, азык промышленностеның үсеш дәрәҗәсен күтәрергә, сәламәтлек саклау мәсьәләләрен фәнни нигездә хәл итәргә булышты.

Коммунизм төзелешенең практик мәсьәләләрен чишүдә фәннең ролен күтәрү югары уку йортларының эшчәнлегенә дә йогынты ясады, аларны саф белем бирү йортларыннан көчле фәнни-тикшеренү үзәкләренә әйләндерде. Узган биш елда Казан вузларында башкарылган фәнни эшләрнең гомуми күләме 120 миллион сумга җитте, ә фәнни эшләрнең өчтән бер өлеше туры дан-туры промышленность предприятиеләренең махсус заказлары буенча алып барылды.

Бишьеллыкта халык хуҗалыгы өчен югары квалификацияле белгечләр хәзерләү шактый үсте. Хәзер республикабыз югары уку йортларында 210 белгечлек буенча кадрлар хәзерләнә. Соңгы елларда Казан, Ленинград, Мәскәү вузларының байтак филиаллары эшли башлады, вуз һәм техникумнарның материаль базасы ныгыды, студентларның социаль контингенты һәм составы яхшырды. Бу безгә кадрлар хәзерләү буенча бишьеллык планны уңышлы хәл итәргә мөмкинлек бирде. Узган бишьеллыкта халык хуҗалыгының төрле тармаклары өчен институтлар һәм техникумнар 85 мең белгеч хәзерләде, бу узган җидееллык белән чагыштырганда 12 мең кешегә артык дигән сүз. Тугызынчы бишьеллыкта югары белем бирү тагын да үсәчәк.

Безнең республиканың нефть һәм химия промышленностен үстерүдәге уңышлары, машина төзелешен тагын да күтәрү, промышленность һәм авыл хуҗалыгының төрле тармакларын комплекслы механикалаштыру һәм автоматлаштыру тугызынчы бишьеллыкта безнең галимнәр алдына җитди хәл итүне сорый торган күп кенә мәсьәләләр китереп куя. Без фәнебезнең киләчәгенә ышанабыз, чөнки республикадагы фәнни

тикшеренүләрнең дәрәҗәсе, галимнәрнең хәзерлеге, вузларның һәм фәнни-тикшеренү институтларының материаль базасы бүгенге көндә шундый хәлдә ки, без бүгенге фәннең һәм техниканың теләсә нинди зур мәсьәләләрен чишәргә сәләтле.

Халык мәгарифе мәсьәләләре турында берничә сүз. Мәктәпләрнең структурасында, укыту эшенең эчтәлегендә һәм оештырылуында күп кенә сыйфат үзгәрешләре булды. Республика өч мөһим мәсьәләне хәл итте: гомуми белем бирүне киңәйтү, иҗтимагый үсешнең һәм фәнни-техник белемнәрнең бүгенге дәрәҗәсенә нисбәтән укытуның эчтәлеген үзгәртү, башлангыч белем бирү эшенең эчтәлеген һәм структурасын үзгәртеп кору. Бүген без шикләнми әйтә алабыз: мәктәпләрнең укытучылар коллективы, халык мәгарифе органнары КПССның XXIV съездында мәгариф эше буенча булган Директиваларын уңышлы үтәделәр. Татарстанда мәктәпләрнең яңа программа һәм дәреслекләргә күчүе әйбәт бара. Мәктәпләр чиптәре өзлексез камилләштерелә.

Бишьеллык чорында Татарстанда 125 мең укучыга яңа мәктәпләр салынды, 1,5 миллион сумлык иң яңа җиһазлар белән тәэмин ителгән йөзләрчә кабинетлар һәм лабораторияләр төзелде, югары белемле укытучылар саны тагын 5 меңгә артты.

Бу факторлар укучыларның өлгерешен шактый яхшыртырга, сигезьеллык гомуми белем турындагы законны уңышлы рәвештә тормышка ашырырга, урта мәктәпләр челтәрен киңәйтергә мөмкинлек бирде. Хәзер сигезьеллык мәктәп тәмамлаучыларның 80 проценты урта мәктәпләрдә һәм техникумнарда укый. Боларның һәммәсе безгә партиянең XXIV съезды кен тәртибенә куйган мөһим бурычны — алдагы бишьеллыкта яшьләрнең гомуми урта белем алуга күчүен тәмамларга мөмкинлек бирәчәк.

Сигезенче бишьеллыкта һәм яңа бишьеллыкның ел ярым вакыты эчендә республика узган юлга тагын бер тапкыр әйләнеп карагач, ышанып әйтә алабыз: безнең эшчеләр, колхозчылар, иҗат интеллигенциясе көче белән эшләнгән эшләрнең һәммәсе, нефтьчеләребезнең, химикларның, машина төзүчеләрнең, төзелеш эшчеләренең, әдәбият һәм сәнгать әһелләренең данлы эшләре СССРның 50 еллыгына әйбәт бүләк булачак.

# «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 50 ЕЛ

*КПССның Татарстан өлкә комитеты республикабыз Язучылар союзы органы булган «Казан утлары» журналының чыга башлавына 50 ел тулу уңае белән журнал коллективын, аның укучыларын һәм барлык әдипләрне кайнар котлый һәм чын күңелдән тәбрикли.*

*«Казан утлары» журналының ярты гасырлык юбилее — әдәбият-сәнгать эшлеклеләре һәм журнал коллективының гына түгел, аның күп санлы укучыларының, гомумән, татар совет культурасының бәйрәме ул.*

*Журнал эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли булган татар совет әдәбиятын үстерүдә, аның башка тугандаш әдәбиятлар белән дуслыгын ныгытуда, коммунистик партиялелек, социалистик реализм принципларын тормышка ашыруда гаять зур роль уйный. Ул әдипләрне һәм сәнгать көчләрен оештыруда, аларның игътибарын социалистик һәм коммунистик төзелешнең актуаль мәсьәләләренә юнәлтүдә, киң катлау укучыларны идея-эстетик тәрбияләүдә партия өлкә комитетының якын ярдәмчесе булып тора.*

*«Казан утлары» журналы үзенең юбилеен совет халыкларының КПССның XXIV съезды карарларын тормышка ашыру өчен киеренке көрәш алып барган, СССР төзелүгә 50 ел тулуны каршыларга әзерләнгән истәлекле көннәрдә билгеләп үтә. Бу — язучыларга һәм редакция коллективына илебез халыкларының туганнарча дуслыгын, хезмәттәге батырлыгын калку итеп гәүдәләндерү, республикабызның данлы эшчеләр сыйныфы отрядлары — КамАЗ салучылар һәм нефтьчеләр, химиклар һәм машина төзүчеләр, шулай ук авыл эшчәннәре, хезмәтчел интеллигенция вәкилләренең тулы канлы образларын тудыру, бишьеллык геройларын данлау, заманыбызның мөһим проблемаларын күтәрү кебек олы җаваплылык йөкли.*

*КПСС өлкә комитеты, Татарстан язучылары һәм редакция коллективы республикабыз хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүгә лаеклы өлеш кертерләр, укучыларны югары идеяле һәм сәнгатьле язылган әсәрләр белән шатландырырлар, әдәбият-сәнгать тәнкыйтен партия куйган таләпләр югарылыгына күтәрерләр, дип ышана һәм аларга бу мактаулы эштә яңа иҗат уңышлары тели.*

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ

*«Казан утлары» журналы редакциясенә,*

*Илебездә иң өлкән әдәби-нәфис журналларның берсе — «Казан утлары» журналы коллективын һәм аның укучыларын журналның илле еллык бәйрәме белән кайнар котлыйбыз.*

*Журнал, 1922 елның май аенда «Безнең юл» исемендә чыга башлап, дәүләтебезнең барлык үсеш чорларында яңа социалистик җәмгыять*

*кешесе тәрбияләүдә партиянең турылыклы ярдәмчесе булды. Атаклы язучы һәм галим Галимҗан Ибраһимов инициативасы белән оештырылган бу журнал татар совет әдәбиятының яшь көчләрен берләштерүдә хәлиткеч роль уйнады, социалистик реализм әдәбияты өчен барган көрәшнең үзәгендә торды. Сезнең журнал битләрендә Г. Ибраһимов һәм Ш. Камал, К. Нәҗми һәм Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов һәм М. Әмир, Ә. Фәйзи һәм Х. Туфан, М. Җәлил һәм Ф. Кәрим, Ф. Хөсни, И. Гази, Ә. Еники, С. Хәким, Ә. Давыдов һәм аннан соңгы буын талантлы татар язучыларының әсәрләре тормышка путевка алды.*

*Журнал шулай ук тугандаш халыклар әдәбияты һәм чит илләрдәге прогрессив язучыларның әсәрләре белән укучыларны даими рәвештә таныштырып килде.*

*Ярты гасыр дәвамында журналның авторитеты үсте, таралу географиясе киңәйде, тиражы күп мәртәбә артты.*

*«Казан утлары» журналының юбилее — татар һәм, гомумән, бөтен совет әдәбиятының бәйрәме, ленинчыл милли политиканың тантана итүе ул.*

*«Казан утлары» журналы редакциясенә һәм аның укучыларына туган әдәбиятны үстерүдә һәм пропагандалауда, КПССның XXIV съезды карарларын тормышка ашыруда яңа уңышлар телибез.*

*СССР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ СЕКРЕТАРИАТЫ*

*Кадерле дуслар!*

*Күп милләтле илебезнең иң өлкән журналларыннан берсе — «Казан утлары» журналын илле еллык юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз.*

*Бөек Октябрь социалистик революциясенең беренче елларында чыга башлаган Сезнең журнал кешеләрне һәрвакыт гуманизм, патриотизм, интернационализм рухында тәрбияләде һәм тәрбияли.*

*«Казан утлары» журналын атаклы галим һәм язучы Галимҗан Ибраһимов оештырган иде. Галимҗан Ибраһимов журнал тирәсенә социалистик республикадагы фән һәм мәдәният көчләренең алдынгы вәкилләрен туплады. Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Шамил Усманов, Фәтхи Бурнаш, Шәһит Әхмәдиев, Һади Такташ — журналның беренче авторлары булдылар. Муса Җәлилнең үлемсез әсәрләре дә беренче тапкыр «Казан утлары» журналында дөнья күрде. Журнал татар язучыларының бөтенсоюз күләмендә танылган әсәрләренә киң урын биреп килде. Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар», Кави Нәҗминең «Язгы җилләр», Гомәр Бәшировның «Намус», Фатих Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», Мирсәй Әмирнең «Саф күңел», Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» әсәрләре моның ачык мисалы булып тора.*

*Журнал яшь язучыларның эстетик зәвыкларын тәрбияли, әдәби осталыкларын үстерүдә аларга даими рәвештә ярдәм итә.*

*Илле ел эчендә «Казан утлары» заманыбызның иң зур әдәби-нәфис журналлары рәтенә басты. Инде моннан күп еллар элек халык ихтирамын казанган «Казан утлары» журналы Татарстанның гына түгел, ә бәлки бөтен Советлар Союзының җәмәгать һәм әдәбият тормышында күренекле урын алып тора.*

*Кадерле дуслар! «Казан утлары» журналы коллективына, аның талантлы авторларына какшамас сәламәтлек һәм зур уңышлар телибез!*

*Яңа иҗади уңышлар сезгә!*

*РСФСР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ СЕКРЕТАРИАТЫ*

# КИЛӘЧӘККӘ КАРАП

Татарстан язучылары, республиканың барлык культура әһелләре һәм күп санлы укучыларыбыз быел, май аенда, «Казан утлары»на 50 яшь тулуны билгеләп узалар.

Укучыларга мәгълүм, журнал турындагы материаллар шушы елның январь саныннан бирле басылып килде. Төрле елларда редактор булып эшләгән өлкән әдипләребез Гази Кашшаф, Гомәр Бәширов, Газиз Иделле язган мәкаләләрдә, «Казан утлары»ның быелгы беренче санында игълан ителгән «Кыскача биография»дә һәм унбишләп авторның безнең анкетага язган җавапларында журнал узган юл шактый тулы яктыртыла. Шуңа күрә бу мәкаләдә без илле ел эчендә барлыкка килгән традицияләргә, аларның яңа шартларда, социалистик төзелешнең яңа этапларында үсә, яңара, камилләшә баруына һәм иртәгәсе көннең бурычларына тукталырга уйлыйбыз.

КПССның Татарстан өлкә комитеты үзенең котлавында журнал эшчәнлеген: «Казан утлары» эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли булган татар совет әдәбиятын үстерүдә, аның башка тугандаш әдәбиятлар белән дуслыгын ныгытуда, коммунистик партиялелек, социалистик реализм принципларын тормышка ашыруда гаять зур роль уйный. Ул әдипләрне һәм сәнгать көчләрен оештыруда, аларның игътибарын социалистик һәм коммунистик төзелешнең актуаль мәсьәләләренә юнәлтүдә, киң катлау укучыларны идея-эстетик тәрбияләүдә партия өлкә комитетының якын ярдәмчесе булып тора»,— дип бәяли. Татарстан язучылары һәм редакция коллективы партия өлкә комитеты биргән мондый югары бәя белән хаклы рәвештә горурлана һәм андый зур бәянең нинди тырыш, фидакарь хезмәт белән яулап алынганлыгын да яхшы белә.

1922 ел. Яшь Советлар республикасы авыр көннәр кичерә. Илебез беренче бөтендөнья сугышы, чит ил интервенциясе, гражданнар сугышы яраларыннан интегә. Җимерек заводларны сафка кертергә, Идел буена килгән афәт-ачлыкны җиңәргә кирәк. Партиябез әнә шундый шартларда идеология эшенә зур әһәмият биреп, газета-журналлар чыгаруны ныклы юлга сала.

Татар халкының күренекле язучысы һәм зур җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов инициативасы белән Казанда «Безнең юл» журналы — «Казан утлары»ның элгәре — чыга башлый. Бу әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал беренче адымнарыннан ук үзенең кичектермәс бурычы итеп журнал тирәсенә совет-партия җәмәгатьчелеген, язучыларның танылган вәкилләрен туплауны куя. Дөресен әйткәндә, бу — безнең журналның илле ел буена дәвам иткән иң күркәм традициясе. Культура тарихыбызда хөрмәтле урын яулап алган әдип, галим, сәнгать эшлеклеләреннән Галимҗан Ибраһимов, Мирхәйдәр Фәйзи, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Фатих Сәйфи-Казанлы, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин, Шамил Усманов, Нәкый Исәнбәт, Габдрахман Сәгъди һ. б. үзләренең әдәби әсәрләрен, фәнни мәкаләләрен журнал битләрендә бастыра башладылар.

Бөек Октябрь революциясен таныган, илгә, халыкка турылыклы хезмәт итәргә теләгән өлкән буынның тырыш хезмәте совет чорында иҗат дәрте белән кабынган яшь әдипләргә үрнәк булды. Һади Такташ, Кави Нәҗми, Мәхмүт Максуд, Афзал Шамов, Муса Җәлил, Фәхри Әсгать, Гадел Кутуй, Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәти, Хәсән Туфан, Г. Минский, Әхмәт Исхаклар татар совет матур әдәбиятының әле яңа гына аякка баса башлаган чорында җиң сызганып эшкә керештеләр.

Утызынчы елларда, авылда колхозлар төзелгән канлы көрәш чорында, беренче бишьеллыкларның дәртле, шаулы көннәрендә журнал Магнитогорск металлурглары, Донбасс шахтерлары, Мәскәү метрочылары, авылдагы сыйнфый көрәш турындагы очерклар, хикәяләр, повестьлар, ялкынлы шигырьләр белән халкыбызны социализм төзүгә рухландырды, көрәшкә дәртләндерде.

Ил тормышының барлык этабында халыкка тугры хезмәт итүне журнал төп бурычы һәм намус эше дип санап килде. Ил язмышы кыл өстендә торган чакта, Татарстан уллары һәм кызлары барлык совет халыклары белән иңгә-иң торып фашизмга каршы сугышканда, шул исәптән татар язучыларының барысы диярлек каләмне мылтыкка алыштырып, гитлерчыларны дөмбәсләгәндә, журнал ялкынлы публицистика, утлы шигырь һәм гыйбрәтле хикәяләре белән безнең сугышчыларыбызны рухландырып торды. Ул елларда фронтлардан редакциягә килгән хатлар һәм аерым язучыларыбызның журналда бастырган истәлекләре шул хакта сөйли. Хәтта кайбер республикаларда әдәби журналлар, сугыш кыенлыклары аркасында, вакытлыча туктап торган чакта да, безнең әдәби журналыбыз эшен дәвам иттереп, җиңү яулашты.

Язучыларыбызның иҗат активлыгы арту, талантлы яңа романнарны, повестьларны, сәхнә әсәрләрен, поэмаларны, тирән эчтәлекле гыйльми хезмәтләрне, әдәби тәнкыйть мәкаләләрен күбрәк бастыру, гомумән, барлык бүлекләрнең җанлануы тиражның бик нык үсүенә китерде. Укучыга укыр әйбер күбәйде!

Күренекле рус язучысы Николай Тихонов, совет әдәбиятының төп сыйфатын билгеләп, болай дигән иде: «Совет әдәбияты халык белән бер аяктан атлады, ә халык аны батырлыкка, ныклыкка, фидакарьлеккә өйрәтте. Совет әдәбияты Коммунистлар партиясе белән бер аяктан атлады, ә партия әдәбиятны аның барлык этапларында җитәкләп алып барды, аны социалистик төзелешнең җанлы хәрәкәтенә китереп кушты, политик зирәклеккә һәм сизгерлеккә өйрәтте».

Татар совет әдәбияты һәм шул әдәбиятның кезгесе булган «Казан утлары» өчен дә бу нәкъ шулай. Илле еллык эшчәнлеге дәверендә журнал Коммунистлар партиясенең әдәбият, сәнгать һәм культура мәсьәләләре буенча чыгарган карарларын пропагандалау, марксистик-ленинчыл эстетиканың аерым мәсьәләләрен яктырту, формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик татар совет культурасын үстерү эшенә булышу, язучыларны актуаль темаларга, идея-сәнгать ягыннан югары сыйфатлы әсәрләр иҗат итүгә юнәлдерү буенча даими эш алып барды.

«Казан утлары» бүген дә шул күркәм традицияләренә тугрылыклы булып кала.

Партиянең XXIV съезды иҗат иткән гаять зур программа, тугызынчы бишьеллыкның моңарчы күрелмәгән киң колачы язучыларны һәм редакция коллективын әдәбиятыбыздагы бүгенге төп темалар, төп юнәлешләр хакында ныклабрак уйланырга мәҗбүр итә.

Бүгенге Татарстан — илебезнең иң зур индустрия районнарыннан берсе. Илдәге һәр өч тракторның, һәр өч автомобильнең, һәр өч моторның берсе Татарстан нефте белән эшли. Ул гына да түгел. Безнең күз алдында тагын ике гигант: Түбән Кама химия комбинаты һәм Чаллы автомобиль заводы күтәрелә. Илебез халыкларының эчкерсез ярдәме, партия һәм хөкүмәтнең көндәлек кайгыртуы нәтиҗәсендә, Татарстанда эшчеләр сыйныфының сугыштан соңгы елларда яңа бер баскычка күтәрелүен, аның зур хезмәтен чорыбызга лаек олы образлар аша укучыларга җиткерү — редакциянең кичектерелмәс эше. «Казан утлары» алгы көндә әнә шундый роман һәм повестьларга, сәхнә әсәрләренә, киң колачлы поэмаларга йөз тотарга, аларның югары сыйфатлы булуын кайгыртып эшләргә тиеш.

Икенче өлкә — бүгенге авыл. Беренче карашка, авыл турында роман, повесть, поэма һәм сәхнә әсәре бездә кирәгеннән артык күп булырга тиеш иде кебек. Татар язучыларының күпчелеге авылдан чыккан кешеләр. Татар әдәбияты элек-электән авыл әдәбияты булып килде. Әмма соңгы елларда редакциягә килгән әсәрләр арасында «Матур туганда» белән «Тирән тамырлар»га, «Агыйдел» белән «Рәүфә»гә, «Намус» белән «Авылдашым Нәби»гә торырдай әсәрләр күренми диярлек. Хикмәт нидә? Авылны белүчеләр беттемени? Хикмәт, күрәсең, шунда, авылны без элекке тәҗрибәдә, анда да үзебезнең шәхси тәҗрибәдә генә беләбез. Ә бит шәхси тәҗрибәнең үзе генә зур уңышка китерү ихтималы аз. Бүген урта буын иҗеме белән йөртелгән прозаиклар моннан ун еллар элек авыр сугыш елларын һәм сугыштан соңгы

чорны бик күп язалар иде. Бу повестьларның авторлары, сугыш елы авырлыкларын үз җилкаләрендә күтәреп чыккан үсмерләр, ул заманның аяусызлыгын, кешеләр арасындагы каты-кырыс мөнәсәбәтләрне ихлас күңелдән сурәтләп бирделәр, әмма тышкы бизәкләр белән мавыгып, халыкның рухи бөеклеген, ил иминлеге хакына эшләгән фидакарь батырлыгын онытып җибәрделәр. Авыл әдәбиятының бу кимчелеген заманында Ибраһим Гази бик дөрес күрсәтеп биргән иде. Вакыт ул китапларны хәзер рәхимсез рәвештә сайлый. Аларның заман рухын дөрес тотып алып, кеше күңеле аша сурәтләп бирә белгәннәре генә торып калдылар.

Замандашларыбыз турында яңа әсәрләр иҗат иткән чакта өлкән буын әдипләребез тәҗрибәсенә таянырга, алар тәҗрибәсен игътибар беләнрәк өйрәнергә кирәктер. Алар тормышка җитди карый, образларны тирән һәм үзенчәлекле итеп яза, позицияләрен ачык итеп әйтә беләләр. Шәриф Камал һәм Галимҗан Ибраһимов, Кәви Нәҗми һәм Мәхмүт Галәү, Афзал Шамов һәм Ибраһим Гази, Гомәр Бәширов һәм Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир һәм Фатих Хөсни, Әхмәт Фәйзи һәм Гадел Кутуй, Габдрахман Әпсәләмов һәм Гариф Галиев, Гариф Гобәй һәм Атилла Расих... Аларның «Казан утлары»нда басылып, халыкка киң таралган роман һәм повестьлары һәрберсе үзе бер мәктәп, аларда әдипнең бөтен тормышы, яшәү мәгънәсе, озак еллар буена җәмәгать һәм дәүләт эшендә туплаган тәҗрибәсе. Еллар буе нык уйлап иҗат ителгәнгә күрә, ул әсәрләр халыкның күңелен яулап ала алдылар.

1957 елны, Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында, татар совет поэзиясе «батырлык һәм солдат поэзиясе» дигән югары бәя алды. Безнең поэзиябез бу бәяне бөек Тукайның «без сугышта юлбарыстан көчлебез, без тынычта аттан артык эшлибез» кебек олы билгеләмәсенә тугрылыкны саклавы аркасында яулап ала алды. Алыгыз граждannар сугышы чоры поэзиясен, алыгыз беренче бишьеллыклар чорын яки Бөек Ватан сугышы чорында һәм аннан соң басылган шигырьләрне — сез анда гражданлык хисләренең зур бер йөрәк кебек сулкылдап тибеп торуын күрерсез. Кызыл майданда, Билгесез солдат һәйкәлендә янган утта Муса Җәлил һәм Фатих Кәрим, Гадел Кутуй һәм Нур Баян, Рәхим Саттар һәм Хәйретдин Мөҗәйнең, сугыш кырыннан кайта алмаган дисталәгән яшь шагыйрьнең йөрәк ялкыны бар. Бу олы традицияне журнал илле ел буена үстерә килде. Һади Такташ, Фәтхи Бурнаш, Хәсән Туфан, Нәкый Исәнбәт, Муса Җәлил нигез ташларын салышкан татар совет поэзиясен Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Исхак, Әхмәт Ерикәй, Фатих Кәрим, Салих Баттал, Шәйхи Маннур, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Гали Хуҗи, Нәби Дәүли, Әнвәр Давыдов, Шәраф Мөдәррис, Зыя Мансур, Заки Нури, Мөхәммәт Садри, Гамил Афзал, Шәүкәт Галиев, Хисам Камал, Әдип Маликов, Илдар Юзеев яңа шартларда үстереп, тагын да баетып һәм күп тавышлырак итеп алып киттеләр. Алар янына сугыштан соң әдәбият мәйданына килгән бүгенге талантлы яшь шагыйрьләр кушылды. «Казан утлары» журналында соңгы елларда әдәбият мәйданына ялтырап килеп чыккан яшь шагыйрьләрне укучыларга күрсәтеп, игътибар иттерерлек итеп бирү даими төс алды. Ләкин поэтик көчләрне туплау һәм шигъри осталыкны үстерү буенча да журналның эшлисе эше байтак әле. Соңгы елларда күтәрелгән яшь шагыйрьләрнең «эксперимент» үткәрү дәвере озаккарак сузылды, сәнгатьчә бөтенлек, гадилек, осталык мәсьәләләрен безгә җитдирәк итеп куярга вакыт. Шулай ук лирик геройның ил белән, халык язмышы белән бәйләнешен көчәйтә төшәсе бар.

Һәртөрле караш, шул исәптән идеологик караш та, разведкадан башлана. Әдәбиятта без разведчиклар дип очеркистларны атыйбыз. Үкенечле хәлне туп-туры әйтергә кирәк: «Казан утлары»нда бүгенге көндә очерк кытлыгы. Дөрес, без журналның һәр санында очерк бирми калмыйбыз. Ләкин жанрны күтәрерлек, республика күләмендәге, бөтен ил күләмендәге яңа күренешләрне, вакыйгаларны, яңа кешеләрне тормыштагыча киң колач белән сурәтләгән очеркларыбыз юк. Язучылар союзы идарәсе очеркистлар тәрбияләү эшенә аеруча зур җаваплылык белән карарга тиеш. Соңгы елларда СССР язучылар союзына очерк жанрында эшләүче бер генә авторның член итеп алынуы бу жанрда эшләрнең шәптән түгеллеген әйтеп тора. Ә бит очеркистлар юл ярмый торып, зур күләмле монументаль әсәрләр иҗат ителми.

Рус совет әдәбиятында В. Овечкин, Л. Иванов, И. Винниченко, Г. Радов, В. Закруткин очерклары, ил күләмендәге проблемаларны күтәреп, соңыннан монументаль әсәрләр тууга сәбәп булдылар.

Очерк бик әйбәт пропагандист та була ала. Кеше җанын аулау идеология фронтында аеруча бер үткенлек белән куелган дәвердә әдәбиятка зур җаваплылык йөкләнә. Чит илләрдә кайбер «Шәрык белгечләре» Татарстанның нефть промышленностенда татарлардан бер генә дә тау инженеры, тау белгече юк дип бөтен дөньяга лаф оралар. Көлке! Әмма үзебезнең кул кушырып утыруыбызны уйласак — аяныч! Зур химиядә, нефтьтә, мех эшкәртү, сәгать ясауда могҗизалар тудыручы якташларыбыз турында татар язучылары әлегә бик аз язалар. Безнең күз алдыбызда, нибарысы ике дистә ел эчендә, Советлар иленең югары уку йортларында, рус халкының һәм башка тугандаш халыкларның турыдан-туры ярдәме белән, нефть эшендә татарлардан йөзләрчә инженер-техник хезмәткәрләр әзерләнде. Аларның кайберсе инде үзәк министрлыкларда хезмәт итә. Кайберсе Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое дигән данлы исемнәр алуга иреште. Без, татар язучылары, чын сәнгатьчә язылган тирән эчтәлекле, сугышчан рухлы очеркларыбыз белән «Шәрык белгечләре»нең әшәке ялганнарын фаш итәргә тиешбез.

Бераүгә дә сер түгел, әдәби журналның йөзен әдәби тәнкыйть билгели. Әдәби тәнкыйть — әдәбиятның намусы дип юкка гына әйтмиләр. Бу билгеләмәнең дөреслеген безнең әдәби практикабыз да раслый. Кайчандыр, егерменче, утызынчы елларда, татар совет әдәби хәрәкәтенең башында Габдрахман Сәгъди, Гомәр Гали, Галимҗан Нигъмәти кебек зур эрудицияле, тирән белемле, объектив карашлы тәнкыйтьчеләр торган. Югары уку йортларында яшь язучылар әзерләү эше дә, матур әдәбиятны укыту программалары да, китап бастыру, әдәби журнал редакцияләү эше дә алардан читтә калмаган, алар яңа бер талантлы әсәр тууга шатланып, төн йокыларын йокламыйча, иртәгесен иртүк редакциягә мәкалә китерә алганнар. Андый тәнкыйтьчеләр бездә хәзер күпме?

Соңгы елларда әдәбиятыбызның иң җаваплы жанры — әдәби тәнкыйть сизелерлек сүлпәнәйде. Яңа әсәрләрне нигезсез мактау, комплимент яудыру күбәйде. Бу бер безнең әдәби тәнкыйть өчен генә хас кимчелек түгел иде. Леонид Ильич Брежневның XXIV съездда ясаган докладында әдәбият-сәнгать тәнкыйте турындагы мәсьәлә житди итеп куелды, ә менә шушы елның январь аенда КПСС Үзәк Комитеты әдәбият-сәнгать тәнкыйтенә карата махсус карар кабул итте. Карарда: тәнкыйтьнең торышы художество культурасының коммунистик төзелештә үсә барган роле белән билгеләнә торган таләпләргә әлегә тулы җавап бирми, дип күрсәтелә. Совет әдәбияты һәм сәнгатенең үсеш процесслары, социалистик милләтләр культураларының бер-берсен баетулары һәм үзара якыная бару процесслары җитәрлек кадәр тирән анализланмавы әйтелә.

Карарның газета-журнал редакцияләре эшенә бәйле урыны мәсьәләне аеруча кискен итеп куя. Газета-журнал редакцияләренең күбесе тәнкыйть мәкаләләренең идея-теоретик дәрәҗәсенә таләпчән түгелләр, рецензияләү практикасында җитди кимчелекләр яшәп килә диелә. Басыла торган рецензияләр еш кына барьяклы характерда була, нигезсез мактау сүзләре тезеп чыгыла, әсәрнең эчтәлеген өстән-өстән генә сөйләп чыгуга кайтып кала, аның реаль әһәмияте һәм кыйммәте турында дөрес фикер бирми, диелә. Партия карарында марксистик-ленинчыл традициягә таяну, бәя төгәллеге, анализ тирәнлеге, талантка, файдалы эшкә сак килү принцибы алга сөрелә. Шуларның барысы өстенә тәнкыйтьченең эстетик яктан югары зәвыклы булуы зарури итеп куела.

Бар яктан да камил килгән мондый тәнкыйтьчене каян табарга? Прозаикларыбыз, шагыйрьләребез, драматургларыбыз бар да бердәй тигез булмаган кебек, тәнкыйтьчеләребез дә сәләтләре ягыннан бердәй тигез түгел. Шуңа күрә редакциянең бурычы — әдәбиятыбызда инде танылган, нәтиҗәле эшләп килгән тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият белгечләре Гази Кашшаф, Хатип Госман, Хәсән Хәйри, Мөхәммәт Гайнуллин, Гали Халит, Баян Гыйззәт, Ибраһим Нуруллин, Мансур Хәсәнов, Рафаэль Мостафин, Нил Юзиев, Нур Гыйззәтуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Зәет Мәҗитов, Азат Әхмәдуллин, Тәлгат Галиуллин, Илтани Илялова, Флүн Мусин белән бергә, яшь алмашны үстерү, моның өчен журнал редакциясе каршында яшь һәм башлап язучы тәнкыйтьчеләрнең даими эшләүче семинарын оештыру. Редакция бу җитди эшкә иң актив эшләүче өлкән тәнкыйтьчеләрне, галимнәрне тартырга исәпли.

«Казан утлары» 1971 елдан башлап кече жанрдагы әсәрләргә, шул исәптән әдәби

тәнкыйть мәкаләсенә, бүләк биреп бару тәртибен кертте. Еллык эшебезгә йомгак ясаганда әдәбият-сәнгать тәнкыйте жанрында эшләүчеләргә күбрәк игътибар итү шулай ук журнал битләрендә әдәби тәнкыйтьнең, китапларны рецензияләүнең яхшыруына китерер дигән өмет бар.

«Казан утлары»ның 50 еллыгына багышланган мәкаләләрдә редакциянең моннан егерме еллар элек зур күләмле проза әсәрләренең бик зур тырышлык белән эзләп табуы хәбәр ителә. Бүген роман, повестьларга кытлык юк. «Казан утлары»ның 1972 елгы портфелендә өч роман, ундүрт повесть бар. Сүз, әлбәттә, бастырып чыгарырга яраклы, идея-художество эшләнеше камил әсәрләр турында бара. Алар тематик яктан да күп төрле. Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы укытучыларны, Шамил Бикчуринның «Каты токым» романы нефтьчеләрне, Эдуард Касыймовның «Кош канаты белән» романы химикларны, Мәхмүт Хәсәновның «Кама таңнары», Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Шәһәрдә наратлар шаулый», Барлас Камаловның «Урамнар киңәя» повестьлары Чаллы шәһәрен һәм Кама автомобиль заводын төзүчеләрне сурәтли. Галимнәр тормышына Аяз Гыйләҗев «Урталыкта» исемле повесть, авыл эшчәннәренә Хәниф Хәйруллин «Таңнар якты булсын» повесте, елгачыларга Илдар Низамов «Дәрья күзе» повестен, Бөек Ватан сугышына Әмирхан Еники «Без дә солдатлар идек», табигатьне саклауга Мирсәй Әмир «Балыкчы ялганнары», әхлакый темага Мәдинә Маликова «Адашканга юл кайда?» повестьларын багышлыйлар. Өлкән буын каләм осталары белән кулга-кул тотынып эшләүче урта буын һәм яшь буын әдипләрнең үсеп җитүе әнә шулай редакциянең портфелен баетты. Бу — әйбәт күренеш. Бер яктан, ул татар әдәбиятының әле мөмкинлекләре күп икәнен күрсәтсә, икенче яктан, иҗади ярыш атмосферасын тудыра, андый ярыш әдәби осталыкның үсүенә китерми хәле юк.

Әдәби осталык өлкәсендә эшлисе эш байтак әле. Нәкъ менә шунда тәнкыйтьчеләр язучыга ярдәм итәргә тиешләр дә. Моңарчы татар прозасында географик киңлек һәм эрудиция җитмәү, портрет бирә белмәү, фәлсәфи уйланулар булмау кат-кат күрсәтеп килендe. Әкренләп бу кимчелекләрдән арына барабыз. Әмма урта буын, өлкәннәр белән бергә, төпкә җигелеп тарта башлагач, аның сюжет-композиция кора белмәү, ә барыннан да бигрәк, әсәр тукымасын тыгызлый белмәү кимчелеге өскә калкып чыкты. Шунлыктан әдәбиятка бүген генә килүче яшьләрдә дә шул авыру кабатланмасын өчен, журнал битләрендә әдәби уку мәсьәләләрен, осталык мәсьәләләрен күтәргән даими бүлек ачарга карар кылынды

«Казан утлары» үзенең юбилеен СССР төзелүгә 50 ел тулуны каршыларга әзерләнгән истәлекле көннәрдә билгеләп уза. Журнал шул уңайдан тугандаш әдәбиятлар белән татар әдәбиятының элемтәләре турында мәкаләләр бастырып барачак.

«Казан утлары» журналы ярты гасырлык юлына бүген йомгак ясап, хезмәт бәйрәмен үткәрә. Ил белән бергә, халык белән бергә, туган Партиябез белән бергә узылган юл бу. Социалистик реализм әдәбиятының тантанасы өчен көрәш юлы.

Халыкның борын-борыннан килгән матур гадәте бар: эшләгән эшләребезгә сөенеп, тәбрик-котлауларны тыңлаганнан соң билне ныграк буып, җиңне ныграк сызганып эшкә тотыну.

Социалистик реализм әдәбияты безнең җәмгыять үсешендәге төп тенденцияләрне дөрес тотып ала белүе, халык һәм партия тормышындагы мөһим вакыйгаларның мәгънәсен ачып бирә белүе белән көчле булды. Ә хәзер безнең бурычыбыз коммунистик төзелешнең бүгенге үзенчәлекләрен, илдә җәелгән фән-техника революциясенең социаль, әхлакый-психологик аспектларын тирәнтен өйрәнү, безнең заман героен алгы планда, зур итеп гәүдәләндерүдән гыйбарәт.

## Сибгат Хәким

•

Үткәнемә, узганыма бүген
Югарыдан карый гомерем,
Күпер төбендәге алачыклар,
Авылның бар тимер-томырын
Җыеп яткан иске алачыклар,
КамАЗ йотты сезне, КамАЗлар,
Тимерчелек цехларына кереп
Адаштылар сезнең авазлар...
Күрәм чорның олы адымнарын,
Тоям чорның көчле җилләрен,
Атларымны юлга дагалаган,
Ерак юлга көпчәк шиннәрен
Тартып биргән батыр тимерчеләр
(Сезнең утлар сүнеп калмаслар),—
Сез дөрләткән утны, күрекләрне
Киләчәккә йотты КамАЗлар.
Күңелләрнең горурлыгы үсте,
Кызыктырмый инде «Форд»лар да,
Америка сүнеп кала төсле
Кама буендагы утларда.
Дошманнарын үзенең көнләштереп
Үсте Ватан, үсте халыклар...
КамАЗлар юк чакта гына җирдә
Яшәгәннәр икән алыплар.

1972

## Шәйхи Маннур

### Әйтче тагын...

Юкәләрнең яшел күләгәсен
Изге почмак итеп кичләрдә,
Күзли егет бер йорт тәрәзәсен,
Өзгәләнү тулы хисләрдә.

Эх, чыкмас шул,
Чыкмас инде ул кыз
Төн пәрдәсен урап иңенә...

Хәер...
Күк болытлар аша йолдыз
Балкып китә кайчак тиз генә...

Ул да шулай бер күренсә кичен
Акка күмеп шушы юлларны,—
Бер минутлык
Бер күрешү өчен
Бирер идем бөтен дөньямны!..

Уйлый шулай
Сөю сагышында,
Гашыйкның ул юмарт куллысы...
Юкә чәчәкләре баш очында
Аңкый,
Гүя шул кыз сулышы.

Ул озата килгән иде аны,
Күптән инде,
Ун көн электер...
Шуннан бирле тынгы тапмый җаны,
Бар да, бәлки,
Буш бер өметтер?..

«Яратам!..» дип пышылдаган бер сүз
Ишетелгән капка эченнән,
Ул нишләргә белми
Калды өнсез,—
Күпмый торды баскан төшеннән.

Һәм ыргылып,
Үзе пышылдады:
— Ничек дидең,
Ничек, Гөлгенә?
Әйтче тагын,
Әйтче бер генә!..

Юк...
Килмәде ул сүз кабатланып,
Телсез тынлык капка артында.
Ә ул китте,
Китте канатланып...
Бөтен уе — шуның хакында!

Инде ун төн!
Һаман килә монда
Басалмыйча ярсу ялкынын.
Тик ишетми
Кичләр тынлыгында
Пышылдавын «капка артының...

Җил идеме,
Әллә җан идеме,
Кем исертте аны бу хәтле?
Әллә күктән сихри өн иңдеме,—
Шундый татлы сүзне
Кем әйтте?

Ник, ичмаса, кабатламый шуны,
Таңга хәтле сайрап, сандугач?
Күңеле бит аның сагыш тулы,
Нишләсен ул
Артык сагынгач?..

Ул һаман да капка төбен саклый,
Ник күрмисең аны, Гөлгенә?
Ул үтенә синнән,
Мең кабатлый:
«Әйтче, Гөлем, әйтче бер генә!»

Үзең дә юк,
Сүзең дә юк аңа...
Төн эченнән туа
Яңа таң...
Үзе пышылдый ул моңсу айга:
«Яратам! Яратам!
Мин дә яратам!..»

1972

## Гамил Афзал

### Хәерле юл

Туган җирне сөясең дә кебек,
Көясең дә кебек,
Дөнья хәлен беләсең дә кебек,
Көләсең дә кебек.

Син алдыңа карап барасың да,
Елмаясың сыман.
Күзең белән кашың арасына
Дөнья яме сыйган.

Сине сөйгән, иркәләгән кулым
Яулык болгап кала.
Өлкәннәрне ихтирам ит, улым,
Бала күңеле — дала.

Бабайлардан калган изге йола
Юлда юлдаш була.
Дөньяңны гиз, галәмнәрне буйла,
Туган җирне уйла!

Батыр ирләр кулы ташны сыга,
Дус-дошманны сына,
Акылың бар, типсәң тимер сына,
Хәерле юл сиңа!

Серле юллар, серле нурлар алда,
Син менәрсең айга.
Бакчада күп нәфис алсу алма —
Берсен генә сайла.

Сагынырсың безнең язны, көзне,
Бу сагышлы йөзне,
Әлифбадан откан тәүге сүзне,
Онытма син безне.

Яхшы дуслар белән ашың бүлеп,
Күгәрчендәй гөрлә.
Якын дуслар санга сукмый диеп,
Дошманга сер бирмә.

Канат белән күк гөмбәзен кыеп,
Ура данлы юлны,
Гәүһәр кулларыңнан җәүһәр коеп,
Кырыкка яр кылны.

Җаныңа сал әтиеңнең илен,
Әниеңнең телен,
Туган якның көнен, җиләс төнен,
Иртәнге саф җилен!

Туры сүзле, сабыр күңелле бул,
Кеше сүзен тыңла,
Изге теләк, балам, хәерле юл,
Хәерле юл сиңа!

1971

## Шәүкәт Галиев

### Яңгыр ява...

Яңгыр ява, яңгыр ява,
Рәхәтләнеп, биеп ява,
Шатландырып, шаулап ява,
Күр, чистарып китте һава!

Шундый кызык, шундый хозур,
Каралтыга ник керим мин,
Тәнгә сихәт, җанга рәхәт —
Шул яңгырда тик йөрим мин,

Табигатьне туендырып
Болыт җиргә яңгыр сава.
Сусаганнан яңгыр шифа,
Саргайганнан яңгыр дәва.

Куеннардан яңгыр ага...
Кинәт мин сискәнеп китәм:
Радиоактив түгел микән,
Күктән афәт иңми микән?

...Кара болыт, караңгы көн,
Эчпошыргыч яңгыр ява.
Йөрәкләргә чәнчеп ява
Әллә нинди шомлы һава...

1962

## Зәки Нури

# Яза авыл, яза диңгез

НОВЕЛЛА

Диңгезгә хат яза авыл,
Кыз сәламе көн дә китә.
Мәхәббәте шунда аның —
Егет шунда хезмәт итә.

Башта ул да хатлар язды
Әйтеп сагыну сагышларын
Һәм аңлатып йөрәгенең
Эше ничек барышларын.

Ә бер мәлне шып тынды ул,
Хат килмәс булды авылга.
Өзгәләнә кыз йөрәге —
Ялкын да анда, давыл да.

Төшләренә кертмәс булып
Каргады кызый диңгезне:
«Арабызга дулкын кертеп,
Сак та Сок иттең син безне.

Кайда син, иркәм, ник болай
Суга ташланган таш булдың?
Мин хәзер тәмам гаҗиз җан,
Мин тәмам гаҗиз баш булдым.

Гел синең җырны кабатлыйм,
Бер уем юк синнән битәр.
Кайда син, ерак кояшым,
Нурың кайчан килеп җитәр?!»

Җитте ул! Диңгездән килеп
Бер акчарлак канат какты:
Бөтен авыл укып чыкты
Бер кызга дип язган хатны.

Укыдылар, куандылар,
Котладылар авылдашны.
Кыз түземен мактадылар:
«Ә ул кирәк, ә ул яхшы!

Тик кетә белгән йөрәкләр
Янәшә калып берләшә!..»

Су асты морягы белән
Җир өсте кызы серләшә.

Егет язган: «Мин язасын
Газитләр әйттеләр өзеп.
Бөтен җир шарын әйләндек
Тирән су астында йөзеп,—

Егет әйткән, — һәр минутта
Йөрәктә булдың син!» дигән...

Менә бит ул хәлләр ничек,
Менә бит эшләр нинди дән!

Авыл яза, диңгез яза,
Хатлар көн дә йөреп тора.
Әйтерсең бер мәхәббәтне
Бөтен дөнья күреп тора.

1972

## Салих Баттал

### Владивостокта татар җырлары

Бардым да кердем бер өйгә —
таныш өй түгел миңа,—
таныш көй тартты да кертте
мине татар йортына.

Керсәм — өстәл өсләрендә
патефон уйнап тора,
өйдәгеләр оныгылып
шул көйне тыңлап тора.

Алып киттем аның җанны
иркәли торган моңын,
ни белән түлим, кемнәргә
рәхмәтен әйтим моның?!

Рәхмәт бу өйдәге чит, тик
якын хуҗаларга да,
җырчыга да һәм шулай ук
Эдиссон[1] бабайга да...

Яшәвем алдында калды
бер генә теләк инде:
укучымнан мин дә шулай
рәхмәт ишетсәм иде!

1972

## Зөлфәт

### Сайрамас идеммени?

Сайравына һушым китеп
Тыңлап тордым мин иртән —
Бу табигатьнең йөрәге
Сандугач түгел микән?
Күкләргә ашты күңелем
Шул моңчарга сарылып,
Сайрап үлә сандугачлар,
Йөрәкләре ярылып.
Йөрәккә кунган шикелле
Сайрамачы, кит инде...
Шушы сайрауларың белән
Үтерәсең бит инде!
Каян килгән сиңа бу моң? —
Томшыгың көмеш бугай,
Томшыгың көмеш булмаса
Сайрамас идең болай.
Аңлар өчен ил шатлыгын,
Кайгыларын, язмышын —
Тик бер тапкыр тыңлау җитә
Шул сандугач тавышын.
Табигать миңа сандугач
Язмышы бирсә әгәр,
Сайрамас идеммени соң
Илем өчен,
горур йөрәк
Ярылганчыга кадәр!

1972

[1] Фонографны беренче уйлап табучы. Ред.

## Гәрәй Рәхим

# Арадашчы

*Укытучыма*

Мин сабый чакта, мин камыр чакта,
Битараф чакта акка, карага —
Син арадашчы булып кергәнсең
Бу дөнья белән минем арага.

Син — арадашчы! Бөек илче син
Әлифбалардан, физикалардан...
Син — арадашчы! Ерак тарих һәм
Бүгенгем белән ике арада.

Ятлар тормышның бер канунына
Мең төрле итеп бәя биргәндә,
Син инандырдың мине һәрвакыт
Дөреслек дигән бердәнбер фәнгә.

«Тик шуның белән син илгә кирәк,
Хаклыкка табын»,— дип өйрәткәнсең.
Әнә шулай син мине — камырны
Тимердәй нык бер кеше иткәнсең.

Син бөек илче булып калырсың
Бу дөнья белән минем арада.
Рәхмәт, укытучым, хәзер инде мин
Битараф түгел акка, карага.

1971

Шамил Бикчурин

# КАТЫ ТОКЫМ

РОМАН

## I

Инде барысы да эшләнде кебек. Буровой җиһазлары озатылды, кирәк-яраклар машиналарга төялде, кайсы кая таралган кешеләр дә җыелып бетте бугай — кузгалырга вакыт.

Зөбәеров, буровой күперчегенә менеп баскан килеш, тагын бер мәртәбә тирә-якка күз йөртеп чыкты. Нәрсә булса да калыр дип куркудан түгел, китәсе килмәүдән иде. Ияләнелгән...

Разведка тормышын «чегән тормышы» дип тикмәгә генә әйтмиләр бораулаучылар. Эш гомер буе күченеп йөрү, урын алыштыру белән бәйле. Булган барлык буровой хуҗалыгың — алтмыш тонналап вышкаң, берсе-берсе бишәр тонналы дизель моторларың, насосларың, пар казаннарың, электр станцияң һәм эреле-ваклы башка җиһазларың белән яңа урынга килеп туктыйсың. Урнашасың, мең бәлаләр белән эшне җайга салып җибәрәсең, бораулый башлыйсың. Көннәрдән бер көнне скважинаң тәмам. Күчәргә кирәк. Китәсе килми, нәрсәдер кызганыч. Шушы ярты елга якын сине интектергән буровоеңа, мең кат каһәрләнгән скважинаңа, каргалган мәйданыңа күнеккәнсең. Барысы үз, барысы якын.

Ә син беренче мәртәбә килеп туктаган кыр, таныш булмаган елга буе яки әрәмәлек? Суыкларда сиңа сыенырга урын биргән авыл, җылы өй, сине туган итәргә өлгергән кешеләр? Барысы, барысы дөнья бәясе! Моны бер Зөбәеров кына түгел, һәр бораулаучы-разведчик кичерә. Тик бал тәмле дип бармакны йотып булмый. Китәргә кирәк...

Зөбәеров күперчектән җиргә сикерде.

Мастерның кузгалуын күреп, бораулаучылар да ыгы-зыгы килә башлады: озатырга чыккан авыл кешеләре, фатир хуҗалары, монда табылган яңа дуслары, кышын бергә эшләгән кочегар кызлар белән хушлашырга тотындылар. Зөбәеров та алар арасына кереп буталды. Ул төркем эченнән үзе яшәгән фатир хуҗасын эзләп тапты да:

— Ярый, Сәләхетдин бабай, тагын бер мәртәбә зур рәхмәт! — дип шапылдатып, картка кул бирде.— Гаеплэштэн булмасын, дөресен әйткәндә, рәтләп сөйләшергә дә вакыт калмады...

— Инде кая таба юл тотабыз дисең, улым?

— Еракка, бабай, еракка! Моннан йөз чакрымнар бар. Сагындык елгасы буена.

— Юлыгыз уң булсын, балам. Тагын килегез, кунак булырсыз. Рәйсә килен белән кил, яме!

— Рәхмәт, бабай, рәхмәт! Бер кочуч рәхмәт!

Зөбәеров үз бораулаучыларын фатир керткән тагын берничә кеше белән хушлашты, нишдидер үзенә таныш булмаган әбиләргә, апаларга кул биреп чыкты, аннан кочегар кызлар янына килде. Разия белән Кәримә дөньяларын онытып, көлешә-көлешә, бораулаучы егетләр белән сөйләшеп торалар. Сөлек булып ябышканнар, кычыткан чыпчыгы урынына чыркылдашалар.

— Ну, кызлар, егетләрне җибәрәбезме инде? — диде Зөбәеров.

— Үзләре бит җибәрмиләр!

— Бер кеше урманда: «Аю тоттым».— дип кычкыра икән. Иптәше: «Бире китер!» — ди икән. «Бармый бит!» — ди икән тегесе. «Алайса үзең кил!» «Җибәрми бит!» — дип акыра икән иптәше.

— Ә, ние шул, абый, «Әлифба»да шундый әкият бар иде,— дип, кызлар дәррәү көлеп җибәрделәр.

Зөбәеров кып-кызыл булып кызарды:

— Киттек, егетләр, киттек! Ярый, сау булыгыз, кызлар! — Як-ягына каранды: — Ә Гөлниса кайда?

— Кайда аулак, шунда! — дип көлеп җавап бирделәр кызлар.

— Әһә, димәк, Фәрхетдин белән?

Фәрхетдиннең автобус артында Гөлнисаны кочаклап торуын күргәч, бармады, читтән генә эндәште мастер:

— Абзыкаем Фәрхетдин, түбәтәең бәрхетдин, әйдә, утыр машинага!

— Синең ярың яр буенда, минем куенда! — дип, Зөбәеровның үзенә генә ишетелерлек итеп такмаклады Фәрхетдин.

— Китәр алдыннан йола буенча хет бер утырышып аласы иде бит, мастер? — диештеләр бораулаучылар, һаман да кузгаласылары килмичә.

— Утырып туярсыз әле — йөз километр барасы! Автобуска! По коням!..

Болай гына, ансат кына китеп булмый икән әле. Автобуска утырыша башлагач, тагын хушлашырга тотындылар. Кайсылары кочаклашып, кайсылары кул биреп, җилкә сугып, кайсылары яулык болгап, нәрсәләрдер әйтеп, кычкырып калды.

— Хуш иттек, сау булыгыз!

— Кунакка килегез!

— Аман булыгыз! — Монысы казакъ егете Сапарбай тавышы.

Ниһаять, Гөлнисаның кулыннан тотып, Фәрхетдин дә автобус баскычына күтәрелде:

— Гуд бай, җаным! — диде ул, кайдандыр отып алган сүзен исенә төшереп.— Ышанмасаң, Ык елгасына таяк тыгып кара, су артса — ул минем сагыну күз яшьләрем булыр...

Автобуска кереп, тәрәзәгә борылгач, Зөбәеров тетрәнеп китте — кочегар кызлар аның каршында гына күз яшьләрен сөртеп торалар иде. Әйе, упкәләп, әрнешеп елый торганнардыр. Бик тә салкын хушлашты бит мастер «буровой кызлары» белән, бригадага җылы бирүчеләр, ямь, кот бирүчеләр белән...

Мастер кузгалырга торган автобустан сикереп төште дә, өч кызны берьюлы кочагына алып, каты итеп кысты.

— Гафу итегез, кызлар, сезнең белән бер туйганчы сөйләшә дә алмадым. Әш бит, эш!.. Ә сез безне онытмагыз, кунакка килегез... Юк, әшкә килегез сез көзгә. Мин сезне кайчан да шатланып кабул итәм...

— Онытырсыз шул.

— Онытмыйм! Килештекме? Көтәбез!

Зөбәеров автобуска менеп, шоферга кузгалырга кушкач кына кемдер араларында Мотгәрәй юклыгын абайлап алды.

Шау-шу китте:

— Мотгәрәй кайда?

Мотгәрәй иртән монда иде — чатырларны җыешып, барысына да ярдәм итешеп йөрде, машинага әйберләрне төяште, башкалар белән бер табында утырып ашады. Шуннан соң аны күрүче юк.

Дөрес, аның кая да булса берүзе китеп югала торган сәер гадәтләре бар. Ләкин күченәсе көнне югалып йөрү — бу инде чын-чыннан башсызлык!

Бораулаучылар яңадан шау-шу килеп машинадан төштеләр. Озатухушлашуларның да яме-тәме калмады.

— Ну, кая олакты бу Мотгәрәй?

Шуннан җыелышып юрау, фарыз итүләр китте. Берәүләр әйтә, ул, мөгаен, су керергә чапкандыр, ди, йөзә белми, Ыкка төшеп чуммаса гына ярар иде, дип хафалана. Анысына да ышанырга була — көн кызу, керер дә батар...

Икенчеләре, Мотгәрәй баш төзәтергә Башкортстанга чыгып киткәндер, дип юрый. Бик мөмкин. Кичә скважинаны тәмамлау, нефть табу хөрмәтенә бригадада тантаналы җыелыш булды һәм соңыннан, гадәттәгечә, бораулаучылар әрәмәлектә мәҗлес уздырып алганнар иде. Мотгәрәйнең иртәдән бирле кәефе булмады. Башкортстан күпер аша, Ык аръягында гына. Җитмәсә, анда вакыт та бездәгегә караганда ике сәгатькә алда йөри, кибетләр ике сәгать алданрак ачыла...

Мотгәрәй мәсьәләсендә Фәрхетдиннең үз шиге бар: «Соңгы көннәрдә Мотгәрәй бик үзгәреп китте, вакытлы-вакытсыз югала да башлады, ай-һай, авылда берәр «чәчбигә» гашыйк булып, хушлашырга китмәде микән?» — ди.

Озатырга килүчеләр әйтәләр: «Күптән түгел генә ул трактор бригадиры Вафа белән авылда йөри иде, икесе дә бераз кызмача иде»,— диләр.

Моны ишеткәч, Зөбәеровның яңак сөякләре калкып чыкты.

— Ахмак ул, минә кем! — дип кычкырды мастер, шоферы янына килеп. Әйтерсең ул Мотгәрәйне түгел, шоферны ачулана иде.

— Киттек авылга!

Ләкин авылга барырга туры килмәде. Алда, үр төшеп килүче атлы арба күренүгә, кемдер:

— Әнә Мотгәрәй! — дип кычкырып җибәрде.

Чыннан да, ат тотып утырган кеше янында Мотгәрәйнең түбәтәй кигән зур башы чайкалып килә иде. Ул да булмады, Мотгәрәй чиелдык тавыш белән җырлап та җибәрде:

Ап-ак җиләкнең чәчкәсен
Ничек таптап үтәрсең,
Бу кадәрле дус-ишләрне
Ничек ташлап китәрсең!

— Дуңгыз! — диде Зөбәеров, җиргә төкерде.

Автобус янына килеп җиткәндә дә әле, Мотгәрәй, беркемгә дә игътибар итмәстән, башын кырын салып җырлавын белә иде:

Барсаң туры, кайтсаң туры
Буровойның кантуры.

Килмэс идем монда туры,
Дус-ишләрнең матуры.

— Дөньяга карашы үзгәргән моның! — диештеләр кешеләр.

Аны алып килүче трактор бригадиры Вафа арбадан төште дә, чайкала-чайкала, Зөбәеров янына атлады.

— Син аны гаеп итмә, мастер,— диде ул, әле бер күзен, әле икенчесен кысып.— Мотгәрәй ул — алтын кеше! Асыл таш ул! Без аны ни... үзебезчә, крестьяннарча гына озату ясадык, ягъни...— Вафа, имән бармагы белән шыкылдатып, чикләвек кебек калкып торган бугаз төеренә чиртте.

Мотгәрәй жырлавыннан туктап, кызарган күзләрен Зөбәеровка төбәде:

— Институт бетердем дигән буласың инде, ә? Югары белемле инженер дисең инде, ә?

Ул арада арба янын бораулаучылар сырып алды.

— Ай-вай, мас булгансың, гой! — дип әрләп алды Мотгәрәйне Сапарбай.— Әйдә, нәмә эшләп ултырасың!

Мотгәрәй кызарып, шартлап чыгарга житкән күзләрен акайтып, Сапарбайга карады.

— Ни эшләп йөрисең син минем республикамда? Кыяфәтсез! Нәрсә калган сиңа монда?

Аксый-аксый Кадермәт килеп житте, кешеләрне аралап, Мотгәрәй алдына килеп басты.

— Я, төш, Мотгәрәй, кешеләрне көттермә!

— Тотынма син миңа, кулың керле! — дип акырды Мотгәрәй аңа.

Кадермәт бу сүздән күгәренеп-бүртенеп китте, тешләрен кысып, йодрыкларын йомарлады:

— Эх, шулаймы?!

Ике-өч кеше Кадермәтнең кулларына ябышты:

— Кирәкми, ул исерек...

Тин-Тиныч Мотгәрәйне арбадан күтәреп алды да автобуска таба атлады.

— Кая алып китәсез мине? Беркая да бармыйм мин!

— Күп сөйләшмә!

Бораулаучылар автобуска утырыштылар. Әле машина кузгалгач та, Мотгәрәй:

— Тотмагыз мине! Китмим мин сезнең белән, барыбер качам! — дип кычкырып маташты. Бераздан инде Тин-Тинычның жилкәсенә башын куеп, йокыга китте.

— Изелде арыш умачы,— диде Фәрхетдин.

Автобустагылар көлешеп алдылар да тындылар. Машинаның тигез гөрелтесеннән оеп, һәркем үз уена чумды.

З ө б ә е р о в *(ачуланып Мотгәрәйгә карап ала)*. Өйрәтергә кирәк бу ахмакны. Нәкъ Ибраһим-Задәчә кысарга кирәк. Юкса, бер дә кешеләрне саңга сукмый башлады. Чыннан да, аңламыйм мин бу бәндәне — нәрсә уйлап, кайда, ни эшләп йөри соң ул? Яна урынга баргач, жыелыш жыеп, акылга утыртмый булмас. Ибраһим-Задә нәрсә диде: «Мастер булсаң шуны бел, ул таудан биек, кыядан каты, диңгездән колачлырак булырга тиеш».

К а д е р м ә т *(үз-үзен кая куярга белмичә, өзгәләнеп бара)*. Кулың керле... Мин кешеләрдән шул сүзне ишетү өчен сугышып йөрдемме? Шул адәм актыгы, дары төтене иснәмәгән Мотгәрәйдән кимсеттерү өчен кан койдыммы?.. Эх, мондый хурлыкка түзгәнче сугыш кырында ятып калган булсам!

Т и н-Т и н ы ч *(итәгендә йоклап яткан Мотгәрәйнең такыр итеп кырылган башын сыйпап)*. Эх, умач, умач! Әйбәт малай син үзен, шулай

да сөймим мин синдәйләрне! Эшенне яратмагач, нигә монда разведкага килеп баш катырып йөрергә? Кайтып китәр идең, ичмаса, авылына, азмы-күпме кешеләргә файдаң тияр иде! *(Аякларь ойый башлавын тоеп, Мотгәрәйне уятмакчы була, аның колагын уа, Мотгәрәй ыңгыраша.)* Йокла инде, алайса, рәхәтләнеп автобуста. Разведкага кермәсәм, гомеремдә арбадан башканы күрмәгән булыр идем! *(Уйланып бара торгач, күңелсезләнеп китә.)* Монда да очрамады Валя. Тапмасымны белсәм, буровой дигән булып килеп тә йөрми идем. Зөбәеров сүзенә ышандым, җүләр. Аның «табабыз» дигән сүзенә алданып, никдидер күз күрмәгән, колак ишетмәгән Миңлебай, Карабаш якларын бораулап йөрдем. Валя Ык буйларында эшлидер дигәч, өметләнеп монда килдем. Инде тагын Сагындык елгасы буйларына алып китә. Имеш, Язтургай мәйданы — яңа мәйдан, барлык геологлар шунда җыелып ятарга тиеш. Валяны тапсаң шунда табарсың... Белмим инде, ялганлап кына йөртми микән ул мине, үзенә эшче кирәккә генә? *(Кискен хәл иткәндәй.)* Ант итеп әйтәм, менә Язтургайга хәтле генә барам да, Валя анда булмаса, ташлыйм да китәм бригадасын! Нык шунда шартлап ярылмый Зөбәеровың! Валяны эзләргә китәм. Җәяүләп, аркама капчык асып бөтен ил буйлап эзләргә чыгам!

Саакян. Ошамый бу бригада миңа. Мастеры да күкрәк киереп, тамак төбе белән генә сөйләшеп йөри. Ибраһим-Задә булмакчы! Аныңча кылану гына әле ул Ибраһим-Задә булдым дигән сүз түгел! Аңа җитәргә әле биш вагон нефть эчәргә кирәк! *(Кинәт автобусның утыргычына сугып куя.)* Бетте, китәм! Теләсә нәрсә эшләсен Зөбәеров, Төркмәнстанга үз бригадама кайтым китәм! Ибраһим-Задә мине монда өч скважина тишкәнче генә дип җибәрде — дүртне тиштем, карышмадым. Инде Язтургайда да эшлисем юк, вәссәлам! *(Бара торгач тынычлана, басыла. Тәрәзәгә борылып, тирә-яктагы табигатькә сокланып карый башлый.)* Ә Татарстанның табигате матур, Төркмәнстанның бер якта торсын. Ә кызлары! У-у, Кәримәнең күзләренә генә кара син — ут чаткысымыни! Киткәндә миннән күзен дә алмады, автобус тәрәзәсеннән гел миңа гына карап торды. Хат язам дигән иде, язар микән? Эх, өйләнсәң икән аңа! Алып кайтсаң икән дә: «Менә киленегез»,— дип, Ибраһим-Задәгә күрсәтсәң икән!..

Фәрхетдин *(блокнотын чыгарып, анда тезелеп киткән кызлар исемлегенә өстәп «Гөлниса» дип язып куя. Бик кәефләнеп кызларның исемлеген санап чыга).* Гөлниса — егерменче. Егерменчесе дә калды. Күрсәтми генә күз яше дә сыгып алды бугай — ни эшлисең, дөнья! Тормышың шулай яратылгач, башны ташка орып булмый. «Үпкән-кочкан — җилгә очкан» — безнең профессиянең девизы. *(Уйланып.)* Шулай да Миңлебай, Карабаш кызларына караганда Гөлниса чибәррәк иде... Ә буй-сыны! Зифа камышмыни!.. Ни әйтсәң дә Ык буенда үскән шул... *(Бераз тәрәзәгә карап бара да.)* Ә бит, бичара, миңа ышанды... Башы булса уйлап карарга иде: безнең профессия белән соң семья тормышы корып буламы? *(Кашын җыерып барган Зөбәеровка карап ала.)* Әнә, ул да өйләнгән. Чибәрлеккә Рәйсә дә Гөлнисадан бер дә ким түгел. Ә нәрсә? Берсе көн-төн разведкада ил гизеп йөри, икенчесе Бөгелмәдә баласы белән ялгыз торып ята. Аена бер дә күрешә алмыйлар. Алай тормыш иткәнче — лутчы чит хатыннар белән йөрим мин!

Үскенбаев *(бармакларын бөгә-бөгә санап утыра).* Узган айда өйгә ике мең ярым салган идем. Бусында ике мең дә җиде йөзне җибәрдем. Ике мең ярым да ике мең җиде йөз — ул буладыр... биш мең дә ике йөз. Бу скважинаны срогыннан элек тәмамлаган өчен мең тәңкә бүләк тә бирсәләр — ул буладыр алты мең ике йөз. Элек җибәргән акчаларга кушсаң, барлыгы кырык алты мең дигән сүз. Әйе, әйе, кырык алты мең. Калым тулып килә, Рәйхана минеке була! Тагын дүрт мең тәңкә нәрсә ул — ике ай да бораулыймсың! *(Уйланып.)* Рәйхана

да әзерләнә булыр инде. Аргамакка атланып минем Карал-Тәбәгә килеп чыгуымны түземсезлек белән көтәдер...

Нәҗип. Эшеннән дә зарланмас идем, ну, теңкәгә тия шушы күченеп йөрүләре! Болай ничек белем алырга кирәк? Кешеләр кебек бер төпләнеп яшәсәң икән дә тоташтан басылып бер укысаң икән! Өч ел эчендә алты урынга күчтек бит инде. Инде Язтургайда да мәктәпкә йөреп булмаса, хушлашырга туры килер буровой белән. Разведкада эшлим дип надан калып булмас...

Зөбәеров *(тәрәзәгә карап, юл буендагы күренешләр белән мавыгып барганнан соң)*. Ярый, яхшымы-начармы, берсен дә түкми-чәчми, кузгалып китүе хәерле. Санап карасаң — бер төпле кеше юк бит бригадада. Берсе дә торырдан, эшләрдән түгел. Имеш, Тин-Тиныч гел үзенең Валясын гына уйлап йөрсен, Саакян кайтып китү ягын гына карасын, Нәҗибе гел уку дип баш катырсын — шул да булдымы бригада?! Бу җүнсез Мотгәрәйнең югалып йөрүдән башы чыкмый, Кадермәте, эчендә яман чире бар төсле, йөзен чытып йөри. Калганнары да я акча турында, я хатын-кыз турында гына уйлап йөри бит аның! Әйләнә башласалар тагын? Бригадада берсенең бер торасы юк!

Эх, булса иде дә кадровый нефтьчеләрең шул Ибраһим-Задәнеке кебек, эшлисе иде рәхәтләнеп! *(Бераз уйланып торганнан соң.)* Юк, эшләп булмас болар белән. Түзә алмам. Исән-имин Язтургайдагы скважинаны тәмамласам, ташлыйм барсын к чорту! Китәм Ибраһим-Задә янына,— һичсүзсез ала ул мине,— керәм үзенә гади бораулаучы булып, эшлим кайгы-хәсрәтсез...

Шул чак автобус каты сикертеп куйды, Мотгәрәй уянып җырлап җибәрде:

Килмәс идем монда туры, мех!
Дус-ишләрнең матуры...

Автобус эчендәгеләр гөр килеп көлешергә тотындылар.

## 2

Күченүнең бу тапкыры мәшәкате белән генә түгел, юлның ераклыгы, җайсызлыгы белән дә шактый алҗытты. Ыкны артта калдырып күпмедер баргач, автобуста кешеләр бер-беренә бәрелә-сугыла ярты сәгатьләр сөргән җир өстеннән чыктылар. Аннан куе урманга керделәр дә су җыелып торган тар, сикәлтәле юлдан бардылар. Ул газаптан гына котылганнар иде, тау буйлап борыла-сырыла кырын урыннан киттеләр. Аумас өчен машина утыргычларына ябыша-ябыша кешеләрнең куллары талып бетте, сикәлтәләрдә чайкала-чайкала эчләренә кату төште.

Инде кечкенә генә авылның чыгасы да таш такыр юлга төшәсе иде. Тик басу капкасына житү белән, кулына кулъяулык кадәр генә кызыл флаг тоткан, җиңенә дә шундый ук кызыл бәйләгән бер кыз машинаны туктатты.

— Ярамый, карантин! — диде ул катгый тавыш белән, капкага кадакланган тактаны күрсәтеп.

— Кадалып китсәгез иде шул карантиннарыгыз белән! — дип сүгенделәр автобустагылар. Үткәреп җибәрүне сорап кызга ялынып-ялварып карадылар, «җаным, бәгырем, алма кисәгем»не әйтеп карадылар, ләкин ул берничек тә игә килмәде. Ахырда бер гөнаһсыз кызга ләгънәтләр укый-укый, «кияү күрмичә тилмерсән иде» дип каргана-каргана, авылны биш-алты чакрымнар читләтеп, әллә нинди сазлыклар, түмгәкләр аша әйләнеп үттеләр.

Аның каравы, буровой утырган яңа урын искиткеч матур булып чыкты. Юлда селкенеп, меңгерәп беткән бораулаучылар, автобустан төшкәч, башта моңа артык игътибар итмәгәннәр иде. Карасалар, бөтенләй ямь-яшел урман янында гына икән буровойлары. Вышкасы да каеннарга терәлеп тора диярлек.

Миргазиян сөзәк үргә күтәрелгән каен урманына, урман буендагы чәчәкләргә, куе үлән белән капланган аланга карап торды да шофер белән сөйләшкән Зөбәеровның җилкәсенә сугып алды:

— Ну, Фазыл малай, сайлый белгәнсез урынны! Буровой түгел, курорт бу!

Хәтта китаптан башка бернәрсә белән дә кызыксынмый торган верховой Нәҗип тә, каен башларына күз йөртеп чыккач, кабартма иреннәрен селкетеп куйды:

— Утынга аптыраш юк икән...

— Ә суы, суы ничек? Кая ул Сагындык елгасы?

— Зурмы? — дип, берьюлы гөжләшеп алдылар бораулаучылар.

Зөбәеров баш бармагын гына күрсәтте.

— Суы шәп, егетләр, көмеш кебек!

Палаткалар, аш-су кирәк-яраклары һәм разведчикларның эрелеваклы бернична чемоданнан торган «хуҗалык» әле арттагы машинада килеп җитмәгән иде. Шул арада өстәге тузаннарны кагып, аякларны язу өчен бераз йөрештереп, тирә-якны күзәткәләп килерлек вакыт бар иде. Бораулаучыларның кайсы Зөбәеров күрсәткән якка — урман артындагы Сагындык елгасына су керергә йөгерде, кайсы чатырлар кору өчен урын эзләргә, кайсы җиләк караштырырга урманга кереп китте.

Мастер Зөбәеровны буровой урыны борчый иде — ул шунда юнәлде. Ул яңа ысулга — су белән генә бораударга ниятләп тора. Сагындык елгасыннан килә торган су буровой белән яхшы тоташтырылганмы, насослар туктап калырлык түгелме, дизельләргә ягулык житәрлекме — шуларны ачыклап кайтасы бар иде аның.

Миргазиян белән Кадермәт, тирә-якны күзәтә-күзәтә, урман буйлап атладылар. Миргазиян юлда очраган чыбык-чабыкларны, агач кисәкләрен җыя барды, туктап, җирдән башлары чыгып торган ташларга, агач төпләренә типкәләде.

— Ташла әле шул иснәнеп йөрүеңне! — дип ачуланып куйды Кадермәт.

— Алай димә! Яшисе бар әле безнең...

Елгага төшә торган сөзәклеккә килеп җиткәч, икесе дә тын калып аска карадылар. Анда куаклар арасыннан кача-поса тар гына елга ага иде. Елгада, пошкыра-пошкыра, анадан тума шәрә бораулаучылар су керә. Шулдыр инде Сагындык дигәннәре. Инеш дисәң — инеш түгел, елга дисәң — елга диярлеге юк.

— Балыгы бар микән?

Кадермәт Миргазиянның соравын ишетмәде, елганың аргы ягындагы шушы урманның дәвамын күзәтте. Анда агачлар сирәгәя барып, иген басуына, басу ниндидер бер авылга барып тоташа иде.

— Шушы микән Язтургай авылы?

— Әллә барып киләбезме?

— Нәрсә син?

Әле урнашмаган, баш-күз алмаган, эшли башламаган көенчә, Миргазиянның мондый тәкъдиме Кадермәтнең ачуын китерде. Миргазиянга әлеге авылның бер дә хаҗәте юк, әмма Кадермәткә авылга барып килергә кирәк иде. Үзенә бик әйбәт кенә ярдәмче табарга иде авылдан.

Кадермәт кулы астында эшләгән буровой эшчесе, Азнакай егете Садыйк быел яз, биле кузгалып, больницага керде. Терелгәч врачлар аңа буровойда эшләмәскә кушканнар. Егет әйтә, бөтен җирдә, теләсә

кайда эшләргә ярый, тик буровой гына ярамый, ди. Дәрте дә бар иде, огыйсә, разведкада йөрергә, китте әйбәт егет...

Аннан соң өч кеше алып карадылар, күрер күзгә таза гына егетләр иде. Чыдамадылар. Шуның берсе: «Ходаем сакласын сезнең бу эштән. Лутчы мин көрәк белән төн жир казыйм, кувалда белән таш ватам, буровой дигән бу чегән тормышына якын да киләсем юк»,— дип китте...

— Син ничек уйлыйсың, Миргазиян, кеше табылырмы бу авылдан?

Миргазиян дәшми генә арыш басуы артында, рәшә арасында жемелдәп күренгән авылга карап торды да, кабынып китеп, кулын селти башлады:

— Кешесе булыр! Ә менә бораулаучысы!.. Алсак та карап, тикшереп алырга кирәк... Юкса, нинди хәлгә төшердек бригаданы... Килгәне кача, калганы үзеч бүгенлек кенә дип йөри. Крестьян жыябыз. Колхозчы, дала көтүчеләре, һөнәр белмәгән солдат-матрос жыябыз... Син менә нәселдән килгән потомственный эшче баласы. Минем эти дә гомер буе заводта слесарь булган. Казна эше безнең каныбызга сеңгән. Без тимердән башка яши дә алмыйбыз. Ә менә бу Мотгәрәйләр, Сапарбайлар, Фәрхетдиннәр нәрсә дип кергәннәр буровой эшенә? Гыйлеме була торып мастер нәрсә дип алган аларны? Нәрсә караган? Менә шул кадерен жибәрәбез без эшченең. Пролетариат дигән зур исемгә тап төшерәбез!

Эшче сыйныфы мәсьәләсендә сүз кузгалдымы — Миргазиян битараф кала алмый. Юаш, басынкы дип йөргән егетебез кинәт ут кебек кабынып, дөрләп китә дә, кулларын бутап, рабучий классның кем булуын, киләчәктә кем булырга тиешлеген исбат итәргә тотына.

Күңел жибәрмәс өчен Кадермәт иелеп аяк астыннан сарут үләне өзеп алды, аның сабагын тешләре арасында изгәләп торды.

— Бер яктан син хаклы, Миргазиян. Тик хәзер заманы шундый инде, күрәсең: эшче крестьян була, крестьян — эшче...

Шул арада разведчикларның хужалыгы төялгән иске йөк машинасы да килеп житте. Су кереп, хәл алып кайткан егетләр әйберләрен бушатырга керештеләр.

Башта машина әржәсеннән түмәр-түмәр итеп бөтереп салынган яшел брезент палаткалар ыргытылды. Аның артыннан һәркем үз чемоданын — бер дә калмый буровойдан буровойга йөри торган шәхси милкен кабул итеп алды. Жиргә савыт-сабалар, чиләкләр, мичкәләр, балталар, көрәкләр һәм башка кирәк-яраклар төшерелде. Бераздан машинаның һәр дүрт ягы да өстәлләр-тумбочкалар, караватлар, радиоалгычлар, домино, шашка-шахмат тартмалары белән тулды. Волейбол тубы, көзге, велосипед та онытылмаган, кармак таягы һәм тырма белән бер иске сәнәк тә ияреп килгән. Хәтта Геннадий Еланский үзенең гантельләре белән герләрен, Саакян чүлмәк савыттагы үрмәле гөлләрен дә машинадан калдырмаган.

Чатырлар кору белән житәкчелек итүне электәгечә үк, һичкемнән сорап тормыйча, Кадермәт үз өстенә алды. Бу эшнең остасы буларак, ул иң элек урман буендагы чәчәкле акланга кереп, адымлап үлчәп чыкты. Бер кишәрлек жирне кулындагы сәнәге белән сызып билгеләде дә команда бирде:

— Башларга!

Мастердан алып бурильщикларга, верховойларга, буровой эшчеләренә кадәр чатырлар коруда эшләделәр.

Кадермәт корылган һәм корыла башлаган чатырлар буенча йөрде, аларны тарттырып куйган бауларны капшады, ныклыгын тикшереп брезентларга суккалады, кешеләргә бәйләнгәләп, баулар беркетелгән чөйләргә типкәләде.

Палаткалар рәте буйлап йөри торгач, Сапарбай янына килеп туктады Кадермәт.

— Син үзең, Сапарбай энем, «мин дала баласы» дисең, ә үзең чатыр да кора белмисең!

— Нәмә житмәгән тагын?

— Тәрәзәң синең артка, урманга караган түгелме соң?

— И-и, Кадермәт әкә, миңа тәрәзәм кая караса да барыбер!

— Төзәт, хәзер үк әйләндереп куй чатырыңны!

«Тәрәзәм кая караса да барыбер», Кадермәт бер читкәрәк китеп Сапарбай сүзеннән көлде.

Туры әйтте егет. Кадермәтнең үзенең дә шулай түгел микән?

Кадермәт килгәндә, мастер Зөбәеров тирләп-пешеп чатыр тарттыра, үзе ниндидер җинел көйгә сызгыра иде. Кадермәт аның эшен карап торды-торды да чатырның бауларын селки башлады.

— Кабат бәйләргә туры килер, Фазыл туган.

— Ярап торыр шунысы да.

— Җил иссә, авачак бу! Төзәт, төзәт!

— Шаяртма!

— Ышанмыйсыңмы?

Кадермәтнең кочак җәеп чатыр өстенә авуы булды, чатыр ишелеп тә төште.

— Фу, күсе мыек! Тиле дигән саен тигәнәк бүе арттыра!

Зөбәеров сүгенә-сүгенә бер читкә барып утырды, тәмәке кабызды. Ул арада инде Кадермәт китеп барган, башка чатырлар өстенә авып йөри иде. Чатырларның сыйфатын тикшерүдә бердәнбер ысулы шул иде аның.

«Билгеле, Кадермәт хаклы»,— дип, тәмәке тартып бераз тынычлангач, тагын эшкә керешә Зөбәеров. Бу юлы инде ул Кадермәт түгел, шайтан килсә дә гаеп таба алмаслык итеп, үтә тырышып, чатырны мәңгегә коргандай итеп корды. Чыннан да бит әле аның бу чатырга кунакка хатыны белән нәни кызы Ләлә киләсе бар. «Менә отпуска гына алыйм, бу ай азагына булмаса, киләсе ай башында барып чыгарбыз»,— дип язган иде бит хатында Рәйсә. Палатка унайсызрак булса да җәй әле, көннәр җылы, өстән яңгыр үтми, бер айлап бергә яшәп калырга була. Аннан берәр җае чыгып, Фазыл үзе ял алыр, Рәйсә янына Бөгелмәгә кайтып тагын бер ай бергә торырлар. Ни дисәң дә елына ике ай — алай ук аерым яшәү түгел әле ул...

Матур гына хыялланып торганда, чатырлар артыннан тагын Кадермәт килеп чыкты. Чатырының ныклыгына иманы камил булса да, Зөбәеров тагын шүрләп алды. «Ватар бу күсе мыек».

— Син инде, Кадермәт, сикерсәң дә артыгын кыланма,— диде ул Кадермәткә.— Беләсеңме, минем хатын киләсе бар бит әле монда. Кызым белән...

— Алай булгач бигрәк тә! — Кадермәт кискен хәрәкәт ясап чатыр өстенә аугандай итте, тукталып көлә башлады.

— Болай да күренеп тора, мастер! Палаткаң хатының белән кызыңны гына күтәрерлек!

Кадермәт көлүеннән туктады да кинәт уйчанланып калды. Моңсу, йөрәк әрнеткеч авыр булып китте аңа. Әйе, кешеләрнең хатыннары да килә, балалары да, туганнары да... Кадермәткә беркем дә килми. Беркеме дә юк аның, хәтта хат язучысы да юк...

Урыныннан кузгалып, авыр гына китеп барды.

Кадермәтнең вакыт-вакыт сөмсере коелып, күңелсезләнеп киту галәтләрен Зөбәеров күргәли һәм әлегрәк аны буровойдагы хәлләрдән килеп чыккан нәрсә дип кенә карый иде. Көннәрдән бер көнне эшы комитетка чакырган язу килеп төште. Чиста түгел икән үткәннәре Кадермәтнең — пленда чакта ниндидер җинаять эшләгән, ахрысы. Аның үзе әйтми, ләкин район үзәгеннән кайтып кергәч, Кадермәтнең йөзеннән үк билгеле иде. Ул көнне буровойда да җүнләп эшли алма-

ды — беренче килгән кешедәй каушады, нәрсәгә тотынырга белми аптырап калгалады, кулы калтырады.

Бу вакыйга Зөбәеровны авыр хәлгә китереп куйды. Мастерның киңәш-табыш итешүчесе дә, буровойда барысын өйрәтеп, акыл биреп торучысы да, аварияләр булганда кыен хәлләрдән чыгаручы да Кадермәт иде. Шулар өстенә мастер ана, олы кеше итеп, үзе киткәндә бораулаучыларга күз-колак булуны да, төрле хуҗалык эшләрен дә тапшыра. Нәрсәгә тотынса, шуңа кулы ябышып тора торган кешенең җинаятьче яки сатлык җан булуына ышанасы килми...

Эшен бетереп, яңгыр сулары кермәсен өчен, башкалар кебек чатыр тирәли канау да казып куйгач, Зөбәеров, зур йорт салган кешедәй, әйләнеп чыкты. Кадермәткә ошатып, барабан карындыгыдай киерелгән чатыр өстенә ауды һәм канәгатьлек белән күккә карап торды.

— Ә Рәйсә килсә бу урынны яратыр иде,— дип уйлады ул биектә, ике үркәчле дөягә охшаган болытка карап.— «Менә ни өчен сез женнәргә бер дә чир кагылмый — сез курортта яшисез!» — дип көнләшер иде.

Һавадагы ике үркәчле дөя күз алдында җыерыла, куырыла башлады һәм инде ул дөягә түгел, күбрәк аюга охшый иде. Нәкъ быел кызы Ләләгә алып кайтып биргән уенчык аю баласы төсле.

— Мастер, күрмисеңмени, яңгыр килә!

Каерылып караса, аның баш очында шул ук тиктормас Кадермәт. Ул үз чемоданнары белән бергә машина яныннан Зөбәеровның әйберләрен дә алып килгән, ут капкандай ашыга иде.

Чыннан да, көнбатыштан бу якка ишелеп кара болыт килә, ул инде урман өстенә килеп җиткән иде. Кайдадыр теге баштта дөбер-дөбер күк күкри, яңгыр яфракларны шаулата иде.

Биш минут та узмады, яшенле яңгыр, дәһшәтен салып, монда да килеп җитте. Әйберләре белән кереп посарга өлгергән кешеләрне куркытырга теләгәндәй, ул урман өстеннән иләмсез үкереп чатырларга ташланды, брезент түбәләрне тишәрдәй булып шакыды, кечкенә чатырлар шаһәрчеген суга коендырды. Вакыт-вакыт ялтырап киткән яшен караңгы, бөркү чатырлар эченә бәреп керде, күкрәве белән урман аланына таш кыялар ишеп төшергәндәй итте.

Әмма разведчикларның эшләре беткән, күңелләре тыныч иде, башларына яңгыр таммаганга шөкер итә-итә, тыштагы зилзиләгә игътибарсыз гына гәп саталар иде.

Чатырга кешеләр билгеле бер тәртип белән урнаша. Сул кырыйдагы беренче чатыр гадәттә мастерныкы була. Шушы ук чатыр бригаданың «кунак йорты» хезмәтен дә үтәгәнгә, бирегә Зөбәеровның койкасы белән тумбочкасыннан тыш иске язу өстәле, юл йөрүдән пыяласы чатнаган шкаф, бригадага бүләк итеп бирелгән яңа радиола һәм кустарьлар ясаган берничә артсыз урындык та кертәләр.

Буровойга килгән кешеләр (ә алар көн аралаш диярлек булып тора) куна-нитә калса дип, өстәмә караватт та куела. Әмма югарыдан килгән кешеләр япа-ялгыз кырда кунып ятуны бик хуп күрмиләр, шуңа караватт гел буш тора, җыештырылган була, анда-санда Зөбәеровның хатыны белән нәни кызы килгәндә генә тузыла иде.

Мастер чатыры белән янәшәдә Зөбәеровның рәсми булмаган ярдәмчесе, уң кулы — Кадермәт һәм аның вахта члennары урнаша. Кадермәтнең якында булуы аралашу өчен дә бик җайлы — кычкырыбрак дәшсәң дә бер-береңне яхшы ишетәсең. Кадермәт вахтасы белән рәттән Сергей Саакяннныкылар яши, уң яктагы иң кырый чатырны һәрвакыт Тин-Тиныч бораулаучылары кора. Арткы рәттәге ике чатырны дизельчылар, электриклар, шоферлар һәм башка ярдәмче эшчеләр өчен калдыралар.

Тин-Тиныч чатырын бригадада «галимнәр чатыры» дип йөртәләр. Валентин үзе өченче ел инде читтән торып нефть техникумында укый һәм «мал иясенә охшамаса харам була» дигәндәй, аңа ияреп Нәҗип тә китап-дәфтәрләр белән дуслашып китте. Кадермәт вахтасыннан монда Миргазиян да керә. Эштән бушаган араларда аларның һәркайсында китап булыр, кайчан карама караватларда аунап укып ятарлар. Верховой Нәҗип үзлегеннән укып яренгә унынчы класс өчен имтихан бирмәкче була, Миргазиян быел, җай туры килсә, кичке бишенчегә керергә җыена.

Бу палаткада Фәрхетдин генә иптәшләренең үгетләүләренә бирешми яши. Уку мәсьәләсенә аның үз карашы бар — разведка шартларында белем алу мөмкин түгел дип саный ул. Алай гына да түгел, укуга каршы яхшы ук агитация дә алып бара иде.

Менә шулай тышта каты яңгыр яуганда һәм беркая да чыгып булмаган чакта уку, дөресрәге, имтиханнарга хәзерләнү өчен бигрәк тә уңайлы. Тик Фәрхетдин генә тынгы бирми. Ул, тезләрен кочаклап, караватына менеп кунаклаган да иптәшләренең әле берсен, әле икенчесен үчекләп утыра.

Бу күңелсез чатырдан үзгә буларак, Саакян вахтасындагылар музыка-җыр яраталар, Сергей үзе гитара уйнарга һәвәс, ә аның буровой эшчесе Габбас яхшы ук гармун тарта белә, помбур Михаил Кубракның тавышы әйбәт. Бу чатырда бары тик Мотгәрәй генә, үги бала шикелле, берьякка да кушылмый боегып утыра.

Сменадан кайтып, үлле-мәлле йоклап алалар да, бисмиллалары итеп, иң беренче җыр җырларга тотыналар. Бүген әллә юлдан бик арып килгәнгә, әллә яңа урынны ятсынып, Фәрхетдин кергәндә тып-тын утыралар иде.

— Нигә җырламыйсыз? Яшеннән куркып калдыгызмы әллә? — дип, җан кертеп җибәрде боларга Фәрхетдин. Сергей искереп, буяулары кибеп беткән гитарасын алды. Көйли алмыйча озак кына шөрепләрен боргалады, кылларына чиерткәләде. Фәрхетдин белә: түземсез җырчы Мишаны юри газаплый ул. Шуның аркасында Сергей белән Миша ачуланышып та бетәләр.

Миша моңлы һәм көр тавышлы украин җырларын сузып җибәрсә, күршеләр тып-тын кала.

Кызыклы ягы белән аерылып торган кешеләрне, әлбәттә, һәр чатырдан табарга була. Хәтта иң тыйнак, житди вахта дип исәпләнгән Кадермәт вахтасында да Геннадий Еланский кебек, буровойдан арып кайткач, икешәр потлы гер күтәреп йөгерүче әкәмәт затларны күрергә мөмкин. Әмма кешеләр аның янына түгел, Фәрхетдин янына җыелалар. Фәрхетдин мәзәк сөйләүчән, шуңа күрә кызык ишетергә керүчеләр белән чатыр эче шыгрым тулган булыр, идәндә басар җир, карават, тумбочка өсләрендә утырыр урын калмас, пыскыткан тәмәке төтене эченнән Фәрхетдиннең шаян күзләре генә ялтырап күренер.

Яңгыр туктап, Зөбәеров артистлар чатырына кергәндә әле генә яңгырап торган җырны Фәрхетдин алыштырырга өлгергән иде инде. Гадәтенчә, фуражкасын кыңгыр салып, кызлар белән булган вакыйгасын сөйли:

— Грамотный кыз белән йөрмә икән гомереңдә. Карабашта эшләгәндә шулай бер мәлне укытучы кыз белән танышкан идем. Таныштым, рабочий икәнне әйтмәдем. Юкса, бер дә безнең эше дегет чүлмәгенә карый торганнардан түгел — борыны бик югары. Инженер Фәрхетдин Хисаметдинович, мин әйтәм, шушы буровойның хуҗасы, дип кул бирәм. Бирүен бирәм кулны, ләкин инженер булуның җаваплылыгын белми бирәм икән.

Беренче кичне үк минем белем дәрәҗәсен сыный бу. Нәрсәләр укыйсыз, нинди кинолар карыйсыз, янәсе. Музыка яратасызмы? Миндә

белем ягы, үзегез беләсез, күршедән әҗәткә алып торган сүз белән абынып егылганда табылган хәрефтән гыйбарәт. Ташла әле дим моңа, туеп беткән алардан, мәхәббәт турында гына сөйләшик! Ә тегенең үз туксаны туксан. Пушкин мина күбрәк ошыймы, Маяковскиймы? Достоевскийга минем караш ничек? Тургеневка? Нindидер Сервантнымы, Сервантесныймы уйлап чыгарды. Сырттан тирне агыза бит бу! Инженер булгач, күрәсең, белергә тиештер инде аларны. Минем дә сер бирәсем килми. Әйе, мин әйтәм, беләм аларны, бик яхшы беләм. Тургенев ул безнең бораулау конторасында бухгалтер булып эшли, минем рабучийларны да обижать иткәли, ә теге Достоевский бер булдыксыз бәндә инде шунда, минем буровойда помощник! Авария артыннан аварияне ясап кына тора! Ә ул Мольерны әйтәсеңме? Аның белән армиядә бергә хезмәт иткән идек. Ул лейтенант, ә мин майор. Ничава малай үзе, тик менә бер дә самостоятельный түгел...

Кыз көлә — мине шаярта дип уйлый инде. Миндә соң шаяру кайгысымы! Ничек булса да сүзне борып җибәрү кыйммәт.

Моның һаман үз туксаны туксан: Поль Сартр ошыймы сезгә, Экзюперины укыганыгыз бармы?

Ахырда түзмәдем, әйттем дә салдым моңа: ә соң, мин әйтәм, син БУП дигән китапны укыганың бармы?

Аптырады да калды бу. Бер җиргә карый, бер күккә — хәтеренә төшермәкче була, боргалана, сыргалана. Нинди китап соң ул, кем язган, авторы кем дә, фәлән дә төгән. Эх, мин әйтәм, үзең укытучы, үзең шуны да белмисең! Ә мин аны ятлап бетергән, күңелдән беләм! — дим.

Бораулаучылар да уйга калды.

— Чыннан да нинди китап соң ул БУП?

— Наданнар! Томаналар! — дип кычкырды Фәрхетдин.— Аны һәр солдат белә! — «Боевой устав пехоты»!

Шаулатып бер көлеп алдылар.

— Я, я, шуннан? — диде кайсыдыр бер түземсезе.

— Шуннанмы? Шуннан кызым китап сөйләвеннән туктады. Минем чын гыйлем иясе икәнлегемә төшенде булса кирәк — андый четерекле сорауларны бирми башлады!

— Тик шулай да ташлады!

— Анысы синең аркада! — дип җикеренде Фәрхетдин Мотгәрәйгә.— Ахмак син! Шулай бер көнне вахтадан соң килдем теге кыз белән концертка. Кием яхшы, өс-баш чиста, авыл халкы да каян белеп алган, шайтан, иптәш инженер, монда утырыгыз, безнең янга утырыгыз, дип кенә тора. Кызны култыклап алып кереп чумдым кешеләр арасына, эре генә сөйләшеп утырам. Шул вакыт җен кебек майга баткан менә бу ахмак Мотгәрәй килеп кермәсенме! Килеп тә керде, мазутлы куллары белән минем ак якадан эләктереп тә алды. «Ник буровоеңны чистартмый киттең, мөртәт?» — дип, бу мина җикеренепме-җикеренә. «Бар, йөгер, имеш, мастер чакыра, кирәгеңне бирәчәк!» Билләһи, идән ярыгы булса, шул ярыктан төшеп китә идем.

Хахылдап көлешкән егетләрне чак тыеп, Зөбәеров шундый сорау бирә:

— Инде, Фәрхетдин, турысын әйткәндә, төскә-биткә кеше шаккатыра торганнардан түгел, буй-сынга да әллә ни күренмисең, грамота ягың да чамалы, кай җиреңне генә яраталар соң синең кызлар?

Фәрхетдин уйлап-нитеп тормастан:

— Тешләремне,— дип куя һәм, берсе өстенә берсе атланып үскән эреле-ваклы тешләрен күрсәтмәс өчен читкә борылып, авызын кулы белән каплый.

— Дөресен генә әйткәндә, синең ару-талу белмәгән авызыңны ярата торганнардыр,— ди Миша.

— Ә нәрсә? Кызлар алар Карабаш кибете кебек сәгатенә бер генә ачылып ябыла торган авызны яратмыйлар!

— Җилгә жилләп, бозга бозаулап йөрисең инде шунда! — дип куйды чатырның караңгы башыннан Мотгәрәй. Аның сүзен Зөбәеров кына ишетте.

— Ярый, җәмәгать, ял итәргә кирәк! Иртәгә иртүк эшкә! — диде, егетләрне куып.

Фәрхетдин зарлана-зарлана урыныннан торды:

— Армиядә старшинадан гаҗиз була идем, инде монда мастер тынгы бирми! Кайчан бу дөньяда командасыз гына яшәрмен!

Бораулаучылар чатырларына таралыштылар.

## 3

Чатырына кайткач, Зөбәеров ярты төнгә кадәр буровой документларын актарып утырды... Шунда ул беренче нефть ачкан еллардан калган геологик картага килеп юлыкты. Карта тузган, таушалган, майланып-каралып беткән иде. Бөкләп сумкага салган урыннары киселеп чыккан. Дүрт ел тулып узуга карамастан, Зөбәеров бу картаны һаман саклап тора, документлары арасында кадерләп кенә асрый.

Берничә районны нокталар белән әйләндереп алган геологик картада зур итеп кызыл белән төртеп куйган аның ноктасы да бар. Бу Зөбәеровның Чияле тауда бораулаган беренче скважинасы.

Кечкенә генә авылга яшел йөзе белән карап торган тәбәнәк кенә тау. Тимәш халкы аны Чияле тау дип атаган. Бәлки, кайчандыр монда кызарып чия пешкәндер, ә ул вакытта тау битендә ап-ак кар кебек исәпсез-хисапсыз ромашкалар гына үсә иде. Бер нәрсәсе белән дә аерылып тормый иде бу тау.

1948 елның 16 июль иртәсе дә гадәти бер иртә иде. Еллар буе булган кебек, бу иртәдә дә Чияле тау өстенә кояш чыкты, имәнлектә күке кычкырды, авыл буасында, берсеннән-берсе уздырышып, бакалар бакылдады. Таң белән уянган авыл хатыннары сыер саудылар, ашыга-ашыга көтү кудылар. Салам түбәле өй морҗаларыннан багана-багана төтен күтәрелде.

Гадәттәгечә гап-гади иртә иде.

Һәм шушы иртәдә Чияле тауда нефть фонтаны атты. Ике мен метрга якын тирәнлектән ургылып чыккан бу нефть егерме-утыз метрлар өскә күтәрелде, тыелгысыз ташкындай шаулап, тау битеннән кечкенә инешкә акты.

Июльнең шушы гади иртәсе, моңарчы берниндн даны-шөһрәте булмаган кечкенә Тимәш авылы, аның ромашкалар үсеп утырган тәбәнәк Чияле тавы күз алдында кинәт кенә олы булып үсеп китте. Ромашкино нефть ятмасы булып телләргә керде, еракларга ишетелә башлады.

Шул ук елны Чияле таудан ерак та түгел, Вәли хуторы дип йөртелгән авыл кырыендагы 10 нчы номерлы скважинадан фонтан бәрде. Ул да булмады, Зәй-Каратай авылының бәрәңге бакчалары артында салынган скважина нефть бирде. Шул көзне Миңлебай авылы янында моңа кадәр бакалар патшалыгы булып кына хезмәт иткән сазлыктан нефть таптылар. Бераздан иске Суркино урманы эченә утыртылган буровойдан рапорт алынды: «Нефть бәрде. Тәүлегенә алты йөз тонна бирә».

Чияле таудагы скважинаны файдалануга тапшырып, котлаулар, бүләкләр, баш әйләнгеч мактаулар белән үткән берничә көннән соң Зөбәеровны конторага чакырдылар.

Ул килгәндә, агач баракка урнашкан контора яны машина белән тулган иде. Монда яңа чыккан озын торыклы «Волга»лар да, күпне

күргән зәңгәрле-яшелле «Победа»лар да, кечкенә, тупас борынлы «Москвич»лар да бар иде. Алар белән янәшәдә брезент түбәле «ГАЗ»-лар һәм фанер кабиналы йөк машиналары. Күренеп тора — болары инде контора һәм бригада транспорты.

Ишек алды, ишек төпләре шыгрым халык, коридорда кешеләрне ерып йөрерлек түгел.

Болай да кысан директор кабинетында таныш мастерлардан, начальниклардан, геологлардан тыш, район, өлкә житәкчеләренә, Уфа, Куйбышев, Баку вәкилләренә, хәтта Мәскәү галимнәренә һәм Нефть министрлыгы кешеләренә хәтле бар иде. Һәммәсенең диярлек кулында папирос, трубка, бөтенесенең телендә Чияле тау, Ромашкино, Миңлебай, Вәли хуторы...

Конференция башланганчы, стенаны инләп торган картага күз төшереп алды Зөбәеров. Геологик картага охшаган икән дип уйлады. Тик монда разведка чикләре шактый киңәйгән, бораулаunion скважиналар саны бермә-бер арткан иде. Картадагы кара сызык Чияле тау тирәсен генә түгел, Шөгер, Әлмәт, Бөгелмә тирәләрен әйләндереп ала, хәтта моннан йөз километрлар ары булган Ык һәм Чирмешән елгаларына кадәр барып житә иде. Нәрсә бу, монда жыелып килгән галимгоıләмәнең фантазиясеме, әллә контора, район житәкчеләренең хыялымы?

Чикләре зур булмаган нефтьле урынны геологлар чыганак диләр. Чыганаклар зуррак территорияне алып торсалар — нефть мәйданы була. Ә жир асты катламында нефть берничә урында мәйдан-мәйдан булып ята икән — ул инде нефть ятмасы.

Чияле тауда бораулаучылар нинди байлыкка юлыктылар, ниндирәк катлам ачтылар — чыганакмы ул, мәйданмы яисә зур бер ятмамы, табылган бу хәзинәнең запасы күпме, чикләре нинди — разведчиклар өчен әлегә бу билгесез табышмак иде.

Абруйлы нефть белгечләре, исемнәре илгә таралган галимнәр, министрлыктан килгән зур дәрәжәле кешеләр, Ромашкино — очраклы чыганак кына түгел, Ромашкино — зур бер нефть ятмасы, диделәр. Стенага эленгән картада төсле карандашлар белән ноктал ар куелган иде. Шул нокталарга төртә-төртә хыялланып киттеләр: Ромашкино академик Губкин теориясенә нигезләнгән Урал — Идел районының гигант «кара алтын» бассейны булырга тиеш икән.

Шунда ук яна бурычлар да куелды: Ромашкинодагы разведка-бораулау бригадалары санын арттырырга; Әлмәт, Баулы, Ютазы якларында яңа разведка-бораулау конторалары оештырырга; бригадаларны житәкче кадрлар, бораулаучылар һәм кирәкле техника белән тәэмин итәргә — шуның белән Татарстанда нефть эзләү эшләрен тулы куәтенә җәелдереп жибәрергә.

Әкият төсле иде болар.

«Аның тиз генә буласы юк әле, телдә, кәгазьдә генә калыр әле бу бурычлар»,— дип, башта ышанмыйчарак, шикләнебрәк йөргән иде Зөбәеров. Ләкин нефть кебек зур эштә шик-шөбһә белән озак йөрергә ирек бирмиләр. Аны конторага чакырып алдылар. Бу килүдә инде теге вакытта күргән зур кешеләрнең берсе дә юк, директор бүлмәсендә бары тик контораның үз кешеләре дә бригада житәкчеләре — мастерлар гына иде.

Контора директоры Иван Андреевич Никитин, беркайчан да тавышын күтәрми торган кеше, кыска гына итеп әйтте:

— Солдатсыз командир булып йөрү житәр, мастер. Син инде, егет, һавадан торна көтмә, кешеләрне үзең эзлә, тап һәм бораулый башла! — диде.

Каян табарга ул кешеләрне? Ничек бораулый башларга? Кемгә киңәш белән барырга?

Институтта чакта аның Ибраһим-Задәсе бар иде. Буровойга да орденын тагып килә торган шушы горур, таләпчән мастерда ул практика узган иде. Зөбәеров Мәскәүгә дипломякларга кайтып киткәндә Ибраһим-Задә озата килеп, вокзалда тост күтәреп әйтте: «Колагыңа киртләп куй, егет: мастер ул таудан биек, кыядан каты, диңгездәй киң колачлы булырга тиеш. Буровойдагы кешеләрең өйрәткәнне генә көтмәсеннәр, кушканны гына эшләмәсеннәр...»

«Таудан биек, кыядан каты, диңгездәй киң колачлы». Ничек шулай булмак кирәк?

Житмәсә, нефть чыкканын ишетеп, көн аралаш Бөгелмәдән Рәйсә килә. Килә дә итәккә диярлек тагылып йөри, бетмәс-төкәнмәс сораулары белән жанга тиеп бетә: «Ничек соң, Фазыл, нефть чыкты дисең, инде бергә яши башлыйбызмы? Квартир бирәләрме?»

Төрлечә боргаланырга туры килә Фазылга. Маңгаеннан тирләре бәреп чыга. Әйе, ди, нефть чыгуын чыкты, ди. Бик мул чыкты, ди. Тик бит әле эш болайрак тора... Син разведчик дип әйтәләр конторада... Разведчик булгач разведчик бул инде, диләр... Сәфәр чыгарга кушалар... Ни бит инде, Рәйсә, күбен көткәнне азын гына көтәрсең... Әнә, Карабаш якларын бераз гына сукалап кайтыйк та... Между прочим, Карабаш ул Бөгелмәгә дә бик якын икән... Ни барысы егерме километр гына... Жай чыкса атна саен кайтып йөрергә була. Әйе, әйе, хәтта көн аралаш! Түз инде...

Бичара Рәйсәнең күзеннән мөлдерәп яшь коелып төшә. Иренен тешләп баса да кайдадыр бер ноктага карап катып кала. «Юк икән безгә бергә торулар!» — ди...

Бик кыен хәлдә калган Зөбәеров Ибраһим-Задәгә телефоннан шалтыратып, нишлим икән? дип киңәш сорады.

— Бакуда минем дустым Әбүбәкер бар иде,— дип башлады сүзен Ибраһим-Задә.— Шул дустым олы улын өйләндерергә жыена. Килен сайлый, имеш. Малаен кызлар янына алып бара да тукмый, алып бара да тукмый. «Нигә кыйныйсың, абзый?»,— дип сорыйлар моннан кызлар. «Кушмасаң эшләми, каһәр»,— дип әйтә икән Әбүбәкер. «Кушмагач нигә эшләсен инде ул»,— диләр икән тегеләре. Болар яныннан китеп икенче төркем кызлар янында кыйный башлый икән малаен. «Нигә кыйныйсың, абзый?» «Менә кушканны гына эшли!» «Кушканны эшләгәч яхшы бит инде»,— диләр икән. Өченче төркем янына алып барып кыйный икән улын. «Нигә кыйныйсың?» «Кушканны гына эшли!» Арадан бер кыз чыга да: «Тагын да өстә, абзый, үзе белеп эшләсен!» — дип әйтә икән. «Менә шушысы булыр минем киленем»,— дигән Әбүбәкер.

«Өйрәткәнне көтмә, үзең белеп эшлә». Әнә шул үзең белеп эшләү иң авыры булып чыкты да шул. Зөбәеров иң беренче үз белдеге белән бригада жыярга тиеш булып чыкты.

Беренче кешене Зөбәеров юлда тапты. Буровойга кирәк-яраклар алу өчен Урал заводларының берсенә командировкага жибәрделәр аны. Поездда кайтканда Уфа тирәләрендә ул утырган купега сары бөдрә чәчле һәм чәченнән дә сарырак кашлы, таза гына бер моряк утырды. Кулында аның ике-өч китап сыярлык кечкенә чемоданы да бер гитарасы гына бар иде. Керү белән егет формасын салып тельняжкадан калды һәм чемоданын баш очына куеп урынына сузылып ятты.

Моңарчы шау-шулы юлчыларга очрап, йоклый алмый интеккән Зөбәеров тыныч кеше эләгүенә шатланырга да өлгермәде, әлеге моряк, чалкан яткан килеш генә гитара уйнап, жырлый башлады:

Очи черные,
Очи жгучие,
Очи карие...

Ярты төнгә кадәр бер үк чегән көен уйнап, күзләрнең ничә төрле булуын кабатлап, жанына тиде Зөбәеровның. Ахырда Зөбәеров түзмәде, торып тәмәке кабызды, тавышын тыя төшеп:

— Шулай ук шәп идемени соң күзләре? — диде.

Моряк кергәннән артык беркатлы икән. Шундук гитарасын кырыйга куйды да торып утырды:

— Күзләреме? Бик шәп! Тик белмим, карадырмы, сорыдырмы — әйтә алмыйм. Валя исемле ул. Рәсемен журналда күреп кенә танышкан идем, заочно,— дип сөйләп китте. Баш очыннан тиз генә чемоданын алып «Огонек» журналы чыгарды, аны актарып кыз рәсемен эзләп тапты һәм Зөбәеровка сузды.— Геолог ул, нефть эзләргә җибәргәннәр. Менә, ышанмасагыз, укып карагыз.

Егет үз хәләтен күптән берәү белән дә уртаклаша алмаган, күрәсең, танышмы, таныш түгелме, эч серләрен теләсә кемгә бушатырга әзер иде.

Зөбәеров морякның кәефен төшермәс өчен генә журналны алган булды.

Кыз чыннан да чибәр иде. Чәчен, модага туры китереп, купшы итеп күпертеп куйган, җиңелчә косынка бәйләгән. Күзләре гаҗәпләнеебрәк ачылган, зур, хәтта кирәгеннән артык зур. Кулында аның планшет, аркасында нефтьче геологларга хас булмаган рюкзак һәм иңенчесендә, ни өчендер, кәйлә дә бар иде. Күрәсең, фотографка эффект өчен шулай кирәк булгандыр.

— Ярыйсы,— дип, Зөбәеров журналны егеткә кире бирде.

— Янына дип кайткан идем, булмады, киткән...

— Кияүгәме?

— Юк, иженче урынга, эшкә.— Егет көрсенеп алды.

— Димәк, танышуың шуның кадәр генә булган,— диде Зөбәеров, үзе дә сизмәстән егетнең язмышы белән кызыксынып куйды.

— Мин дә гаепле түгел, ул да... Океанга йөзәргә чыгып киткән идек... Алты ай хат язып булмады...

— Ә хәзер нишләргә уйлыйсың?

— Белмим шул... Әллә кире китәргә инде...

— Кайтыр урының юкмыни?

— Беркемем дә юк шул. Әни белән энемне фашистлар үтергән, әти дә сугыштан кайтмады. Демобилизациядән соң, барыр урын булмагач, моторист булып сәүдә пароходына эшкә кергән идем... Валя белән танышмаган булсам, кайтасы да түгел идем, юкса...

— Әйе, брат, шәп килеп чыкмаган,— диде Зөбәеров, көрсенеп.— Шулай да хәзер кая барасың соң?

— Валяны эзләп карарга исәп... Татарстанда бик күп нефть тапканнар икән. Шунда киткәндер, диләр.

— Ай-һай, егет, романтика белән шөгыльләнмисең микән?

Бераз икесе дә тып-тын булып яттылар. «Бәлки, егет хаклыдыр,— дип уйлап куйды Зөбәеров.— Яхшы кыз, чын кеше булса, эзләп карау да урынлыдыр. Тик, белмим шул инде...»

Күңеленнән берәм-берәм Валя исемле кызларны үткәрә башлады Зөбәеров. Бәлки, кайда булса да күргәне бардыр бу егетнең Валясын? Зөбәеров белән институтны бетерде бер Валя — ләкин ул геолог түгел, инженер-экономистлар факультетын тәмамлады. Рәсеме дә аңа охшамаган. Бер Валя күптән түгел генә бораулау конторасына эшкә керде. Бухгалтер, бөтенләй рәсемдәге бу кызга тартым түгел. Әйе, Валялар дөньяда күп. Тагын бер Валя нефтьчеләр ашханәсендә эшли. Таныш геологлар арасында Валялар бөтенләй юк.

— Син, егет, Татарстанга барасың баруын да, анда бит Валяң юк,— диде Зөбәеров, морякның хәтерен-фәләнен саклап тормыйча. Егет сискәнеп аягына басты.

— Ә син каян беләсең?
— Шунда эшлим мин, нефтьтә.
— Чынмы? Кем булып?
— Бораулау мастеры.
— Бораулау мастеры?! Сезгә эшчеләр кирәкмиме?
— Әллә киләсеңме?
— Валяны тапсам! — диде егет һәм кинәт очына башлады. — Ул шунда! Һичшиксез шунда! — Зөбәеровка кирәк кадәр кулын сузды. — Валентин Валентинович булам. Тын океан морягы. Профессиям — моторист. Эчке янулы двигатель һәм пар машиналары буенча...
«Эчке янулы двигатель һәм пар машиналары»ннан да бигрәк, морякның «Валентин Валентинович» дип үз-үзен зурлап әйтүе кызык тоелды Зөбәеровка. Ни өчен бу егет Валентин яки Валя гына түгел, ә Валентин Валентинович ук?
— Алайса, безгә киттек, Валентин Валентинович,— диде мастер, соңгы сүзгә басым ясап.— Ә мин Фазыл Зөбәеров булам...
Валентинны Зөбәеров әнә шулай тапты һәм ул бригадада Валентин Валентинович булып түгел, ә исеменең яртысы кыскартылып «Тин-Тиныч» кына булып калды.
Икенче булып бригадага Кадермәт килде. Командировкадан кайтып төшүгә, ишек төбендә аны кара тут йөзле, чал чәчле, Чапайныкына охшатып җибәргән мыеклы бер кеше туктатты:
— Сез түгелме Зөбәеров? — диде ул, аның каршысына ук килеп.
— Мин.
— Сезгә эшкә кермәкче идем.
— Һөнәрегез? — диде Зөбәеров.
— Нефтьче,— диде мыеклы.
— Бораулаучы түгелме? — диде гаҗәпләнебрәк Зөбәеров.
— Техник.
— Тау техникы?! Соң бит сезгә мастер булып эшләргә мөмкин! — дип кычкырып җибәрде Зөбәеров.— Әйдәгез әле кадрлар бүлегенә, әйдәгез! — дип, килүченең җиңеннән тотып алды. Мыеклы каушап читкә тайпылды, баскыч болдырына сөялде.
— Юк инде. Бораулаучы да ярап тора миңа...
— Ошатсаң бик шәп соң! Үземә генә киләсең!
Шул арада тәрәзә ачып, Зөбәеровны дәшеп алдылар. «Мин хәзер чыгам»,— дип кереп китте мастер.
— Син, иптәш Зөбәеров, бу кеше тирәсеннән читтәрәк торсаң икән,— диде кадрлар бүлеге начальнигы.— Шикле бәндә... Арт ягы чиста түгел...
— Ничек? Төрмәдә булганмы әллә?
Кадрлар бүлеге начальнигы теш арасыннан сызгырып чыккан тавыш белән:
— Аннан да начаррак,— диде.
— Пленда мы?
— Син бала-чага булма, иптәш Зөбәеров,— дип чажгырды бүлек мөдире.— Син Иван Андреевичның үзенә кереп чык әле...
Бу «шикле бәндә» директорда булган икән инде. Иван Андреевич сүзнең кем турында барасын мастеры авыз ачу белән үк аңлап алды:
— Керде ул минем янга. Әйе, сөйләштек, документлары белән танышттык,— дип, тыныч кына сөйләп китте.— Принципта мин аны эшкә алуга каршы түгел. Безгә махсус белеме булган кешеләр кирәк, бик кирәк. Тик... нигә соң ул үзенең яшәгән, укыган җирендә — Бакуда эшләмәгән? Нигә Башкортстанда калмаган? Ниһаять, нигә махсус техник белеме була торып Куйбышев нефтьчеләрендә йөк ташучы

гына булып эшләгән? Менә нәрсәләр борчый мине! — Иван Андреевич кулындагы карандашы белән өстәл кага башлады.— Статьясы бит «кырык җиде». Аңлыйсынмы, «кырык җиде». Хезмәт дисциплинасын бозган өчен.

Директор яныннан чыкканда Зөбәеров бу «шикле бәндә»не алмаска дип ышанып чыккан иде инде. Әле һаман кызу кояш астында, ишек төбендә басып торган Кадермәт тә бер карау белән моны аңлады. Башта ук күренеп тора иде бит: секретаре кадрлар бүлегенә, кадрлар бүлеге директорга кертеп җибәрде, директор сүзен өзеп кенә әйтә алмыйча, Зөбәеровны котәргә кушты. Билгеле, Зөбәеров тагын нинди булса да сылтау табачак...

— Күренеп тора, мастер, сина минем турыда матур сүз әйтмәгәннәр,— диде Кадермәт, Зөбәеровның мин-минлегенә шактый кагылышлы итеп.

— Әйтмәделәр шул,— диде Зөбәеров, боргаланып тормыйча гына.— Документларын чиста түгел икән.

— Документларым чиста булса, мин сезгә ялынып та йөрмәс идем.

Кадермәтнең газаплы, йончыган йөзен күреп Зөбәеров та капылт кына китеп барырга кыймады, Кадермәт тә, нәрсәдер көткәндәй, һаман урыныннан кузгалмады.

— Нишләргә кала соң инде миңа? — диде ул, аптыраулы тавыш белән.— Сугышта мине фашист үтерә алмады. Ә хәзер тыныч заманда мангаема пуля җибәримме? Я, әйтегез әле, зинһар, нәрсә эшләргә миңа?

Зөбәеров папирос кабызды.

— Я, ярый, яз гаризаңны,— диде.— Сине үз өстемә алам.

Өченче кешене Зөбәеровка директор үзе тәкъдим итеп җибәргән иде. Өстенә бишмәт, аягына тула оек белән резин галош кигән Мотгәрәй исемле бу кешене беренче күрүдә үк өнәмәде Зөбәеров. Тәбәнәк гәүдәле, кыска аяклы, балан бәлеше кебек җәенке битле һәм балалар борыны кебек кечкенә борынлы бу егет цирктагы клоуннарны хәтерләтә иде. Карап торуга да чат авыл кешесе гомер буе промышленностьта эшләгән директорга кай җире белән ярагандыр, һич төшенә алмады Зөбәеров. Җитмәсә, гаризасына да «верховой» итеп алырга дип язган бит әле хуҗа.

— Вышканы күргәнең бармы? — диде Зөбәеров.

— Комбайнчы мин.

— Ни өчен колхоздан качтың? — дип, икенче соравын бирде мастер, «колхоз» сүзенә басым ясап.

Ни дип әйтергә дә белмичә бик озак азапланды егет. Кипшенгән иреннәрен бер ачты, бер япты, бер унга, бер сулга карады, пычрак галошлары белән идәндә таптанып торды.

— Сәлимгәрәйгә ачу итеп качтым,— диде аннан.

Кем ул Сәлимгәрәй, аңа нинди ачуы булган бу егетнең — тарихына кереп торуны кирәк дип санамады Зөбәеров, тотты да зәһәрләнеп гаризаның бер читенә: «Буровойны якыннан да күргәне юк», дип язып чыгарып җибәрде. Җитәр, берне алды — моряк булды, икенчене алды — гөнаһлы бәндә, өченчегә тагын буровойның нәрсә икәнен дә белмәгән крестьянны аласы юк. Ачуы бер килмәгәе, бораулау эше бит ул көрәк белән бәрәңге казу түгел.

Мотгәрәйне өч мәртәбә җибәрде директор — ужәтләнеп өч тапкырында да кире борды Зөбәеров. Әгәр дә Ибраһим-Задә яныннан кеше килмәгән булса, Зөбәеров Мотгәрәйне якын да җибәрми иде. Ибраһим-Задә шулай да яхшы кеше, бәхетсез шәкертен кызганган — ярдәм итим дип, вакытлыча гына булса да бер тәҗрибәле бораулаучысын, Зөбәеров өчен яхшы таныш Сергей Саакянны җибәргән.

Шуннан соң бригадага Мотгәрәй дә, Сапарбай да, алар кебек

нефть исе иснәп карамаган башкалар да сыйды. Асылда, Карабаш янындагы беренче скважинаны шушы барлы-юклы кешеләр белән башлап җибәрделәр дә.

Менә хәзер картада шул елларның авыр эзләре буйлап майлы таплар, карандаш белән төртеп, төрлечә кыландырып буяп куйган аерым билгеләр генә калган.

Кыен булды эшләве ул елларда. Бораулаучылар җитешмәү, тәҗрибә булмау өстенә торбалар, инструмент кытлыгы интектерде. Төрле милләт вәкилләре белән эшләү, төрле гореф-гадәт, төрле холыкның җанга тигән вакытлары аз булмады. Ялан кырда эшләү, чатырларда, кеше өсләрендә тору дисеңме, болай да мәшәкатьле, киеренке хезмәтнең ыгы-зыгылы, дәгъвалы яклары дисеңме — бу фани дөньяда әле барысы да кирәгеннән артык.

Кем белә, шушы скважинадан нефть чыкса, бәлки әнә ул Язтургай дигәннәре авыл булып кына калмас, шәһәр булып куяр, янындагы менә шушы куе урманы паркка әверелер...

Шулар турында уйлаган саен Зөбәеров авырлыкларны онытып җибәрә төсле, үзенең эше белән горурлану кичерә. Бөтен нәрсәнең башы шушы разведчиклардан башлана бит. Чыннан да разведчиклар килгәнче исеме-аты ишетелмәгән авыл яки кыр, тау, елга гына була. Менә разведчиклар килеп беренче чатырларын корып җибәрәләр. Нәкъ Чияле тау битендәге кебек, Карабаш әрәмәлегендәге кебек, Ык буендагы кебек, чатырлар янына беренче учаклар ягыла, беренче җыр җырлана, өшеп-туңып беренче төн куныла. Шуннан үтелгән беренче метрлар, беренче скважина — барысы да беренче. Таш йортлар, клублар, мәктәпләр... Карыйсың — биредә беренче яңа поселок, беренче шәһәр...

Ләкин аңа тикле бик-бик ерак иде әле.

## 4

Бик иртә, яктырыр-яктырмаста ук, Зөбәеров Тин-Тинычлар чатырына килеп керде.

— Торырга, җәмәгать! — дип кычкырды ул, йокысызлыктан карлыккан тавыш белән.

Одеял астында төрле-төрле кыяфәтләргә кереп яткан бораулаучылар караватларын шыгырдатып селкенеп куйдылар, кемдер мыгырданып алды, ләкин җәйге тәмле йокыдан уянучы булмады.

— Подъем! Подъем! — дип, Зөбәеров Тин-Тинычның аягыннан килеп тартты, аннан башын тезләре арасына ук куеп яткан Фәрхетдингә төртте:

— Подъем!

Фәрхетдин, йомран кебек, одеялы астыннан башын чыгарды:

— Ташла әле шул сүзеңне, мастер, армиядә старшинадан да туеп беткән идем инде!

Мышный-мышный Сапарбай торып утырды, күзләрен угалады да янадан мендәренә ауды.

— Нәрсә, Үскенбаев, йокы туймадымы?

— Туймады, Фазыл әкә.

Пружина кебек атылып, Валентин чәчрәп торды, ачу белән одеялын читкә атып бәрде:

— Син, мастер, бу Фәрхетдин дигән бәндәне я моннан күчер, я бөтенләй эштән ку!

— Нәрсә булды?

— Йокы бирми ул кешеләргә! Төн буе әллә нинди экиятләр сөйләп ята, иртән теләсәң нәрсә эшлә!

Фәрхетдин җавапка аптырамады:

— Сине кем мәҗбүр иткән? Колагына мендәр капла, я чүбек тыгып куй!

— Менә буровоенда йоклап йөрсәң, карарбыз әле! Әйдәгез зарядкага!

Нинди генә көн булмасын — суыкмы ул, яңгырмы, Валентин үзенең гадәттәге физзарядкасын калдырмый. Тельняшкасын салып чатыр алдына чыгып баса да тырышып-тырышып гимнастика ясый. Аннан суны башыннан биленә чаклы коеп, пошкыра-пошкыра юына, тәне кызарганчы сөлге белән ышкый.

Валентин бик кыстаса, кайсы көнне аңа ияреп Фәрхетдин дә физзарядкага чыккан була. Күз буяу өчен генә бер-ике мәртәбә сикергәләп, чүгеп ала, тирә-якка куллары, аяклары белән селтәнә дә өшеп калтыранып чатырга чабып керә, аннан соң күлмәген-чалбарын киеп, фуражкасын башына салып, юынырга чыгып китә.

Верховой Нәҗип үзенең зарядкасын ашка утын әзерләү белән аклаcа, Сапарбай исә «иртәнге уен» белән бөтенләй исәпләшми. «Минем зарядка буровойда,— ди ул.— Көн буена шундый итеп гимнастика ясыйсың — кайтканда кул-аякларны да күтәреп булмый». Юынганда да Сапарбай песи кебек бит очларын гына юа да күзләрен дымлы сөлге белән сөртә.

Тин-Тиныч вахтасы ашап-эчеп буровойга китеп барганда, чатырдагылар барысы да уянып, кайсы юынырга, кайсы зарядка ясарга чыкканнар иде инде.

Көндәгечә бөтенесен көлдереп, үзенең ике потлы герләре белән Геннадий Еланский чатыр тирәли чабып йөри, шәрә башыннан түбәтәен салып, Мотгәрәй кояшта кызынып утыра, кочагы белән чыбык-чабык күтәреп Кадермәт аш пешерергә әзерләнә. «Чатырлар авылында» чын-чыннан разведчиклар тормышы башланган.

— Хәерле юлга! Аягыгыз җиңел булсын! — дип кычкырды буровойга китүчеләр артыннан Кадермәт.

— Кара аны, завхоз иптәш, кайтуга мунча өлгерсен! — Бу мастер Зөбәеровның боерыгы иде.

— Мунча гына түгел, коймак та өлгерер!

Мунча дигәне Кадермәт «проекты» белән фронттагыча җиргә казып эшләнгән подвал сыман нәрсә иде. Аның стеналарын монда балта эшен белгән бердәнбер кеше «Мотгәрәй остадан» бураталар, сайгакларын һәм түшәмен йомры агачлардан Сергей белән Миргазиян җәя, ә мичен Кадермәт үзе чыгара иде. Балчык белән мунчаның түбәсен ябу, мунча ташы китерү эшләренә Еланский, Габбас кебек көчләрен кая куярга белми йөргән таза егетләрне кушалар иде.

Гомумән, разведкада егетләр җир мунча салырга да, бер-берсен себерке белән тукмый-тукмый чабарга да, җиренә җиткереп мунча керергә дә яхшы ук өйрәнеп киттеләр. Кадермәткә ияреп, аларның берсүзсез төзелешкә чыгып китүләре дә шул мунча ятуларыннан иде булса кирәк.

Җир мунчаны Мотгәрәй генә төземәде. Бура бурап бирергә карышмаса да, подвалга төшеп мунча керүне түбәнчелеккә санап, авылга китеп бара һәм шунда юынып кайта иде ул. Хәер, аның көтүдән аерылып йөргән мал кебек аралашмый яшәве бер бүген генә түгел иде инде...

Мунча өчен җир казу, агач хәзерләү, бура бурау эшләре якында гына ишетелеп торган буровой гөрелтесе белән бергә барды. Егетләр шаяртып сөйләнделәр: берьюлы Язтургайда ике объект салына — коммуналь мунча һәм девон скважинасы. Мунчачылар янына берничә мәртәбә Зөбәеров та килеп китте.— Мунчаны капитальный итеп салыгыз. Язтургайда җир каты. Буровойда нервлар таушалса, мунча кереп тынычландырырбыз,— диде.

Төшкә кадәр егетләр буровой тавышын тыңлап, шау-гөр килеп эшләделәр. Бер колагы белән Кадермәт егетләрне тыңласа, икенчесе белән скважина ягында булды. Менә анда шахта казылды, зыңлатып юнәлеш торбасы төшерделәр. Хәзер шурф борауларга җыеналар булса кирәк. Чү, нигә туктап калдылар әле? Ни өчен лебедка шауламый, нигә дизельләр тынды?

Кадермәтнең борчылуы юкка гына булмаган икән, берничә минуттан мунча салучылар янына Сапарбай йөгереп килде.

— Вышка ава, вышка! — дип кычкырды да яңадан буровойга чапты. Чатырлар янында берәү дә калмады.

Буровойда хәл мөшкел иде. Скважинага юнәлеш торбасын төшереп, шурф бораулауга керешү белән, буровой астында җир убыла башлаган, вышка аву куркынычы туган.

Зөбәеров, каушап, буровой вагонынннан килеп чыкты. Бригада аны көтә иде. Брезент киемле зур кара төркемне куркуга күңеленнән сызып узды: «Кеше кушканны көтмә». Бүген шушы кешеләр алдында ул я мастер булып кала, я разведкадан качып китә.

— Нишлибез, мастер? — Тин-Тиньчның шул сүзен генә көткән кебек, бораулаучылар кабынып китте:

— Булмый икән безгә яшәүләр!

— Төкерергә буровоена!

— Геологлар үзләре бораулассын!

Зөбәеров бригаданы юатып торуның мәгънәсезлеген аңлады, мәсьәләне бик кискен хәл итәргә кирәк иде.

— Нәрсә сарык көтүе кебек катып калдыгыз! — дип кычкырды ул. — Цемент кудырырга кирәк! Таш табарга, агач!! Вышка аусын дип көтәсезме?

Кара төркем тарала башлады. Дөпелдәп моторлар кабынды. Кешеләр урманнан агач төпләре, түмәркә, бүрәнә кисәкләре өстерәп чыктылар. Зөбәеров белән Кадермәт күлмәкләренә кадәр салып ташлап, бораулаучылар китергән нәрсәләрне җир упкынына тондыра тордылар. Ярты сәгать эчендә скважина бугазына өеме белән агач, йөге белән чыбык-чабык кереп бетте, буровой янында колонналар нығытырга дигән тау кадәр цемент бар иде — ул юкка чыкты. Ләкин хәвеф бетмәгән иде әле, контордан вәгъдә ителгән цементны әле һаман китереп җиткермиләр иде. Нишләргә? Урман кисәргә тотынсаң, кирәклесен ике-өч сәгатьсез дә өлгертеп булмаячак. Аңарчы скважина убылып төшсә? Менә кайчан бүтәннәр кушканны көтмичә, үз белдеге белән эшләр сәгать сукты. Зөбәеровның акылы гаҗәп бер киеренкелек белән эшли иде.

— Мунчаны сүтегез! Живо! — дип команда бирде ул.

Кадермәт манма су булган Зөбәеровка карап алды:

— Син нәрсә, мастер, безне мунчадан мәхрүм итмәкче буласыңмы?

— Мунча кайгысымыни әле монда?! — дип, Зөбәеров сүгенә язып калды. — Урман бетмәсә, мунча салыныр.

— Мичен үк чыгарган идек бит инде..

— Ташларын, кирпечләрен дә китерегез!

— Тфү, юлдан килеп юынырга да язмаган икән, — дип төкеренеп, авыз эченнән мыгырдана-мыгырдана, мунчаны сүтә башлады Кадермәт. Кызганыч, ләкин берни эшләр хәл юк... Менә шулай инде аларның бәхет яклары... Килеп утырмыйсың — буровой ава башлый, бораулларга тотынмыйсың — су бәреп чыга, скважинаң ишелә... Шунда Кадермәт Карабаш мәйданында катлам ишелеп, 1700 метр тирәнлектә кысылып калган инструментны искә төшерде. Ык буенда сиксән метр тирәнлектән фонтан урынына су бәреп чыккан скважинаны хәтеренә алды. Утыз градус салкында сифон астында калдылар. Бозлы су верховой сәндерәсенә кадәр күтәрелеп, кешеләрнең өсләренә явып торды. Бу адәм дигәнең чыдаса чыдый икән...

Зөбәеровның да хәләтен яхшы аңлый Кадермәт. Бу чуар халык белән эшләве җиңел түгел. Инде бу мәйданга килгәч яхшы гына алдырырбыз дип көткәннәр иде — мә сиңа!..

Кичкә таба таш, цемент төяп контордан машиналар килеп җитте. Ләкин мунчаны буровой йоткан иде инде. Өч машина агач, ике машина таш, әллә никадәр цемент китте, скважинаның бирән тамагы һаман туймый иде әле.

Кешеләр арыды, күлмәкләре манма су булып, тәннәренә ябышты. Ниһаять, кояш баеп килгәндә җир асты куышы томаланды, буровой нигезе ныгыды, вышка аву куркынычы бетте.

Иркен сулыш алып җибәрделәр.

Тин-Тинычларны алыштырып, Кадермәт бораууларга керешмәкче иде инде.

— Тукта әле, туган,— дип, Зөбәеров аның кулыннан тотты. Бик җитди буласы килә иде мастерның һәм шул ук вакытта ирен читендә елмаю, күзендә мутлык сизелеп тора иде.— Сабыр ит әле син, Кадермәт.

Нәрсә әйтер икән дип мастерга төбәлделәр.

— Ни өчен без буровойда гел җәфа чигәбез? Ни өчен дөнья безгә һәрвакыт тискәре ягы белән генә карап тора?

— Фәрештәләрнең йокысы туймаган сәгатьтә туганбыз,— дип, Фәрхетдин көлдерергә чамалады.

— Эх, син, тел бистәсе! Йолабыз юк безнең, логабыз! Менә нәрсә өчен нужа чигәбез без! Бар әле, Сапарбай белән минем чатырдан әрҗәләрне алып кил әле!

— Нишләмәкче буласың? — диде Кадермәт.

Ул арада бер әрҗә йомырка, бер әрҗә вино һәм бер янчык вак акча күтәреп Сапарбай белән Фәрхетдин килеп җиттеләр.

— Майна! Төшер инструментыңны! — дип команда бирде Зөбәеров.

Биш-алты метр бораулагач, мастер инструментны янә күтәрергә кушты, аннары бер уч акча, ике йомырка алып скважина янына килде.

— Бу йоланы Ибраһим-Задә эшли иде. Порт нык булсын дип борынгылар кирпечне йомырка белән ябыштырып салганнар. Хәерле юлга! — Зөбәеров нәрсәдер укыгандай итеп йомырка белән акчаларны чылтыратып скважинага төшереп җибәрде.

Мастердан соң бораулаучылар да берәм-берәм килеп скважинага акча салырга, йомырка ыргытырга керештеләр. Һәркем үз белгәнен әйтте. «Ватылмаска», «авариядә утырмаска», «интекмәскә». Фәрхетдин монда да Фәрхетдинлеген итте, йомыркаларны, акчаларны скважинага салгач, кулларын өскә күтәреп такмаклап китте:

— Әфсен, тәфсен, җитмеш җиде кат җир астына төшсен, тамугны тишсен, оҗмахка барып җитсен, шунда ватылсын, нефть булып атылсын!

Йоланың азагында әягүрә генә берәр стакан вино эчтеләр. Аңысы бораулаучыларга аеруча хуш килде.

## 5

Моннан да авыры юк иде Мотгәрәй өчен — күңеле буш, эч поша, кулга тотарлык эш кирәк. Уналты сәгатенең сигезен йоклап уздырса да, тагын шуның кадәр вакыт кала. Ашарга пешереп, кер юып янә берничә сәгатьне этеп-төртеп үткәреп җибәрә Мотгәрәй — алай да тик торуларның санына чыгарлык түгел. Урманга кереп тиктомалга сәгатьләр буена агачлар арасында буталып йөри, туйганчы җиләк ашый, Тин-Тинычка гөмбә җыя — ләкин әле һаман вахтага барыр вакыт

житми. Шуннан соң кайтып, чатырлар куләгәсенә барып утыра, тирәяктагы кырларны күзәтеп тәмәке пыскытырга керешә. «Бу буровой дигәннәре тоташ эшсезлек икән,— дип уйлый ул.— Мондый чиллэдә колхозчылар басудан кайтып керми бит»...

Урак өсте килеп житә башласа, Мотгәрәйнең шулай өянәге кузгала инде — ул ашамас, эчмәс, сөйләшмәс була. Ә инде кырда комбайннар тавышы да ишетелсә, тәмам йокысы кача, төннәрен кандала талаган кеше кебек борсаланып ята башлый. Әй сагындыра шул комбайн тырылдаулары. «Барып штурвал артына бер генә утырсаң иде дә күз күреме житмәс иген кырына чумсаң иде»,— дип уйлана ул. Булыр микән тагын шундый көннәр?

Язтургай мәйданына килеп урнашкан көннән бирле Мотгәрәй вахтадан соң әнә шулай үзен кая куярга белми йөри башлады. Кыш булса бер хәл иде, ул үзенә эш табар, кергән фатирында ишек алларын себереп, карын көрәп, я абзарларын тазартып булса да вакытын уздырыр иде. Ә монда бар белгәнең чатырда йокы симертү, я юкны бушка аударып йөрү. Шул да булдымы тормыш?!

Былтыр жәй дә Мотгәрәй, беркемгә дә әйтмичә, разведканы ташлап авылга кайтып китәргә дә жыенган иде, тик колхоз председателе Сәлимгәрәйгә уч итеп кенә калды. Эшли алмаган, куганнар дияр. Аннан буровойда кеше житмәү дә тотып калды бугай. Качса, Зөбәеровтан бигрәк, үзенең вахта башлыгы Сергей Саакяннан шүрләде. Гажәп кызу канлы әрмән. Эзләп артыңнан килер, «дезертир» дип авылдашларың алдында якаңнан сөйрәп алып китәр, оятка калдырыр...

Быел яздан бирле эленке-салынкы гына эшләп йөрүе дә Мотгәрәйнең китәргә ниятләвеннән иде. «Ялкаурак эшләсә, бәлки бригададан куарлар, разведкадан мәңгегә котылырмын»,— дип уйлаган иде ул, ләкин ничек кенә сүлпән эшләмәсен, уч иткәндәй, Мотгәрәйгә авыр сүз әйтүче булмады. Түзделәр... Әле һаман түзәләр... Ә кырда инде быел да комбайн жырлый башлады. Быел икмәк ничек икән? Яхшы чыга микән?

Мотгәрәй бер көнне иртүк торды да кунакка барырга жыенган шикелле яхшылап кырынды һәм Сагындык аръягына, комбайн тавышы ишетелгән якка китте.

Басуда бер генә комбайн эшли иде. Мотгәрәйгә бик тә таныш үзйөрешле «СК-4» зур әйләнеш ясап ары башка киткән, арыш арасында аның кабина башындагы ак түбәтәе — зонтигы гына күренеп тора иде.

Урып киткән жирне, төшерелгән саламнарны, камыл башларын караганнан соң, комбайнчысы тәжрибәсез икән, дигән нәтижәгә килде Мотгәрәй. Ә бит Мотгәрәйне: «Чәч алучы парикмахер белән бер»,— ди торганнар иде авылдашлары. Ул урып киткән жирдә камыл кыска, тигез булыр, төшерелгән салам да муенса кебек тезелеп калыр иде. Сыйфат тикшереп йөрүчеләр, ничаклы гына эзләнсәләр дә, жирдә бер генә кистерелгән башакны да таба алмыйлар иде. Мотгәрәй исеме ничә еллар колхозның Мактау тактасыннан төшмәде.

Ә монда? Монда Мотгәрәйнең исемен телгә алучы да юк. Хәтта начар бораулаучылар рәтенә дә кертмиләр. Яши шунда эт типкесендә...

Бил тиңентен салам күбәсенә чумып утырды да комбайнны көтеп алды Мотгәрәй. Комбайнчы чыннан да яшь, әле мыек та чыкмаган егет иде. Күрәсең, быел гына укып кайткандыр.

Мотгәрәй турына килеп житү белән, комбайнын туктатып, егет жиргә сикерде.

— Папиросың юкмы, абый? — диде ул, чая кыланырга тырышып.

— Әллә тарта да беләсең?

— Беләм! Ә син комбайн йөртә беләсеңме соң? — Егет үзенең һөнәре белән Мотгәрәйнең авызын томаламакчы иде, ахры. Ләкин шундый ук тон белән «беләм» дигән жаваптан соң уңайсызланып калды.

Мотгәрәй папиросы белән шырпы тартмасын салам өстенә куйды:

— Алайса менә нәрсә, син тарта тор, ә мин берәрне әйләнеп килим. Машинаны туктатып тору килешмәс...

— Пожалсты!

Комбайнның сиртмәле йомшак утыргычына утырып, штурвалга тотыну белән әйтеп бетергесез иркенлек биләп алды Мотгәрәйне. Тизлекне тоташтырып, педальгә басуга, аякларны чымырдатып, тәненә бер төрле рәхәтлек йөгерде — комбайн, чайкала-чайкала, әкрен генә урыныннан кузгалды, хедер канатларын җилпеп, алдына арышларны баш идерә башлады. Мотгәрәйнең мондый ләззәтне татымавына да инде, уйлап карасаң, өч ел тулып узды бит. Гомер дигәнең үтә дә үтә...

Авылыннан чыгып киткән көнне искә алмаска, онытырга тырышып карады Мотгәрәй — булдыра алмады. Күк айгыр булып килә иде аның күңеленә бу көн. Берничек тә түгел, яхшы тарантаска җигелгән, дугаларына кыңгырау тагылган, кызыл уралган күк юрга булып.

Мотгәрәйнең күрше авылда яратып йөргән кызы — Халидәсе бар иде. Җизнәләренә кунакка баргач таныште ул. Җор иде, телдәр иде, уңган иде кыз. Бер карауда теләсә кемне гашыйк итә, онытылмаслык, ташламаслык итә торган сихерләрне дә белә иде булса кирәк. Моңа кадәр бер кыз белән дә йөрмәгән, бер кызның кулын тотмаган Мотгәрәй Халидәне күрде дә капланды. Төрле йомышлар табып болар авылына Халидәсе килгән булып, апасын, җизнәсен күрергә Мотгәрәе барган булып, бер ел буена егет белән кыз очрашып йөрделәр. Халидәләрнең авылында аларның дуслыгына гаҗәпләнмәгән кеше калмады. «Идел камышы кебек кыз, авылда нинди асыл егетләр була торып, нәрсәсен охшаткандыр ул бүкәннең?» «Билгеле, егетнең җизнәсе председатель булгангадыр»,— дип нәтиҗә ясадылар аннан.

Чыннан да, авылда Халидә артыннан чабучылар күп иде, ул урамга яки клубка чыкса, Халидәгә сырышкан егетләрне куып бетерешле түгел иде — ләкин кыз, ни гаҗәп, аларның берсенә дә карамады. Инде Халидәләр өенә яучылар килеп йөри башлагач, Мотгәрәй түзмәде, бер көнне кызга тәкъдим ясады. Килештеләр. Кояш баегач, күк айгыр җигеп килеп алырга булды Мотгәрәй Халидәне.

Күк айгыр дигәне колхозда бердәнбер нәсел айгыры булып, ул идарә ишек алдындагы абзарда күз өстендә каш кебек сакланып кына асрала иде. Ара-тирә аны председатель Сәлимгәрәй районга барганда җиккәли дә колхозга килгән иң кадерле кунакларны озатып кую өчен генә файдалана. Председательдән башка айгырга тотынырга беркемнең бернинди хакы юк иде.

Ни өчен башка бер атны түгел, ни өчен нәкъ менә шул айгырны — председатель ялына ябышып яткан айгырны сорарга кирәк булгандыр, Мотгәрәй хәзер дә аптырый һәм үкенә. Бирмәде үзенең «күз өстендәге кашын» Сәлимгәрәй.

«Сине бик хөрмәт итәм, Мотгәрәй энем, син безнең иң алдынгы комбайнчыбыз да, ләкин бирә алмыйм айгырны,— диде ул башка сорарга урын калдырмаслык итеп.— Айгыр хәзер генә ерак юлдан — районнан кайтты, бирә алмыйм».

«Сәлимгәрәй абый, кыз алып кайту бит ул кешенең гомерендә бер генә килә, кызганма инде?»

«Булдыра алмыйм, энем. Айгыр минеке түгел, хөкүмәтнеке».

«Унбиш-егерме чакрым әйләнеп кайтканнан нәрсә була инде, Сәлимгәрәй абый?»

«Хатынымны сорасаң бирәм, ләкин айгырны бирмим, булмый!»

Председательнең йөзенә төкерергә дә башка ат җигеп чабарга гына булган Халидә янына. Тик ачу алданрак бит — Мотгәрәй шул төнне гарьлегеннән авылны ташлап чыгып китте.

Шул төнне Халидә, сандыгы өстенә утырып елый-елый, Мотгәрәйне көткән, ул килмәгәч, әнисе аркылы әйттереп, үзенә ячылап йөргән егетне чакырттырып китергән һәм хурлыгыннан ана кияүгә чыккан.

Купме җан газабы кичерде Мотгәрәй күк айгыр аркасында: туган җиреннән китте, сөекле Халидәсеннән колак какты, яраткан комбайныннан аерылды...

Җирне әйләнеп килгәндә комбайнчы егет салам өстенә ятып йоклап киткән иде. «Ярый, арыгандыр, уятмыйм, тагын берне уратып килим»,— дип уйлады Мотгәрәй, егет янынннан комбайнны әкренәйтеп, газны киметә төшеп кенә үтеп китте.

Икенче килгәндә дә яшь комбайнчы урыныннан тормаган иде. «Гамьсез егет икән, моннан комбайнчы чыкмый»,— дип фикер йөртте Мотгәрәй һәм ачу белән моторны юри гүләтеп узды. «Әйдә, тормаса тормас»...

Ары башка житкәндә үзенә каршы арыш арасыннан, яулык болгый-болгый, ашыгып килүче хатын-кызны күргәч, комбайнын туктатырга мәжбүр булды. Килүченең бер кулында чиләк, икенче кулында кызыл ашъяулыклы зур гына төенчек иде. Шул инде, пешекче, нәкъ Мотгәрәйләр колхозындагы кебек, комбайнчыга аш китерә.

— Камил, имансыз, нигә һаман ашарга килмисең? Әллә сиңа хезмәтче бармы монда! — дип, комбайнда кем утырганга да игътибар итмичә, тиргәнә иде пешекче хатын. Камил дигән сүзне дә «Кямил» дип, кызык кына авызын бөреп кычкыра иде.

Арышларны ярып комбайн турына килеп тә житте, Мотгәрәйне күреп катып та калды.

— Пәрәмәч, Камил дип торам! — Ул, аптырап, алъяпкычы белән авызын каплады.— Әллә үзен жен алыштырдымы соң?

— Әллә мин женгә охшаган? — дип көлде Мотгәрәй. Шунда ук тузан утырган маңгаен түбәтәе белән сөртеп алды.

Гажәпләнүнең чиге юк иде бу хатында. Комбайнның бер артына, бер алдына төште, каерылып-каерылып тирә-ягына карады.

— Әстагъфирулла! Кая килеп чыктым соң мин, саташкан? — дип, кире китә башлады. Мондый тамашаны күптәннән күргәне юк иде, күптән болай рәхәтләнеп көлгәне юк иде Мотгәрәйнең.

— Ашыкма, ашыкма! Утыр яныма, илтәм Камилең янына.

— Кайда соң ул? Чынлап әйтәсеңме?

— Бер минуттан кавышырсыз.

Пешекче хатын шикләнә-шикләнә генә кабина янына килде, башта төенен, аннан чиләген сузды. Ничек менәргә белми аптырап тора торган хатынга Мотгәрәй кулын бирде.

— Тизрәк, тизрәк!..

Итәген жыештыргалап азапланганда, Мотгәрәйнең көчле куллары бер секунд эчендә пешекче хатынны кабинага менгереп бастырды. Ләкин шул арада да Мотгәрәй аның йомры тез башларын күрергә, жылы йомшак кулларын тоярга өлгереп калды.

Комбайн белән урдырып барганда да ул үзе янына сыенып барган бу сөйкемле хатынга, аның кабина рамына чытырдап ябышкан симез кулларына, юан беләгенә күз төшереп алгалады.

— Камил дигәнең иреңме әллә? — дигән булды.

— И-и, Камил бала гына бит әле ул! — дип көлде хатын. Бераздан көрсенеп алды.— Минем ирем инде күптән Мәһди артында.

— Нәрсә соң ул «Мәһди арты»?

— Кайтмаска китә торган урын. Тик ходаем күрсәтмәсен инде ул көннәрне...

«Мәһди артының» болар авылында зират икәнен төшенгәч, Мотгәрәй хатынга тагын карап куйды. Шундый яшь, чибәр хатын ирсез калган...

— Нишләп үлде соң?

— Урман кисәргә барган иде. Агач баскан...

Хатын мөнаеп каршыдагы урманга карап тора башлады.

— Күптәнме? — диде тагын да кызыксына төшеп Мотгәрәй.

Ишетергә теләп ул хәтта комбайнны да әкренәйтте. Инде аның күзләре бу хатынның юан беләкләрендә дә, таза кулларында да түгел, урман ягында иде. Әйе, урман күңел ачу урыны гына түгел шул...

— Баласы да калдымы?

— Үзе үлгәндә юк иде. Күрә алмады... Хәзер кызыма ике яшь тулып килә инде...

Шуның белән сүз өзелде, алар егет яткан җиргә килеп җиттеләр. Камил дигәннәре әле урыныннан селкенеп тә карамаган иде.

— Нишләп ятасың, имансыз! — дип, егеткә тәрткәли башлады пешекче хатын.— Сине көтә-көтә аш суынып бетте бит инде!

Сәгатенә карап алды да Мотгәрәй китәргә ашыкты. «Комбайнның моторы әйбәт,— диде ул, күзләрен уып торган егет янына килеп.— Тик мотовилоңны карыйсың, чылбырларыңны майлыйсың бар, аннан хедерыңны аскарак төшереп көйләргә онытма! Юкса, арыш башларын кистерә...»

Мотгәрәй китә башлагач, егет тә сикереп торды, җиргә ашъяулык белән табын әзерләп маташкан пешекче хатын да аның артыннан ташланды:

— Кара инде, кая китәсез әзер табынны ташлап!

— Ашыгам, вахтага чыгасым бар.

— Юкны сөйләмәгез! — дип килеп ябышты пешекче Мотгәрәйнең җиңенә.— Бездә ашны ташлап китмиләр! Ул нинди эш?

— Юк, рәхмәт. Чынлап ашыгам.

— Тукта әле, кем соң син, кая ашыгасың?

— Иртәгә тагын килермен. Хушыгыз!

Йокыдан айныр-айнымас егеткә дә, кулына чүмеч, савыт тоткан пешекче хатынга да кырык төрле сорау калдырып, Мотгәрәй урман юлыннан буровойга кайтып китте.

*Дәвамы бар*

## Хәсән Туфан

### Кайтмый калган дуска

Таяндым да таныш талыңа,
Таңны көтәм, нидер уйланып...
Кояш түгел,
Таулар артыннан
Син чыгарсың кебек елмаеп,
Таянырга таныш талыңа.

Истә синең
Фида гомерең
Текә таулы кырыс юллары:
Милекләр дә сине, коммунар,
Тиеннәр дә кызыктырмады.
Истә синең якты гомерең.

Йолдыз идең юллар өстендә,
Идеал идең, тирән мәгънәдә.
Маяк булып калдың безгә син
Һәм бездән соң килгәннәргә дә,
Йолдыз булып юллар өстендә.

Яктыртасың әле
Син һаман
Заманалар аша илеңне,
Үзе инде сүнгән булса да,
Нуры калган йолдыз шикелле
Яктыртасың әле син һаман...

Ятсаң да син
Сугыш кырында,
Туган җирдән ерак кабердә,
Язылмаган уйларың, сердәш,
Яши һаман минем хәтердә,
Калсаң да син ерак кабердә.

И туган ил! — дигән идең син
Язмышларның кискен чорында,
Без егылсак, балалар калкыр

Аталарның изге юлында! —
И туган ил, диган идең син.

Без көймәдә йөрдек ул көнне
Кичке, җилле, моңсу Кабанда.
Күңел күзен төбәп еракка,
Безнең шаулы, даулы заманга,
Без көймәдә йөрдек ул көнне.

Һава үзе күренмәсә дә,
Сизәбез бит җилләр тавышын,
Җан да шулай
Сизгән, күрәсең,
Заманнарның ничек агышын,
Вакыт күзгә күренмәсә дә.

Күз салдык без
Шәфәкъ артында
Сузылып яткан ерак дөньяга...
Бәйрәм генә түгел, бәла да
Очрар бәлки кайбер юлларда:
Әзерләнә фюрер сугышка;

Диктаторлык культы терелә
Көнбатышта, Берлин астында,
Һәм Нерондай Бенито[1] Римда
Азатлыкны дарга астыра,
Көнбатышта культлар терелә.

Кем уйлаган әле ул чакта
Кирегә дә агар сулар дип,
Кытай халкы азатлыгыннан
Сары токым культы туар дип,
Кем уйлаган аны ул чакта.

Фикерләштек кичке җилләрдә
Безнең даулы дәвер турында.
Киңәш бирде интуиция
Һәр хәләткә әзер булырга.
Фикерләштек шулай үзара.

Туры килер, бәлки, безгә дә
Ил иделен йөзеп кичәргә.
Киемнәрнең кайберен, бәлки,
Яр буена куеп китәргә,
Туры килер, бәлки, безгә дә.

Җәяүлегә — янчык та авыр.
Лачын кошка — һава кадерле.
Җыендык без озын сәфәргә,
Утка ташлап кайбер әйберне:
Җәяүлегә — янчык та авыр.

. . . . . . . . . . . . . .
. . . . . . . . . . . . . .

[1] Италия фашизм башлыгы Б. Муссолини.

...Мәйданнарга чыккан идек без
Заманының кискен чорында,
Без егылсак, бәлки, балалар
Калкыр бит дип безнең урында,
Давылларга кергән идек без.

Өзелмәде ләкин безнең юл:
Тәркем-төркем дәвамнар килә,
Көне өчен түгел,
Иле өчен
Яши белгән яңалар килә,
Өзелмәде безнең изге юл!

Синең эздә — буш урыннар юк:
Анда җитди шонкарлар калка.
Көчле, дәртле, шигъри халыкның
Чын баласы булганнар калка,
Безнең юлда вакуумнар юк.

Таяндым да таныш талыңа,
Таңны көтәм, нидер уйланып...
Кояш түгел, офык артыннан
Син чыгарсың кебек елмаеп,
Таянырга таныш талыңа.

Уфлап куя талда
Язгы җил.
Күрсенә ул гүя син юкка.
Чүп үләннәр үсмәслек итеп
Җир әзерли иләң орлыкка,
Җир әзерли.

1962—72

## Әхмәт Исхак

### Рәхмәт җыры

Мең рәхмәт сиңа, чал Тормыш,
Әй, үлемсез остазым!
Әйтәбез моны сиңа без —
Үзем һәм кырыс сазым.

Өйрәттең армый, иренми,
Һәр минут биреп сабак.
Һәммәсен шуның бер җырда
Бетереп булмас санап...

Өйрәттең әле иләндә
Мүкәләр чагымда ук,
Тик тәпи басып йөрергә,
Китсәм дә егылып, авып.

Өйрәттең, татып булса да
Шелтәнең ачы тәмен,
Һәркемгә туры әйтергә
Яшерми күңелемдәген.

Өйрәттең сүзнең сибәргә
Җан-дуска ягымлысын,
Ахмакка — иң-иң усалын,
Дошманга — агулысын.

Өйрәттең туймый тыңларга
Бар моңын табигатьнең
Һәм тезеп шуны юлларга
Җырларга шигъриятен.

Өйрәттең хисен йөрәкнең
Күкрәккә бикләмәскә,
Сөюдә тугры булырга,
Нәфрәттә — чикләнмәскә.

Хупладың шашып хыялда
Күкләргә ашуларны,
Тыймадың шуклык, шаянлык
Һәм күңел ачуларны.

Дөньяда кем соң ялгышмый?!
Очратсаң шундый чагым,
Үпкәләр, дими, аямый
Укыттың арт сабагым.

Өйрәттең һаман атларга
Алгарак, ераккарак,
Адашсам, юлны табарга
Нинди йолдызга карап.

Өйрәттең тыйнак булырга,
Уңышлы чыкса эшем,
Канатны салындырмаска,
Җитмәгән чакта көчем.

Өйрәттең хак сүз каршында
Кашларны җыермаска,
Түзәргә, күрсәтми яшьне,
Сукканда язмыш башка...

Өйрәттең бик күп, бик күпкә,
Әй, тормыш, чал остазым!
Җырлыйбыз рәхмәт шуңа без —
Үзем һәм кырыс сазым...

1972

## Әхмәт Рәшитов

# Россия

Россия, мин — синең татар улың,
Мин — яраң да синең, дәваң да,
Яңа буыннарның башы да мин,
Үткән буыннарга дәвам да.

Урап кайтсам кайчак узганнарга,
Бу — кер эзләү түгел тарихтан;
Бары күңел бабайларның хәлен
Белер өчен шулай зарыккан.

Эзләмим мин аннан канлы эзләр,
Кынысыннан чыккан кылычны.
Бүгенгегә карыйм:
Уртак Ватан —
Советларның күге тынычмы?!

Дөнья булгач бар да булган инде —
Төйнәлгәндер байтак төеннәр,
Араларда кара мәче йөргән —
Дошман көлгән, дошман сөенгән.

Дошман сөйли кояш баткан якка
Карап безнең кылыч айкауны.
Ә мин телгә алам ике дусны —
Рус Пугачев, татар Канкайны.

Ә мин Пушкиннарны сагынып яшим.
Ирек җәлладлары кулыннан
Пуляларны үзем алып,
Аны
Аралыйсым килә үлемнән.

Ә мин таңнар саен курганнарда
Ил иреге өчен баш салган
Солдатларны санап өзгәләнәм:
Кайсы, кайчан?..
Кайсы яклардан?..

Безгә инде башка иман инде,
Безнең кыйбла — дуслык кояшы,
Коммунизм — безнең уртак язмыш,
Ленин — безгә уртак юлбашчы.

Алкынланып Идел аккан илдә
Төзибез без якты, яңаны.
Россия, мин — синең тугры улың —
Буыннарның яңа дәвамы.

1972

## Әхсән Баянов

### Хаталарым

Сан-исәпсез минем хаталар.
Хаталарым артка тарталар.
Кайчак уйлыйм: ник мин тугандыр,
Тууым да хата булгандыр...

Хаталарым — урман шикелле,
Куе урман аша үтелде.
Мең кугәрү йөртә тезләрем,
Ә йөзләрем — ботак эзләрен.

Биеклекләр, никтер, сөйгәнмен,
Малай чактан түли килгәнмен —
Азмы дисез егылып төшелгән,
Куллар тайган, башлар тишелгән!

Яшьлеккә дә күчкән шул гадәт:
Чибәрлеккә кылып гыйбадәт,
Азмы рәнҗетүгә түзгәнмен? —
Әле дә сулгып куя йөрәгем.

Ник җитмәгән шунда горурлык? —
Кителмәгән капыл борылып.
Яшьлегемнең иң ак көннәрен
Тиешсезгә шулай биргәнмен.

Ә тиешкә җылы чын сүзне
Әйтеп кенә йөргән дисезме?
Яшерә алмыйм инде мин сездән,
Чирләрем дә — үзем юньсездән...

Шул гаҗәп тик: күпме адашып,
Онтылмаган гомер максатым.
Тайпылмыйча дөрес юлымнан,
Шушы көнгә килеп чыгылган!

Акыл соңлап кергән өчен дә,
Кыяфәтем сүнгән өчен дә,
Утсыз янган-көйгән өчен дә,
Артык бирелеп сөйгән өчен дә —

Каеш чыжлап узса аркамнан,
Шикләнмәгез, җавап кайтармам.
Хали булырмын дип хатадан,
Шуннан соң да ләкин әйталмам,

Хаталар,
Әй, шул хаталар!

1971

## Мөдәррис Әгъләмов

# «Хәерле юл сузгә»

Казанымнан автомашинада
Китеп барам. Чагылып кала күзгә
Ерак юлга китүчеләр өчен
Язып куйган: «Хәерле юл сезгә».

...Сары чәчен иңнәремә салып
Назлы кызлар сыман минем тездә
Көз утыра. Уйланулар чәчеп
Ул да китәр: «Хәерле юл көзгә».

Ә без һаман юлда, сәяхәттә.
Ил юлында кала безнең эзләр —
Энә шулай бер китәрбез дә без
Һәм кайтмабыз,
Тол калырлар көзләр.

Тол калырлар җәйләр, кышлар, язлар,
Без үтелгән юллар тол калырлар...
Ил уллары хезмәтләрен илгә
Бирерләр дә
Китеп югалырлар.

Кайтыр алар тугры Тукай булып,
Я кызыллык булып гамьсез йөзгә...
Шуңа бүген минем күкрәгемдә
Теләкнамә: «ХӘЕРЛЕ ЮЛ СҮЗГӘ».

Сүзләрең хак,
кыска булган чакта
Гомерең озын, барыр юлың озын...
Киләчәккә карап китеп барам,
Без барасы офык: КОММУНИЗМ.

Әйтер сүзләр безнең тузга язган,
Безнең йөрәк әйтерсең лә туздан,
Бөгәрләнеп кысыла, шундый кызган,
Гомере учак тирәсендә узган.

Көн килер дә йолдыз атылгандай
Күкрәк читлегеннән аерылыр ул.
Һәм яңгырау кайтыр еллар кичеп.
Бер яңгырау кайтыр: «ХӘЕРЛЕ ЮЛ...»

Озатырлар автомашинада,
Я күтәргән хәлдә,
яки атта...

Тузга язган сүзләр генә калыр —
Дөрес сүзләр генә, безнең хакта.

Ерак әле аңа, канатларың
Әллә ничә тапкыр каерылыр...
«Хәерле юл» бөтен хәр акылга,
Тузга язган сүзгә хәерле юл!

1972

## Галимҗан Латыйп

●

Ничәнче тапкыр аламдыр
Җырларын аның кулга.
Укыган саен ачыла,
Мин әле һаман юлда.

Мәңгелек чишмә шикелле,
Бетми дә,
Саекмый да.
Иң затлы шәраб эчкән күк,
Исертми, айнытмый да.

Әй гаҗәп Шираз даласы,
Гөлләре, елгалары.
Әй минем Шаһнәм, диеп,
Егетнең җырлаганы.

Һәр юлы,
Өтер, ноктасы
Гел үзенчә бит аның.
Укы да,
Оныт дөньяңны
Рәхәтлән, әйдә, җаным.

Россия дисәм,
Алдыма
Килә дә баса үзе.
Каен тәлгәшедәй чәчләр,
Күк төсле зәңгәр күзе.

Язса да язар икән лә,
Әйтсә дә әйтер икән.
Милләтне милләт итәргә
Шундыйлар — үзе җиткән.

1971

Мәҗит Рәфыйков

# РӘХМИЧ

хикәя



Безнең Рәхмәтулла абзый да Бөек Ватан сугышында катнашкан икән ләбаса. Миннән сорасалар, юктыр, эләкмәгәндер, авыруы белән алмаганнардыр, дигән булыр идем.

Менә инде кешенең хикмәтле язмышын әйт тә, тыйнаклыгын әйт... Ә бит ул миңа авылдаш кына түгел, урамдаш та, күрше дә. Аның өе минем нигездән ике өй аркылы гына бит.

Мин дә сугышта булдым, аннары читтә укып йөрдем, читтә яшим, шуңа күрә белеп җиткермәгәнмен, дияр идем, ике-өч елга бер булса да кайткалап, авылдашларның хәл-әхвәлләрен сорашып, язмышларын белешеп торам. Рәхмәтулла абзый белән күрешкән саен, мин сүз башлап та өлгермим, ул инде ачылып китеп, бар белгәнен әйтеп салырга әзер. Ә үзе минем күздә һаман да шул Ватан сугышына кадәрге авыл кибетчесе булып кала бирә... Баксаң, аның Будапешттан җиңүче булып кайтуына инде чирек гасыр узып та киткән!

Гомере буе саулыкка туймас, бөтен барлыгы, торышы-кыяфәте белән сыек кына, сырхау гына бер кеше инде ул. Зур баш, нечкә муен, тар җилкә, урта буй, очлы терсәк, нечкә сыйрак, җилгә җилтерәп йөри торган сөякчел юка гәүдә... Яңагы яңагына ябышкан, зур күзләре өч бөртек каш астыннан тирәннән карыйлар, зур авыз, зур борын тирәсе җыерчыклары тимер тырма теше белән сызылганнар диярсең. Ике бите дә кан бәреп алсуланып тормый, әлеге теге кабыгы әрчелмәгән ак бәрәңге төслерәк... Әмма Рәхмәтулла абзаң борын астында кадерләп кенә бер чеметем юка гына коңгырт мыек кисәге үстереп йөри һәм ирлек галәмәтенең менә шушы кечкенә бер билгесе аның зур авызлы, зур борынлы битен ачып, яктыртып җибәрә,

сабыр, уйчан күз карашларына, бөтен чыраена акыллылык, эчке бер җыйнаклык, интеллигентлык төсмерләре өсти.

Безнең Җидеболак Күгәрчененең Батыршиннар нәселе сәламәтлек җәһәтеннән буын-буыннан шулай сыеграк, куәтсезрәк булган инде алар. Нәсел җепләре, әнә өзеләм, менә киселәм, дигән кебек, чак-чак кына ялгангалап килгән. Теге йөзәр яшәүчән, гаилә саен диярлек таза-таза алтышар-җидешәр ир бала үстерүчән Вәһаповлар, Халитовлар, Мәннаповлар белән тиңләп булмый. Рәхмәтулла абзыйның да фамилиясе генә Батыршин. Атасы Габделгани, авылча әйтсәк, тегүче Әпти була инде — Батырша оныгы Габделмоталлапның үги улы гына булган икән ул. Үз балалары булмаган да бугай әле ул Габделмоталлапның. Зирекледән димләтеп бер тол хатын алган да, Габделгани шул толның элекке иреннән калган улы ул, диләр. Тегү һөнәренә дә атасы мөрхүмнән күрмәкче генә керешеп киткән булса кирәк, югыйсә, безнең авылда элек һөнәр иясе тегүчеләр бөтенләй булмаган да әле, әбиләр нәрсә кисеп, нәрсә тексә, шуны кия биргәннәр — бүгенге авылның модалы киемнәре безнең әби-бабайларның төшенә дә кермәгән... Габделгани чалбар, казаки теккән, әдрәстән укалы ясап, камзул булдырган, биегәндә ике итәге ике якка күбәләк канатыдай ачылып китә торган итеп. Үзе Батыршиннарга ят нәселдән килеп керсә дә, буйга-сынга әллә кем түгел, өтек кенә булган, ул тегүче Әпти. Әмма дә вакчыл, дуамал кызу канлы булган, диләр аны. Таза бәдәнле хатыны Бәдиголҗамалын тимер аршыны белән кыйныйм дисә, сәке йөзлегенә менеп басмыйча буе җитми икән, дип көлгәннәр үзеннән.

Рәхмәтулла абзый, күрәсең, әнисенә тартып кына бераз буй сузган... Үзе шулай какча гына, сырхау гына булса да, гомере буе үз эшен кешегә бирмәс, һәр эшен рәтләп кенә, тәмләп кенә эшләр кеше ул. Кычкырып сүз әйтмәс, әмма үзенекен әйтми дә куймас, дөрләп-кабынып китмәс, әмма сүнеп-сүрелеп тә калмас, әлеге әкрен барып ерак китә торган бер җайга кыймылдый торган кеше булып чыкты ул.

Без малай чакларда ул еллар буе авыл уртасында, мәктәп тыкрыгы каршындагы кооператив кибетендә «керәчин», «лампачи», итек, чалгы сатып, тире, йомырка, йон җыйган чакларында да шул иде, инде менә сигезенче дистәгә аяк басты — һаман да шул!

Әле Ватан сугышы алдыннанрак та, хәтеремдә, әни мәрхүмә белән яңа магазинга бер барып кергән идек. Магазин зур, эче-тышы ап-ак, баскыч басмалары сап-сары итеп юылган, ике якка ачылмалы ишекләре пыялалы, тәрәзәсе киң, якты, киштәләрдә, шүрлекләрдә — элеп куелган пальто, күлмәк, тезеп куелган туфли, кепка. Өстәлдәге пыялалы киң рам астындагы ялтыр язулы-бизәкле хушбуй,ислемай, исле сабын, брошка-фәләннәрне күрсәң, исереп китеп, бу дөнья бик матур бәйрәм генә икән, дип уйларлык...

Магазин эчен уратып суктырылган киң өстәл белән шүрлек-киштәләр арасында, авырсынгандай гына, Рәхмәтулла абзый йөренеп тора. Аксыл чырайлы, моңсу-сабыр карашлы. Башында яңа кара кепкасы, өстендә шәһәрчә тегелгән килешле костюм. Үзе ул болай бер дә ни җитте түгел, авылның «урында эшләүче» кешеләреннән калышмыйча купшы киенүчән,— аягында да ялтыр кунычлы, ялтыр галошлы хром итек икәнен бөтен авыл белеп тора. Үзе магазинга килеп керүче әби-бабаймы, абзый-түтәйме, яшь-җилкенчәкме, бала-чагамы — һәркайсын үз итеп, тыныч кына, йомшак кына, бер дә ашыкмыйча-юмакайланмыйча, нәкъ кешенең йомышынча гына сөйләшә-сөйләшә булган әйберләрен салмак кына хәрәкәт белән бер алып, бер салып күрсәтә-күрсәтә сата да сата,— аңа һич бер үпкә-

җәбер белдерүче юк, кире килеп, бәла салып, тавыш чыгарып йөрүче юк, кыек-мыек эше булмас, җәен-кышын шулай эшли бирде. Башын алга салыбрак, ашыкмыйча гына урамнан узганда да авылны аламаландырмады, үзенә күрә моңсу бер ямь биреп уза иде ул.

Кибеттә кеше сыегаеп, әни белән күршеләрчә саулык-сәламәтлек сорашкач, ул әнигә, саусызлыгына зарланып: — «Менә бит инде, бер тамчы кан юк...» — дип, сөякчел ак кулының баш бармак итләшкәсен уып күрсәтеп торганы әле булса күз алдымда.

Миңлебану түтәй белән Рәхмәтулла абзыйның балалары булмады. Аларның тыкрык башын уратып алган биек читән коймалары эченнән гомер буе бала-чага чыр-чуы ишетелмәде, «урыс капка»ларыннан керүче сирәк булды, чыгучы сирәк булды. Маһирә түтәйләрнең гөрләп-шаулап торган җиде балалы йортлары янәшәсендә Миңлебану түтәй өе кайчакларны ничектер җансыз-терексез, хәтта бераз гына шомлы да кебек тоелып куя иде.

Хәзер дә шулай. Хәзер дә алар икәү генә.

Миңлебану түтәй буе-сыны, төсе-бите белән матур түтәй иде. Әле Ватан сугышы алдыннан гына да капка артларындагы урам коесына ак чиләген тотып чыкканда кызларча көчле, җитез, җиңел күренә иде. Соңрак мин аны күргәнем дә юк. Шул көе генә кинәт сулып, шиңеп киткәндер дә «әни», «әби» дип килүчеләрен көтмичә генә картлыгын кичерәдер.

Әмма Рәхмәтулла абзый барыбер авылның хөрмәтле кешеләре рәтендә булды. Өске урамнан су буена төшә торган тыкрык кем тыкрыгы, дисәң, ветеринар Хөснулла абзыйлар тыкрыгы түгел, Рәхмәтулла абзыйлар тыкрыгы. Чөнки Хөснулла абзыйлар өе тәбәнәк тә, салам түбәле дә, ә Рәхмәтулла абзыйлар өенең калку кызыл калай түбәсе безнең тоташы белән салам түбәле очка ямь биреп тора торган иде... Олы юл күпер башындагы куе ябалдашлы өянкеләр кем өянкеләре дисәң, алар да Рәхмәтулла абзый өянкеләре. Ул әле егерме дүртенче елны — кәләш әйттереп, туй туйлагачрак буладыр инде — үзләренең капка каршындагы күпернең өске як кара-каршы ике яр башына алтышар-җидешәр яшь тал чыбыгы төртеп, киртәләп алган. Менә хәзер шулар, барысы бер туганнар кебек, тезелешеп, җилләргә җилфердәп, олы юлга, безнең урамга, бөтен тирә-якка ямь биреп утыралар. Ишелеп-тармакланып киткән тирән тамырлары белән яр башы туфрагын учлап тотып алганнар — нинди генә шашкын ташулар бәрмәсен, нинди генә калын бозлар какмасын,— кара яр туфрагының бер бөртеген ычкындырмыйча, күперне, олы юл өстен саклап торалар.

Авыл агайлары Рәхмәтулла абзыйны үз күреп, бераз гына ихтирам сиздереп, исеменә русча рәсми олылау галәмәте дә өстәп, Рәхмич дип йөрттеләр. Хәзер генә ул күпләр өчен Рәхмәтулла абзый булып кала бара — өлкәнәю хикмәте...

Үзе ул чыннан да нечкә күңелле, моңлы кеше булды булса кирәк.

Колхозлар көчәеп, куәт алып киткән бер елларны авылда күпләр шәһәрчә тегелгән пальто, костюм, яхшы бүрек алып кия башлады. Кайбер ишек алларында зур-зур челтәр тәгәрмәчле, озын сыйрак, нечкә умырткалы «лисапит»ләр күренә башлады, менә кайберәүләр, шуңа атланып, урам уртасыннан бәйге атларыннан тизрәк узып китә башладылар, утыз биш километр ара узып, район үзәге Мракка барып йөрделәр, минем эти исә үзенең «Фрунзе» маркалы велосипеды белән картлар исәбенчә йөз илле чакрымда ятка Оренбургка да барып әйләнгәли иде. Колхозларның күзгә күренеп баеган, колхозчы күңеленең шатланып янарган чаклары...

Менә шул чакларда Рәхмәтулла абзый безнең Күгәрчендә бердәнбер кеше булып граммофон алып җибәрде. Күктән иңгән бер могҗизадай булды ул граммофон авыл өчен.

Җәйге озын көннең кайнар кояшы еракта, Олы Әйек аръякларында күкшелләнеп яткан Саньяп таулары артына тәгәри барып, тәгәри барып баеп китәр вакытларда, безнең күпер башы өянке ябалдашлары, Уен тавы түбәләре шул кояшка алсуланып торганда, без малай-шалай өй арты бакчасы түтәлләренә йөгерә-йөгерә су сибеп бетереп, кыр эшләреннән кайткан әти-абыйлар тирләп керләнгән тәннәрен, билдән болай чишенеп, пошкыра-пошкыра юынганда аларга комганнан су салып торган чакларда, әниләр, кичке ашларны өлгертеп, табын җыяр алдыннан чиләген күбекләндереп сыер савып утырган матур, моңсу бер сәгатьтә Рәхмәтулла абзый үзләренең кыйблага, Өске урам ягына караган түр тәрәзәсен ачып җибәрә, граммофонын, лалә чәчәгенә охшаш киң авызлы ялтыр торбасын тышкы якка каратып утырта да, безнең бөтен түбән очларны моң дәрьясына салып, пластинка артыннан пластинка уйната торган булып китте.

Үзе шулчак нинди татлы уйлар уйлап, кемнәрен юксынгандыр, хыялында кемнең кайнар күңеленә сыенып, бәхет, ләззәт эстәгәндер — анысын инде кем белсен! Әмма «Сакмар су», «Җәйләүләргә бардым», «Кара да гына урман», «Ике егет мылтык әрчи», «Безнең колхозның кызлары», «Бәдрә таллар»ы белән кемнәрнең күңелендә нинди генә якты хыяллар, нинди генә кайнар хис талпынышлары уятмагандыр...

Кайбер кичләрне минем, Мәһирә түтәйнең Хәкиме белән алар ишек алдында уйнап йөргән җирдән, Рәхмәтулла абзыйлар тәрәзәсеннән моң яңгырагач та, атылып барып, граммофонлы тәрәзә төбендәге киртәгә ябышып, бар дөньяны онытып, тын да алмыйча йотылып тыңлап торган кадерле минутларым бар иде.

Ул җырларны хәзер дә яратып тыңлыйм. Аларны һәр җырчы үзенчәрәк башкара. Ә минем күңелдә алар әле дә шул Рәхмәтулла абзыйның ялтыр торбалы граммофоннан ишеткәнчә яңгырый бирәләр.

Узган җәйне генә Күгәрченгә кайтып, күтмәгәндә бер ачылып, сөйләшеп китмәсәк, Рәхмәтулла абзый минем күз алдымда һаман шул бала-чагасыз, чыр-чусыз өйле, күпер башы өянкеле, тәрәзәсе граммофонлы кибетче Рәхмич көе генә каласы икән...

Бер көнне шулай авыл гизеп, коеп узган яшенле яңгырдан соң лычкылдап яткан пычрак урамнан тая-тая, түбән очка кайтып килсәм, «урыс капка»лары төбендәге тәбәнәк түмәр кисәгендә, ялгызы моңаеп, Рәхмәтулла абзый утыра. Өске урамнан төшкән тыкрыкның югары ягында ни элекке салам түбәле тәбәнәк өйләр, абзар-куралар, бәрәңге бакчалары, яшел мәчет юк — алар урынын зур бер квартал булып, бакчалы-гаражлы урта мәктәп шәһәрчеге биләп алган, Рәхмәтулла абзыйларның элек калку күренгән кызыл түбәле өйләре әле дә шул ук, тик ул алты почмаклап, верандалап, кызыл калай, яки көлсу-аксыл шифер белән ябылган, бизәүле-буяулы якты яңа өйләр янында үзе үк югалып, мескенәеп калган. Күпер башындагы өянкеләре генә ботак-тармакларын тагы да куертып, тагы да мәһабәтрәк булып киткәннәр.

Сәлам бирештек, сүз ялганды. Мин гәпне, үзем дә абайламастан, Ватан сугышы ягына бордым да, шунда ук сагаеп, уңайсызланып та калдым: абзыйның күңеле калмагае тагы, бу сырхау кеше сугышка алынмый калган булса, аның ни гаебе?..

Менә бит бер вакытны Рәхмәтулла абыкаем җиңелчә генә елмаеп: «Һи!..— дигәндәй итте дә, әлеге кычкырып-шаулап сүз әйтмәс, әмма үзенекен әйтми дә калмас басынкы тавышы белән кыска гына, хикмәтле генә итеп сөйләп тә салды:

— Күрелде инде ул сугыш хәлләре... Ай-яй!.. Курский дугада сыерсыз калганыем... Венгриядә, Сөхешфехерварда, анадан тума өс-баш киемсез калдым... Менә бүген шушылай, аллага шөкер, исән-сау дигәндәй, үз капкам төбендә утырам әле...

Мин тиз генә аның өс-башына карап алдым. Башында эшләпәсе, аягында туфлисе, пиджак-чалбарлары да болай чиста-пөхтә генә. Бите шул ук кабыгы әрчелмәгән ак бәрәңге төсле, җыерчыклары гына тирәнәя төшкән. Мин аның хикмәтле сүзләренең табышмагына чумып тын калдым, ул бераз вакыт шушы хәлнең ләззәтен тәмләп сүзсез утырды.

— Артиллерийский взводта установщик ыем,— дип дәвам итте ул.— Противотанковыйда. Нинди снаряд белән атарга, шуны билгеләп биреп өлгереп тор. Бронебойныймы анда, осколочныймы, подкалиберныймы. Йөз дә илле ике миллиметровый орудийный расчет. Командир белән тугыз кеше без... Ул Курский дугадагы хәлләргә... тимер чыдамый, кеше ничек чыдаган?.. «Огонь!» дә «огонь!» «Огонь!» дә «огонь!»... Кая дистә, йөзәрләп өскә килә танклары. «Тигр»лары алдан... Прямуй наводка белән бәрәбез — өлгер генә! Берсе янса, ике ягыннан бүтәннәре килеп чыга. И киләләр, и атабыз... Ут та төтен эчендә калдык... Колак ишетми, күзне әчеттерә... Уңга да борып: «Прицел! Огонь!» сулга да... Ну, мин әйтәм, бу мәхшәрдән сау гына чыксам, Күгәрченгә кайткач, Мүкләкне егып суярыем да итен авылга өләшерием.. Иптәшләр берсе егылып җан бирә, берсе ыңгырашып су сорый. Бер вакыт орудиебез ватылды — турыдан атып эштән чыгардылар... күрше расчет егетләренә барып кушылдым... Менә мондагы җөйләр шуннан җыеп алып кайткан җәрәхәтләрнеке ул... Командирыбыз да шунда харап булды, бахыр. Яшь кенә рус егете иде, Рязань ягыннан... Тугыз кешедән берүзем калдым шул Курский дугада. «За отвагу» бирделәр...

Ул сөйләсә — сүзен, сүздән туктаса — көрсенүен тыңлап утырам.

— Аннан соң да күп хәтәрләр күрелде,— диде ул.— Кемгә ничек туры килгәндер, миңа, дисәң, иң яманы шул Сөхешфехерварда булды инде. Анда да шул тизрәк атабыз да атабыз, үзебез кырылып бетеп барабыз... Куй! Шунда янә үземә телем белән әйттем: «Ай,— мин әйтәм,— шушы утлардан башым сау кайтса, өстемдәге шушы киемнәрне анадан тума калып өләшеп бетерер ием...»

Кырык биштә кайтып кергәч сыерны суеп, итен алтмыш кешегә өләштем. Сугыш күреп кайткан гимнастерка-чалбарны, тузанынсөремен кагып, синең зуратаң тау башы Сәйфетдин картка апменеп бирдем. Шинельне Әпҗәлил картка илттем, күлмәк-ыштанын юдырып Сәгадәт хәлфәгә, аяктагы ботинканы обмоткасы белән — Гайнетдин картка...

Күрәм, Рәхмәтулла абзый бу турыда хикәясен шуның белән түгәрәкләде: сүзен өзеп, тынып калды.

Янымда утырган шушы зур башлы, нечкә муенлы, елмаерга торган зур авызлы күршем Рәхмәтулла абзыйны кинәт ут-төтен эчендә, үлеп яткан иптәшләре арасында кара тәреле «тигр»ларны күрәкүрә, туп янында кайнашкан килеш, батыр килеш күз алдыма китерәсем килде. «Рәхмич-солдат» дип бер язып чыгасы килеп китте. Их, мин әйтәм, берәр батырлык эпизодын чынлап торып сөйләп бирсәме...

Кая ул! Рәхмәтулла абзый булсын да, урамга карап, авызын ачып, тел болгап, мин кырдым да, мин кудым, дип сүз сөйләп утырсын, имеш...

Ә бит чынлыкта исә кырган да, куган да, җиңеп тә кайткан. Өсләренә «тигр»лар килгән, күрәләтә төзәп атканнар. Снаряд тиеп, туплары эштән чыга, сигез иптәше һәлак була — шунда ул акырып, чатыр чабып качмаган, акылын-сабырлыгын җуймаган, йөгерек Җидеболак суы буендагы авылын күңеленә алып, назерен генә әйткән...

Батырлыктырмы бу, юктырмы...

Солдат булыр өчен туганмы ул дөньяга?

Илгә афәт килеп, башына төшкәч, сынатмавы өчен мең рәхмәт.

Мин аны барыбер сөйләтергә тырышам: «— ...кыюлык, тәвәккәллек бик кирәк минутлар булгандыр, Рәхмәтулла абзый»,— дип, уңнан да, сулдан да килеп карыйм — юк кына... Башын иеп, капка алдыннан узган кое сукмагына карап, әллә кайларда калган сугышта күргән-кичергәннәрен яңадан күреп-кичереп утыра — сүзе генә юк...

Ахры, мин өзми куймасны сизептерме, түмәрдән әкрен генә торды да кече капкадан өйләренә кереп китте, бераздан әйләнеп тә чыкты. Кулы буш түгел.

Берәм-берәм тезләремә җәеп, Рәхмәтулла абзыйга Ватан сугышы елларында авылда чагында тырыш хезмәте өчен, аннары төрле фронтларда күрсәткән батырлыклары өчен бирелгән медальләрен, бүләкләү таныклыкларын карап утырам. Командование исеменнән «...123 нче артиллерийский противотанковый полк рядовое Батыршин Рәхмәтулла Габделгани улына...» бирелгән рәхмәт кәгазьләре үзләре бер төргәк. Бераз саргая, бераз таушала, язулары бераз тоныклана төшкән. Кайберләренә безнең атакага ыргылган танклар, солдатлар, самолетлар төшерелгән, кайберләрендә генералиссимусның горур профиле дә бар... «Рядовой Батыршинга... немец-фашист илбасарларыннан Белгород шәһәрен азат итүдә күрсәткән батырлыгыгыз өчен... Харьковны... Полтаваны... Кременчугны... Звенигородканы... азат итүдә күрсәткән батырлыкларыгыз өчен... Корсуньда, Яссы-Кишеневта... илбасарларны тар-мар итүдә күрсәткән батырлыкларыгыз өчен...» Менә Рәхмәтулла абзаң дошманны күрше иләр туфрагыннан да куа бара: «Сомбатель... Кесег... Сөхешфехервар, Будапешт... Винер-Нейштадтны алганда күрсәткән батырлыкларыгыз өчен..»

Бу рәхмәт кәгазьләренә кул куйган командующийларның фамилияләрен аерып-танып алмакчы булам. Язган каралары, күрәм, еллар узган саен бераз уңа, тоныклана икән. Аның каравы, солдат даны ачыла гына, яктыра гына бара...

Аркасын коймага терәп, тын гына утыра ул, аның янында, эчтән генә гаҗәпләнеп тә, горурланып та, мин утырам. Бездән сул кулда, якын гына, урамыбыз коесының озын сиртмәсе күккә сузылган, каршыда, олы юл күпере башында, мәһабәт яшел өянкеләр...

Хәрби медальләр ялтыравына тирәбезгә бер көтү бала-чага җыелганын сизми дә калганбыз...

Белми дә йөрер идем шул...

# ЙОМЫШЧЫ ӘБҮБӘКЕР

хикәя

I



Бу җир дигән нәрсә бигрәк кадерле шул. Җир өчен адәм баласы ниләр эшләмәгән дә, ниләр күрмәгән!

Күптән булган хәл бу. Ул вакытларда Суша суы буендагы Күгәрчен авылы елганың сул ягында гына утырган әле, уң як ярына канатын ташлап өлгермәгән.

Печән өсте икән.

Күк аяз, көннәр коры тора, тик шунысы аяныч: алтын вакыт заяга үтә. Олы мәчет артындагы җыен өе тирәләре «гү-ү» килеп тора. Җир идәнле, кабык түбәле, ертык карындык тәрәзәле бу «парламент бинасы»на чабаталы агайларның тавышлары гына түгел, үзләре дә сыймаганнар — барысы бергә өерелеп кире ишек алдына чыкканнар.

Җыены да гади җыен түгел: биш авылның карты, атларга төялеп, Күгәрченгә килгән. Могтәбәр картлар өй саен йәреп җыйган иганә акчаларын тастымалга төреп алып килгәннәр.

«Йомышчы «хадук»ның сәфәре ерак буласы — пайтәхетнең үзенә үк...

Кама буе болыннарында үлән дигәнең тездән түгел, билдән җиткән. Агайлар, шул үләннең тәмен дә татып өлгермәгән чалгыларын ташлап, җыенга җыелганнар. Җыен өе ишек алдында — шау-шу, колагың тонар. Чебиләгән тәпиле малай-шалай; кайсысы кояштан бер күзен кыскан, кайсысы авызын ачып иягеН кыйшайткан, читтән генә карап тора.

II

**Кама** буеның Кызыл тау аслары — элек-электән алты авылның чабынлыклары булган. Карчыга борын алпавыт Стрекалов — ач күз! — үз авылы халкын хәерчегә калдыруы, кызларын мәсхәрәләве җитмәгән, инде кеше болыннарын тартып алмакчы! Алты авылның чабынлыкларында көтү-көтү үгез симертеп Казанга озатып кына ятасы... Быылтыр булды быылтыр, пистолетын шартлатып, бозауларын җибәртеп, күпме халыкны печәнсез калдырды. (Үзенең һәрбер бозавын закон саклый!) Ә быел Мәликә күле башына ук чыгып юлны баскан. Үткәрми! Өяздән атлы стражниклар чакырткан, становой пристав мыекларын тырпайткан, каш астыннан бүредәй карый...

Ул карчыга борын өяздә дә, губернада да бөтен җир-болын язуларын күптән инде актарып карап чыккан, кешеләрен майлыймайлый... Губернаның Казенный палатасын да үз ягына аударды бугай, ахрысы... Берәү көтү-көтү мал сатып, акча сугып ятсын, монда синең кышкы суыкларда яшь бозавыңа бәйләп элер үлән яфрагың да булмасын, имеш! Йә, кайсы закунга сыя бу?

III

Бер карасаң, бу җыен — бәхетле җыен әле. Үзенең Әбүбәкере бар. Әбүбәкер Солдат, әрсез балта сабы, русчага шомарып кайткан, судлан уңга каләм йөртә белә. Үзе таза, гайрәтле: ак патшага егерме биш ел хезмәт итеп кайткач, сабан туенда Үгез Сәләхине әйләндереп салды; үзе тапкыр, үзе зирәк. Бүтәннәр керә алмас җиргә ул керер, бүтәннәр булдыра алмасны ул булдырыр. Бертуган энесе Мөхәммәтҗан ахун да Әбүбәкергә «Шәкерт абый» дип зурлап кына эндәшә. Әбүбәкер Солдат булмаса, кем бу татар җәмгыятенең сүзен сакат хәтле санатка үткәзерлек итеп язар да, кем аны шундый югары урынга җиткерергә алыныр иде?..

Кибеп-корышып беткән Габделлатыйф карт шау-шуны тыймакчы. Сүзне аны каләмгә элеп теркәп ялгарга да кирәк бит. Әбүбәкергә кыендыр. Кырык кеше кырык яктан колагыңа горголдап торсын әле...

— Гатау кода, тавышың дөнья каплый. Зинһар, әкренрәк сөйлә. Хамматхан кияү, син дә...

Картны ишетмиләр. Шау-шу үзлегеннән басыла төшә.

Әбүбәкер имән түмәргә утырган, шыгырдавык өстәлгә ике бәләген салган, кауры каләмен түш төймәсенә бәйләп элгән тар авызлы шешәсенә манып-манып яза.

«Хөкемфәрма Сенат комиссиясенә.

18... сәнә, без Казан губернасы Лаеш өязе Урахча волосте Күгәрчен, Түбән Тегерменлек, Югары Тегерменлек, Ямаш, Балтач, Күки авыллары дәүләт крестьяннары шушы пригавурны бер сүздән төзедек ки, Городок алпавыты Стрекалов безнең Кама буе Керәүшә суы тамагындагы чабынлык болыннарыбызны тартып алды. Печән чаба алмыйбыз, атларыбыз вә башка терлекләребез бетеп бара. Генеральный межеваниегә кадәр авылларыбызда халык азрак иде, болыныбызны вакытлыча файдаланута өлешләп сатып тора идек, инде хәзер алпавыт Стрекалов безгә акча түләү түгел, әлеге болыннарга үзебезне җибәрми, тиешле кәгазегез юк, ди. Әмма бу болыннар элек-электән безнеке. Без 18... елны да, дәхи аннан соң да губерна Казенный палатасына гозеребез белән мөрәҗәгать иткән идек, беренче тапкыр карар дөрес чыкмады, икенчесенә инде өч ел җавап юк.

Шушы пригавур белән Хөкемфәрма Сенат комиссиясенә мөрәҗәгать итсен дип, Әбүбәкер Биккенә углы Зәетовны ышанычлы вәкил вә йомышчыбыз итеп сайладык. Каләм тотучыларыбыз кул куя, тота белмәгәннәребез тамгаларын сала...»

Герблы ак кәгазьгә ике-өч кенә исем уңнан сулга сырлап куелгач, өч багана булып бер-бер артлы култамгалар тезелде: менә тәпәче читкә авышкан чабагач шикеллесе, менә өч япьле сәнәк кебеге, башына саескан кунган багана сыманы...

Эшлиянче Шәйминең Казанда үз йомышы да бар икән, җирән атын Мөхәммәтҗан ахунның җиңел тарантасына җигеп алды да Әбүбәкер Солдатны ерак сәфәргә озата китте.

## IV

Әбүбәкер, йомры баш, Сенат канцеляриясенә беренче кат ишек ачып кергәнче, җиде көн буенча халык йомышына кечкенә булса да теләктәшләр эзләде, эш йөртү юлларын өйрәнде. Йөзе ачык, кулы юмарт иде. Үзе кебек «хадук»лардан кайсы бүлмәләргә кереп, ничек йомыш йомышлауларын сорашты. Канцеляриягә керер көнне сакалын китәреп, мыегын бөтереп җибәрде, шинель итәге белән искергән итекләрен ышкып ялтыратты, солдат фуражкасын башына кырынрак салып киде. Канцеляриягә (аны «присутственное место» дип тә атыйлар икән) җиңел адым, кыю караш белән, май ярган пычактай шома керде керүен дә... чыгуын шома гына чыга алмады... абынды, төрмәгә үк эләкте...

Сенат кадәр сенатның елкылдап торган палаталарында да күзгә күренмәс биек бусагалар бар икән, «уңдым» дигәндә акча салмасаң, йөзтүбән капландыра икән...

Һаман шул наданлык! Үзең императорский указларны укыштырган акыллы баш бул, авыл сине күз өстендә каш кебек күрсен, үзең, алла колы, санатның саф дөрес карарын сәмруг кошлы кәгазьгә күчереп сиңа тоттырасы өстәл башлыгының кулына «алтын йөгертә» белмә, имеш!..

Сенатның тәфтиш комиссиясе күреп тора: болыннар алты авылныкы. Бу хактагы язулар хәзер «табылмаса» да, алар барыбер булган, бар, мәсьәлә көн кебек ачык. Тәвәккәл алпавыт хәйлә ятьмәсен киң ташлаган: мөхтәрәм губерна хөкемдарларыннан да үз карарын яздырып мөһер суктырып ала белгән... Әмма... бунт кубачак бит... Ярамый!..

Санат комиссиясенең итләч шома битле, калын гәүдәле өстәл башлыгы карар язуын алты авылның ышанычлы вәкиленә тапшырыр алдыннан, ике күзен тондырып, таш бәгырьле юлбасардай аңа озак кына карап утырды. Йомышчы «хадук» күзен читкә алмады, туры карады, әмма елмаеп, йомшап китеп, кесәсеннән янчык та чыгарып атмады. Әллә инде бу вәкил турылыкның да кыеклап йөрүен белми инде.

Өстәл башлыгы озын каурыен ялтырап торган җиз савытка манып, карар кәгазенең буш бер юлына ике-өч кенә сүз өстәп куйды да аягүрә басып карарны йөгертеп укып чыкты. Укуын дөрес укый, хәерсез: болыннар алты авылныкы...

Моңарчы русча язу танымаган булып маташкан Әбүбәкер Солдат, карарны алгач та ябырылып укый башлый бит! Ни күзе белән күрсен: буш юлга алты авыл урынына алпавыт Стрекалов исеме язып куелган...

Җан ачуы куба Әбүбәкернең, үзен тыя алмыйча, китереп торып сала ак битле өстәл башлыгының яңагына.

— Ник дөрес язмыйсың?.. Ник алдашасың, машинник?

## V

Ике газраилдәй ике җантимер Әбүбәкер дәгъвачыны саңгырау диварлы бер соры йортка алып килеп, тимер ишектән кертеп җибәрәләр, тышкы якта зур йозак шалтыр-шолтыр килеп бикләнә.

Калын ла икән әби патша салдырган хәбесхананең стеналары, салкын ла икән таш идәннәре, биек лә икән рәшәткәле тәрәзәләре...

Ришвәтче хөкемдар! Шатланып калгандыр әле. Каты суктың, янәсе, ярар, аның каравы, үкенечең ачырак булыр, болын кирәк булса, горур башыңны иеп кире килерсең әле...

Әбүбәкер кайгыда. Ай, надан халык, кара сарык... Юллык сумма җыеп бирә белгәннәр, императорский санатка ришвәтлек җыя белмәгәннәр...

Айлар үтә, еллар үтә. Чыга Әбүбәкер төрмәдән. Җәйге көнне проспекттан барганда каткан такыясын салып бер ишек пыяласына карап тора: кара сакалы агара башлаган, куе чәче сирәгәйгән. Үзе эчтән шатланып куя: әле ярый Себергә җибәрмәгәннәр, шушында, санатлы пәйтәхеттә генә утыртканнар, югыйсә, кире килеп йөреп булмас иде...

Бер графта ат караучы булып, өс-башын бераз төзәтеп алгач, йомышчы Әбүбәкер янә санатка бара, шома битле өстәл башлыгын янә бер күреп кайта да, хезмәтчеләр өендә каләмен тотып, бер почмакта хат язарга утыра. Озак кына баш ваткач, кыска гына сүз сырлап, исемен теркәп куя: «Нигә ни кирәк, ни булса ни була. Әбүбәкер Биккенә улы».

Хатны түләп алулы итеп энесе Мөхәммәтҗан ахун исеменә җибәрә.

## VI

Мөхәммәтҗан ахун Балтачка киткән булган икән. Күгәрченнән бер малай ат менә дә артыннан чаба.

— Ахун абзый, сөенче! Шәкерт бабайдан хат килгән!..

Йомышчы хадукларыннан өмет өзгән авыл картлары тагын Күгәрченгә җыела.

Хикмәтле хатны укыйлар, кулын таныйлар. «Була» сүзен күргәч, сүнгән дәртләре кабынып китә. Алты авыл дәфтәрләргә тамгалар тездереп, икенчели акча җыя...

Ярый, җыйдылар, инде ничек җибәрерләр? Йомышчы белән дисәң, аңа янә юллык акча кирәк... Юлда үзен таласалар?..

Эшлияче-камытчылар Күгәрчендә, чүлмәкчеләр Олы Көл белән Гремячидә, дугачылар Тегермәнлектә, көмешчеләр-коемчылар Балык Бистәсендә... Ә бит менә генә торган Урахча русында тимерче-калайчылар бар!..

Күгәрченнән бер карт тимерче алачыгына килеп керә.

— Драстуй, Ыстапан Басилич! Адин харуши кумган ыздилай!..

Алты авыл картлары җыйган суммаларын яңа комган төбенә тыгызлап салалар да өстеннән икенче төп каплап ямыйлар,— тот та су тутыр, таһарәт ал!

Китә мөселманның гөнаһсыз комганы почтовый белән Санкт-Петербургка... императорский санаттан алты авыл болынын йолып алып кайтырга...

## VII

Әбүбәкер ишектән килеп кергәч тә кесәсенә бер сугуы була, авыр гәүдәле өстәл башлыгы урыныннан сикереп тора, шома гына хәрәкәт белән бикле шкафын ачып, яңадан күчереп язган карарны китереп чыгара.

— Бир... Мә, укы...

Йомышчы язуны сабырсызлык белән бер күз йөгертеп чыга, икенчегә аерым юлларын кайта-кайта күздән кичереп укый.

Кәгазьне кыштырдата-кыштырдата дүрткә бөкләп, керләнгән кулъяулыгына төреп куен кесәсенә тыккач, шинеле өстеннән бер сыйпап ала да кинәт авыр сулап: «Менә бит, малай, ә!..» — дигән сымаграк чал кергән башын чайкап тора. Аннары, хөкемдарны бар

дип тә белмичә, ялтырап яткан паркет идәнле бу бүлмәне, алтын рамдагы император портретын, онытмаска кирәк әле бу алтын сарай кетәкләрен дигән сыман, үткен күзләре белән бер сөзеп карап чыга да, берсүзсез җиз тоткалы биек ишекне киң ачып, горур кыяфәт белән чыгып китә.

## VIII

Әбүбәкер карарны исән-сау алып кайтып җиткергән, шуның рәхмәте белән генә алты авыл крестьяннары кансыз алпавытның тырнагыннан ычкынып калганнар.

Күгәрчендә өлкәннәр әле дә сөйлиләр: элек, Әбүбәкер якты дөньядан киткәч, авылның кайбер динлерәк картлары иртәгә Керәүшә тамагына печәнгә төшәсе дигән көнне кичке намазда горур йомышчы рухына өчәр рәт дога кылганнар, имеш: авыр туфрагы җиңел булсын, янәсе, нәсел-ыруының рәхмәте артсын...

Комган төбенә яшереп хөкемфәрма сенатка ришвәт җибәргән авыллар хәзер, әлбәттә, күптән инде колхоз авыллары. Җир аларга Ленин Декреты белән бирелгән — һичнинди түләүсез мәңге файдалануга... Күрше алпавытларының җир биләмәләре дә киселгән аларга. Гражданнар сугышы фронтларында бу авылларның һәркайсыннан дистәләрчә, хәтта йөзләрчә ир-егет Совет власте өчен сугышкан. Берәвесе әле унҗиденче елны штурм белән Зимнийны алганда ятып калган, диләр.

Күгәрченгә барган саен, басуларын-кырларын бер карап әйләнгәч, мин авылның зиратына, музейханәгә кергәндәй кереп, кабер ташларын бер карап чыгам. Карт каеннар арасындагы сырлап-бизәп язылган ташларда борынгы болгарларның таш язу алымнары төсмерләнә.

Ярчылган-кыйпылган, ауган ташлар да бар анда. Язуларын яшел мүк сарган, кырып чистартмыйча аерырлык түгел. Зәетовлар үзләре бер оядарак җирләнгәннәр. Йөз дә ун яшь яшәгән Биккенә карт ташы бар, Мөхәммәтҗан ахун ташы бар, аның улы — заманында губернада дан тоткан педагог-мәгърифәтче Ризаэтдин учительнең дә ташы бар. Ризаэтдиннең кече улы Исмәгыйл Зәетов хәзер Мәскәү университетының география факультеты педагогы, күренекле галим. Исмәгыйл ага бер көнне үз фатирында миңа бронзадан эшләнгән Нифертити башын күрсәтте. Язулы. Каһирәдән килеп укыган бер гарәп егете диссертациясен яклагач бүләк иткән. Исмәгыйл ага аның фәнни җитәкчесе булган икән. Йомышчы Әбүбәкернең нәселдәше...

Әбүбәкернең үзенең кабер ташын тапмадым.

Ташы булыр иде, башы ерак юлларда югалган, диләр.

Кайсы якларга, җыенның нинди йомышы белән соңгы сәфәренә киткән ул, кай җирләрдә гомере өзелгән — боларын миңа беркем дә әйтә алмады.

## Үзбәк Саттаров

# КЫЗЫМ ХИКӘЯЛӘРЕ

## «Потам, потам...»

Гүзәлгә бер яшь чамасы. Йөри дә алмый, сөйләшә дә белми әле, аерым сүзләрне генә әйткәли. Әттә, әннә, әби, апа. Өчаякка бастырдык моны, йөрергә өйрәтәбез. Өчаяк белән бик тиз өйрәнде тәгәрәргә. Кулыңны чабып:

— Тотам, тотам! — дисәң, торып чаба. Үзе көлә, үзе йөгерә. Тиздән безгә ияреп «тотам, тотам» дигән сүзне кабатлый башлады. Тик ул аны үзенчә әйтә: «Потам, потам»,— ди. Соңрак, «карагыз миңа, мин ничек тиз йөгерәм», дигәнне дә:

— Әти, потам, потам,— ди башлады.

Тиздән өчаякның исеме дә потам-потамга әйләнде. Өчаяк кирәк булса, «потам, потам» дип сорап ала иде.

Шулай көннәрнең берендә иртән ашыгып эшкә җыенабыз. Гүзәл тәрәзәдән карап утыра.

— Әти, әти! — ди бу миңа. Янына килдем. Бармагы белән тәрәзәгә күрсәтте дә:

— Апа потам, потам,— ди.

Карасак, урамда бер хатын йөгереп бара.

Бусы инде апа йөгерә дигән сүзе иде.

## «Әти, песи...»

Көннәрнең берендә Гүзәлне дә, аның өчаягы «потам-потам»-ны да күтәреп, әбиләренә килдек. Анда кара мәче бар иде. Аны күрүгә Гүзәлне кулда тотарга хәл калмады, мәчегә үрелә башлады. Ай-вайга карамыйча, үрмәләп барып, мәчене тотты. Йонынынан умырып алып, кыскалый, йолыккалый да башлады. Мәчесе дә бит торып йөгерми, күзләрен йомып, баланың йолкуына риза булып тик тора. Аркасына да яткыра бала мәчене, колагыннан, бер

аягыннан, муенынннан эләктереп тә күтәрә, урталай бөкләп тә кочаклый. Мәче мырлый гына.

Шулай да башка шик төште, кызым мәченең берәр җирен авырттырыр да, мәче аны я тешләп, я тырнап качар, дим. Мәчене кулыннан алып идәнгә куйдым да, аркасыннан йонын сыйпый-сыйпый:

— Песи, кызым, бу — песи,— дидем.

Гүзәл дә миңа карап:

— Песи, ә... песи,— дип кабатлады.

Бу хәл онытылып бетте инде. Көннәрнең берендә эштән кызымны сагынып кайтып кулыма алдым. Булмаган хәл — кызым минем мыекны сыпыра.

— Песи-песи,— ди кызым.

Әнисе, чыгып китәргә дип, киенгән килеш ишек төбендә тора иде.

— Әнисе,— мин әйтәм,— кызыбыз тагын бер сүз өйрәнгән.

Әнисе шатланып Гүзәлне кулына алды, ә Гүзәл аның пальто якасын сыпыра:

— Песи-песи,— ди.

Шулай итеп, барлык йонлы әйбер дә шактый вакыт «песи» дип аталды, хәтта щеткалар да!

## «Бәлилә түгел, бә-ли-лә!»

Көннәрнең берендә кызым ашап утырган җирдән «бәлилә» сорый башлады. Нәрсә генә бирен карасак та, бәлилә булып чыкмады. Аптырагач, урыныннан торып китте дә өстәлгә чи бәрәңге алып килеп куйды:

— Менә бәлилә,— ди.

— Кызым,— мин әйтәм,— бу — бәлилә түгел, бу — бәрәңге!

— Бәлилә,— ди, ризалаша үзе.

Бәрәңге пешкәч, ашарга утырдык.

— Бәлилә пеште, аша, кызым, бәлилә! — дим, аныңча.

— Бәлилә түгел, бә-ли-лә! — ди.

Янәсе, мин әйткәнчә әйтмәгез, үзегезчә бәрәңге диегез. Аның бер үзе өчен генә бәлилә ул.

## «Әтием...»

Бигрәк тәмле телле булып китте бу бала. Җөмлә төзеп сөйләшә башлагач, «әти» дими, «әтием» дип, болай да йомшак күңелне эретеп җибәрә.

— Кызым, син нигә миңа һәрвакыт «әтием» дисең, беркайчан да «әти» дип әйтмисең? — дим.

Гүзәл бер әнисенә, бер әбисенә карады, шукланып:

— Әни дә, әби дә шулай әйтә бит,— дип куя.

Чыннан да алар әтиең кайтты, әтиеңнән сора, әтиең янына бар, әтиең ачуланыр, диләр. Шулай булгач, Гүзәл өчен дә «әтием» була инде.

## «Айрат абый буламыни?»

Айрат абыйсы килде безгә.
— Кызым, бу Айрат абыең була инде, аңа «Айрат абый» дип дәшәргә кирәк,— дидем.
Шактый гына кич утыргач, бер-берсенә күнегешеп беткәннән соң, Гүзәл аны үз итеп, бөтерчеген әйләндерергә кушты.
— Айрат, кил әле, бөтерчекне бик нык итеп әйләндереп бир!
— Нинди Айрат булсын ул сиңа? — диде әнисе, бераз шелтәләп.
Гүзәл үпкәләп яныма килде:
— Айратмы соң ул, абыймы? — диде.

## «Саескан»

Башка авылларны белмим, безнең авылда кушаматсыз бер генә кеше дә юк иде. Минем үземнең дә, хатынның да кушаматларыбыз бар. Ничек икәнен әйтмим генә, кирәк кеше үзе белә.
Көннәрнең берендә безгә Хәерниса апа килде. Ул бездә еш була. Балалар да аңа ияләнеп беттеләр.
Шулай бер көнне Хәерниса апа хатыным белән сөйләшеп утырганда яннарына Гүзәл йөгереп килде һәм кычкырып шатлыклы тавыш белән:
— Әни, мин белдем инде, бу — Саескан апа ич! — диде.
Бала — бала инде, бу сүз өчен Гүзәлне гаеп итүче булмады булуын, әмма Хәерниса апа ниндидер бик ашыгыч эшен искә төшереп, кайтып китте.

## «Чып-чыпчык»

Балаларның уенчык чыпчыклары бар иде, пружинасын борсаң, җим чүпли торганнар иде. Ә менә тыштагы чыпчык җим дә чүпли, оча да. Гүзәл миңа аны күрсәтеп:
— Чып-чыпчык!..— ди.
Мин аңламыйм:
— Нәрсә-нәрсә?
— Чып-чыпчык...
— Ник алай дисең?
— Нигә соң син күк күгәрчен дисең? Ул бит оча торган күгәрчен дигән сүз.

## Иске бүрек

Яз килә, тышта яңгыр катыш кар ява. Минем барасы җирем бар, ашыга-ашыга киенәм. Гүзәл килеп җиңемне тарткалый, ә үзе:
— Җүләр дә инде син, әтием! — ди.
Яңа сүз ишетеп, өйдәгеләр бар да тынып калалар.
— Нигә, кызым, әтиеңә җүләр дип әйтәсең?
— Җүләр дими, тышта кар ява, ә ул яңа бүреген кия! Ярамаган тагын иске бүрек!

## «Эчем поша»

Гүзәлнең кәефе юк. Башка чакта бер дә тик тотып булмый торган бала — уйнамый, тик утыра. Бу хәл миңа сәер тоелды:

— Кызым, ни булды сиңа? — дим.

Бала боек күзләре белән миңа карап:

— Эчем поша!..— ди.

Мин аптырап калдым.

— Ничек инде, «эчең поша?»

— Әнә бит, эчем пош-пош дип тора,— ди.

## Әби шуны да белми...

Гүзәлнең әбисе кунакка килде. Беркөнне ул хатыныма кызым дип дәшкән иде, аны Гүзәл тыңлап торган икән. Иягереп яныма килде дә:

— Әтием, әби әниемә «кызым» ди. Әниләр «кызым» булмый инде, әби шуны да белми! — диде.

## Дөреслек

Бер көнне, бакчадан кайткач, кызларым пышын-пышын нидер сөйләшеп утыралар. Зурысы:

— Олыларга ышанма син, алар балаларны алдыйлар,— ди.

Барып сүзләренә катыштым:

— Ник алай дисең, кызым, кем сине алдады?

Балаларча турылык һәм әчкерсезлек белән:

— Син дә, әни дә безне алдыйсыз,— ди ул.

Аптырап калдым:

— Без кайчан, ничек дип алдадык сезне? — дим.

— Балаларны больницадан алмыйлар, кибеттән алалар. Светаны әнә кибеттән алганнар, әнисе шулай ди. Больницада бер әйбер дә сатмыйлар, кибеттә генә саталар. Ә сез безне больницадан алдык дисез!

Сүз моның белән генә бетмәде, кечкенәсе өстәде:

— Мин дә беләм балаларны каян алалар икәнен, аларны кибеттән дә алмыйлар, больницадан да алмыйлар — аларны әниләр таба,— диде.

## Мин кайда идем мин юк чакта?

Күрәсең, безнең «син юк чакта», «сеңелең юк чакта» дип сөйләшкәннәр уйландырган баланы.

Көннәрнең берендә бу миннән сораша башлады:

— Гөлнара юк чагында мин бар идемме?

— Бар идең.

— Нигә соң алай булгач, «син юк чакта» дип әйтәсез.

— Ул чакта әле син дә юк идең.

— Мин юк чакта мин кайда идем соң?

## Нури Арсланов

### Кайтмый калмый

Чәчелгән, сибелгән татар,
Яфраклар очкан сыман,
Таралган,
туган якларын
Калдырган кошлар сыман.
Кошлар кайта язлар җиткәч,—
Күңелле безнең яклар!
Кошлар кебек сайрашырга
Кайта безгә кунаклар.

Кай чагында, сагышлардан
Нечкәрсә күңелләре,
Өздереп җырлап җибәрә
Моңлы татар көйләрен.
Шунда ул туган якларын
Төшерә уйларына:
Йөргәндәй була Камада,
Агыйдел буйларында...

Телләргә, яңа җирләргә
Күнегә сабыр гына:
Ямьле булса да торган җир,
Туган җир сагындыра!
Кайта ул, кайтмый калалмый,
Ризыгын бер татырга,
Гөрләшеп туган телендә
Эчләрен бушатырга.

1972

## Илдар Юзеев

### Ни ясар тимерче

Кайгыдан, шатлыктан
Арудан бушанып,
Изрәгән бар тараф,
Ал таңга ышанып.
Йокламый тимерче,
Ут-күмер дөрләтә.
Гүя ул сабыйның
Бишеген тирбәтә.
Куллары — күректә,
Учакта — тимере.
Янамы күмере,
Янамы гомере...
Ал да сал сандалга,—
Ут шары өлгергән.
Тик менә тимерче
Ни ясар тимердән:
Куянга читлекме,
Балыкка кармакмы,
Табутка кадакмы,
Бүрегә тозакмы,
Шагыйрьне зинданга
Бикләүче йозакмы?
Ни ясар тимерче:
Атларга тышаумы,
Азатлык сөюче
Муенына кыршаумы?
Нәниләр сөенеп
Атынып таганмы,
Сабанмы, кылычмы?
Кылычтан сабанмы?
Шатлыкмы, хәсрәтме?..
Таңнарга ала чык.
Борчылып, сискәнеп
Көтә Җир — алачык.

1971

## Равил Фәйзуллин

●

Әгәр дә мин хөр, бәйсез бер
табигать улы булсам,
кош-киекләр дусы булып,
ялгыз куышта торсам,
мин сине җибәрмәс идем
авылына, каласына...
Без куышлы уйнар идек
чәчәкләр арасында.

Мин сине менгерер идем
печән төялгән йөккә!
Аллы-гөлле дугадагы
кыңгыраудан биеккә!
Ярым ачык иңнәреңә
ал яулык салыр идем.
Салават күперенәчә
озата барыр идем.
Синең юлыңа җитәрлек
дәртле җыр бирер идем.

Чакырсаң, ерак дип тормый
йөгереп килер идем.
Качсаң да син, югалсаң да,
мин эзләп табар идем.
Бит очындагы миңеңнән
барыбер таныр идем,
риза булсаң, гомерлеккә
яр итеп алыр идем.

Шат гомер кичәр идек!
Баш астына мендәр итеп
чәчәкләр түшәр идек.
Таң алдыннан хәл белергә
йолдызлар төшәр иде.

Әгәр дә мин хәр, бәйсез бер
табигать улы булсам.
Киек-кошлар дусы булып,
ялгыз куышта торсам...

1971

## Ренат Харис

### Чаллыда уйлану

Туган җирнең һәрбер үзгәреше
Күңелләргә сала үз эзен...
Нинди генә яңарыш булмады,
Син саклдың, халкым, үз йөзең.

Дус халыклар сиңа өй салышты,
Үзләренчә иплән һәм көйләп,
Тик синеңчә елмайдылар, халкым,
Дуслар төсе булган бу өйләр.

Дус хакына күпме мәҗлес кордың,
Дусларыңнан күпме сый алдың —
Бәлки, сыең бераз үзгәргәндер,
Үзгәрмәде ләкин сыйлавың.

Нинди генә җырлар җырламадың,
Кушылмады сиңа кем генә?!
Ләкин моңың синең еллар аша
Яңгырап бара,
Бара мәңгегә.

Батырлыгың — ата-бабалардан,
Горурлыгың — синең горурлык.
Үзең өчен һәм дусларың өчен
Кыя булып басып торырлык.

Изге йолаларга тугры халкым
Өмә җыйган бүген үзенә...
Күңелем минем,
Үз халәтен саклап,
Яңаруын, баюын сизенә.

1971

## Рәдиф Гатауллин

### Сүнмәс утлар белән

*«Казан утлары»на*

Шәһре Казанымның үзе кебек
Исемең балкып яна уйларда.

...Карурманда калган юлчылардай
Халык таралышкан чорларда,
Еракларда өмет булып күренеп,
Күңелләргә күчеп, җырларга,
Шундый утлар янган:
Алга таба
Юл күрсәтеп янган, ялт итеп;
Сүнми торган якты идеал кебек,
Җанда йөртеп, саклап, яд итеп,
Эзләп килгән кешеләр, баккан аңа,
Килгән алар — читтән, төбәктән.
Чокырлардан чыккан Чокрыйлардай,
Казакъ даласыннан Акмулладай,—
Урал, Себерләрдән, Төмәннән...
Казан тарткан Тарих-Болгар булып,
Яктылыгы һаман чакырган.
«Үз төбенә төшмәгән һәр нуры»,
Ә тирәсе һаман яктырган,
Уфа, Оренбурга нурын чәчкән,
Өмет баглар кешеләренә,
Ул ут биргән яктылыкка мохтаҗ,
Үзенә кардәш булган халыкларга —
Телдәш, уйдаш күршеләренә.
Шулай килгән ул Бишенче елга —
Тукай җаны кабынган елга
Һәм уянып халык, сәнгать күгенә
Зур йолдызлар яндырган чорга.
Революция ялкыннары белән
Кергән Казан Бөек Октябрьга,
Мәгърифәтче уйдан — Ленинга.
«Безнең юл»лар,
«Атака»лар белән
Ул улларын дәшкән җыенга.

Бай тарихлы, зур намуслы халкым,
Юлыңның һич сүнмәс утлары!
Шул утларга охшап чын сәнгатьнең
Күпме байлыклары тупланды.

...Горурланып әйтә бүген һәркем:
— Юлың якты «Казан утлары»!

1972

## Рәшит Әхмәтҗанов

●

Эх, сабый чакларымда да
Мин бала булалмадым.
Җир канлы, күкләр болытлы
Булса да еламадым.

Бөртекләп, мыскаллап җыйдым
Дөньяның сафлыкларын.
Шул ук дөньяга очырдым
Сафлыкның аккошларын.

Дошманнар атты илемә —
Уклары миңа тиде.
Иелү — калкып басарга
Тын алу гына иде.

Илемнең изгелекләрен
Саклаган йөрәгемә —
Яшәүләр бирде һәрчакта
Үлемне үтерү генә.

Әй, узган еллар килсеннәр,
Күрсеннәр танышларын:
Мин һаман очырам дөньяга
Хисләрем аккошларын.

1972

Фәнил Мансуров

# ЯКТЫТАУДА БҮЗ ТУРГАЙЛАР

ПОВЕСТЬ

*...тургай картаймый.*
*И. Гази.*

Яктытау өстендә язгы йомшак җил исә. Каршымда күе кыяклы яшел ужым аксыл рәшә уйнаган офыкларга таба дулкын-дулкын булып йөгерә... Һавасы да сулап туйгысыз — борыннарны кытыклап туфрак исе, сусыл үлән исе анкый. Шушыннан, әле басып торган Яктытау өстеннән, язгы йомшак җил аша:

— Дөнья ма-туррр!..— дип, бөтен җиһанга кычкырасы килә.

Кинәт кенә югарыда челдер-челдер кыңгырау чылтыравы ишетелгән кебек булды. Кыңгырау... Башымны артка ташлап, зәңгәрсу күккә күтәрелеп карасам, бүз тургайлар, канатларын җилпи-җилпи, кояш тирәли очалар. Алар да яз күренешләренә, дөнья матурлыгына гашыйк, күрәсең:

— Челдерр... чел-дерррі..

Яктытау өстендә бала чактан ук таныш, җанга якын җыр — тургайлар моны тибрәнә. Һәм ул як-яктагы офыкларга таралып, күз җитмәс җирләргә, бөтен җиһан әйләнәсенә кабатлана-кабатлана яңгырыйдыр төсле.

— Дөнья ма-турр!..

Һәркемнең аерата якын күргән үз җыры бар. Менә мин Яктытауда тургайлар сайравын ишеттемме, күңелләрем кузгалып, тәмам гаҗизләнеп калам. Бу сихри җыр тансык та, сагышлы да миңа...

Җир өстендә ни хикмәтләр барын тургайлар да сизенә, ахры. Әнә бүген нинди: «Дөнья матур, дөнья ма-турр!» — дип сайрыйлар. Ә бит истә, һаман да истә... мин бәләкәй чакта шушындый бер язны алар бөтен күкне иңрәтеп челдер-челдер елаганнар иде.

## I

Көтү кайтыр алдыннан безгә Күли абзый килеп керде. Килеп керде дә, өйдәге әче бу исенә борынын жыерып, түргәрәк узды, аннары, Әнүнең хаты-хәбәре бармы? дип, сугыштагы эткәйне сорашты. Ахыр да ул:

— Колхоз дубырында атларның күпме калганын беләсең, Бикә, аларын да военкомат чүпләп кенә тора,— диде, борчулы тавыш белән үзалдына сузып.— Май ахыры житеп килә, ә Яктытау басуы һаман сөрелмәгән. Ничек тә аны кысыр калдырмаска кирәк. Шуңа күрә хужалыктагы сыерларны да жикмичә булмый.

Әнкәй казаннан чуен чүлмәккә тавыклар бәрәңгесе — кабыклы вак бәрәңге сосып маташа иде. Күли абзыйның сыерларны да жигәргә туры килә дигәнен ишеткәч, алюмин чыбыктан үрелгән соскычын казан читенә элде дә бригадирга сәерсенеп карады.

— Син ни сөйлисең, Тимерхан?!

Алар сүзенә ничек кушылырга белми тора идем, менә шундук жае да чыкты. Күли абзыйга әнкәй: «Тимерхан», дип эндәште бит. Иске чабатама яңа киндерә ишеп маташкан жиремнән — мич алдыннан тордым да:

— Күли абзый, Күли абзый, синең исемең Тимерханмыни? — дип сорадым.

Ана ни өчен «Күли» кушаматы тагылганын белсәм дә, юрамал белмәмешкә салышкан булам. Болай әллә ние дә юк аның. Миннән дә бәләкәй чагында ул, төнгелеккә атлар сакларга баргач, шунда кечкенә бер колын — көлкәйне күреп: «Күли, күли...» дип үзенә чакырган. Янындагы иптәш малайларына бу житә калган. Хәзер авылда кечесе дә, олысы да аны шул кушамат белән йөртә. Исеме белән үзенә генә эндәшәләр.

Күли абзый минем сорауга нәрсә диярга дә белмәде, ахры, ютәлләгән төсле булә-булә каты гына тамак кырды. Әнкәй исә ниндидер бер яшерен, эчке елмаю белән мине әрләргә керешге:

— Олы кеше белән шулай сөйләшәләрмени, агач тел!

Аның чын-чынлап ачуланмаганын сизеп торам.

Күли абзый да:

— Тиргәмә, Бикә, хәзер ул синеке генә түгел, колхозның да күз терәп торган өмете,— диде.— Эш сыерларга килеп терәлгәч, бу егет кенә кырыйда торып калмас,— диде.

Мин бер башка үсеп киткәндәй булдым.

Әнкәй, ябык аркамнан сөйгәндәй итеп:

— Куй инде, борынын да жыя алмаган шушыны,— диде дә мине читкәрәк этәрде.

Әмма каушап калмадым, форсаттан файдаланып:

— Мүкләкне жиктерсәң, мин дә сабанга чыгам,— дип үзенә әйтеп салдым.

— Менә бит!..— Күли абзый бердәнбер сул кулын селтәп, минем сүзне эләктереп алды.— Булырдайның әллә кайдан күренеп тора.

Бәләкәй чагында ул да тиктормас бер нәрсәкәй булгандыр. Югыйсә, ашлык сукканда барабан авызына кулы белән барып керер идемени. Әмма мин белә башлаганнан бирле ул — кеше ни әйтсә дә карулашмас, тешләшмәс, юаш кына бер бәндә иде. Яшькә әнкәй чамасында булса да, һаман өйләнмәгән, сазаган егет иде, инәсе белән генә яши иде. Чулак булгач, кешеләрдән һәрвакыт кимсенеп, кыюсызланып, басылып калгандыр, күрәсең. Безнең эткәйләр сугышка киткәч, ир-ат затыннан авылда ул берүзе генә диярлек торып калды. Элегрәк Күли абзый, башка бик күпләр кебек, колхозда төрле эшкә йөри иде. Ә хәзер аны безнең төбәккә бригадир итеп куйдылар. Әмма моңарга ул тамчы да

масаймады, һаман әүвәлгечә юаш кына йөри бирде. Мина калса, ул сугышка алынмавына хатыннардан хурлана төсле иде.

Әнкәй минем сабанга чыгарга атлыгып торуыма да, Күли абзыйның үтереп мактавына да исе китмәде:

— Олылар сүзенә кысылма! — диде кырт кына.— Көтү кайтыр вакыт житте, бозауны да карамагансың.

Киндерәсе ишелеп бетмәгән иске чабатамны мич астына аттым да, борынымны салындырып, атлар-атламас кына чыгып киттем.

Күтәрмә төбендәге Акбай әйтерсең мине күптән зарыгып көткән, түбән төшүгә, нәрсәгәдер зарлангандай, койрыгын болгый-болгый, аякларыма килеп уралды. Минем урында әнкәй булса, эч пошырып йөрмә әле, дип, аны читкә тибеп кенә жибәрер иде. Мин алай итмәдем. Икебезнен дә хәлләр бер чамаларак, ахры, нигә бер-беребезне кыерсытырга.

Мин йонлач Акбайны кочаклап күтәреп алдым, ялварулы төссез күзләренә карап:

— Су менә шулай болгана,— дидем.

Бу минем сүзләрем түгел, әнкәй белән ачуланышканнан соң әткәй һәрвакыт шулай әйтә торган иде. Алар үзара болай тату булсалар да, әнкәйнең апасы Тайфа түтәй аркасында кайвакыт чәкәләшеп китәләр иде. Тайфа түтәй ул чакта да бездән ике генә өй аша ихатасыз-нисез кечкенә өйдә ялгыз тора иде. Жизнәйне хәтерләмим, аны читтә зимагурлыкта йөргәндә спирт эчеп үлгән диләр. Авылда хәзер дә ул кешене «зимагур һади» дип атыйлар. Менә шул Тайфа түтәй һәрвакыт бездә иде. Хәер, ялгыз башы нишләсен, аптыраудан да керә торгандыр. Әмма кереп әйбәт кенә сөйләшеп утырса бер хәл, нәрсә турындадыр сүз кузгата да әткәйне үртәргә керешә иде. Шуннан әткәй берәр катырак сүз әйтсә, авызын турсайтып чыгып киткән була иде. Әнкәйгә бу житә кала иде, әлбәттә:

— Син ир кеше, нигә шуна да чыдамыйсын!

— Мине бала-чагага санап утырмасын! — дип, каршы төшә иде әткәй.

Менә шуннан өйдә низаг куба иде.

Монда кайсы гаепле, һич тә минем баш житәрлек түгел. Хәер, соңгы вакытта азрак аера башладым булса кирәк...

Тукта, күлмәк итәкләрен жилфердәтеп, әнә Тайфа түтәй үзе дә керел килә. Кулында кара чүмеч. Көтү кайтыр вакыт житте бит, сөт сорарга дыр инде. Сугышка чаклы аның бик әйбәт кәжәсе бар иде. Шул мәхлук, бер кичне көтүдән кайтмыйча, авыл башында бүреләргә юлыгып, әрәм булды. Шуннан бирле Тайфа түтәй һәр көнне бездән сөт кереп ала. Әйе, бер көнне дә калганы юк... Ә узган кышны үзенә нича әйтеп тә саламга бармады. Әле билем авырта дип, әле аякларым тубырлана дип хәйләләште. Әнкәй шуна һаман: «Түтәй... түтәй...», дип өзгәләнеп тора. Мин Акбайны жибәрдем дә үзем күтәрмә артына качтым. Ә эт ау-һаулап Тайфа түтәйгә өрергә тотынды.

— Чәбәә!.. Чукынган!.. Нәмәстәгә шушы әрәмтамакны асрыйлардыр,— дип, чәрелдәвек тавыш белән сукранды ул.

Шунда шыгырдап-сызгырып өй ишеге ачылганы, Күли абзый белән әнкәйнең сөйләшә-сөйләшә чыкканы ишетелде. Мин тиз генә өй артына шылдым да койма аша тыкрыкка сикердем. Аннары урамга чыгып, югары очтагы Яктытауга киттем.

II

Әнкәй Мүкләкне жиктерергә күнде микән? Күли абзый әйтмешли, атлар аз калды шул, бармак белән генә санарлык. Бөтен эш хәзер хатын-кыз жилкәсендә. Бүген дә әнкәй арып-талып кайтты. Инде бер

атна бардыр, арбага үзләре жигелеп, көн дә тирес чыгаралар. Шундый чакта авыз ерып, ничек уйнап йөрмәк кирәк. Мин үзем бүгеннән жин сызганырга әзер, кушсыннар гына. Әгәр Мүкләкне дә жиксәк...

Шулай уйлана-уйлана бозау артыннан китеп барганда, күлмәк жинемнән берәү эләктереп алды. Әйләнеп карасам, бөтен битен-йөзен сипкел баскан, житен чәчле Тәзкирә. Миңа авыз ачарга да ирек бирмәде ул:

— Кайдан бирле эндәшәм, ишетми дә ишетми, сакбай,— дип үпкәләргә үк керешәте.— Үзең көтү каршыларга барырбыз дигән идең.

Мин аны юатырга, шул ук вакытта үз күнелемдәге дә тизрәк әйтергә теләп:

— Бер нәрсә сөйлимме, Тәзкирә? — дидем.

— Жә! — диде ул, ачыла төшеп.

— Мүкләкне жигеп сабанга чыгамын.

— Кем әйтте?

— Әнкәй... Күли абзый да... Ышанмыйсынмыни?

— Әгәр сүзеңдә торсаң, ышанам.

Мин ана туп ясарга сыер йоны йолкып бирермен дип бүген иртән вәгъдә иткән идем. Бөтенләй исемнән чыккан. Нишләргә? Егет сүзе бер булыр, ди торган иде әткәй. Миңа да башка чара калмады, Тәзкирәне кулыннан алдым да:

— Әйдә алайса! — дидем.

Житәкләшеп түбән очка көтү каршыларга йөгердек.

Шунда Тәзкирә, миңа ярарга тырышыпмы:

— Әллә, Хәйрүш, чынлап та Мүкләкне жигәсеңме? — диде янәшәмдә йөгергән килеш.

Мин, азрак туктала төшеп, Күли абзыйга охшатыбрак әйтә салдым:

— Бер басуны да кысыр калдырырга ярамый, ничек тә сөрергә кирәк...

Тәзкирә бөтенесен аңлаган төсле «ә-ә...» диде сузып.

Көтү авыл башына кереп килә иде. Иң алда, бәрәннәрен ияртеп, терек-терек кәҗәләр командасы, алардан артта, урамга йон, сөт исе таратып, акыра-бакыра сарыклар, сыерлар кайта. Бөтенесе ашыга, ихатада ашлы су барын белеп, бары да кызу-кызу атлый. Яланда әлегә терлек авызына элэгерлек әллә ни юк шул. Көтү артыннан кара-кучкыл тузан күтәрелеп кала.

Тәзкирә кырыйга, читән буена тайпылды, ә мин көтү уртасында калдым. Әнә безнең Мүкләк тә кайтып килә, муенында кечкенә кыңгырау. Артык азгын булганга сугышка чаклы әткәй таккан иде аны. Һаман челдер-челдер йөри. Әгәр көтүдән кайтмый калса, кыңгырау тавышыннан барып табабыз. Хәзер бик үзбуйлый йөрми инде, өйгә туры кайта. Әнкәй дә аны, синең белән бер яшьтә, ди, олыгая инде, ди. Ә мин яңа әле егет булып киләм... Башка терлекләр арасыннан Мүкләккә әкрен-әкрен якынлаштым. Бу көтүдә безнең сыер гына ак, бүтәннәре я кызыл, я кара, я ала... Тик Мүкләк мине күреп, башын чайкый-чайкый, икенче якка каерылды. Арага кемнәрнеңдер кара сыеры килеп керде. Аны куалап, янадан Мүкләк янына чыктым. Дөрес, ак әйбер кер күтәрми. Ә тупны жиргә бәреп уйнамагач, ни пычагыма. Шулай да ак — ак инде, карар күзгә дә, тотар кулга да күңелле. Каралта икән, кыз кеше бит, үзе юар. Бу юлы сыер ябага йонын йолыкканга игътибар итмәде, кызу-кызу атлады. Ахырда иелә төшеп корсак астына үрелгән идем, ул кинәт кенә башын янга борып миңа укталды. Алдатмадым, шундук кырыйга тайпылдым. Менә инде ул, мөгезем юк дип тормый. Аннары урамның икенче ягына чыктым.

Тәзкирә шатлыгыннан нишләргә дә белмәде.

— Хәзер моны кайнар суга чылатып, озак кына әвәләрсең,— дип, аны өйрәттем.— Тыгызланмаса, сикерми ул.

— Анысын үзем дә беләм...

Бер заман, исемә килеп, күтәрелеп карасам, көтү таралып беткән. Йөрәгем жу-у итеп китте. Сыер артыннан авыл башына томырылдым...

Яктытау итәгендә Мүкләкне бозавы белән күргәч, башыма китереп суктылармыни, ыңгырашып җиргә чүктем.

Ә тегеләрнең исләрендә дә юк. Әнә Мүкләк озын муенын артка таба сузган да теле белән бозавын ялый, иркәли; әнә бөтерчеге дә кечкенә койрыгын камчы төсле селкеп, анасының җилененә борыны белән төртә-төртә имә. Дөнья рәхәтенә чумганнар!..

Урынымнан күтәрелеп, аларга таба әкрен генә кузгалдым. Әмма Мүкләк башын түбән иеп, кыска-кыска мөгрәнеп куйды, ул да булмады, күзләрен алартып, сөзәргә үк килә башлады. Мин түбәнгә әллә ни йөгерә алмадым, артымнан ул шундый итеп китереп төртте, аяк астындагы җир баш очымда берничә кат әйләнеп, тәгәри-тәгәри барып төштем. Муеныңдагы кыңгыравы да челдер-челдер туктаусыз ачулы чылтырады. Торып йөгерергә дигәндә Мүкләк тагын бәреп екты. Шар ярып акырып җибәрдем.

Шунда ниндидер ир кешенең сыерга кычкырган тавышы ишетелде. Аның югарыдамы, түбәндәме икәнен дә аера алмадым. Мүкләк тә артта калган бозавы ягына борылды, теге тавыш иясе дә яныма килеп туктады. Ул — күрмәгән, белмәгән бөтенләй ят кеше — өстенә кояшта уңган яшел гимнастерка, галифе чалбар, башына кызыл йолдызлы таушалган фуражка, аягына кирза итек кигән ниндидер солдат иде. Кулында — яшел юл капчыгы. Мин аны күргә сикереп тордым. Әмма башым әйләнүдән чайкалып куйдым. Әлеге солдат шундук беләгемнән алды да:

— Тебе очень больно? — дип сорады.

Мин аптыраудан аның озынча яңаклы ябык йөзенә тутырып карадым. Аның чәчләре генә түгел, керфегенә хәтле саргылт-ак, күзләре зәңгәрсу иде. Солдат минем аркамнан сыйпап:

— Больно? — дип сорады тагын.

Сыер сөзсен дә, авыртмаган кая инде

Аннары ул бозавы янындагы Мүкләккә төртеп күрсәтеп, нәрсәдер дияргә авызын ачкан иде, мин өлгеррәк булып, исемә төшкән беренче рус сүзен әйтеп салдым:

— Нашы.

— Айда, погоним домой! — диде ул, мине кулымнан алып.

Кара, кара, аңлыйм лабаса, сыерны өйгә куалап кайтарыйк, ди. Хәер, бишенче классны бетереп, азрак та русча сукаламагач, ни эшкә ярый. Тәзкирә кебек икенчедә генә укыган түгел лә. Шулай да монарчы рус кешесе белән бер дә сөйләшкәнем юк иде. Бераз тәтелдәргә мөмкин ләбаса.

— Әйдә!..

Икәүләп Мүкләкне түбәнгә кауладык. Бозау да иярде. Олы кеше булгач, бер дә карышып-усаллашып тормады сыер, күндәм генә атлады. Эш беткәч... Әнкәй нәрсә дияр инде? Бая Тәзкирәне очратмасам, бозауны алып кайтырга житешә идем. Каян килеп бүген Мүкләге дә Яктытауга чапкандыр... Түбәнгә төшкәч, аларны бәрәңге бакчасы артыннан үзебезнең тыкрык уңаена алып киттек. Урам тутырып кеше көлдерә-көлдерә бу килеш кайтып булмый инде. Житмәсә, Мүкләкнең муенындагы кыңгырау да, безне күрегез дигән төсле, нечкә, янгыравык тавыш белән туктаусыз чылтырады.

Солдат миннән төрлесен сорашты, өйдә кемнәрегез бар, диде, этиең сугыштамы, диде. Мин дә рус, татар сүзләрен бергә буташтырып, өйдә әнкәй белән икәү генә торабыз, дидем, эткәй Мәскәү ягында — сугышта, дидем. Шунда солдат, үзенә төртеп күрсәтеп, мин дә Москвадан, диде.

Күңелемне әйтеп биргесез куаныч бөтереп алды. Бу минутта мина ул эткәйне дә күреп беләдер төсле тоелды. Һәм мин ана дөньядагы иң якын, иң зур кешегә караган кебек сөеп карадым.

Тик ул монда нәрсәгә килде икән?

Менә без ике ягы да иске читәнле тар тыкрыктан салам түбәле өйләр тезелгән киң урамга килеп чыктык. Мин солдатка койма эчендә сирень куакларына күмелеп утырган зур гына өйне күрсәттем:

— Нашы!..

Жил капканы йөгереп барып ачтым, сыер белән бозауны ихатага тиз генә куалап керттем.

## III

Кеше алдында оятка калудан котылдым котылуын, әмма әнкәй күзенә ничегрәк, ни йөз белән күренергә? Ичмасам, солдат та үз юлына китмичә, күзләрен ихатага төбәп, һаман басып тора.

Күтәрмә янынннан әнкәйнең үртәүле тавышы ишетелде.

— Менә сыбызгы, хараплар иткән, уенга әсәреп, тагын урам чапкан...

Иш өстенә куш дигәндәй, Тайфа түтәй дә чыгып китмәгән икән, ул да әнкәйне куәтләп:

— Бу арада теле дә озынайды,— дип чәрелдәде.

Теле озынайды дип, нәрсә әйткәнмендер. Гел-гел без ашап утырганда кергәч, кичәгенәк: «Тайфа түтәй, әллә моржада төтен туктаганны карап торасыңмы?» — дигән идем. Теле озынайды дип шуны әйтүе микәнни?

Әнкәй, ашлы су тулы лаканны берүзе күтәреп, күтәрмә яныннан читкәрәк күчереп куйды.

Шунда әйләнгәләп торган Тайфа түтәй, бүген сөт эләгүдән өметен өзепме, калай чүмечен селтәп, ачык капкага таба борылды да мине күрде.

— Әнә урам алабаен!..— Шунда солдат та күзенә чалынып, төелгәндәй, шып тынды, аннары кисәк кенә кабынып, әнкәйгә кычкырды:— Карале, капка төбендә нинди солдат?

Әнкәй дә каушап калды, баскан урыныннан алга да, артка да кузгала алмый торды:

— Әллә Әнвәрбәгем инде?!.

Башка чакны булса, жир-күкне яңгыратып, аларның икесеннән дә көләр идем. Әле кая, гаебең баштанаяк ашсын да... Кемдер әйтмешли, күзләренә йон үскән, ахры, икесе дә эткәй дип ымсынды. Хәер, яхшыга юрыйлар моны бездә, ымсынган кешең белән күрешәсең, диләр.

Солдат та аларның ымсынуын сизенде, ахры, сирәк тешләрен ялтыратып елмайды, әмма ихатадагы ике хатынның да куллары кинәт салынып төшкәнен күргәч, ул шундук житдиләнде. Әллә ерактагы сугыш гарасатын әнкәй белән Тайфа түтәй йөзендә дә күреп, йөрәге парәпарә телгәләнеп куйдымы?

Ә мин моңа эчтән сөендем генә, югыйсә, бозауны кайтарып япмаган өчен әнкәйдән кисәү агачы эләгә дә эләгә иде.

Менә әнкәй белән Тайфа түтәй, канатлары сәлперәйгән ана казлар кыяфәтендә, әкрен генә атлап, әмма ниндидер яңалык белергә өметләнеп, зур кызыксыну белән капка төбенә безнең янга чыктылар.

Солдат аларга:

— Здравствуйте! — дип, баш какты.

Әнкәй дә пышылдауга якын тавыш белән тартынып кына:

— Исәнмесез! — диде.

Ә Тайфа түтәй, читкәрәк туктап, юка иренле зур авызын солдатка күрсәтмәскә тырышкандай, яулык чите белән каплаган иде.

Мин, бер дә белмәгәнем юк төсле, әлеге шул энкәйнең күнелен юмаларга тырыштым:

— Мәскәүдән килгән ул, эткәй яныннан,— дип әйтә салдым.

Болай чыннан да ул Мәскәүдән инде, үзе шулай диде, ләкин аны эткәй яныннан үк дип ялгышрак ычкындырдым.

Шулай әйтүем булды, Тайфа түтәй яулык чите белән каплаган авызын ачты да тотынды сорашырга. Солдат аның ни татарча, ни русча булмаган сүзләрен печтек тә аңламады.

Ахырда Тайфа түтәй, тавышын күтәреп:

— Әллә тый сакбайскиме? — диде.

Солдат һаман да берни төшенмәде.

— Бу бәндә урысчаны да белми, ниместер,— диде Тайфа түтәй, бик белдекле кыланып.

Пырхылдап көлеп җибәрә яздым.

— Китче әле, тузга язмаганны сөйләмә,— диде энкәй дә ана каршы.

Шунда солдат телгә килде, авыл Советыгыз кайда? дип сорады.

Энкәй сүз белән дә, ым белән дә, хәзер анда беркем дә юк диде, әйдәгез, өйгә керегез, диде.

Тайфа түтәй, кинәт кенә җилпенеп, энкәйгә ябырылды:

— Сантыкай, нишлисең, бәлки ул сугыштан качып йөрүчедер, икегезне дә суеп чыкса,— диде пышылдаулы тавыш белән.

— Ниткән качып йөрүче булсын, азрак кешесенә кара! — Энкәй Тайфа түтәйгә бүтән игътибар итмәде.— Әйдәгез, әйдә,— дип эндәште солдатка.

Аның артыннан солдат та иярде.

— Әй-й, башсызкай, үзенә җавап бирергә туры килсә, нишләрсең?!

— Бүтән кайгың булмаса, борчылма, мин — солдат хатыны!

Аның бу соңгы сүзе Тайфа түтәйгә шундый кадалды, чыдамады ул, һава шаулатып ухылдады, бергөрле сәер җилкенү белән түбән очка таба элдерде...

Өйдәге солдат энкәйгә сугыш турында сөйләми микән?

Утар алдыннан күтәрмәгә очтым, күтәрмәдән өйгә атылып кердем. Ишек төбендә энкәй:

— Котырдыңмы әллә, игелексез! — дип, бозауны карамавыма эчтән шелтәләү белән бергә, әлеге кыланышыма кисәтү белдерде.

Дөрләп янган учакка су сипкәндәй, шундук басылдым.

Өйдә дә әллә ни юк иде: солдат һәрвакыт җыештырулы түргә узган да урам як ике тәрәзә арасына эленгән рамдагы карточкаларны караштырып тора иде; энкәй, казанда нәрсәдер пешерергә җыенып, мич алдындагы ләгәннән учакка тизәк тутыра иде, бары да мин кәтмәгәнчә гадәти иде.

— Сыерларны яптыңмы?

— Әйе.

— Бар, бәрәңге алып чык.

Идән астындагы баздан аш табагы тутырып бәрәңге алып чыкканда, каты-каты басып, ишектән Күли абзый килеп керде.

— Кунагыгыз бар икән,— дип, солдат янына түргә узды ул.

Шунда аның эре сөякле киң йөзендә, таныш түгел солдатны күреп гаҗәпләнүдән бигрәк, әлегәчә мин бер мәртәбә дә күрмәгән үзсүзле кырылык билгеләре күренеп киткәндәй булды. Әмма солдат, хәрбиләрчә честь биреп, үзе белән күрешкәч, Күли абзый әүвәлге юаш, бер гөнаһсыз кыяфәтенә кайтты.

Солдат, аның бригадир икәнен белгәч, гимнастерка кесәсеннән дүрткә бөкләнгән ниндидер кәгазь чыгарып, аңа сузды.

Ә мин, авызымны ачып, бәрәңгеле табакны тоткан килеш, түр уртасында туктап калганмын.

— И-и, балакай, нәрсәгә инде сиңа зурлар сүзе,— дип, әнкәй эндәшмәсә, һаман аларга карап шулай торасы икәнмен.

Үзем дә уңайсызланып, оялып киттем, тизрәк бәрәңге әрчергә тотындым.

Ләкин эчтәге корт һич тә тынгылык бирми. Тагын тегеләрнең сүзләренә колак салам. Бу килештән бәрәңге әрчүе дә уңайсыз икән, әйтерсең кулыма беренче мәртәбә пычак тотканмын. Мич алдында самовар куеп маташкан әнкәй үзе дә аларны тыңлый, минем якка күз дә салмый.

Күли абзый, солдатның кәгазен караганнан соң, аңардан тагын нәрсәләр сорады да әнкәйгә:

— Өфедәге военкоматтан вакытлыча безгә җибәрелгән солдат лабаса,— диде.

— Үзебезнең авыл кияве лә ул.

— Ничек?!

— Теге ни, югары очта бар иде бит Габдрахман бабайлар, шулар Сатирасының кияве.

Кара, кара, сөйләшеп тә өлгергәннәр икән.

— Алар егерме беренче елны өй эчләре белән үлеп беттеләр түгелме соң?

— Сатиралары исән калды ла... Аны балалар йортына җибәргәннәр иде.

Аларга карап торган солдат та сүзгә төшенде, ахры, Соня үзебезнең авылда медсестра иде, Москва янындагы сугышта үлде, диде, ун яшьлек улым белән дүрттәге кызымны детдомга озаттылар, диде. Тик балаларының кайдалыгын белми икән. Москвадан эвакуацияләр дигән хатларын алган идем, шуннан гайре бернинди хәбәрләрен белмим, диде.

Гаҗәп хәйран хәлләр!..

Мин ул Сатира дигәннәрен күреп тә, ишетеп тә белми идем.

Күли абзый бу хәбәргә ни дияргә белми тынып торды да әнкәйгә әйтә салды:

— Тайфаттәй анда сугыштан качып йөрүче дип котны алды...

— Кайчан?..

— Әле янарак безгә килде дә, бар җәтрәк, Бикәләрдә калды, ди...

Әнкәй, үртәлеп, бер сүз белән генә:

— Юньсез! — дип куйды.

Менә ни өчен түбән очка элдергән икән ул.

— Ярый, бүгенгә сездә кунсын инде, иртәгә күз күрер,— диде тагын Күли абзый.

— Кунсын, кунсын, аларның беркеме юк ла авылда...

— Күпкә түгел ул, бер атнага гына.

— Киткәнче бездә торса да сүзем юк. Тик менә сыерны... ана сөт кирәк булыр инде.

— Иртәгә көтүгә ку, правлениедә тагын сөйләшербез.

Бәй, Мүкләкне җигәргә әнкәй ризалашкан лабаса. Тик хәзер булмый инде, өйдә кунак бар...

Мин бәрәңгене аннан-моннан әрчеп бетердем дә тиз-тиз юып, казанга салдым.

Озак тормады Күли абзый, кайтырга кузгалды. Әнкәй өтәләнеп:

— Хәзер бәрәңге пешә, самаварым да кайный,— дип кыстап та карады, тик ул күнмәде.

Әнкәй матчадагы асылмалы лампаны алды да, куыгын чүпрәк белән сөртеп, ут кабызды. Кеше булмаганда мич сырындагы сукыр лампаны гына яндырабыз. Ә бүген безнең өйдә сугышта йөргән солдат — Мәскәү абый бар.

## IV

Иртәгесен әнкәйнең пышылдап эндәшкән тавышына уянып киттем.

— Хәйрулла, Хәйрулла, дим. Тизрәк тор әле!

Күзләремне ачып булмый. Нәрсәгә бу вакытта уята инде. Әле яңа гына яттым бит. Җылы мендәрне тагын да ныграк кочаклыйм.

Тагын әнкәйнең ялынычлы тавышы:

— Тор инде, балакаем...

— И-и...

— Көтүдән сыер калды.

Бу соңгысы мине йокы исәнгерәвеннән айнытып җибәрде. Ачудан шундук торып утырдым да:

— Нишләп яттың?! — дидем чекерәеп.

— Әкренрәк, абыеңны уятасың,— дип пышылдады әнкәй.

Мин аны бөтенләй онытканмын. Шушы агач караватта кичтән ук икәү бергә яттык бит. Мендәргә чумып, әчке якта әнә нинди тын гына йоклый ул. Мин шым булдым. Караваттан да тавышсыз гына шуып төштем.

Ах, шушындый эшләр төшмәсен иде башка. Бер тапкыр үзган җәйне Мүкләкне көтү артыннан йөгерткән идем. Очраган һәр кеше урам тутырып:

— Бу нинди яшь килен?! — дип, авыз ерып калган иде.

Көтү Каенлыкка якынлашып бара иде. Каенлык дигәч тә, урман түгел, Канлыкүл чокыры буена әткәйләр, әнкәйләр утырткан полоса гына ул. Тик аны хәзер беркем дә әүвәлге яман аты белән йөртми, бары да Каенлык ди. Кайчандыр элек заманда аргы яктагы Алкын кешеләре белән безнең авылныкылар әлеге чокыр буенда җир өчен сугыша торган булганнар. Шул кан коештан килеп чыккан да инде аның әүвәлге исеме. Бөтен бәла ниндидер Кәрим дигән байның явызлыгы аркасында килеп чыккан диләр. Ике арада ни рәвешле ут йөрткәндер ул, белмим, әмма аның исемен ике авыл халкы да хәзер сүгенү сыйфатында гына телгә ала. Канлыкүл чокыры буенда мин белә-белгәннән бирле ап-ак каеннар шаулап утыра. Безнең көтү менә шул Каенлыктан күпер аша аргы якка чыгып, югарыга таба менеп китә.

Чират көтүенә бүген Тәзкирәнең картәтәсе Шәрип бабай чыккан икән. Ул безне күрүгә туктады да, чыбыркысын беләгенә урый-урый, көтеп алды. Аның өстендә күлмәк-ыштан булса да, башында колакчынын салындырган иске бүрек иде. Гаҗәп кеше ул, кышкы салкыннарда гына түгел, көннәр җылыткач та бүрек киеп йөри. Мүкләкне үзе янына йөгертеп житәрәк, ул карлыккан тавыш белән:

— Сезнең сыерны да сабанга дигәннәрие бит, нишләп куасыз,— диде.

Олы башы белән шулай кычкырып торгач, мин дә аның сакалы бар дип тормадым.

— Кем әйтә?! — дидем коры гына.

— Анысын әниең беләдер,— диде ул, сүзне кыска тотарга теләгәндәй кузгалып.

— Ә син беләсенме, Шәрип бабай, кичке акыл иртәнгә ярамаганны?

— Җә, нәрсә? — диде ул, тагын туктап.

— Бездә кунак солдат бар, Өфе госпиталеннән чыккан, сөтсез-майсыз нишлисен...

— Нинди солдат ул?

— Безнең авыл кияве.

— Кияве?.. Кемнеке?..

— Анысын кайткач үзең белерсен...

Шәрип бабай, китек кашларын җимереп, мыек астыннан сизелерсизелмәс көлемсерәде дә:

— Һайт, тел бистәсе! — дип аяк типте.

Үз сакалын санламаганны тойса да, ул, минем дә авыз тутырып сагыз чәйнәмәгәнне аңлады булса кирәк. Мүкләкне көтүгә таба куалап алып китте.

Мин Шәрип бабай артыннан бераз карап тордым да кайтырга кузгалдым. Әкрен генә атлыйм. Бөтен әтраф тын, өф иткән җил дә юк. Бары кайдадыр еракта чеңдер-чеңдер кошлар сайраганы гына ишетелә. Сабан тургайлары, ахры. Иртә уяналар икән... Ә Тәзкирә һаман да мыш-мыш йоклый булыр. Юрганы астына кул тыгып, әкрен генә аяк табанын кытыклыйсы иде. Тиберченеп елап җибәрер иде бугай. Кызлар гомергә шул, черки тешләмәс — чыррр итәр! Тукта, безнең очта ниндидер кара нәрсә очып йөри түгелме? Әллә тилгән инде. Әнә бер ихата өстеннән икенчесенә әкрен-әкрен күчә. Иртән иртүк канга сусамаса! Менә ул капылт кына түбәнгә атылды. Ниндидер хатынның һай-һаулап «дөнья» ярганы, тавыклар тузынганы ишетелде. Ләкин тилгән абзарлар артыннан шундук күккә күтәрелде. Аның озын аяклары арасында берни дә юк төсле иде. Күрше ихаталарда да тавыш кузгалды:

— Көш, көш, тилгән!..

Мин дә шул якка таба томырылдым.

Бу тирәдә рәт чыкмагач, тилгән, озын канатларын җилпи-җилпи, югары очка таба авышып күздән югалды.

Мин кайтып җиткәндә әнкәй утар алдында тыз-быз килеп йөри иде. Әнә ул аяк астындагы карачкыны алып койма буена атты, менә ул чуар тавыкны пыр туздырып читкә куып җибәрде. Югыйсә, берсе дә аңа унайсызламый иде. Нәрсәгәдер ачуы кузгалган, күрәсең. Мине күргәч тә ачылмады.

— Әллә тилгән безнең чебешләргә төштеме? — дип сорадым.

Әнкәй, бу сораудан нидер сизенгәндәй, миңа беркавым текәлеп торды да, аннары шикләнердәй нәрсә тоймаган төсле, телгә килде:

— И улыкаем, монда әле тилгәннән дә яманрагы бар...

— Нәрсә?..

Ләкин әнкәй мине баласытты, аптыратырга теләмәде, ахры, сүзне шундук икенчегә борды:

— Бар, бозауны да Яктытауга мендереп төш инде,— диде.

Менә хәзер берсе артыннан икенчесе китте, йөгер генә. Шулай да аның ярым-йорты ычкындырып ташлаган сүзен күңелгә салып:

— Әнкәй, нигә тилгән тургайлар төсле түгел? — дип, тагын авызымны ачтым.

— Явыз булганга! — диде ул, кыска гына.

— Ни өчен явыз икән ул?

— Әй, юк белән башымны катырма әле!..

Тилгәннән дә яманрагы дип кемгә төбәп әйтте икән? Беләсе иде дә, булмады.

Утарның салынкы капкасын ачтым да күшәп торган бозауны ихатага куалап чыгардым. Башка көннәрне шома борыны белән әледәнәле капкага төртеп ашыктырыпмы ашыктыра иде. Кичәгенәк кич Яктытауда гарык булганчы кинәнгәч, әле мин куалаганга да исе китмәде, әкрен генә атлады. Ачудан таяк алдым да сырт тирәсенә берне состым. Ярыйсы төште, янтыкларын сикертә-сикертә ишек алдына атылды.

Әнкәй:

— Артык чаптырма, улым,— диде дә өйгә кереп китте.

Шунда биләмдәге Акбай капкадан кайтып керде, шаярулы чаңгелдәп бозауга якынлашты. Бозауга җитә калды бу, койрыгына ут капкандай өркеп, кисәк кенә борылды да кире томырылды. Бозау артыннан Акбай элдерә, алар артыннан этка кычкыра-кычкыра мин йөгерәм,— ихата тутырып өчәү чабабыз. Ахырда түзмәдем, туктадым. Шунда

Тәзкирәләр ихатасында сузып-сузып сыер мөгрәгәне ишетелде. Колакларын торгызып бозау да шып тукталы. Акбай гына әле артка, әле алга омтылып, әзрак чәңгелдәп торды да, бу ангыра бер нәрсә дә аңламый дигәндәй, койрыгын салындырып, читкә китте.

— Хәйруллакаем, нишләп болай иртәләден?

Күрше ихатадан үземә эндәшкән тавышка борылып карасам, коймә буенда Тәзкирәнең әнкәсе Маһирәттәй басып тора.

— Әллә... мин гел шулай...

Дөресен әйтергә кыймадым.

— Әле Тәзкирәнең сынар күзе дә ачылмаган...

Тик минем Тәзкирә турында сөйләшәсем килми. Очраган саен Маһирәттәй мине: «Кияү... кияү...» дип ирештерә. Кеше алдында түгел, әлбәттә. Әле тагын кызын китереп кыстырды. Сүз дә юк, Тәзкирә әйбәт кыз. Аның мина исем атаганын хәтерләмим. Ул һәрвакыт ягымлы тавыш белән: «Хәйруш», дип эндәшә. Аны мин генә түгел, әнкәй дә ярата. Маһирәттәйнен «кияү» дикюе генә бер дә күнелгә ятмый.

Мин бу тагын телләнмәсен дип, шул ук вакытта кызыксынып:

— Нишләп сыерыгызны көтүгә кумадыгыз? — дидем.

— Сабанга диләр бит...

— Күли абзыймыни?

— Әйе.

— Шәрип бабай да көтүдә, сабанны миңа тоттырырсын әле.

— Тоттырмыйча, кияү кешегә ни...

Менә ишетмәсәң — ишет, бик сагызланып торсаң, шулай була ул!

Әллә үзенә: «Тәзкирәнең толымын тартып өзәм!» дип кычкырасы инде? Күй, болай да «тел бистәсе» диләр, я тагын әллә нәрсә әйтер.

Мин башымны түбән идем дә, бозауны куалый-куалый, урамга чыгып йөгердем.

## V

Өйгә әйләнеп кайтканда ишек келәсендә түбәтәй зурлыгы йозак эленеп тора иде. Аптырап калдым. Әнкәй эшкә китте дә микәнни? Алайса, Мәскәү абый кая булыр? Мондый чакта ишек бикле булса да, кече якта шудырып ачылмалы тәрәзә бар. Мин кайвакыт шуннан кереп, катык ашап чыгам. Учакта пешерелгән кабартма белән. Күптән инде ипи салганыбыз юк. Йөзлеккә тотынып, ниргәләргә баса-баса, тәрәзәгә үрмәләдем. Тик ул да бикле булып чыкты. Кичтәнге терәве алынмаган иде. Җиргә кире төштем. Нишләргә? Берәр яры киткәндә әнкәй Тәзкирәләргә әйтеп китә иде, әллә аларга кереп чыгасы микән?

Ихатадан урамга чыксам, безнен капка төбендә Тәзкирә басып тора. Әллә чәчен дә тарамаган инде: толымнары тузынган, маңгаенда мендәр мамыклары.

— Синен инәң дә селсәүиткә киттеме? — дип сорады ул.

Күнелемә шундук шомлы уй йөгерде: әллә бездәге солдат, Тайфа түтәй әйтмешли, шикле кеше булып чыктымы? Баягынак әнкәй: «Монда тилгәннән дә яманрагы бар»,— дигән иде, чыннан да шуңа төбәп әйтте микәнни?

— Сугыштан тагы ниндидер язу килгән,— диде Тәзкирә.

Моны куанычлы хәбәр түгелдер дип белсәм дә, җиңел сулап куйдым. Җиңел сулавым шуна — Мәскәү абыйга күнелемдәге ышанычым җимерелмәде. Әммә бу җиңел сулау шул секундта ук икенче шомга алышынды.

— Нинди язу икән?

— Әллә,— диде Тәзкирә, еларга җыенгандагы төсле борынын җыерып.

— Әйдә, без дә барабыз.
— Кирәкми, инәй самавыр куярга кушты.
Тәзкирәне житәкләп кыстасам да, ризалашмады, артка тартылды.
— Кирәкми, бармыйм.
Ахырда ана кул селтәдем дә китеп бардым. Бераз баргач, арттан килмиме дип борылып карасам, Тәзкирә безнең капка төбенә утырган да ике кулы белән күзләрен уа-уа еларга керешкән иде. Нишлисен, авыл Советындагы язу үзенә бик нык тартса да, кире борылдым.
— Ни булды?
— Селсәүиттәге язу минем әтәй турындадыр...
— Сугышта синең әтәң генә түгел... минеке дә анда.
— Әнү абзыйның хаты атна саен килеп тора, ә минем әтәйнең былтырдан бирле юк.
— Бәлки ул хат язарга ярамый торган жирдәдер.
— Нинди жир ул?
— Аны, Тәзкирә, безләге солдаттан сорарбыз, жәме?
Тәзкирә моңа ышанып, тынычлангандай булды.
— Нинди солдат ул?
Мин ана Мәскәү абый турында белгәннәремне әйттем дә борчак сибәргә тотындым:
— Медальләре шундый күп аның, дистәгә якын, бары да алтын...
— Ә ордены?
— Алары да бар... Йолдызлы орденын үз кулым белән тотып карадым.
— Ә анысы нинди?
— Ничек «нинди»? Алтын инде.
— Алдыйсың ла...
Мин, үз ялганыма үзем ышанып, үпкә катыш тыенкы гына әйтеп куйдым.
— Сине алдап миңа мал явадыр шул.
Ләкин мин аны рәнжетергә һич тә уйламадым.
Әнә ул, әлеге кыйланышымнан аптырап, гажиз бер төстә зур соргылт күзләрен елтыратып миңа карап тора.
Үзем дә сантый инде, берәр нәрсә тел очыма килдеме, тотынам икеләтә-өчләтә арттырырга, ышанырдаен да, ышанмастаен да.
— Син самавыр куюыңны да оныттың...
Кинәт кенә Тәзкирә тагын еламсырап:
— Үзем генә куркам шул,— диде.
Өйгә кергәч, «жиң сызганып» эшкә тотындык. Тәзкирә казаннан жиз самоварга су сала, мин озын пычак белән чыра теләм. Кулларыбыз тик тормаган кебек, безнең телләребез дә туктаусыз лепер-лепер килде. Күбрәген Тәзкирә сайрады. Бер дә капка төбендә әле генә елап утырган кызкай димәссең.
— Чәйне үлеп ярата ие минем әтәй. Эштән кайттымы, бер утыруда — бер самавыр. Шунсыз өстәл яныннан кузгалмый ие ул.
— Ә минем әткәй чүмеч тутырып салкын суны гөбердәтеп эчәр иде дә шуның белән — вәссәләм.
— Һи-и, аларны чагыштырырга, синеке — язу эшендә, ә минеке — тимерче. Көпозын тимер кыйнап кара да, аннан су гына эчәрсең.
— Син дә, алайса, чәй яратасыңдыр?
— Кирәге бар ие. Инәй кайчак ипине азрак кап, чәйне күбрәк эч дип карый да — барыбер.

Мин шырпы сыздым да чырага ут элдереп самовар трубасына төшердем. Тәзкирә мич авызындагы коры тизәкләрне кабалана-кабалана чыра өстенә тутырды, аннары корымланып каткан юллык трубасын куйды.
— Хәйрүш, бу сугыш озакка барыр микән, ә?

Тик аңа ничек дип җавап бирергә соң, тиз бетәр дияр идем, тизлеге күренми, озакка сузылыр дип әйтер идем, күңел ышанмый.

— Әлләче.

— Ә мин, сабан туена бетәчәк, дим!

— Белмим шул.

— Ә Мәскәүгә немецләр керә алмадылар бит?!

Менә шуңа күрә Тәзкирәгә, сугыш озакка барыр дип, әйтәсе дә килми. Әйе, без кәчле, японнарны да, финнәрне дә кыйраттык. Бу немецләрне дә җиңәрбез. Әмма тизме, озакмы — бусын һич тә әйтә алмыйм.

Шунда Тәзкирә, берничә секундка сулышын тыеп торды да:

— Инәй кайтты! — дип, ишек бусагасы аша сикереп, чыгып чапты.

Урамда Маһирәттәй югары очка карап, кемгәдер кычкырып-кычкырып сөйли иде:

— Андый кеше югаламы соң, бер-бер кулы гына да аның тегермән ташы хәтле...

Куанычлы хәбәр алып кайткан, ахры, көр тавыш белән, Шәйхи абзый турында булса кирәк, әнә нәрсә ди бит.

Мин дә йөгереп чыктым. Очраган саен аның: «Кияү... кияү...» дип ирештергәненә дә исем китмәде.

Маһирәттәй үзебезнең капка төбендә әнкәй белән сөйләшеп тора иде.

Кызы чыгып биләгенә асылынгач, ул аны кочаклап үк алды, сабый баланы иркәләгәндәге кебек, иреннәрен очлайтып, гөлдер-гөлдер сайрарга керешге:

— Кызыкаем, әтәннең исән хәбәре бар. Бәхеткәйләребез бетмәгән икән, аяз көннең кояшкайлары безгә дә насыйп икән...

Тәмам мөкиббән китеп, аларга карап торганда:

— Хәйрулла! — дип әнкәй эндәште.

Тәзкирәләр дә кереп киттеләр.

— Мин хәзер эшкә китәм,— диде әнкәй, үзе янына килгәч,— менә ачкыч, өстәлдә катык белән кабартма калдырдым... Өйне җыештырырсың.

Мин, ул әйткәннәрне колак яныннан гына үткәреп, әлеге хәбәрне ахырынача белергә ашкындым:

— Шәйхи абзый үзе хат язганмыни?

— Юк, командирлары...

— Ник үзе түгел?

— Анысын белмим, ниндидер секретнәй җирдә ди бугай.

Баягынак Тәзкирәгә: «Бәлки ул хат язарга ярамый торган җирләдер» дип, уйнап кына әйткән идем, кара инде, рас булып чыкты. Тик ул «секретнәй» дигәннәре нинди җир икән соң? Мәскәү абыйдан сорыйсы иде, сугышта булган кеше бит ул, фәлән төштә дип, анык кына әйтмәсә дә, чүтеки белә булыр.

— Кая китте, әнкәй, бездәге солдат?

— Селсәүиттә...

— Безгә тагын кайтамы соң ул?

— Кайта, кайта, тимерче икән ул, алачыкта эшләячәк,— диде әнкәй, китәргә кузгалып.

Ә мин, аерылырга теләмичә, һаман аны сөйләндерергә тырыштым:

— Әнкәй, син бүген нинди эшкә барасың?

— Нинди булсын, тирес түгәргә инде.

— Ә сәнәгең кая?

— Бәрәч,— диде әнкәй, үз-үзенә ачуланып,— ушым китә башлады, ахры, бар алып чык әле.

Өйдә кабартма белән катыкны сыпырткач, савыт-сабаны юдым, идән себердем. Аннары ишекне бикләп, кире урамга чыктым.

Шулай аптырабрак карап торганда үзләренең капка башында Тәзкирә күренде.

— Беләсеңме, минем әтәй кайда?

— Кайда? — дип, шундук капка янына барып бастым.

— Партизаннар янында, ди.

Партизаннар турында минем күп укыганым бар иде. Гаҗәп батыр кешеләр! Их, менә шулар кебек йөрергә дип, ашкынып куя идем.

Тәзкирә капка башыннан төшеп, кулындагы ап-ак йон тупны әвәли-әвәли, каршыма басты. Ул, житен чәчләрен тарап, ике толымга үргән иде. Житмәсә, күлмәген дә алмаштырып актан кигән. Мин аңа Шәйхи абзый өчен сокланып-кызыгып карап тордым. Аның әтисе партизан!.. Ә минем әткәй кем икән? Дөрес, ул да сугышта кечкенә кеше түгелдер, авыл Советында секретарь булып утырганны.

— Тагын нәрсә, Тәзкирә?

— Шул гына... Хәбәре дә шуңа килми торган.

— Ә мин әйтәм, «шул гына» түгел, партизан булгач, немецларның оясында йөри инде ул.

— Әлләче.

— Хәтта аны Берлинга ук жибәргәннәрдер әле.

Тәзкирә моңа чынлап ышанды, ахры:

— Инәй белә микән? Эштән кайткач әйтим әле.

— Әле ул китте дәмени?

— Әйе. Сыерны да алып китте. Яктытауда тапау жир сөрергә диме.

Мин аңа Мүкләкне ни өчен көтүгә куганны әйттем дә:

— Әйдә, Тәзкирә, без дә барабыз,— дидем.— Шәйхи абзый турында да сөйләрбез.

Анысыннан бигрәк, Маһирәттәй миңа сабанны тоттырырга вәгъдә иткән иде.

Тәзкирә дә киреләнеп тормады, шундук риза булды.

Күрсен әле ул минем ничек сабан сабын тотканны!

Ләкин юкка гына йөргәнбез, Яктытау өстендә беркем дә юк иде. Бары талгын жил генә үләннәрне тибрәндереп сызгырына иде.

Тәзкирә аптырап:

— Бәлки, бүген жигәргә генә өйрәтә торганнардыр,— диде.

— Әйе шул, өйрәтмичә буразнага ничек төшерәсең, ди.

Юк, мин борынны салындырмадым.

Яктытаудан күренгән киңлек — аксыл рәшә өртелгән офыклар, түбә өстендәге чалт аяз биеклек мине үзенә бөтереп алды. Мин кулларымны югары күтәрдем дә шул сихри киңлеккә:

— Һәллүррр!..— дип аваз салдым.

Бөтен әйләнә шыңгырдап яңгырады. Миңа кушылып, көмеш тавышлы кызыкай кычкырып көлде. Менә ул, сикерә төшеп, йон тубын чалт аяз күккә чөйде. Ап-ак туп, канатлы коштай, зәңгәрсу биеклеккә очты...

## VI

Мәскәү абый арып-талып кичен кайтып керде.

Ул безгә көнозын нишләп йөргәнен тел белән дә, ым белән дә аңлатты.

Алачыкта бер бөртек күмер юк икән. Ансыз нишли ала тимерче? Шуннан көнозын күмер яндырып булышкан.

Әнкәй, казаннан чиләккә жылы су салып, Мәскәү абыйга бирде дә:

— Мә, су салып торырсың,— дип, чүмечне миңа тоттырды.

Аның өчен дигәндә инде — ике аягым идәндә, Мәскәү абый артыннан йөгерә-йөгерә чыктым.

Ихатада ул гимнастеркасын, эчке күлмәген салгач, исем китеп шаккатып калдым: аның бөтен тәнендә тотам-тотам кырыкмаса-кырык кара, кызыл җөй иде. Әллә ничек, карарга да куркыныч. Ә күз дигәнең, каһәр, һаман шуңа тартыла. Янгынга да, киселгәнгә дә охшаган алар, бары да бер төрле сәер җыерылу белән тартышып-укмашып торалар. Кешенең ут эчендә йөргәне әллә кайдан күренеп тора. Сугыш турында сорармын дигән идем, уңайсызландым, әнә тәнендә күпме яра эзе, ә күңелендәгесен каян беләсең...

Мәскәү абый тәнендәге яраларына минем текәлеп торганымны сизенепме, үзе генә юынмакчы булган иде, риза булмадым, чиләктән чүмеч тутырып су алдым да: «Әйдә, әйдә!» — дип, иелергә куштым. Ул су чәчрәтә-чәчрәтә башын-муенын юарга кереште.

Ахырда, Мәскәү абый тастымалга сөртенгәндә, мин аңардан:

— Исемегез ничек? — дип сорадым.

— Михаил... сина дядя Миша булам...

Бер сүз дә әйтмәдем, бары тыенкы гына елмаеп куйдым.

Аннары ул кинәт җитдиләнеп, беренче тапкыр күргәндәй, мине баштанаяк карады да:

— Алачыкка ярдәмләшергә барасыңмы? — диде.

— Барам! — дип баш кактым.

— Көчең җитәрме?

— Үзең дә күрерсең!

Югыйсә, беләктәге «тычканны» да күрсәтергә булыр иде, тыелдым.

— Ярый, әниең риза булса...

Әнкәй каршы киләме соң, миңа эш кенә булсын, ул шатланып риза.

Өйгә кергәч, Миша абыйның сүзен шундук әнкәйгә әйттем, тик ул, мин уйлаганча, бигүк егылып төшмәде.

— Шулаймыни, үзең дә куалды чаклы, куалды да синең хәтле, кайсыгызны кайсыгыз күтәрер икән?!

Мин дә борын агызып йөри торган малай түгел, күз дә йоммадым, аңа әйтә салдым:

— Хәзер заманалар икенче!..

Әнкәй кычкырып көлде дә:

— Бар, бар, туйгач үзең дә ташлап качарсың,— диде.

Шулай да ул: «Юк белән булышып, төртенеп йөрмә», дип әйтмәде, үз ирегемә куйды, янәсе тотынып-сынап кара.

Әнкәй икебезгә дә, аш алдыннан эчегез дип, ике кружкага тутырып өстәлгә яңа сауган сөт куйды. Мин аны ике-өч сулышта капладым. Ә Миша абый әнкәйнең кыставына каршы: «Яратмыйм», дип баш селкеде. Ничек инде «яратмыйм!» Минем үземнең бөтен ашаганым-эчкәнем катык та сөт. Әнкәй ни әйтергә белми авызын ачып калды. Миша абый тагын баш селкеде. Ә без аңа тәрбия кирәк дип, Мүкләкне дә сабанга бирмәдек. Шундый талымлы булса булыр икән. Үзе тимерче. Җитмәсә, госпитальдән соң пыклап савыгырга да кирәк. Нишлисең, кешенең авызына егып салып булмый. Әнкәй аны башка кыстамады.

Нигә Тайфа түтәй бүген сөткә кермәде икән? Әллә кичәге өчен хәтере калдымы? Булыр, булыр, ул гомергә шулай, атналар буе түрсаеп, ачуташ кабып йөри.

Аштан соң Миша абый, яшел юл капчыгыннан кәгазь, каләм алып, өстәлдә нәрсәдер язарга кереште. Мин яңа киндерә ишә башлаган иске чабатамны миң астыннан сөйрәп чыгардым. Әнкәй исә тезләре тишелгән чалбарымны кәҗәнкәдән алып керде дә әнә сапларга ут янына барып басты. Тик ул җепне әнә күзенә кертә алмады, миңа кушты. Әткәй өйдә чакта аның кемгә дә булса энә сапларга кушуын хәтерләмим. Күзләре әллә нишләде, һаман шул сугыш аркасында инде: борчылу, күз яше... Шунда әнкәй бик уйчан төстә язып утырган Миша абыйга карап торды да:

— Әллә хат язасынмы? — дип сорады.

Теге дә берниндн тылмачсыз елмаеп баш какты.

Елмайса да, аның зәнгәрсу күзләрендә ниндидер сагыш-моң сизелеп тора иде.

Әнкәйгә энәсен саплап биргәч, әлеге чабатамның киндерәсен ишәргә утырдым. Әнкәй дә карават читендә минем чалбарны ямарга тотынды.

Тик Миша абыйның күңелендәге сөйләр сүзләре тел очында калган икән:

— Һаман да шул балалар эчне пошыра. Инде кайда гына язып карамадым. Юк, берниндн җавап юк. Хәер, үзем дә әле монда, әле тегендә дигәндәй... Уфа госпиталенә эләккәч, бирегә киләсе иттем. Гомер булып әллә башка күрә алам, әллә юк. Ни дисәң дә балалар анасының туган авылы... Узган елны бергәләп килергә җыенганда гына һич көтмәгән нәрсә — сугыш чыкты. Аннары икебезне дә хәрби хезмәткә алдылар. Ярый әле, балаларны Москвага озаттылар, немецлар безнең авылны нигезенә чаклы яндырып бетергәннәр... Тик менә хәзер аларны ничек табарга? Зурысы рәсем төшерергә бик әвәс иде. Аның бер рәсеме әле дә күз алдымда: күктә кып-кызыл кояш, болында эре-эре җиләкләр, ә шул болын уртасында әниләре кояшка карап тора. Кызым да туп кебек иде, туктаусыз биеп, җырлап кына тора иде... Ичмасам, шуларның кайдалыгын белсәм, бер кайгым кимер иде. Әле үзебезнең военкоматка язып карарга булдым...

Әнкәй барын да аңлаган шикелле, чалбар ямавын да онытып, аны бөтен ихласы белән тыңлады.

Миша абый, янәдән өстәлгә иелеп, кыштыр-кыштыр хат язуын дәвам иттерде. Әнкәй дә үзалдына йомылып чалбарга ямау салырга кереште. Әмма мин киндерәне ишәргә ашыкмадым, үз-үземә әсәрләнеп, уйланып утырдым. Олылар тынып калгач, күңелдә әллә нинди — эч пошу дисәң, эч пошу да түгел,— йөрәкне сызып кына сыкраткыч бер төрле авыр тойгы кузгалды. Их, әткәй!.. Әгәр син өйдә булсаң, мин шушы иске чабатамны яңадан мич астыннан сөйрәп чыгарыр идемме?

Ботинкамның «авызы» әллә кайчан ачылды. Ә башта ул нинди шыгыр-шыгыр сайрап тора иде. Кая хәзер андыйларны күрү! Хәер, анысы кечкенә нәрсә, син исән-сау әйләнеп кайтсаң, бары да булыр иде әле... Әгәр шушы минутта һич көтмәгәндә ул кайтып керсә, кеше алды дип, зурмын дип, бер дә оялып тормас идем, муенына асылынып идем дә, төкле, каты битләреннән суырып-суырып үбәр идем. Сугыштагы әткәйне сагынудан да көчлерәк берәр төрле сагышлы юксыну бар микән бу дөньяда?!. Шунда әнкәй, кулындагы энәсен кызу-кызу уйнатып:

— Селсәүиткә дә көн аралаш диярлек «кара пичәтле» язулар килеп тора, бу афәттән безнең Әнвәрбәк исән каламы инде, ходаем,— диде сузып-көйләп.— Хатларында үзе тегесен болай, монысын тегеләй итегез дип, һаман безне кайгырткан була. Без өйдә ничек тә чыдарбыз, сугыштагы кебек, өстебезгә ут явып тормый. Ул үзе турында гомергә уйлый белмәде...

Мәскәү абый, хат язуыннан туктап, башын күтәрде дә, күңеле белән әнкәйнең хәсрәтен тойгандай, әмма ничек тә ярдәм итәргә белмәгән гаҗиз бер төстә, карандаш башын авызына кабып тутырып-тутырып аңа карап торды.

— Монда чакта да шул иде. Эшкә чыгып китә дә ут алгач кына өйгә кайтып керә. Төшке ашау да юк, иртәнге бер стакан коры чәй белән көнозын чаба. Әрли башласаң, туктале, карчык, дип, кырык төрле сәбәп таба. Я берәрсенең семьясы җимерелгән дә, шуларны килештереп йөри, я булмаса, берәрсенә өйлек бурага агач юллап районга барган. Кеше өчен дигәндә, ул гомергә шулай иде...

Әй, бу сугышны!..

Иртәгә иртүк мин дә алачыкка барам.

Кичәгенәк Күли абзый: «Эш сыерларга килеп терәлгәч, ул гына кырыйда торып калмас»,— дип, бер дә юкка әйтмәгәндер.

## VII

Тыкрыкның түбән башында — инеш буендагы саман алачык, әйтерсең күптәнге ташландык бина: ишек алдында берничә ватык сабаннан башка берни дә, беркем дә юк... Бер елга чаклы бу алачык яны язга керү белән жыен төсле була иде, ир-ат халкы кыек юлны туры итеп шушында жыела торган иде. Андагы гәп, андагы мәзәк... Хәзер исә бер адәм заты да күренми.

Миша абый уйга талгандагы бер төрле авыр, салмак хәрәкәт белән алачык ишеген шалтыратып ачты. Эчтә дә күз күреп өйрәнмәгән бушлык: учакта күптән сүнгән вак күмерле саргылт көл, күрек сабы арба тәртәсе төсле югары күтәрелгән, кап-кара жир идән уртасындагы сандал бүкәне тирәсендә дә бернәрсә аунап ятмый, менә шушы сәер күренеш күңелне кисәк кенә шомландырып жибәрде.

Без башта алачык артындагы чокырдан мич алдына күмер керттек. Шакмак-шакмак күмер, жиргә бәрсәң дә ватылмый, таш кебек. Ә мондый күмерне килде-китте өйрәнчек кеше генә яндыра алмый. Аннары без ишек алдындагы ватык сабаннарны ачкыч, келәшчә белән сүтәргә тотындык. Күбрәген Миша абый эшләде. Мин дә кушканны тырыша-тырыша башкардым. Бу сабаннарның берсе дә яраулы түгел,— берсенең тәгәрмәче ватык, икенчесенең күчәре сынык, өченчесенең төрәне төптән каерылып чыккан,— алар белән ике сәгатьтән артык азапландык.

Алачыкка кергәч, Миша абый янып-янып челеп беткән иске чиләк белән учакка күмер салды, каен тузына ут элдерде, күрек сабын жай гына басарга керeште. Учактагы күмер дөрләп янган каен тузыннан зәңгәрсу сыек ялкын булып гөрелди-гөрелди яна башлады. Күңел күтәрелеп китте. Баскан жиремдә таптанып куйдым. Әйтерсең бернинди сугыш чыкмаган, бары да әүвәлгечә. Озакламый ир-атның көллесе бирегә жыелачак. Әйе, әйе... Учактагы күмернең ялкыны мина гади ялкын булып түгел, бөтен шатлык, бәхетләрне яңадан тергезүче тылсымлы бер кодрәт-көч төсле тоелды. Мин дә күрек сабына ябышам. Миша абый бер сүз дә әйтмәде, күрек сабын бөтенләй бирде дә үзе аяк астындагы сынык күчәрне алып учакка тыкты. Учакта гөрелдәү күтәрелгәннән-күтәрелде. Моңарга Миша абыйның да йөзе яктыра барды. Әнә ул кисәү агачы белән утлы күмерне күчәр өстенәрәк өйде, учакка текәлгән күзләрен кыса төшеп, үз алдына куанычлы елмайды. Әлеге сабан күчәрен кыздыру аның өчен бу минутта иң зур бәхет иде булса кирәк. Уйласаң, сугыш аркасында ул күпме көннәр шушы эшенә тотына алмаган. Чын оста һөнәрчегә бу коточкыч авыр нәрсәдер. Менә ул каралып беткән сөян саплы куалдыны кулына эләктерде дә ут кебек янган күчәрне учактан сандал өстенә салды. Мин дә күрекне өрдерүдән туктадым. Миша абый куалды белән күчәрнең кызган башын кыйный башлады. Тирә ягына эреле-ваклы «йолдызлар» чәчрәде. Мин, урынымнан кузгалмыйча, аңа кызыгып карап тордым.

Шул вакыт тышкы якта арба тәгәрмәче шыгырдаганы, кемнеңдер эндәшеп атын туктатканы ишетелде. Ул да булмады, ишектә, бөтен гәүдәсе белән көн күзен каплап, Күли абзый күренде. Бусагада тукталып беравык карап торды да жинел хәрәкәт белән кырын-кырын эчкә узды.

— Менә кайда икән ярдәмче,— диде ул.— Ә мин өй борынча кеше эзли-эзли аяксыз калдым.

Ихтыярсыз авызым ерылды.

Ләкин Миша абый аңа игътибар итмәде,— тимергә кызуында сукмасаң, сине көтеп тормый ла,— кучәрне әйләндерә-әйләндерә һаман кыйнавында булды.

Күли абзый алачык эчендәге бөтен нәрсәне күзеннән үткәрде дә Миша абыйның кул астына ук диярлек килеп басты. Солдат та, сүрелә төшкән кучәрне кыйнаудан туктап, аңа күтәрелеп карады.

— Эшли башладыңмы? — диде бригадир.

— Тотынган булдык әле.

— Әле нинди сабаннарны ремонтлыйсыз?

— Ничек «нинди»?

— Чит колхозныкы түгелме, диюем...— Сизелеп тора, бригадир Миша абыйдан риза түгел.— Әүвәл үзебезнекен карыйсы иде.

— Сезнең нәрсәләр?

— Лобогрейкалар... дүрт лобогрейканың берсе дә төзек түгел.

— Кайда алар?

— Келәтләр алдында.

Миша абый киерелә төшеп көлеп җибәрде.

— Күрәсездер, кулларым икәү генә... Ярдәмче табыгыз, кичкә бәлки тотына алырмын. Дүрт лобогрейка гына дисез бит.

— Ат тырмалары да бар.

— Алайса, ике сөйләшү юк! Башлаган эшне мин ташламыйм.

— Соң, алачык безнеке лә...

— Мин солдат, миңа кайсы колхозныкы да барыбер.

— Ярдәмче булачак!

— Әле лобогрейкагыз да, тырмаларыгыз да китерелмәгән, ярдәмчегез дә күренми, нәрсә кирәк соң миннән?

Күли абзый мондый катылыкны көтмәгән иде, ахры, шундук йомшара төште.

— Ат та алып килдем, сыңар кул белән генә булдыра алмам дим.

— Шуңа да кеше юкмыни?

— Бер кешене кырыкка бүләргә житешеп йөрим, юк... тегендә кирәк, монда кирәк...

— Мене егетне ал.

— Аның белән генә шул...

— Ә мин бүленә алмыйм, сельсоветта сөйләшкәнчә, үзем теләп алынганмын икән, бераз эшләп тә китәргә кирәк...

Алар шушы рәвешле тарткалашып алдылар: русчаны чамалавымча, моңардан артык булмаса да, ким түгел иде; ахырда барыбер килештеләр.

Миша абыйның сүзе дөрес, безнең авыл Советы икән, аңа кайсы колхозныкын ремонтласа да барыбер.

Күли абзыйныкыча, үз-үзеңне генә кан кайгырту була түгелме соң?..

Иске чабаталы аякларымны бөкләп, кабык арба төбенә җәелеп утырдым.

Бераз баргач, Күли абзыйдан читләтеп сорадым:

— Әллә бу урыс белән борчак бер дә пешмәдеме?

Ул, дилбегәсен тоткан килеш, кулсыз ягына авыша төшеп, миңа каерылып карады.

— Нигә алай дисең? — Аның яшькелт күзләрендә сынаулы караш иде.

— Һаман теге сабаннарны ремонтлап калды бит.

Күли абзый, җавап бирүдән элек, янадан тураеп утырды, юка дилбегәсен тарткалап, үшән биясен куалап алды. Әмма тегесе койрыгын чак кына кыймылдатып куйды да әүвәлгечә ялкау гына атлавында булды. Күли абзый да аны башка куаламады, кузгалган күнеле бераз

басыла төштеме, әллә әйтергә теләгән сүзен яна оештырып бетердеме, алга караган килеш эчендәгеп әйтеп салды:

— И-их, үзебезнең Шәйхи булса, барын да үзе юллап, әллә кайчан ремонтлап куяр иде. Ә менә нәрсә, безнекеме, башка колхозныкымы, исе дә китми...

Аңа каршы сүз катып, сүз көрәштереп тормадым, бер омтылуда кабык арба төбеннән җиргә сикереп төштем дә кире йөгердем. Берни сизмәде Күли абзый, һаман алга карап, сөйләнә-сөйләнә китеп барды.

Алачыктагы солдат, күрекне баса-баса, сүзсез генә ниндидер көй суза иде. Аның тавышы, калын булса да, моңлы, күңелгә якын иде. Мин ихтыярсыз тукталып калдым. Бу көй безнең «Карурман» кебек озын, сагышлы, әмма ул, беренче мәртәбә ишеткәнгәме, ят та шикелле тоелды. Бераз тыңлап тордым да шым гына эчкә уздым. Миша абый ишектән төшкән шәүләмнән мине шундук күреп алды, күрек өрдерүеннән дә, көй сузуыннан да туктап, сагаюлы гаҗәпләнеп, нигә кире кайтуымны сорады.

Мин нәрсә әйтергә дә белми капылт аптырап калдым. Турыдан әйтер идем, уңайсыз, кыекка боргаласам, барыбер беләчәк. Беравык ык-мык иттем дә, әллә ни әһәмият бирмәгәндәй:

— Әй, шуның, гел үзен генә кайгырта...— дигән булдым.

Әмма Миша абый минем тел төбемне аңлап, яныма килде дә куалдыдай авыр кулын кечкенә иңбашыма салды, шелтәле караш белән күзләремә батырып карап торды, аннары телгә килде. Син дөрес эшләмәгәнсең, диде, нинди бригадир ул үз колхозын да шулай кайгыртмагач, диде. Һәрхәлдә, мин аны шулай аңладым һәм тагын да ныграк аптырап, гаҗизләнеп калдым. Менә сиңа кирәксә, Күли абзыйны үз-үзен кан кайгыртудан гаепләдем дә үзем гаепле булып калдым. Солдат иңбашымнан авыр кулын алды да кисәтүле тавыш белән, олыларны шулай тыңлыйлармыни, диде, аннары янәдән күрекне өрдерергә кереште.

Бая күңелемне кузгаткан матур гөрелте миңа хәзер берничек тә тәэсир итмәде; алачык эче генә түгел, әлеге минутта хәтта бөтен дөнья шыксыз, ямьсез булып тоелды; тамак төбенә төер утырды.

Шулай нәүмизләнеп, каккан казыктай бераз басып тордым да тышка чыктым. Ишектән кырыйгарак туктап, кулмәк итәгемә юеш күзләремне сөрттем, тирән сулыш алып, алачык артындагы инеш буена карадым... Ни күрәм: яр буенда Тәзкирә, иңбашларын сикертә-сикертә, нәрсәдер эшләп утыра. Әллә берүзе «бишташ» уйный инде? Аны күргәч, күңел әллә ни күтәрелмәсә дә, битләремне тагын бер кат сыпыргалап, әкрен генә шул якка таба кузгалдым. Әнә ул, уң кулы белән бер ташны чөячөя, сул кулының ике бармак арасыннан башка ташларны «ояга» җыя. Менә ул ташларны «ояга» җыеп бетерә дә миңа күтәрелеп карый... дигәндә, янә икенче төрлесенә керешмәсенме. Юрамал күрмәмешкә салыша. Болай кыйланып утыруына җен ачуым чыгып, иңбашына төртеп алдым. Кызыкай да ташларын ыргытып, сикереп торды, әче бер ургәлү белән:

— Ялганчы! — дип кычкырып җибәрде.

Сүз әйтә алмадым, телем тотлыкты.

Тәзкирә күземә керердәй булып чәрелдәргә тотынды:

— Кичә нәрсә дидең, Яктытауга инәйләр сабан сөргән җиргә менәрбез, дидеңме? Мин күрмәсен дип, иртән иртүк алачыкка качкансың.— Ул кабарып торган күлмәк кесәсеннән йон тупны җәһәт кенә алды да миңа сузды:— Мә, кирәге сукыр бер тиен...

Бөтенләй каушап калдым.

Ул әлеге тупны кулыма тоттырды да тыкрыкның югарыгы башына урамга таба җан-фәрманга йөгерде.

Уф-ф, бөтенесенә үзем гаепле, ахры. Менә нинди хур итеп йөгерде, артына әйләнеп тә карамады. Ярый әле — мондагы хәлне белмәде ул, югыйсә... Күли абзый да, Миша абый да үзләренчә дөрес, күрәсең. Чынлап, нинди бригадир ди ул үз колхозын да шулай кайгыртмагач. Ә Миша абыйга вакыт калерле... Инде нишләргә? Юк, болай ярамый! Тәзкирә дә сәбәбен белгәч, кичерер...

Мин йон тупны чалбар кесәсенә тыктым да Миша абыйга күренмәс өчен, алачыкны «бер чакрымнан» урап, Күли абзый артыннан чаптым.

## VIII

Өйалдында кемдер шатыр-шотыр кул тегермәне әйләндерә.

Шул тавышка күзләремне ачтым. Агач караватта зәңгәрсу тышлы мендәр өстендә ялгыз гына ятам. Бөтен тәрәзәләрнең пәрдәләре корулы. Гаҗәпсенеп киттем. Кая Миша абый, әллә миңа эндәшмичә алачыкка киткән дәме? Хәер, мин аның өйгә кайтканын да күрмәдем. Күли абзый белән лобогрейкалар, тырмаларны алачык янына ташып бетергәч, ул миңа, бар, син кайта тор, диде. Арыган да, ачыккан да идем. Төсемә чыккандыр, күрәсең. Күли абзый юкка гына мине бәләкәйсетмәгән икән, көчкә ташып бетердек... Мин тырыш, чыдам булырга, гомумән, сынатмаска уйласам да, чарага куймады Миша абый, көйләп-көчләп дигәндәй кайтарып җибәрде. Өйдә әнкәй төшкелеккә дип пешереп калдырган кычыткан ашының яртысын «ә» дигәнче ялтыратып куйдым. Ярыйсы авыраеп, караватка яттым, шуннан гайре берни белмим... Кул тегермәне тавышына менә яңа уянып киттем.

Өйалдына чыксам, әнкәй ярма ярып маташа: идәнгә зур гына чүпрәк палас җәеп, шуңа кул тегермәне утырткан да өске ташын тоткасыннан тотып җай гына әйләндерә, уртадагы кечкенә мөшкәгә алюмин табактан учлап бодай сала, аскы таш әйләнәсеннән чүпрәк палас өстенә бүлем-бүлем ярма агып төшә. Байтактан бу кул тегермәнен кузгатканыбыз юк иде. Кәҗәнкедә бераз арыш бар да барлыкка, тик аңардан ярма ярып булмый. Мин бу күренешкә куанып:

— Кайдан бодай алдың? — дип сорадым.

Әнкәй, кул тегермәнен әйләндерүдән тагын туктап, зур хәбәр әйтергә теләгәндәй, мөлаем бер караш белән миңа күтәрелеп карады.

— Селсәүиттән солдат абыеңа китерделәр, балакаем.

— Ә кая үзе?

— Кая булсын, эштә... Кайтып ашады да китте.

— Әллә төнлә дә эшләдеме?

— Ниткән төнлә булсын, әле кич тә җиткәне юк.

Ачык ишектән тышка күз ташладым. Безнең өйнең күләгәсе Тәзкирәләр өенең почмагына да төшмәгән иде. Димәк, сәгать дүртләр чамасы гына. Йокы саташуыннан менә шунда гына айныдым.

— Ә син эштән ничек иртә кайттың?

— Бригадир кайтарып җибәрде...

Бу Күли абзыйның житешмәгән җире юк икән. Миннән алачыкта торып калган иде бит.

Шунда әнкәй:

— Балакаем, утар бик пычранган, шуны тазартып чыгарыр идең,— димәсенме.

Мин моны ничек аңларга да белмәдем.

— Ә алачыкка?

— Өлгерерсең әле, урыныннан качмас.

Малаеның күңелендәге чак кына сизми микәнни?

— Болай да соңлаганмын, эштән соң кеше көлдереп йөрергәме?

— Әле туймадыңмыни?

— Беренче көн булганга гына азрак арыткан, югыйсә...

Әнкәй баштанаяк мине күздән кичерде дә өйалдын шыңгырдатып көлеп җибәрде: мин дә аның күңеле йомшаруын сизеп, авызымны ердым.

— Нишләп берүзе генә булсын, төштән соң Шәрип бабаң да төшеп китте.

— Шулаймыни?

Мин инде тотып тыйгысызга әйләндем.

Әмма ишектән атылуга, әнкәй артымнан кычкырып туктатты.

— Кая чабасың шул кадәре?.. Алачык җене кагылмагандыр ла...

Теләр-теләмәс кире борылдым.

— Абыеңа чәй алып төш.— Аннары ул кул тегермәне янынннан күтәрелде дә, өйгә кереп, тимер чәйнек күтәреп чыкты.— Түгә күрмә, аяк астына карап атла.

Монысы инде бөтенләй шаштырып җибәрде. Хәер, алай димәсә, әнкәй буламыни ул...

Алачыктан тавыш ерактан ук ишетелде.

— Дың-дың-дың!..

Колакны ярырдай булса да бу тавыш күңелгә бик якын иде. Авыл өстендә иртәсен дә, кичен дә һәрвакыт шулай яңгырап торсын иде ул.

Ә мин, кая аяк астына карап атлау, йөгерә-йөгерә төштем. Әмма чәйнектәге чәйнең тамчысы да түгелмәде.

Алачыкта Шәрип бабай белән Миша абый гына иде.

Карты аякларын аерып баскан да сандал өстендәге лобогрейка ургычын ике куллап тоткан, ә яшьрәге шул ургычның уртадагы бер пычагына зур гына чүкеч белән кызу-кызу суга.

Шәрип бабай мине күрүгә:

— Менә тагын бер ярдәмче килде,— дип, күңелле шаулап алды.

Мин аның бу сүзенә игътибар итмәгән булып, чәйнекне почмактагы кечкенә өстәлгә куйдым да алар янына килеп бастым.

Миша абый, чүкечен сандал бүкәне өстенә куеп, лобогрейка ургычының әлеге ныгытылган пычагын тотып, тарткалап карады.

— Үзебезнекен төзәтәсезме? — дип сорадым Шәрип бабайдан.

— Әйе.

Шәрип бабайга бу тимерчелек эше бөтенләй белмәгән-күрмәгән шөгыль түгел иде. Гомумән, ул мин белә-белгәннән бирле колхозда даими эшкә йөрми иде. Шулай ук аның картмын дип, өйдә сакал сыйпап кына ятканын да күрмәдем. Һәркөнне диярлек алачыкта иде. Малае Шәйхи абзыйга бусын-тегесен булышып, һаман кыштыр-кыштыр йөрүендә иде. Әмма бирәдә аңа җиңелчә генә түгел, хәтта җиң сызганып эшләргә дә насыйп икән. Заманасы шундыйга әйләнгәч, нишләсен инде.

Миша абый кулындагы ургычны сандал бүкәненә сөяп куйды да маңгаендагы бөрчек-бөрчек тирне кул сырты белән сөртеп алды:

— Чәй китердеңме? — дип, почмак өстәлдәге чәйнекне күтәреп борынынннан голт-голт эчте, аннары ишек бусагасына утырып, кесәсеннән тәмәке янчыгы чыгарды.

Шәрип бабай да озын колакчынлы бүреген калкытыбрак куйды да солдат янына килде:

— Кая, мин дә төтәтим әле,— дип, шунда чүгәләде.

Аның тәмәке тартканын минем беркайчан да күргәнем юк иде.

Алар икесе дә төкрекли-төкрекли тәмәке төрделәр дә, урыннарыннан торып, учактан кабызып алдылар.

Алачык эченә сасы төтен таралды.

Алар янадан ишек төбенә килеп чүгәләделәр.

— Михаил браток, сезнең авыл башкаладан еракмы?

— Илле километрлар булыр... Анда электричкалар гөжләп тора иде.

Шәрип бабай тәмәкесен саксызрак суырды, ахры, азрак йөткеренеп торды, аннары сабыр гына:

— Ә үзең бу һөнәргә кайда өйрәндең, авылдамы? — дип сорады.

— Әйе, минем батька тимерче иде...

Бу Шәрип бабай русчадан яхшы гына сыпырта икән. Дөрес, бераз сакаурак төсле, әмма тиз, шома сөйли.

Шәрип бабай тәмәкесен бөтенләй онытты.

— Минем Шәйхуллага менә бу егетнең картәтәсе Габделгалләм карт куалды тоттырды.

Колакларым дөрес ишетсә дә, шаяртмыймы дип, ышанмыйча, Шәрип бабайның күзләренә карадым.

— Зрә булган кеше иде мәрхүм.

Мин картәтәйнең тимерче икәнен бер генә түгел, күп тапкырлар ишетеп белә идем, әмма бусын... әткәй белән әнкәйнең дә бу хакта авыз ачып телгә алганнарын хәтерләмим.

— Тик үзе бик коры нәрсәкәй иде. Кая аның белән гәп сатып утыру! Алачык янында малай-шалай чуалса да, хәзер утлы кисәү күтәрер иде.

Бер заман минем малай да әлеге шушы алачык тирәсендә чаба башлады. Әллә нинди тимер кисәкләре алып кайта. Күренеп тора, нидер маташтыра. Сораштырам, әйтми. Шулай да эчтә — корт. Белмәссең, Галләм картның җене кузгалып, кагылуы бар. «Анда барып, эш кешесенә мишәйт итеп йөрмә»,— дидем. Малай да, ярар, ярар, диде, каршы сүз әйтмәде. Ә ул тишек борын мине алдаган гына икән. Атна-ун көн үттеме, юкмы, Галләм карт үзе безгә килеп кермәсенме. Жу-у итеп киттем. Нәрсә кырды икән минем тишек борын? Шулай килеп керде дә Галләм карт, түрдән әйләнеп, ишек төбендәге эскәмиягә утырды. Утырды да каш астыннан миңа карап: «Малаеңның кулы нәрсәгә кычытка█ын син беләсеңме?» — диде. Йөрәгем бөтенләй урыныннан кузгалды. Әләгә икән хәзер. Ул тагын: «Тирә-якта атаклы булачак!» — димәсенме. Димәк, бур-карак!.. Шунда Галләм карт: «Менә үзе ясады», дип, кесәсеннән йозак чыгарып күрсәтте. Ышанырга да, ышанмаска да белмәдем, аптырап калдым. «Булмас ла!..» Шуны гына көткән төсле ул урыныннан торды: «Син нинди ата кеше, малаеңның йөрәгендә нәрсә ятканын да белмисең!» — диде. Аннары, түрдән янә әйләнеп килде дә кырт кисеп: «Аны миңа өйрәнчеклеккә бир»,— диде. Мин аңардан моны һич тә көтмәгән идем. Дөрес, тишек борын булса да, малайның йозак тикле йозак ясавы кечкенә нәрсә түгел. Шулай да аның үз малае бар бит. «Бер казанга ике тәкә башы ничек сыяр?» — дидем. Габделгалләм картым капылт басыла төшеп: «Минекенең тимер-томырга хирeслеге юк, күбрәк ташка басылганны укырга ярата»,— диде. Моны ул малаена рәнҗеп түгел, бала күңелендәген мин дә аңласын өчен шулай әйтте. Әлипне таяк дип белмәсә дә, башлы кеше иде мәрхүм.

Бу тишек борын шундаен авыр эшкә чыдармы дип башта курыккан идем, махы бирмәде. Ә уйласаң, Габделгалләм карт көенә түзәргә дә кирәк, көнозын туктаусыз дың да дың...

Шәрип бабай сүнгән тәмәкесен кулында угалады да ишектән тышка атты.

Улын сагыну-юксыну бөтереп алды булса кирәк аны.

Шәйхи абзый минем дә күз алдымда: йөк атыдай зур гәүдәле иде; күкрәге, беләкләре тоташ кара йон иде. Әткәй аны инәсе ягындагы картәтәсенә охшаган ди торган иде. Югыйсә, Шәрип бабайга кара, бүй үстерми калган кебек, гәүдәгә кечкенә, юка. Шунадыр, ахры, малай-шалай да кайвакыт аны өнәп бетерми иде. Теге көнне Мукләкне көтү артыннан йөгерткәндә мин дә нинди телләштем. Ә Шәйхи абзыйга алай итәрсең. Әмма ул тышкы яктан атасына охшамаса да, күңеле белән нәкъ Шәрип бабай иде: беркемгә бер авыр сүз әйтмәс. Эш дигәндә инде харап...

ФӘНИЛ МАНСУРОВ ◆ ЯКТЫТАУДА БҮЗ ТУРГАЙЛАР ◆

Шулай да мин аңламыйм, нәрсә дип әткәй картәтәйнең куалдысын үз кулына алмады икән? Әнә Кули абзый да ике сүзнең берендә: «Их, Шәйхи булса!» — ди. Әнү дип телгә дә алмый.

Миша абый да тәмәке төпчеген аяк астына ташлап, итек үкчәсе белән сүндерде, тирән уфылдап куйды, аннары ишек бусагасыннан салмак кына кузгалып:

— Да-да,— диде эчке бер мәгънә белән.

Үз алдына тынып калган Шәрип бабай, кинәт айнып, түбән салындырган башын күтәрде, чүгәләгән җиреннән торып басты, як-ягына каранды.

— Сиңа да бу һөнәргә өйрәнәсе иде, улым,— моны миңа төбәп әйтсә дә, һаман ул нәрсәдер эзләде һәм тапты, ахры, мич буендагы яшел эмале ярыйсы чәпәкләнгән иске бер мискигә күзе төште.— Һай, хәтер дигәнең, югыйсә, үз кулым белән шушында куйдым инде,— дип, ул шуны иелеп алды да мине үзе янына чакырды.— Күрәсеңме төбендәге тишекне, ямарга кирәк... Хәзер син игәү ал, шушы тишек тирәсен чистарт, ялт итеп торсын... Эшнең башы менә шул сиңа!..

Миша абый озын бер тимернең башын учакка тыкты да кисәү агачы белән күмерне өебрәк куйды. Шәрип бабай җай гына күрек сабыннан басып, учакка өрдерергә кереште. Мин дә алардан калышмадым, мискинең тишек тирәсендәге тутыгын тырыша-тырыша игәү белән кырдым.

Әнкәй: «Әле туймадыңмыни?» — дигән була, эш башында ук туйсаң, аннары харап!..

Миша абый әлеге тимерен учактан алып, ут кебек янган башын сандалда чүкеч белән тапарга тотынгач, Шәрип бабай, почмактагы өстәл янына килеп, мискидәге тишек тирәсен ничек тазартуымны яргаланган имән бармагы белән сыпыра-сыпыра җентекләп тикшерде.

— Ярыйсы, ярыйсы... Хәзер без аны менә дигән итеп ямарбыз.— Тимер чыбык саплы кечкенә чүкеч төсле паяльникны ишек ягы чөйдән алды да учактагы утлы күмергә илтеп тыкты.— Кая әле безнең кислота, әнә икән...— Рәшәткәле тәрәзә төбендәге кул аясыдай кәгазьгә төрелгән акбур сыман нәрсәне һәм кесәсеннән чыгарган ап-ак кургаш кисәген өстәлгә куйды, учактан паяльникны алып килде.— Менә паяльникны шушы кәгазьдәге кислота белән әфсенләп алабыз да, кургашынга басып, бер-ике тамчы әләктерәбез дә...

Бу арада Миша абый да кулындагы тимерне тапыйсын тапап кирedән учакка тыкты.

— Әнә күзедәй тагын бер тишегә бар... менә, менә... монысын үзең яма,— дип, Шәрип бабай күрек сабына тотынды.

Күңелемдә учактагы гөрелдәү көенә монарчы ишетмәгән-белмәгән нинидер яңа җыр кузгалгандай булды.

Ашыкмыйча, җай гына эшләдем.

Шәрип бабай да, Миша абый да үз шөгыльләрендә булдылар.

Менә хәзер әнкәй күрсен иде.

Ә Тәзкирә?..

Шул чак ишеккә башымны борсам, бусагада Тәзкирә басып тора. Әллә нишләп киттем. Шулай да сер бирмәдем, карап алдым да эшемдә булдым. Башлап аңа картәтәсе эндәште:

— Нәрсәгә килдең, кызым?

— Болай гына,— диде ул.

— Ничек инде «болай гына?» Инәң нәрсә кушканны оныттыңмы әллә?

— Үзең утын турамыйча да китмәч...

— Кәҗәнкә астында бардыр бит.

— Биш былтыр инде...

Мин мискидәге тишекне ямагач, шикләнеп кенә Шәрип бабайга күрсәттем.

— Әллә булдырдың да? — диде ул, игътибарын миңа күчереп.

— Әйе.

Тәзкирә тожыраеп миңа карап торды.

— Кургашынны күбрәк тондыргансың икән... Ярый, молодис, Тайфа түтәң үзе дә рәхмәт укыр инде...

Авызымны ачып аптырап калдым.

— Иртәгә сугыш чыгасы көнне Шәйхуллага керткән иде, шуннан бирле ятты да ятты...

Хәер, кемнеке булудамыни хикмәт. Беренче эшем бит бу минем, беренче!.. Күңелем канатланып җилпенде.

Ишек бусагасындагы Тәзкирәнең түземе бетте, ахры:

— Картәтәй дим, әйдә, инде,— диде,— казан астын тергезергә вакыт...

Шәрип бабай көлде:

— Соң, балакай, ничек итеп эш ташлап кайтыйм ди.

Миша абый да нәрсәдер аңлады булса кирәк, Тәзкирәгә карап елмайды.

Аннары Шәрип бабай миңа:

— Әллә, Хәйрулла улым, йөгереп кенә син кайтып киләсеңме?— диде.

Мин ни, нәрсә кушсалар да, картлар әйтмешли, разый.

— Абзар артында иске казыклар бар, шуны турарсың,— дип өйрәтте ул.

Мин, алачыктан чыгу белән, чалбар кесәмдәге теге йон тупны Тәзкирәгә суздым. Ләм-мим кызыкай, ник бер сүз әйтсен. Әлеге тупны, нәни песи баласы төсле итеп, иплән кенә миннән алды да кулына йомып, түшенә кысты. Бераз шул килеш баргач, ул:

— Инәйләр янына мин дә бара алмыйм, минем дә вакыт юк хәзер,— диде, иртәнге өчен гафу үтенгәндәй.

Ләкин мин ул күңелсез нәрсәне яңартырга теләмәдем.

— Тәзкирә,— дидем, сүзне икенчегә бору нияте белән,— нигә синең картәтәң жылыда да бүрек киеп йөри?

Ул башта әллә нишләп китте, аннары гына елмайгандай итеп телгә килде:

— Аның... ни...

— Пеләшмени?

— Түгел.

— Нәрсә соң?

— Әй лә...— Ул алгарак йөгергәндәй итте дә түбин күккә чөйде.— Аның колаклары юк... аклар кырыккан...

Беренче мәртәбә ишеткәндәй, эсселе-суыклы булып киттем.

Әй, бу телне, тилчә телне сандалга салып тапыйсы гына бар. Сүзне икенчегә борырга әйтерсең бүтән нәрсә беткән.

Без, тишек борыннар, күп вакыт кешенең кемлеген истән чыгарабыз.

Тәзкирә белән башка берни дә сөйләшмәдем. Эчемнән бер үк сүзне кабатлап: «Менә нинди кеше ул!.. Менә нинди кеше ул!..» ди-ди атладым.

## IX

Күтәрмә төбендә Акбай чәңгелди-чәңгелди өрергә кереште. Шул арада кемдер күтәрмәгә чабып менде дә ишек келәсен шалтырата башлады. Бу тавышка әнкәй: «Чукынып йөриләр»,— дип сукрана-сукрана урыныннан торды. Мин дә: «Кем икән?» — дип, караватта шым гына ятам. Миша абый һаман борын сызгыртуында. Көнозын тимер кыйнап артыграк арыган, ахры, әлеге тавышка селкенмәде дә. Әллә ана

районнан берәр хәбәр బармы? Югыйсә, бу вакытта безнең ишекне беркем дә какканы юк инде. Әнкәй, аяк очына гына басып, ашыга-ашыга тышкы ишеккә чыкты, тавышны тизрәк туктатырга теләгәндәй, кискен генә пышылдап:

— Кем анда? — дип сорады.

Ә тегесе шар ярып эндәште:

— Бу — мин... мин...

Тайфа түтәй түгелме соң? Нишләп йөри ул җиде төн уртасында?

— Ач инде тизрәк, сөенче!..

Урынымнан яртылаш калкынып, колакларымны торгыздым.

Әнкәй үзе дә, әллә каушаудан, ишекне шалтыр-шолтыр китерде.

— Сөенче, Бикә, сөенче...

— Тукта, әкренрәк, нинди сөенче?

Тайфа түтәй пышылдауга күчеп, колакны ярырдай сызгырулы тавыш белән кызу-кызу сөйләргә кереште:

— Әле менә Алкыннан кайтып килешем. Күкәй сатарга барган идем... Стансага яралы солдатлар төялгән тауарный килеп туктады. Кайсының башы бәйле, кайсының — бөтен гәүдәсе. Шунда сыңар кулын муенына аскан берсе бөтен вокзал буенча: «Сафардан берәрсе юкмы?» — дип кычкырды... Бу, мөгаен, берәрсеннән хәбәр алып кайткандыр дидем дә, әйберемне дә онытып, шуның янына йөгердем. Хәтта кешегә бәрелеп егыла яздым. Ул да, ерактан ук күреп, миңа каршы килде... Ие, икмәктер... Каршы килде дә: «Әллә сез Сафарданмы? Әнвәрбәкне беләсезме?» — диде. «Ничек белмәгән, ул минем кияү»,— дидем. Башта ул авылдашы гына дип уйлаган булды, ахры, күзенә басып шулай дигәч, кеше алдында мине кочаклап ук алды... Киявегез исән, апа, ул да яраланды»,— диде. Шатлыгымнан каушап калдым. Зиһенем таралды. Шул арада пуез да кузгалды. Әлеге солдат үз вагунына сикереп менде дә янәдән бөтен вакзал буена: «Гаиләсенә сәлам әйт, апа, аягы яраланды...» — дип кычкырды... Зур сөенеч бит бу... Исемә килеп, әйберем янына барсам, күкәйне чиләге-ние белән алып киткәннәр... Ие, икмәктер... Кайгырмадым, сәдакәсе булсын, дидем. Мал табыла ул... Әле менә шуннан кайтып килешем...

Өй алдына чыгарга күпме генә укталсам да үз-үземне тыйдым. Әнкәй: «Сүз җыярга чыктыңмы?» — дип, барыбер кертеп җибәрәчәк. Яртылаш күтәрелгән килеш, тынымны кысып, шым гына тыңлап яттым.

— Кая җибәрделәр ди, сорашмадыңмы?

— Сорарга өлгермәдем, пуез кузгалды.

— Ниндирәк кеше иде соң?

— Әйтеп торам бит, зиһенем таралды дип... Бер кап-кара башкорт иде бугай... Кисәк кенә каушадым да калдым.

— Ничегрәк яраланганын да әйтмәдеме?

— Анысын да юк...

— Һи-и, син дә инде!

— Минут эчендә ни генә сорашасың... Аягы яралангач, озакламый кайта да кайта инде... Кем белә, бәлки, бүген-иртәгә кайтып төшәр. Пуез көн дә килә... Итәк-чабуыңны җыя тору ярый... Әле менә төн уртасында шуңа уятеп керүем...

— Нинди «итәк чабуны» әйтәсең?

— Өеңдә ята бит... Кая салдың ул урысны? — Тайфа түтәй ишектән үрелеп карады, әмма берни күтәрмәде. — Ходай белсен! — дип куйды.

— Син диваланасың, ахры... Теге көнне дә таң тишеге белән кереп: «Фатирга урыс төшергәч, йокың килә башладымыни», дип талап чыктың... Эндәшмәм дигән идем үзеңә...

Мин Мүкләкне көтүгә куып кайткач: «Тилгәннән дә яманрагы бар», дип миңа кемгә төбәп әйткән икән әнкәй.

— Ушына кил, кызыкай...
— Юкны чәпчемә!
— Яшь чагында хатын-кыз күңелендә шайтан утыра, ди, алла сакласын, шул каһәр котыртып карап булуың бар.

Бусы әнкәйне чыгырыннан чыгарды:
— Тимә намусыма! Зимагур хатыны түгел мин!..
— У-уй, җир бит! Күпме күкәй югалттым, сөенче алырга дип, кайдан тикле чабып кайттым. Ни әйткәненне дә белмисең! — Тайфа түтәй, үкчәсенә каты-каты басып, күтәрмәгә чыкты.
— Күкәй югалткан... сөенче алырга...— Әнкәй дә, ишекне ябып, шартлатып әлеп куйды.— Әле ни хәлдәдер... кан кайгырасы урында!..

Тайфа түтәй күтәрмәдән төшкәндә тәмам шашынып тагын кычкырды:
— Сыерыңны сабанга да бирмичә, урыс сыйлап ятасыңмы?! Солдат хатыны, имеш!..

Әмма Акбай аңа башка кычкырырга ирек бирмәде, өрә-өрә капка төбенә чаклы куды.

Ярый, минем янда яткан Миша абый уянмады, югыйсә, җир тишегенә керердәй оят була иде.

Әнкәй шым гына өйгә үтте дә кечкенә сәкегә тавыш-тынсыз менеп ятты.

Мин дә мендәргә сендем.

Озак та үтмәде, әкрен генә елаган тавыш ишетелде. Күтәрелеп кечкенә сәке ягына карадым. Әнкәй башыннан ук бөркәнеп яткан, өстендәге юрганы селкенеп-селкенеп куя. Эндәшергә дип авызымны ачкан идем, сиздермәү хәерлерәк дип, кире яттым. Өзгәләнеп шулай бераз елады да ул, аннары туктады.

Бары да тынды, низаг та, бусы да... Мич астындагы чикерткә дә бер төрле оеткыч тавыш белән черек-черек сайрады. Миша абый да борынын талгын гына сызгырта бирде... Шунда йөрәк турыннан нәрсәдер әкрен генә әрнеп-әрнеп авырта башлады.

Уйласаң, әнкәйгә бернинди тавыш кузгатмаска була иде. Ярый, Тайфа түтәй сөенче алырга кергән ди. Ул бит әтлек үйлап түгел, чын күңеленнән... Әткәйнең ничек яралануын сорашмаган икән, анысын әле үзебез дә белмибез. Ничек кенә булмасын, әткәй исән... Ә Тайфа түтәйнең юк-барга бәйләнүе гомер бакыена. Урыс тотасың өеңдә, имеш. Тагын әллә нинди шайтан... Басындырып өйрәткәч ни... Әткәйгә нинди бәйләнә иде ул: селсәүиттән урлыйсың... Шунда син, әнкәй, Тайфа түтәйгә ник бер сүз әйтсәңче, киресенчә, соңыннан: «Син ир кеше, нигә шуна да чыдамыйсың!» дип әткәйне әрли идең. Хәтта бер заман Тайфа түтәй үзебезгә урманнан алып кайткан утынны да, ат башыннан әләктереп алып, үз ишеге алдына кертеп бушаттырды. Әткәй, урамдагы кешеләрдән оялып, аңа каршы тора алмады. Ә өйдә син Тайфа түтәйнең бу кыланышын хуплап: «Бик әйбәт иткән»,— дидең... Хәзер менә үзең дә ишетмәгәненне ишетәсең... Әмма бу юлы да чыдарга, әткәй хакына гауга чыгармаска кирәк иде... Үлеп сагындырды аны. Һаман хәтердә, печәнгә барганда ат дилбегәсен миңа бирер иде дә, үзе арба читенә утырып, борын астыннан бер җыруны әйләндерер дә сузар иде:

Сандугачлар сайрый, әй, кайларда-а-а?
Әрәмәкайларда, талларда...

Әткәй, көйгә-моңга әллә ни нечкә булмаса да, ялаңга чыккач, үзалдына шулай җырлый иде. Табигать кочагында сирәк йөргәнгә күңеле кузгала торган булгандыр. Югыйсә, ул я районга чаба, я авыл Советында утыра иде... Әллә нинди бетмәс-төкәнмәс эшләр...

Якында гына тонге тынлыкны ярып, кемнендер тамагы карлыккан этәче аваз салды. Аның бер-ике кат сузып-сузып кычкыруы булды, югары очтагы, түбән очтагы этәчләр дә уянды. Көндез бәрәнге гайре азык эләкмәгәч, күпчелегенең тавышы көчсез, зәгыйфь иде. Шулай да алар ничек итеп һәрвакыт билгеле бер сәгатьтә уяна торганнардыр. Чындырмы, сугыш чыгасы тенне әтраф әтәчләре гадәттәгедән иртәрәк кычкырган ди... Туктале, авылда ничә әтәч бар икән: берәү, икәү, өчәү... унау... егерме...

Кинәт кенә уянып, өстемдәге юрганны алып ыргыттым.

Минем яндагы Миша абый тын гына йоклый. Кечкенә сәкедәге әнкәйнең урыны буш.

Өй эче ярыйсы яктырган, пәрдәләре корулы тәрәзәләр зәңгәрсу...

Урамда сыерлар мөгрәгәне, сарыклар бакырганы ишетелде. Көтү китә, ахры. Бүген чират көтүендә кем икән? Безнең бердәнбер терлек сыер гына булганга, ике чират әйләнешенә бер генә чыгабыз. Тукта, нишләп әнкәй капканы ачып Мукләкне кумый? Көтү үтеп бара лабаса. Урынымнан сикереп тордым да күтәрмәгә чыктым.

Әнкәй ихата уртасында тавыклар ашаганны узалдына оеп карап тора, ә утарда, жанына урын тапмагандай, муенындагы кыңгыравын чылтырата-чылтырата, Мукләк кычкыра.

— Көтү үтеп китте бит...— Күтәрмәдән жиргә сикердем.— Нигә кумыйсың?..

Селкенмәде дә әнкәй, бары тик минем тавышка әйләнеп карады да кире борылды.

— Мукләк калды бит!..— Каршысына барып бастым. Тавыклар пырылдашып тузынды.— Сыерны... сыерны...

— Тавыкларны куркытма,— дип, әнкәй жиңемнән читкәрәк тартты.— Нишләп әле тордың?

Аның болай да ач яңаклары тагын да суырылган, күз төпләре бакыр тәнкәдәй ясмыкланган, әүвәлге мөлаем йөзендә чак кына да чырай нуры калмаган иде.

Мин тонге хәлне белмәмешкә салышып:

— Көтү тавышына,— дидем дә янәдән утарга карадым.

Ә ул һаман сузды, әткәннең хәбәре бар, аягы яраланган, диде. Алкын стансасында бер солдат Тайфа түтәңне күреп әйткән, диде, гомумән, минем әлеге тынычсызлануга игътибар итмәде, шул ук вакытта сизәм, үзе дә мине борчырга теләмәде, Тайфа түтәй белән икесе арасындагы ләм-мим.

Утардагы Мукләкнең дә сабырлыгы бетте, ахры, башы белән капканы дер-дер китереп актарырга керешге.

Әнкәй:

— Әй, чукынмыш, жимерәсең бит! — дип, кырт кына аңа таба борылып кычкырды.— Сине күптән сабанга бирәсе булган, көчеңне кая куярга белмисең.

Әллә шуның өчен аны көтүгә кумаганмы?

— Сыерны сабанга бирәсеңмени? — дидем мин, борчылып.

— Нигә?

— Мин хәзер анда чыга алмыйм, алачыкта эш муеннан.

— Кешесе табылыр...

— Алайса, үзең чыгасыңмы?

— Кем карар тимерчеләрне?!

— Юк, юк, Мукләкне бирмә, әнкәй, кеше сыеры кешегә нәрсә, кыйнап-тукмап бетерерләр...

Мукләк бахыркай да, сизенгәндәй, әнә ничек утарга сыеша алмый ярсына.

Күңелемә авыр таш төшеп утырды.

## X

Инде ике сәгатьтән артык көтәбез. Шәрип бабай һаман күренми. Көтәбез дигәч тә, кул кушырып утырмыйбыз, килүгә жиннәрне сызгандык... Эш белән булыша торгач, Мүкләк кайгысы жиңеләйде. Бу өлкәннәр бигрәк сәер, бер-бер нәрсә уйладылармы, безнең сүзне колакларына да элмиләр. Ни әйттем әнкәйгә, тыңламады... Шулай да бу Шәрип бабай нишләп һаман юк икән? Почмакта әнә күпме тишек-тошык савыт-саба жыелды. Алачыкта тимер кыйнаган тавышны ишетеп, югары очтагы, түбән очтагы хәтсез хатын кичә кич шул нәмәстәләрне күтәреп төште. Берсе:

— Аяк-кулларыгыз сызлаусыз булыр, шушы табагымны гына ямап бирегезче,— дип юмалый.

Икенчесе шома телләнеп:

— Үзегезне тавык шулпасына чакырмакчы идем дә, бүләргә тәрилкәләрем калмаган икән,— ди.

Өченчесе, дүртенчесе... Нәрсәләр генә алып төшмәгәннәр. Барына да ашыгыч кирәк. Шәйхи абзый заманында өйрәнгәннәр тиз дә тиз дип. Ә ул берсенә дә кире какмый иде, хәтта каршыларында ук әмәлләп бирә иде. Хәзер савыт-сабага бигрәк тә мохтаҗлык зур. Яңасын алыйм дисәң, кибеттә дә, базарда да юк. Әйләнәсең дә искегә тотынасың. Әгәр Шәрип бабай тизрәк төшсә, тимерче кулы көтеп яткан шул нәмәстәләрне ямый башлар идем.

Миша абый да бер лобогрейканың шатунын сүтеп алды. Валга беркетелә торган башыннан кырт сынган. Менә шуны ялгапмы, ничек булса да ясарга кирәк. Бу лобогрейканың бөтен жире төзек, бер шушы шатун аркасында эшкә ярамый ята. Әлбәттә, Шәйхи абзый заманында булса, бу кисәген атып бәрер иде дә икенчене генә ясар иде. Кая соң ана тимере! Миша абый әлеге сынык шатунны гөжләп янган учакка тыкты, бер төрле буш караш белән шунда текәлеп калды. Әллә эченнән Шәрип бабайны уйлый идеме?

Миша абый учакка бераз текәлеп торгач, мич алдындагы кыстыргыч белән ут кебек янган шатунны кире алды да сандал өстенә салды. Куалдысы да кул астында гына икән. Шатунны әйләндерә-әйләндерә кыйнарга тотынды. Кызуы сүрелеп, көл төсенә кергәнче кыйнады да суга тыкты. Чиләктән чыжлап пар күтәрелде. Нишләтә икән моны? Берни аңламыйча карап тордым. Аннары ул шатунны «сантиметр» белән үлчәде, күрекне басарга миңа ымлап, учакка яңадан тыкты. Тик бу юлы ул аны озак тотмады, кире алып, тагын бераз кыйнады, тагын озынлыгын үлчәде. Әһә, белдем, озынайта, шатунның сынып кыскарган өлеше кадәр озынайта. Кара, кара, әллә ни нечкәрмәде дә. Хәзер шатунның валга беркетелә торган башын гына эшлисе калды.

Шунда күзем төшеп, ишектән карасам, кулларын жилбәгәй җибәреп, тыкрыктан җәяү генә Күли абзый төшеп килә. Үзе ашыга, бер йөгерә, бер атлый... Ни булган аңа? Гомергә үз җаена гына йөргән кешенең дә сөякләре җиңеләер икән. Әлегәчә мин аның болай каушаганын бер дә күргәнем юк иде. Миша абыйга: «Күли абзый килә», дип әйтергә дә өлгермәдем, аһ-ваһ итеп алачыкка үзе дә килеп керде. Шул уңайга баш кагып исәнләште дә:

— Шәрип агайны югалттыгызмы? — диде, ниндидер бер мәгънә белән.

Миша абый, безнең бригадирны әүвәлдән белмәгәнгә, аның әлеге халәтенә игътибар итмәде, бары:

— Әллә бүтән яры җибәрденме? — диде.

— Алай гына булса... Селсәүиткә малае турында язу килгән дә, йөрәге тотып егылган.

— «Похоронный»мыни?

— Юкка чыкты дигән хәбәр...

Мин бөтенләй аптырап калдым:

— Әле кайчан гына командирлары секретный җирдә, партизанлыкта, дип хат язган иде.

— Әнә шул хат инде, селсәүит прсидәтеле алдаган гына...

Тәзкирә белә микән инде? Теге көнне нинди шатланган иде бахыр. Елыйдыр, болай да нечкә күңелле нәрсәкәй.

— Да-а!.. Да-а!..— дип кабатлады Миша абый да үзалдына.

— Шул язуны күреп калган берәү Шәрип бабайга бүген иртәнчәк ычкындырып ташлаган. Дөрес, яманлыктан түгел инде, белмичә, ялгыш...— Миша абыйга аның исем-атын әйтеп тормады ул.— Хәер, монда кемне дә гаепләве кыен. Күптән түгел күрше авылда бер хатын шулай үлде. Хат ташучы кыз берни әйтми-нитми кертеп биргән дә... Шуннан соң андый хатларны селсәүит прсидәтеле үзенә ала башлады. Бәлки, кайберәүләрне ымсындырып тору да хәерледер...

— Да-а!.. Да-а!..

— Менә Шәрип агай... Ишетүгә тизрәк чабып барган инде. Өстенә басып сорагач, прсидәтел дә, нишләсен, боргалап тормагандыр. Карт кешенең йөрәге андый авыр кайгыны күтәрә аламыни. Ни дисәң дә житмешнең өстендәге кеше.

— Да-а!.. Да-а!..

Күли абзый беравык тукталып торды да:

— Бу сугыш күпләп чүпли башлады әле, беркөнне ике кеше турында... берсе яраланган, берсе хәбәрсез югалган... коточарлык нәрсә бит, ә! — дип, борын астыннан үзалдына сөйләнде, аннары сулышы кысылгандай бөтенләй тынып калды.

Әмма беребез дә эчтән тынмады. Әнә Миша абый, кырыс карашын бер юнәлешкә төбәп, үзе дә сизмичә: «Да-а!.. Да-а!..— дип һаман кабатлады. Менә Күли абзый, күңеле тулышкан бер кыяфәттә, нишләргә дә белмәгәндәй, әледән-әле башын селкеп куйды. Бәлки алар бу минутта — берсе ут эчендә бергә йөргән дус-иптәшләрен күз алдына китергәндер, икенчесе барча ир-ат авылдашларының шушы алачык алдында кичләрен шау-гөр килеп утыруларын сагынып хәтерләгәндер. Минем дә күз алдына китерердәй, сагынып хәтерләрдәй истәлекләр күп. Монда хәзер шунысы мөһим: агачның очы корыса, тамырына җитә, диләр, берүк Шәрип бабайның хәле яхшыра күрсен!..

Башны юләрләтердәй бу уйлардан беренче булып Миша абый айныды:

— Шулай да сыгылып төшәргә ярамый, үч итеп, дошманга үч итеп!..— диде ул.

Әйе, усал җилләр сыгылган агачның ботакларын да каеручан була.

Солдатның бу сүзләреннән Күли абзый башын югары күтәрде, күзләрен зуррак ачты.

— Шәрип бабай өчен үзем эшлим! — дип, эчемдәген мин кычкырып ук салдым.

Азрактан Күли абзый үтенгән рәвештәрәк Миша абыйга:

— Иң элек тырмаларны карап алыйк,— диде.

— Ярый, ярый... Башта менә бу шатунның эшен бетерим дә...

Күрәсең, сөрелгән басуны йомшартырга тырмалар бүгеннән кирәктер.

Алачыкта куалда белән тимер кыйнаган тавыш, су буйларыннан авыл өстенә артылып, тагын да ныграк яңгырады.

— Дың... дың... дың!..

## XI

Миша абыйның эшләре тагын да тыгызланды.

Төштән соң алачык алдына күрше колхозлардан сабан, лобогрейка, жилгәргеч кебек нәрсәләр китереп тутырдылар. Тимерчегә ярдәм итәргә ике кешеләре дә бар: берсе бүгенме-иртәгәме солдатка алынырга торган яшь кенә егет, икенчесе, Шәриф бабай ишеләре булыр, ябык кына озын буйлы бабай иде. Алар да килү белән эшкә тотындылар.

Ә мин менә шундый чакта тугарылдым куйдым. Һич уйламаганда...

Тырмаларның тешләрен барлап бетергәч, Күли абзый мина:

— Бик кибектерде, энекәш, бар, әйрән алып төшче,— диде.

Үзем дә бераз ялыккан идем. Миша абый кушканнан бушаган арада ике савыт ямадым, өченчесен ямарга чистартып куйдым. Бер минут та тик торылмады.

Мин Күли абзыйга баш кактым да чыгып йөгердем.

Тар тыкрык арасын ике-өч кенә талпынганмындыр, ямь-яшел үлән сарыган кин, якты урамга килеп чыктым.

Күзләрем камашып калды.

Бер мәлгә тукталсам, хәйран тамаша: түбән очтагы ике хатын безнең Мүкләкне ат арбасына жиккәннәр дә, берсе башыннан, икенчесе тәртәдән тотып, әйләме әйдә, урам тутырып киләләр. Муенындагы кыңгыравы моңсу гына чылтырый. Житмәсә, өере белән бала-чага ияргән. Кычкыралар, бакыралар. Кара инде, кара... Әйтерсең ниндидер бер сылуны борынгыча рисвай итеп йөртәләр. Камыты да камыт төсле түгел, ике пулән агачы. Йодрыкларымны таштай кысып, бар булмышыма көдерәеп, аларга каршы кузгалдым.

— Нишләп мыскыл итеп йөртәсез?!— дип, сыерны башыннан эләктереп алдым.

Мүкләк тә сизенде — тартыла-сугыла атлаган жиреннән шып туктады; кайнар сулышын бөтен йөземә бөркеде, зур ачылган юеш күзләре ялварулы елтырады.

Әлеге түбән оч хатыннары,— берсен Әдүкәй бичәсе, икенчесен Хәбибкамал дип йөртәләр авылда,— чәрелдәшеп миңа ябырылмадылар, киресенчә, тәмле телләнеп, юмаларга керештеләр.

— Тимерхан булмады бу, чистый Күли... Шушындый хужасы барында, нишләп безгә өйрәтергә кушкандыр. Адәм тәганәсе...

Хәбибкамал шулай башлауга, Әдүкәй бичәсе дә тотынды:

— Егете егет инде генәме! Күлыннан килмәгән эше юк. Алачыкка да белми куймаганнар...

Уф-ф, йөрәккәем, ишетәселәрем бар икән.

— Кая чыбыгыңны! — дип, мин «ыбыр-чыбыр»ны аралап, арбага сикердем.

Хәбибкамал озын тал чыбыкны миңа шундук бирде. Әмма Әдүкәй бичәсе сыерны ычкындырмады.

Миңа ышансалар да, Мүкләккә — юк, ахры.

«Һа-ай» дип кычкырып, аягүрә бастым. Мүкләп минем тавыштан коты очып, капылт-кинәт алга ыргылды. Үзем дә, тез буыннарым ычкынып, арба артына чак-чак әйләнеп төшмәдем. Әдүкәй бичәсе дә, тәртә башына сугылудан куркып, читкә тайпылды. Хәбибкамал исә:

— Нишлисең, адәм баласы?!— дип сөрәнләде.

Бу ике хатынның берсе дә моны көтмәгән иде.

Мин дә сыер башыннан эләктереп алганда уйламаган идем, алар төчекәйләнеп торган арада арбага сикереп мендем. Алар шундук сизенгәндерме, белмим, әмма вакыт сузып тормадым, бу юлы инде ачыктан-ачык чыбык белән Мүкләкнең сыртына салдым. Сыерның күзенә ак-кара күренмәде, арт аякларын тәртәгә шарт-шорт бәреп, койрыкларын болгый-болгый шашынып чапты. Тегеләргә әйләнеп карый

да алмадым. Тәгәрмәч шыгырдавына, ачулы чылдыраган кыңгырау тавышына нәрсә кычкырганнарын да ишетмәдем. Ул да түгел, сыер «арка башына» менә торган тар гына тыкрыкка таба борылды. Ә аның бу як кырыенда «телеграм» баганасы. Әгәр Мукләкне урам уртасына каера алмасам, арба күчәре бәреләә дә бәреләә. Шул чак үзем дә арба әрҗәсенә тәгәрәдем. Исемә килеп, урынымнан торганчы, нәрсәнедер аударып-җимереп үттек. «Телеграм» баганасын дияр идем... Күтәрелеп, артка күз ташласам, тыкрык почмагындагы иске читән казыгы-ние белән актарылып аугaн. Мин әлегә бернәрсә турында да уйлый алмадым, бары шул — тегеләрдән тизрәк качарга, тизрәк качарга!.. Шулай да арба читенә тотынып чүгәләдем. Мукләк тә сүреләә төште, ахры, баягыча шашынып сикерә-сикерә чапмады. Әнә тыкрыкның урам башында бала-чага күренде, аннары тегеләр. Әмма бары да җимерек читән янында туктап калдылар. Менә без авыл артында җәелеп яткан «арка башына» килеп чыктык. Әллә монда куркынычсызлыкны тоеп, әллә хәлдән таеп, кайсы булгандыр, Мукләк тагын бераз әкренәйде. Мин дә куркып тормадым, сикереп төштем дә башыннан әләктереп алдым... аннары тәртә арасыннан чыгардым.

Әнә ул, әле генә булган хәлләргә аптырагандай, башын түбән салындырып, туктап калды.

Тегеләрнең берсе дә арттан менмәде.

— Котылдык.

Әнкәй артык орышмаса ярый ла. Хәер, орышса, үз башым үземдә түгелмени? Әйттемме ана: «Бирмә!» — дип, әйттем.

Тик менә тыкрык башындагы теге читәнне генә нишләтергә?..

Кинәт кенә Мукләк түбән салындырган башын күтәрде дә авыл ягына карады, тамак төбе белән кыска-кыска мөгрәнеп куйды. Нәрсә бу, барыбер булдыра алмадыгыз диюеме? Аннары, колакларын торгызып, бөтен бәдәненә шул якка таба борылды, каты-каты басып, кыю гына бер-ике адым атлады.

Бәрәңге бакчалары артында — читән буенда безнең кызыл бозау тожыраеп карап тора лабаса.

Нишләп әле биредә ул? Әнкәй Яктытаугa кумады микәнни?

Мукләк тә аны кай арада күреп алгандыр.

Бозау, чакыруны ишетүгә, кечкенә койрыгын камчыдай селтәп, нәзек сыйракларын кояш нурында елт-елт китереп, чабулый-чабулый килде. Шулай чабулап килде дә,— һаман бар белгәне шул,— шома борынын җәтрәк анасының җиленәнә төртте. Мондый иректә очрашканда аларны аерырга уйлама да. Теге көнне Мукләк Яктытау итәгендә нинди көлерәеп миңа ташланган иде. Ярый шунда Миша абый килеп чыкты, югыйсә, бөтен кабыргаларны санын иде. Менә әле дә ул бозавын беравык кызу-кызу ялады да башын күтәреп тирә-ягына каранып алды. Янәсе, ул-бу юкмы? Ә үзләренә шундый рәхәт, ахры, берсе комсызланып тәртә-тәртә имде, икенчесе билен сыгылдырып-сыгылдырып куйды. Карап торулары бер хозурлык!

Бу юлы мин үзем дә аларны аерырга теләмәдем. Барыбер Миша абый да сөт эчми, әйдә рәхәтләнсеннәр. Бер-береннән канәгатьләнгәч, икесен дә арырак — кеше күзеннән аулак төшкәрәк алып киттем.

Алачыктагы эш тә, Күли абзый сораган әйрән дә онытылды.

Ләкин миңа бу килештән әллә ни озак йөрергә туры килмәде.

Чирәм өстендә, әткәй шикелле борын астыннан моңланып, сыер ашаганны саклап утыра идем, шунда:

— Менә кая качкан ул! — дигән тавышка сискәнеп киттем.

Борылып карасам, җил-давылланып әнкәй килә. Күлмәк итәкләрен ыштан бөрмәсенә кыстырган. Кулында тал чыбыгы да бар.

— Хәзер сыртынны каезлыйм!..

Мин сикереп тордым, үзем дә сизмәстән, берничә адым артка чигендем.

— Әнкәй!.. Соңыннан, соңыннан... Әйдә башта сөйләшик!..

— Соңыннан дисеңме?! — Әнкәй бер-икене эләктереп тә алды: — Менә сиңа, менә сиңа!..

Болайга киткәч, мин дә үзсүзләнеп:

— Мә, рәхәтләнеп каезла! — дип, аркамны ана каршы куйдым.

Бусы үтемлерәк булды, ахры, күз бәбәкләрен биетеп, капылт туктап калды ул, аннары сузып:

— И-и, балакай, бу кадәрле Тайфа түтәңә охшарсың икән, бөтен холкың аныкы,— диде.

Мин катып калдым, бүтән сүз әйтә алмыйча:

— Син үзең,— дип ыңгыраштым.

Чыннан да, мин аның үзенең кайбер кыланышларын Тайфа түтәйнең холкына охшата идем.

— Әйдәле алайса, сөйләшик...

— Нишләп мин Тайфа түтәйгә охшыйм ди?

— Сүзне икенчегә борма, җәме!.. Мин бит иртән татарча әйттем сиңа, оныттыңмыни?.. Әткәң анда яраланып ята, без монда шулай кыйлансак, нәрсә булып бетәр?

Кара, кара, бер дә Тайфа түтәйгә уч итеп дими.

— Тирес түккәндә ат арбасына җигелеп, бөтен җилкәләребез чиләнеп бетте. Инде сабанга да, тырмага да үзебезме?!.

— Чит кеше карап йөртәмени аны?!.

— Урамда иплән кенә өйрәткән сыерны кем дулатты?.. «Чит кеше» дигән син юләр түгелме? Җитмәсә, кеше читәнен җимергәнсең. Хәзер аны ничек төзәтәсең? Китергән казыгың, кискән талың бармы?.. Ярый, сыер яңып егылмаган... Ниең калганые сиңа урамда? Алачыктан туеп качтың дамыни? Мактанчык!..

## XII

Кичә өйгә кайткач читән хуҗасы артымнан бастырып керде дә тотынды тиргәргә, чыда гына. Шуның өстенә әнкәй дә тәбе-тамыры белән янадан купмасынмы. Бердәнбер кеше Миша абый гына мине яклады:

— Тимәгез малайга, аныкы да дөрес,— диде.

Шулаен шулай да, әмма Хәбибкамал белән Әдүкәй бичәсе Мүкләкне бүген дә алып киттеләр.

Бер сүз дә әйтә алмадым, күтәрмә төбендәге Акбайны кочаклап:

— Су менә шулай болгана,— дип мыгырданып калдым.

Бүген алачыкка бару түгел, хәтта ул якка борылып та карый алмадым. Юк агачны табып, шулардан казык очлап, көнозыны диярлек вакытым үтте. Ә тыкрык башындагы читән, бөтен авылга мине рисвай итеп, кичә дә тузынып ятты, бүген дә. Ичмасам, хуҗасы да шуны азрак рәтләп куя белмәде.

Абзар алдында йомычкаларны җыештырганда капкадан Миша абый кайтып керде. Кайтып керде дә, минем янга килеп, ирештергән шикелле:

— Эшләр барамы? — диде.

Мин дә сер бирмәс өчен сорауга каршы:

— Нишләп иртә кайттың? — дип сорадым.

Ә ул, һаман авызын ерып:

— Кайттым әле,— диде, аннары кесәсеннән һич көтмәгән нәрсә — өчкел конвертлы хат чыгарып күрсәтте.— Балалардан килде...

Ярый әле — үпкәләп өлгермәдем.

Үзем дә искәрмәстән, аның кулындагы хатны тартып алдым, конверт тышындагы кәкре-бөкре язуларга карадым. Анда сызыла-сызыла төрле кул белән берничә адрес язылган иде: Полевая почта... Москва... Уфа... Алкинский... Башта берни аңламадым, кат-кат укыдым.

— Ике айдан артык мине юллап йөргән,— диде Миша абый.

Менә ни өчен адрес өстендә адрес икән.

— Нәрсә язганнар?

— Түмәнне ишеткәнең бармы? Менә шул якка җибәргәннәр.

— У-у, Себердә үк, еракта...

Миша абый хатны кесәсенә кире тыкты.

— Бу казыклар теге читәнгәме?

— Шулай иде дә...

— Әйдә алайса, төзәтеп алыйк.

Миша абыйның шатлыгы эченә сыймаганы сизелеп тора.

— Бүген алачыкка төшмисеңмени?

— Анда да өлгерербез...

Башта без ауган читәнне иплән кенә торгыздык, берничә терәү куйдык, аннары су сала-сала казыклар утырттык.

Берүземә көн озыны җыкланырга җитә иде бу.

Казыкларны утыртып бетергәч, ул:

— Боларны тимер чыбык белән тарттырып куясы иде,— диде.

Әткәй заманасыннан бирле кәҗәңкә астында яткан алюмин чыбыкны тәргәге белән өстерәп алып чыктым.

Кара-каршы торган казыкларны бер-беренә шундый тарттырып бәйләде ул, пар ат белән давыл кузгатып үтсәң дә, әлеге читән хәзер «әһ» тә итәрлек түгел, койма төсле булды.

Ахырда Миша абый уң кулын иңбашыма салып, җитди генә:

— Әйберләрне җыештырып керт тә, Шәрип бабаңның хәлен белеп чыгарбыз,— диде.

Әйберләр дигәне: балта, кул пычкысы, чүкеч һәм келәшчә — шуларның барын чиләккә тутырдым да тиз генә ихатага кертеп, өй артында калдырып чыктым...

Тәзкирәләр ишеген ачуга әллә нинди дару исе борынга ярып керде. Җитмәсә, күз дә тышта калган, аяк астындагы чабатага сөрлегеп чак егылмадым. Шул арада тирә-юнь азрак ачыла төшкәндәй булды: болай да кечкенә өйнең урам як тәрәзәләре корулы, пәрдәләр җыелмаган иде. Тыштан кояш яктысы төшмәгәч, хәтта ап-ак мичнең йөзенә сары суккан төсле күренде.

Шәрип бабайны түр сәкегә салганнар иде.

Без ишек төбеннән үк кычкырып сәлам биреп тормадык, болай да хәле билгеле, аяк очы белән генә басып тавыш-тынсыз аның янына уздык.

Ул да ияк астына тикле бөркәнгән юрганын бераз ачты да җинелчә калтыранган сөякчел сул кулын күкрәгенә салды.

— Авырып киткәнсең икән,— диде Миша абый, аның хәленә керергә тырышкандай, йомшак тавыш белән.

Шәрип бабай сизелер-сизелмәс кенә баш кагып куйды. Шунда мин мендәр өстендәге бүрексез башын күреп, игътибар белән текәлеп карадым. Колаклары төптән үк юк иде, алар урынында зур-зур яра эзләре дә кечкенә түгәрәк тишек иде. Тик мин кызганулы бер чиркану белән карашымны шундук читкә алдым.

— Өйдә беркем дә юкмыни?

Миша абыйның соравына җавап бирүдән элек, ул башын кырыйгарак кучереп, җайлап салды, аннары кипшенгән күксел ирennәрен кыймылдатып:

— Килен эштә... кайтырмын дигәние дә, һаман юк әле... Кызны районга жибәргәниек, дарулар алырга...— дип, зәгыйфь тавыш белән көйләбрәк русча сөйләде.

— Хәлең ничек соң?

— Хәл шул инде... уң як саным кузгалмый. Әллә ничек сөм тоймас булды. Камфор белән дә сылап караган иек, име тимәде...

— Паралич микәнни?

— Әллә инде.— Шәрип бабай күкрәгенә салган кулы белән юрган астындагы уң кулын чыгарды.— Менә бит бармаклары да селкенми.

Чыннан да, аның уң кулы сынган гөл ботагы шикелле иде, мускуллары да бәлшерәйгән, тиресе агарган иде.

— Больницага барырга кирәк.

— И-и, анда миннән гайре дә тулыдыр.

— Бу килеш ятарга ярамый.

— Юк инде, үлсәм шушы түшәгемдә үләм...

Миша абый тынып калды.

Бу өлкәннәрнең берсе дә Шәйхи абзый турындагы хәбәрне кузгатмады.

Шәрип бабай да шундук:

— Үзегез ничек соң? — диде.

— Балалардан хат килгән дә, шуны алырга кайткан идем...

— Шулаймыни? Исәннәрме?

Тик Миша абый эчендәген ана сиздермәде. Кешенең хәсрәтле чагы, житмәсә, түшәккә егылган, синең сөенеч-куанычларын аның хәсрәтен тагын да көчәйтәчәк. Андый чакта күңел кыллары кирәгеннән артык киеренке, үтә нечкә булучан. Шуңа күрә Миша абый аның соравына сабыр-сүрән генә җавап бирде:

— Түмән өлкәсендәге Кондинский дигән җиргә урнашканнар.

— Конда дисеңме? Түмәннән төньякка китеп...

— Анысын язмаганнар, белмим.

— Башкача булмас,— диде ул, кинәт житдиләнгән карашын түшәмгә күчереп.— Колчак җиңелгәч, безне шунда җибәргәннәрие...

Түшәктә ярты сансыз яткан Шәрип бабай Миша абыйның шатлыгын йөрәге белән тоеп, хәттән ашкан үз кайгысын тәмам оныткандай, берьюлы җанланып киткән төсле булды.

— Баржа белән айдан артык бардык.

— Башка юл юкмыни?

— Хикмәт тә менә шунда. Үзәк юл өстендә Колчак җиңелсә дә, кеше үтмәс җирләрдә — төньякта һаман әүвәлгечә ие. Безне Совет власте ясарга җибәрделәр. Тура — Тобол — Иртыш — Конда елгалары аша бардык.

— Ай-һай, аннан кире кайтулары да...

— Курыкма, кайтырлар... Анда байлык зур, суында балык, урманында җиләк дигәндәй... Исән булуларына шатлан.

Кире чыгар алдыннан Шәрип бабай миңа:

— Син ни хәлдә, дөнья җимерәбезме? — диде авыз кырые белән көлемсерәп.

Нәрсәгә төрттергәнен сизеп торам.

Шунда Миша абый да шаяртып әллә нәрсә әйтте.

Соңгы вакытта мин аның «татарчасына», ул минем «русчама» шундый өйрәнеп киткән идек, кем нинди телдә сөйләшә — игътибар иткән юк, ярты сүздән кирәген эләктереп ала идек.

Ә бу юлы аңламый калдым.

Шулай да каушамадым, Шәрип бабайның күзенә туры карап, елмайдым да:

— Җимерәбез,— дидем.

## XIII

Төшкелектән яна гына килгән идек.

Кояш та алачык тәрәзәсеннән яңа гына авышкан иде.

Сулышына кабынырдай булып Күли абзый килеп керде.

— Бар, Хәйруш, әнкәңә дәш, Яктытауда сыерыгыз әллә нишләде,— дип кычкырды.

Бәлки ул кычкырмагандыр да, һәрхәлдә, миңа шулай тоелды.

Әмма аның каравы, мин бер сүз дә әйтә алмадым, шул мизгелдә, күзән җыердымыни, катып калдым. Ничек катып калсам, берничә секундтан соң шулай бар булмышка кубып, алачыктан чыгып йөгердем.

Күпме генә чабып кайтсам да, ишектә әлеге шул түбәтәй зурлыгы йозак иде.

Кая китте икән әнкәй? Суга дисәм, көянтәсе күтәрмә башында эленеп тора. Берәрсенә керде микән? Алай дисән, бала-чага, карт-корыдан гайре беркем дә юк авылда.

Күли абзый да безне узып, юкка гына алачыкка төшмәгәндер, ул күргәндә дә, күрәсен, өй бикле булгандыр.

Юк, минем дә сабырлыгым житмәде, урамда бик азга тукталып, түбән очка, югары очка каранып тордым да Яктытауга чаптым.

Күзләрем белән ерактан ук Яктытауны айкадым. Битләвендә борчылырлык нәрсә күренми. Бары тик шул — Яктытау яшел күлмәген киеп алган да, итәкләрен аяк очына тикле җәеп, кояш күзендә тын гына уйланып ята. Юк, юк, бу ерактан гына шулай, янына барып житүгә ул, күптән көткән төсле, көчле жиле-сулышы белән бөтереп алды да күкрәгенә күтәрде. Ә монда — берничә ел тапауда яткан бу басуда — ят бер күренеш: әнә соңгы буразна буенда сабанга жигелгән сыерлар, әнә алардан читтәрәк уюлап хатын... Мин алар янына барып житкәнемне дә сизмәдем. Биредә, хатыннар әйләнәсендә, Күли абзый белән Миша абый да бар иде. Әмма мин берсенә дә игътибар итмәдем, аякларын сузып уртада яткан сыерыбызны күрдем дә:

— Үлгән!..— дип үзалдыма пышылдадым.

Мүкләк башын арткарак ташлаган да, кемгәдер бик каты рәнжегән сурәттә, берниндн хәрәкәтсез-тынсыз ята; зур кара күзләре салкын, жансыз, авызы бераз ачылып, нык кына кыйшайган.

Елый да, сораша да алмадым.

Әдүкәй бичәсе еламсыраган тавыш белән:

— Балагә тарыдык,— диде.

Ә Хәбибкамал, киресенчә:

— Әнә Тимерхан үзе җавап бирсен,— диде.— Тәмле телләнеп, юмакайланып кына йөрмәсен.

Тик Күли абзый эндәшмәде. Хәер, биредә эндәшүдән узган иде инде.

Бераздан әнкәй дә мал «брачына» утырып килеп житте. Берәрсе очрап әйткәндер, күрәсен. Ул ат туктаганны да көтеп тормады, арбадан сикереп төште дә бер төрле улаган шикеллерәк аваз белән Мүкләккә ташланды:

— Жаннар кебек иде сыер-каем, хараплар гына бул-га-аан!

Бөтен тәнем-җаным тетрәнеп куйды.

Кайбер хатыннар да түзмәделәр, күзләрен яулыкларына сөртә-сөртә кырыйга борылдылар.

Әнкәй, Мүкләкнең башыннан кочаклап, такмаклый-такмаклый үкседе.

— Сөтенне беркайчан да беркемгә кызганмадым лабаса-а...

Чыдый алмадым, читкәрәк китеп бастым.

Кинәт зәңгәрсу күктә буз тургайлар чыңравы ишетелде. Күтәрелеп карасам, безнең баш очында, югарыда кара нокта булып бушлыкка эленгәннәр дә сузыпмы-сузалар:

— Челдерр... чел-деррр!..

Әнә алар берничә секунд канат җилпеп алдылар да тагын һавада эленеп калдылар.

— Челдерр... чел-деррр!..

Менә алар түбәнгә уктай атылдылар, җиргә җитәрәк кире борылып, яңадан зәңгәрсу күккә күтәрелделәр.

— Челддерр... чел-дер!..

Юк, сайрамый иде бу тургайлар.

Алар җирдәге әлеге хәсрәтне сизенеп, һавада кая бәрелергә белмичә, өзгәләнеп-өзгәләнеп елыйлар иде.

Әнкәй бераз бушангач, мал «брачы» — гомер-гомергә тәкә печеп йөрүче түбән оч карты — аны читкәрәк этәрде дә, Мүкләкнең башын, күкрәк-корсак турыларын капшап-капшап карады, аннары хатыннардан:

— Ничегрәк булды соң бу? — дип сорады.

Хәбибкамал:

— Мин күрми дә калдым,— диде.

Әдүкәй бичәсе аңа каршы төште:

— Ничек «күрми калдың» ди?!

Биредә Мәһираттәй дә булган икән.

— Үз шаукәгездән үзегез курыкмагыз,— дип, ул усал гына әйтте.— Сез түгел, буразнаның теге башындагы кеше — мин дә күрдем.

— Шуны әйтеп торам лабаса,— дип, Әдүкәй бичәсе аны бүлдерде.— Ару гына барган җиреннән кинәт кырыйга тартыла башлагач, Хәбибкамал: «Кая төртеләсең», дип чыбык белән суккание, гөрселдәп ауды да китте...

Хәбибкамал курку катыш аңа:

— Нишләп сугыйм ди, селтәндем генә бит! — дип җикерде.

Бу миңа җитә калды, әлбәттә.

— Кыйнап үтергәнсез! — дип уртага чәчрәп чыктым.

Әмма Күли абзый шул сыңар кулы белән күлмәк якасыннан эләктереп алды да үзебез тикшерербез дигән шикелле:

— Ярамый,— дип, мине читкә тартып чыгарды.

Алай гына бирешергә исәбем юк иде, мал «брачы» сүзеннән соң үземне-үзем көчләп тыйдым.

— Барыбер Алкынга алып барабыз,— диде ул авыр сабырлы тавыш белән.— Юкка чәпчемәгез...

Ә Миша абый бер якка да катнашмады, биредәгеләр арасында үзен чит сыман хис иткәннән дә түгел, гомумән, ул әлеге казаның зурлыгын тойса да, мин аңламаган сәбәпләрен уйлап, ахры, бөтенесен бер төрле халәттә тыңлап торды.

Ахырда хатын-кыз, ир-ат — барысы бергә сыерны арбага күтәреп салдылар.

Ләкин Мүкләкнең бәдәне аркылырак төшеп, башы читкә салыныбрак калды. Мин беркемгә дә эндәшеп тормадым, төзәтеп салырга керештем. Тик аны мин генә кузгатырлык түгел иде. Шундагы кайбер хатыннар:

— Ятсын шул кеч...

— Көчәнмә юкка,— дисәләр дә, куймадым, киресенчә; хасланыбрак тотындым.

Әлегәчә бер якка да катышмаган Миша абый, минем йөрәкнең нәрсәгә кыйналганын сизенеп, җаны түзмәде, ахры, ярдәмгә килде.

Атны урау, сөзәк юлдан кайтыр якка алып киттек.

Күктәге тургайлар, һавада кая бәрелергә белмичә, һаман еладылар:

— Челдерр... чел-деррр!..

Чыдамадым, әнкәйгә сүз каттым:

— Ишетәсеңме?..

Минем юкка гына сүз катмаганны шундук аңлады ул.

— Жә, житте!

— Тилгән явыз, кайберәүләр тилгәннән дә явыз...

Әнкәй төксе генә миңа карады:

— Нәрсә дисең?

— Сыер тикле сыерны үтерделәр дим...

Бусына әнкәй эндәшмәде.

— Мине тыңламадың. Үз аягы белән биреп жибәргән сыерны менә хәзер арбага төяп кайт инде. Чит кешегә нәрсә...

Башын текә тотып, арба артыннан тын гына ниярде ул.

— Әткәй кайтып төшсә нишләрбез, яралы кешегә сөт тә, май да булмагач...

Бу килеш әнкәй озак бармады, иңбашымнан мине кочып, үзенәрәк тартты да:

— И-и, балакай, әле синең уйнап кына йөрер чагың бит,— диде.

— Уйнарсың монда! — дип, читкә тартылдым.

Чыннан да атнадан артыктыр, төбәк малайларын күргән дә, очраткан да юк. Аларның да эшләре күптер, югыйсә, алачыкка төшәрләр иде.

— Нишлисең... әткәй урынына да калгач...

— Алайса, син дә аның кебек нык бул!

Әйтерсең үзе, Мүкләкне башыннан кочаклап, үкси-үкси еламады.

— Сыерсыз да кал, авыз да йомып тор!

— Вакыты шундый, улым, сугыш... Бөтен авырлыкка да түзәргә туры килә... Ил өстенә ябырылган афәт безнең йортны гына читләтеп үтмәс...

Капка төбендә безнең бозау Акбай белән мәш килеп уйный иде. Әнә ул чалкан яткан Акбайга жиңелчә төртеп-төртеп ала да бер-ике адым артка качкан була. Тегесе дә нинди шаяра, шундук аякланып, озын койрыгын селки-селки, бозауның борын төбенә үк барып ята. Ә бозау шуңа тәмам әсәрләнеп, муенын аска суза да янәдән башы белән Акбайга үрелә. Бу фани дөнья аның ай-ваенда да юк иде.

Менә ат, авыр арбасын сөйрәп, капка алдына килеп туктады.

Акбай кырыйга, койма буена тайпылды, моңсу, акыллы күзләрен арбага текәде, өнсез калды.

Ә бозау исә берни аңламады, арба тутырып яткан анасына борыны белән төртеп карады да ачык капкага борылды. Ярый әле — теге көнне «арка башында» бу аңгыракайга туйганчы имәргә ирек биргәнмен, югыйсә, гомерлек үкенече кала иде...

## XIV

Күптәннән йолдызлар күзләгәнем юк иде.

Алачыктан кайтып, ашап-эчкәч, капка төбенә чыгып утырдым.

Урам тып-тын. Югары очта да, түбән очта да бер кеше авазы ишетелми.

Сугышка чаклы егет-жилән, кыз-кыркын тавышы, гармун моңы ярты төнгә чаклы тынмый иде.

Анысы, моңысы, ә менә ат көтүе саклап, яланда куна ятулар, андагы әкият, жыр... искә төшсә, күңелләр кузгала.

Шулай уйланып утырганда, сиздермичә берәү арттан килеп, ике күземне дә каплады. Сискәнеп киттем. Сикереп торырга омтылдым. Тик әлеге «берәү» мине жиргә жиңел генә кире утыртты.

— Кем бу?

Чамалап белер өчен, ике күземне дә каплаган кулларга ябыштым. Ябыштым да тынып калдым, ул куллар шундый йомшак, шундый жылы.

мин аларны күзләремнән каеру түгел, әле беркайчан татымаган рәхәт хис белән сыйпап-сыйпап куйдым.

— Тәзкирә-ә!

Ул томалаган күзләремне шундук ычкындырды, көлә-көлә читкә сикерде.

Мин аны кул сузымында эләктереп алдым.

— Әле син шулаймыни?!.

Тик ул кисәк кенә җитдиләнеп, боерулы тавыш белән:

— Куй, тимә! — диде.

Үзем дә кыенсынып киттем.

Моңа игътибар итмәде Тәзкирә, гади генә:

— Нишләп утырасың? — дип сорады.

Телемә килгән беренче сүзне әйттем:

— Йолдыз санап...

— Ничәү булды соң?

— У-у, аны санап бетерергә таң атканчы утырырга кирәк.

Тәзкирә карасу-зәңгәр күктәге җем-җем янган эре йолдызларга күтәрелеп карады.

— Тимер казык йолдызын таба аласыңмы?

— Нинди йолдыз ул?

— Төньяктагы.

— Ә-ә, Котып йолдызымы? Әнә, Чүмеч йолдызның сабы очында.

— Җидегән диген... Картәтәй әйтә, Җидегән йолдызы — җиде кызның җиде кубызы, ди, җиде төн уртасында җиде кыз шул җиде кубызда җил-җил уйныйлар, ди...

— Ә Тимер казык йолдызы нишли?

— Тимер казык — күкнең аркасы.

— Шулаймыни?!

— Әллә ышанмыйсыңмы? Җидегән йолдызы бер төн эчендә әллә күпмегә авыша, Тимер казык урыныннан да кузгалмый...

— Каян беләсең?

— Картәтәйдән... Ул әйтә, Тимер казык йолдызы мине үлемнән коткарды, ди.

— Ничек?

— Себердә чагында аны иптәшләре белән тайга уртасындагы бер авылга җибәргәннәр. Барып төшсәләр, анда безнекеләрдән качып яткан аклар икән. Боларны шундук эләктереп алганнар. Ә аклар шундый явыз кешеләр икән, кешеләрнең телен кисканнәр, күзен чукып чыгарганнар, колакларын өзеп алганнар. Шулай җәзалаганнан соң, бөтенесен дә агачка асарга дип, урманга алып кереп киткәннәр. Мүк каплаган тип-тигез төштән барганда, картәтәй, җир упкандай, аю базына төшеп киткән. Иптәшләре дә, аклар да күрми калган...

— Нинди баз, аюлар казыганмыни?

— Түгел. Сунарчылар казыган. Аюны анда базга төшереп тоталар икән.

Без, капка баганасына арка терәп, чүгәләп утырдык.

— Ә тайганың кай якка китсәң дә иге-чиге юк, ди. Андый урманда үлеп калуың да бик ихтимал. Картәтәй, көндез кояш уңаена авышканда, төннәрен шул Тимер казык йолдызына карап, юлын турылаган. Юкка гына ул аны «күкнең аркасы» дими торгандыр. Әнә бит ул йолдыз нинди, башкалардан яктырак булып, җем-җем яна. Бүген дә сугышта аңа карап, әллә кемнәр атлыйдыр әле.

— Ә немецлар төнлә йөрергә курка, ди... Сугыш булмаса, безнең Мүкләк тә үлми иде.

— Аны Алкынга алып бардыгыз бит, нәрсә диделәр?

— Поруктан, диделәр, авыр эш ярамаган.

— Теге хатыннарга бирми булмадымы?

— Нәрсә булсын.

Тәзкирә генә белми, ул бахырларны мин нинди рәнҗеттем. Үзләре дә ник каршы сүз әйтсеннәр, болай да котлары алынган нәрсәкәйләр, тәмам телдән яздылар. Сәбәбе ачыкланган та куанмадылар. Югыйсә, миңа ябырылырга мөмкин бит. Тик мин монысын Тәзкирәгә әйтмәдем.

Шулай да Мүкләк кызганыч, бик тә кызганыч.

Тәзкирә тагын дәвам итте:

— Картәтәй әйтә: «Баш исән булса, мал табыла», ди. Әтәннең хәбәре килеп тора, яраланган булгач, кем белә, бүген-иртәгә кайтыр да. Ә менә минем әтәй...

— «Похоронный» түгел бит, хәбәрсез югалды дигәннәр. Ана ышана башласаң... Андый хәлләр сугыштан ерак җирдә дә була. Миша абый да үз балаларының кайда икәнен белми иде. Өмете өзелгәндә, хат килеп төште. Ә ул күпме йөргән диген? Ике айдан артык. Синең әтәңнең хәбәрсез югалуына мин ышанмыйм...

## XV

Бүген алачыкка төшәр алдыннан Миша абыйны нәрсәгәдер авыл Советына чакыртып алдылар.

Менә хәзер сәгатьтән артык аны көтеп утырам. Китте дә батты. Ничмасам, төшә торам дип, алачык ачкычын алып калмаганмын.

Шулай каңгырып торганда, яшел эмале ярыйсы чәрдәкләнгән миски күтәреп, уйламаган-көтмәгән кеше — Тайфа түтәй безгә килеп керде. Өй эче кинәт караңгыланып киткәндәй булды. Нәрсә, Акбай биләмдә калды микәнни? Тавышы ишетелмәде. Килеп керде дә, мич алдын себереп маташкан әнкәйгә текәлеп, ишек төбендә туктады. Мин бар ни, юк ни аңа, күз дә салмады. Шулай ук әнкәй дә, кулындагы себеркесен тоткан килеш, билен турайтып, аңа каршы аягүрә басты. Тагын башлана инде дип, котым чыгып, урынымнан күзгалдым. Теге төнне әнкәй куып чыгарганнан соң безнең бусаганы Тайфа түтәйнең беренче атлап керүе иде. Икесенең дә тотышларына караганда, алар яңа, беренче мәртәбә күзгә-күз очрашалар булса кирәк. Тайфа түтәй әнкәйгә озак карап тормады, кыю гына түргәрәк узып, кулындагы мискине ихата як тәрәзә каршындагы өстәлгә куйды. Бу — алачыкта Шәрип бабай белән икәү ямаган миски иде. Тайфа түтәй бер сүз эндәшмәгән кебек, әнкәй дә авызын кыймылдатмады, иреннәрен кысып аңа карап торды.

— Менә катык керткән ием, бүген генә оеткан...

Мин моны көтмәгән идем.

Әнкәй дә шундук:

— Мыскыл итмә! Әллә катыкка моң дип белдеңме безне?! — диде.

Әмма Тайфа түтәй кызмады.

— Маһирә сипарат сөте керткән ие, сәгатьтән артык кайнаттым, сап-сары май кебек.

— Әче телең генә җитмәгән, агу да керттеңмени?

— Әстәгъфирулла! Ишетмәсәң — ишет!.. Әче телем үземнеке инде, аны нишләтеп тә булмый. Ә катык... бернинди гөнаһсыз хайванныкы бит бу.

Моңа карап кына әнкәй тынмады:

— Болар да сыерсыз калды дип, сөенә-сөенә керттеңме?

Тайфа түтәй әүвәлгечә сабыр-түзем торды.

— Шул тиклем юләргә санама инде.

— Әгәр юләр булсаң, болай да кыйланмас иден...

Әнкәй тагын нәрсәдер әйтергә авызын ачкан иде, күзенә мин чалынып, әле яңа күргән төсле шомыраеп, кинәт туктап калды, әйтергә уйлаганы сер, бала-чага алдында ярамый, күрәсең.

Урынымнан кузгалдым, игътибарсыз күренергә тырышып, алар яныннан шәүлә төсле тавыш-тынсыз үттем дә ишек алдына чыктым.

Алар нәрсәдер әйтешеп алдылар.

Болай да тырпаеп торган колакларым шундук үрә басты.

— ... сугышка чаклы Әнвәрбәкнең тенкәсенә тиден,— диде әнкәй.

— Әй, сенелем, минем дә җаным бар лабаса, бала-чагасыз-нисез тол калып кара, аннан белерсен.

— Сина аның яхшылыктан башка, тырнак очы кадәре дә яманлык кылганы булмады.

— Шул шул менә... Мина гына түгел, өй борынча... Хәзер дә телдән төшермиләр: әл дә Әнү өебезне бетереште, әл дә Әнү төбәгебезгә кое казыттырды, әл дә Әнү... әл дә Әнү...

Алачыкта Шәрип бабай үз малае Шәйхи абзый турында сөйләгәндә: «Картәтәйнең куалдысын нигә эткәй үз кулына алмады икән?» — дип пошынган идем, юкка гына алайса, аны гына түгел, эткәйне дә сагыналар икән.

— Ә минеке сон, минеке, ата зимагур, эчкече иде... Менә шундый бәндәгә бәйләнеп, җан кебек гомерең заяга үтсен дә йөрәк сызламасын. Кеше иренең булганлыгына көнләшми хәлең юк...

Тайфа түтәй мышык-мышык борынын тартырга тотынды, тавышы да, мон-зар тулы көй сузгандагыдай, үзгәрде.

Бу зурлар бала-чаганы гына оста әрлиләр, уйласаң, үзләре дә алардан ким түгел: бер-берен рәнҗетү дисеңме, бер-береннән көлү... Әллә ни кыйланып бетәләр, аннары чак кочаклашып үбешмиләр...

Әнкәй дә басылды, сыктый-сыктый сөйләгән түтәсен бүлдермәде.

— Сыерың үлгәч, ничек керергә дә белмәдем. Мин ул солдатны яратмаудан түгел бит, синең өчен курыктым. Яшь күнел, шайтан котыртып куйса дип... Аны үземнән беләм. Салкын өйдә салкын түшәктә ялгыз ятып кара. Башка тузга язмаган уйлар килә. Ятасың, ятасың да, салкын мендәрне кочаклап, үкси-үкси елыйсың... Берсе дә күңелем тарлыктан түгел...

— Мин дә сине әүвәл шулай уйлый идем. Әнвәрбәккә бәйләнгәндә дә, бу ятим дип, аптыраудандыр дип, гел-гел аяп килдем. Инде хәзер минем белән...

— Ышан, начарлыктан түгел лә... Кем уйлаган ул кешенең әйбәт буласын. Мин башта Сатираның урыска чыкканына аптыраган идем... Сыерына страхауай ару чыккан икән.

Тайфа түтәй моны ихлас әйтте. Кеше күңелен юкка карурман димиләр, беркайчан да капылт бәрелергә ярамый, акылны алдан йөгәнләмәгән чаклар минем үзем дә дә булгалый.

Шунда кемнеңдер капкадан ашыга-ашыга кергән аяк тавышы ишетелде.

Мин өй ишеге турыннан күтәрмәгә уздым.

Әнкәйләр шым булдылар.

Әлеге аяк тавышы иясе Миша абый иде.

Аның ашыгуына да, хәтта яныл-пешеп чыгуына да игътибар итмәдем.

— У-уй, озак.

— Мина китәргә... фронтка,— диде ул.

Бер мәлгә башым әйләнгәндәй әллә нишләп, берни уйлый алмый тордым, аннары аның китәчәге кисәк кенә күзалдыма килеп, кычкырып җибәрдем:

— Әнкәй!..

Аның килгәненә атнадан артык, вакытлыча гына җибәрелгәнен белсәм дә, аерылышу сәгате сугар дип уема да кергәне юк иде, җитмәсә, иялэшеп беткәч кенә...

— Мә алачык ачкычын... Әле шунда төшеп мендем. Хатыннар китергән савыт-сабаларны ямап бетерерсең... Тик башта теге печән җыйгыч

ат тырмағын төзәт, аның әллә нәрсәсе калмады... Өйрән, оста тимерче бул!..

Бусына, аякларым җирдән аерылып, түбәм күккә тиде.

— Мондый бәхет кемгә бирәүгә тәти!

Шул арада мин эндәшкәнгә, Миша абый тавышына өйдәгеләр дә чыкты.

— Мина сугышка китәргә...

Миша абыйның бу сүзеннән әнкәй дә аптырап калды.

— Кайчан?

— Озакламый ат килергә тиеш.

— Әй, аллакаем!..

Барыбыз да өйгә кердек.

Ыгы-зыгы купты, бер якта әнкәй йөгерсә, икенче якта Тайфа түтәй кабаланды.

— Көн әлгәре дә әйтмәгәннәр, ичмасам...

— Син казанына тиз генә аш сал, мин самавыр куя торам.

Миша абый аларга: «Борчылмагыз!.. Зинһар, мәшәкатьләнмәгез!..» дип тә караган иде, тыңламадылар.

Мина да, утын кертеп, казан асты тергезергә куштылар.

Миша абый үзе яшел юл капчыгына әйберләрен тутырырга кереште.

Ләкин аш пешү түгел, самовар кайнап чыгарга да өлгермәде, Күли абзый иске тарантаска җигелгән авыл Советы алашасы белән капка төбенә килеп туктады.

Өйгә керүгә ук әнкәй аны әләктереп алды:

— Ашләттегез, ашләттегез дә, тизрәк китегез дип куалыйсызмы? Кешене азрак ял иттереп, мунча кертеп, хөрмәтләп җибәрсәгез, дөньягыз җимерелер дип йөрәгегез алындымы?..

— Туктале, аш бит анда түгел, военкомат сәгате-минуты белән хәбәр иткәч, нишлисең, алар белән сатулашып булмый.

Миша абый елмаеп-елмаеп куйды.

Тайфа түтәй дә:

— Әллә катык булса да капкалап аласызмы? — диде өтәләнеп.

Тик берсе дә эндәшмәде.

Әнкәй кабаланып идән астындагы базга төшеп китте, озак та тормады, кулына ярты литрлы шешә тотып, кире чыкты.

— Менә сары май, күчтәнәчебез булыр.

— Юк, юк, кирәкми.

Әмма ул ялынып дигәндәй тормады, Миша абый кулыннан яшел юл капчыгын алды да, авызын тиз-тиз чишеп, май тутырылган әлеге шешәне тыкты...

Урамга озата чыккач, Күли абзый миннән:

— Син, Хәйрулла, алачык ачкычын алдыңмы? — дип сорады.

— Алдым.

Әнкәй дә моны ишетте, башкаларга сиздермичә генә, аркамнан җиңелчә сөеп куйды.

Читтәрәк тартынып торган Тайфа түтәй ат кузгалуга тарантас янына йөгереп килде дә Миша абыйның уң кулыннан тотып алды:

— Сау бул, кияүкәй! Сау бул!..— Яшькелт күзләреннән эре бөртекле яшь атылып чыкты.

Әнкәйгә әйләнеп карадым: аның йөзе авыр уйлы, карашы житди, хәтта азрак усал да шикелле күренде.

Авыл Советы алашасы кай арада безнең яндагы тыкрыкка борылды, кай арада бәрәнге бакчалары башына җитте, күз бәбәкләре талырга да өлгермәде, Яктытау ягына борылып, читәннәр артына күмелде.

— Хуш!.. Миша абый, хуш!.. Солдат абый...

## XVI

Көннең үткәне сизелмәде дә.

Миша абый киткәч, алачыкта үзем хуҗа булып эшләгәнгә генә түгел, башка нәрсә дә сәбәп булды моңа.

Капкадан чыгып, Тәзкирәләр турыннан узганда кемдер тәрәзә шакыды. Карасам, аскы кечкенә өлгедә Шәрип бабайның сакал-мыек баскан йөзе. Нәрсә уйларга да белмәдем, борылып кердем.

Түр сәкедәге түшәктә яткан Шәрип бабай ишектә мин күренүгә, ниндидер сере бар төсле: «Мондарак кил әле», дип эндәште.

— Нәрсә бар, Шәрип бабай?

— Михаил абыегызны озаттыгызмы?.. Әйбәт кеше. Минем белән дә хушлашып чыкты... Ачкычны сиңа бирергә кушканнар икән, әле шунда барышыңмы?

— Әйе.

— Кәҗәнкә почмагында кечкенә бер ящик бар, Шәйхулла абзаңның кораллары, сиңа кирәк булыр, алып төш шуларны да.

Ә ул ящикта ниләр генә юк иде: калай кайчысы, төрледән-төрле шөреп ачкычлары, келәшчә-карга борыннары, тимер пычкысы, бораулар, игәүләр...— тимерче кешегә болар бары да кирәк.

Кәҗәнкә почмагыннан өйалдына алып чыккач, ящикны нишләтергә дә белмәдем. Дөресен генә әйткәндә, бу кадәре хәзинәне Шәрип бабай болай гына бирәп җибәрер дип күңел ышанмады. Шулай беравык аны күтәреп тордым да идәнгә куйдым.

Шәрип бабай минем икеләнгәнне сизенде, ахры:

— Картәтәңнең дә кайбер нәрсәләре исән ие, аякка бассам, аллаһе боерса, карап бирермен әле,— диде.

Әллә заманында картәтәй дә Шәйхи абзыйга үз коралларын бирде микән?

Тик мин сорашып тормадым:

— Рәхмәт! — дидем дә ящикны күтәреп чыгып киттем.

Хәтта капкада очраган Тәзкирә янында да туктап тормадым, урамга чыгып, күңелем белән оча-канатлана алачыкка төшеп киттем.

Миша абый әйткән печән җыйгыч ат тырмасы белән көнозын маташтым. Дөрес, аның әллә нәрсәсе юк иде. Өйрәнчек тимерчегә дугайлы берничә озын теш ясап беркетүе, тырманың күтәргеч-төшергеч кулсасын төзәтүе хәтсез ярымга төште. Ярый әле — Шәрип бабай ящигы белән Шәйхи абзый коралларын бирәп җибәрде, югыйсә, ул печән җыйгыч ат тырмасын бүген бетерә алмый идем. Ир мактана, корал эшли дип юкка әйтмәгәннәр. Нәрсәгә тотынсам да, шул ящиктагылар кирәк булды. Әкрен эшләнде, әмма бары да җиренә җиткерелде. Күңел дә жырдан бушамады. Моңа, әлбәттә, эшнең җайлы баруы гына түгел, Шәрип бабайның зур ышанычы да сәбәпче иде. Шулай итеп көннең үткәне сизелми дә калды.

Кич өйгә кайтсам, тагын...

Мин ихатада күренүгә өйалдыннан әнкәй:

— Улым, әткәңнән хат бар,— дип кычкырды.

Күтәрмәдән әллә атлап, әллә очып мендем.

— Кая?

Әнкәй кулындагы өчкел конвертлы хатны алдым да тиз-тиз актарып комсызланып укырга керештем.

«Туган якта яшәүче кадерлем Бикә, бердәнберем, өметем-ышанычым Хәйрулла улым, сүнмәс, сүрелмәс кайнар сәламнәремне сезнең тарафларга юллап калам...»

Йөрәгем әллә нишләп китте.

«Бердәнберем, өметем-ышанычым...»

Мондый сүзне әнкәй булып әнкәй дә әйткәне юк.

Бөтен хат озынына ул безнен хәлләрне сорашып-кайгыртып язган-язган да, ахырда гына үзе турында берничә җөмлә сызгалаган:

«...Сул аягым җиңелчә яраланып, атнадан артык кыр госпиталендә яттым. Менә хәзер тагын фронтка — алгы сызыкка җибәрделәр...»

Бусына шатланырга да, кайгырырга да белмәдем. Шатланыр идем, яраланган хәбәрен Тайфа түтәй ишетеп кайткач, бәлки бүген-иртәгә кайтып төшәр, кайтып төшәр дип өметләндем. Кайгырыр идем, илдә сугыш барганда, бөтен ирләр яуда булганда, гарипләнеп, ул берүзе генә авылда ятса да әйбәтмени? Шулай да көн озыны күтәренке йөргән кәефем җимерелмәде.

Хатны әнкәйгә бирдем дә күтәрмәдән кире очып төштем.

Ә ул артымнан:

— Кая чабасың, аш өлгерде? — дип кычкырып калды.

Туктамадым, өй артындагы бакчадан койма аша сикердем дә тыкрыктан урамга йөгереп чыктым.

Яктытау мине — тишек борынлы кечкенә тимерчене — гадәттәгечә колачын җәеп каршы алды. Минем бөтен төшем — якты дөньяга сокланып туймаган яшькелт күзләрем, ике якка тырпаеп баскан колакларым, хәтта тез башлары ямаулы зур чалбарым белән аягымдагы «чачаклы» иске чабатам да Яктытауга бик тә таныш иде. Үз чиратында Яктытау — сөзәк кенә югары күтәрелгән сихри итәге, җиргә ятып уйнаган көчле җиле, зәңгәрсу күкне инрәтеп сайраган бүз тургайлары — һәммәсе, һәммәсе белән бергә мине дә үзенә тәмам гашыйк иткән иде. Бер мизгелгә туктадып, тирә-ягыма әйләнеп карадым. Әнә мине Мүкләк сөзеп ыргыткан урын... Менә Миша абый сыердан аралаган төш... И-их, шул сөзгәк әле дә исән булса иде, мине биш-алты метрга ыргытып, Миша абыйның көчле кулларына барып төшәсе иде... Әнә ул киткән юл, ирләр кулындагы кан тамыры төсле, боргалана-боргалана еракка сузылган... Кинәт кенә сулышымны тыеп, башымны артка ташлап, зәңгәрсу күккә карадым. Ә анда Тәзкирәнең йон тубына охшаш бүз тургайлар бар әтрафны инрәтеп сайрыйлар. Карале, карале, хас та Мүкләк муенындагы кыңгырау. Челдеррр... челдеррр!.. Әллә алар да Мүкләкне һаман юксыналармы?.. Әлеге мине — тишек борынлы кечкенә тимерчене — җиргә ятып уйнаган көчле җил бөтереп алды да Яктытауның сихри итәгеннән күперен яткан җылы сулышлы киң күкрәгенә очыртып күтәрде.

Ә биредә шундый биек, бөтен тирә-як уч төбендәге шикелле күренә: аста, Яктытаудан читтәрәк, йөзенә зәңгәр эңгер бөркәнгән тып-тын авыл, яңа сөрелгән кап-кара басу башында — алсу офыклар...

Бу күренеш күптән таныш булса да, бүген, беренче мәртәбә күргәндәй, бер авылга, бер ерактагы офыкларга карап, тиле кеше төсле үз-үземә сөйләндем:

— Ник син болай моңсу, авылым? Кичке эңгер үтәр дә китәр. Төн артыннан сызылып таң атар. Менә күрерсең, иртәгә дә көн аяз булачак. Әйткән иде диярсең. Әнә күрәсеңме, офыклар нинди алсу...

1970

**Зәки Нури**

# ЖУРНАЛ ӨЧЕН, ЖУРНАЛ БЕЛӘН

Журналга мин кордаш һәм чордаш буларак бары берничә генә эчкерсез сүз әйтергә телим. Ничектер туры килеп, без журнал белән бер тирәдәрәк туганбыз: инде менә илле яшьтәгеләр булып чыктык... Ләкин дөресе шул: журналга мин инде сугышка чаклы елларда ук шигырьләр, ә соңыннан исә шигырьләр белән бергәттән тәрҗемәләр, рецензияләр, мәкаләләр һәм очерклар җибәрүдән һәм 1968—1971 елларда аның баш редакторы булып эшләүдән башка, бернәрсә дә бирмәдем кебек. Киресенчә, ул үзе миңа, барыбызга да биргәнчә, бик күпне бирде. Санып калсаң, чыннан да аз түгел бит! Беренчедән, әдәбиятыбызның иң яңа һәм иң яхшы әсәрләрен ай саен килеп торган яңа саннардан вакытында укып бару мөмкинлеген безгә шул журнал бирде һәм бирә. Икенчедән, миңа, әле башлап кына язучы бер үсмергә, язучылар исеменнән Кави Нәҗми, Гомәр Бәшир, Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Сибгат Хәким имзалары куелган хатлар алу бәхетен шул журнал китерде. Өченчедән, берәр язганың басылып чыкса — түбәләремне күккә тидереп шатлану минутларын мин шул журналны алгач кичердем. Дүртенчедән — минем өчен, бәлки, иң кадерлесе — Ватан сугышы елларында, фашист тылында, Белоруссиядә, Константин Заслонов җитәкләгән партизаннар берләшмәсенә, самолет белән килеп төшкән берничә журналны поход биштәремә салып, патрон белән бер дәрәҗәдә кадерле итеп йөрткән куанычлы көннәр һәм атналар гомер-гомергә онытылмастыр шикелле...

Менә ни өчен журналны мин һәрвакытта да безнең һәммәбездән дә олы булган остаз итеп санадым һәм санармын.

Журналны без әдипләрнең иҗат тәҗрибәсен, аларның иҗтимагый һәм политик эшчәнлеге үрнәкләрен, тугандаш әдәбиятлар белән аралашу практикасын өйрәнә, туплый һәм пропагандалый торган бер үзәк дип тә беләбез. Дөресрәге, иҗатны, тәҗрибәне, эш нәтиҗәләрен яктырта яки туплый гына түгел, ә практик эшне Язучылар союзы идарәсе белән бергә оештыра да ул. Бирәдә В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән татарча лениниана материалларының иң зур күпчелеген журнал тапты, журнал яздырды, журнал тәрҗемә иттерде дисәк, һич ялгыш булмас. Юлбашчыбызның Себердәге сөрген еллары һәм Польшада чактагы зур эшчәнлеге турында шигырьләрне һәм репортажны, мәсәлән, мин журнал кушуы буенча шул якларга барып яздым. Бүтәннәр исә журналның шундый ук бик мөһим социаль, политик һәм әдәби заказын Ульяновскига, Куйбышевка, Ленинградка, Шушенскоега, Уфага, Псковка һәм Ленин булган бүтән урыннарда йөреп кайткач үтәделәр. Нәтиҗә шул: хәзер безнең Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган биш томлы татарча лениниана-

быз бар, аның алтынчы томы исә быел чыгачак! Димәк, журнал безне киң дөньяга чыгара, безнең эшчәнлекнең һәм географик, һәм тематик офыкларын киңәйтү эшенә зур өлеш кертә.

Безнең хөрмәтле укучыларыбыз өчен дә журнал яңадан-яңа офыкларны әледән-әле ача тора. Аның соңгы елларда «Якташларыбыз сәяхәттә», «Алар бездә булганнар», «Елмаеп-көлеп кенә...», «Балаларга укыгыз», «Бездә кунакта» кебек рубрика белән бирелгән әсәрләр бик хуплап каршыланды. Эзләнүләр һәм ачышлар уңышлы дәвам итә.

Без, әдипләр, заман героикасы материаллары белән журналның эчтәлеген тагын да тирәнәйтү, аның тематик колачы белән сәнгатьчә сыйфатын төрле яклап күтәрү өчен тагын да күбрәк тырышырга тиешбез әле. Журнал өчен ешрак һәм яхшырак язган әдип журнал белән бергә тизрәк үсәчәк!

## Мирсәй Әмир

# ЗУР БАЙЛЫГЫБЫЗ

«Казан утлары»н мин «Безнең юл» исеме белән чыга башлаган еллардан ук диярлек укып киләм. Иң башлап ул миңа үзем яшәгән чорның алдынгы әдипләре, шагыйрьләре һәм әдәбият белгечләре — тәнкыйтьчеләре белән дөресрәге, аларның иҗатлары белән танышып барырга мөмкинлек бирде. Әдәбиятка булган мәхәббәтемне, аның актуаль мәсьәләләре белән кызыксынуымны арттырды. «Шушы ук журнал минем кулыма каләм дә тоттырды» дисәм, бу сүз, әлбәттә, юбилей көннәрендә матур яңгырар иде, ләкин ул дөрес үк булмас иде. Чөнки шул ук елларда бездә башка газета-журналлар да чыга, алар арасында яшьләр өчен үзрәк, редакция ишекләре җиңелрәк ачыла торганнары да бар иде. «Кызыл яшьләр», «Авыл яшьләре» кебек органнар аша үтмичә, «Безнең юл»га күтәрелү җиңел түгел иде. Шулай булуы белән ул миче һәм минем каләмдәш кордашларымны тырышыбрак язарга рухландырды. Әйе, «Безнең юл»да әсәр бастыру яшьләр өчен дәрәҗә иде. Аңа ирешү җиңел түгел, аның өчен тырышырга, үз чорыңның таләпләре югарылыгында торган әсәр язарга кирәк иде. Шулай да бу дәрәҗәгә мин шактый иртә ирешкәнмен дип уйлыйм. Яшьләр матбугатында 1926 елның азагында гына исеме күренә башлаган кеше — 1928 елның башында ук инде «Безнең юл» авторлары җөмләсенә керде: журналның шул елгы 3 нче санында минем «Бәхет порошогы» дигән хикәям басылып чыкты. Димәк, бүген «Казан утлары» исемендә 50 еллыгы уздырыла торган журналыбызда басыла башлавым шул саннан исәпләнә дигән сүз.

Сүз уңаенда шунысын да әйтеп үтәсем килә: «Бәхет порошогы» бәхәсле хикәя булып чыкты, аның турында миңа үз вакытында уңай яктан да, тискәре яктан да күп кенә сүзләр ишетергә туры килде. Ягъни журналның таләпчәнлеге формаль генә түгел, әдәби әсәрнең, авторның (ул яшь булса да) индивидуаль үзенчәлекләрен дә (кайвакыт алар бәхәсле булса да) искә алз белә торган акыллы таләпчәнлек булган. (Ул хикәяне 40 елдан соң үземнең сайланма әсәрләр җыентыгыма кертергә мөмкин дип тапканмын икән, ул, бәхәсле булу белән бергә, әдәби яктан билгеле дәрәҗәдә әһәмияткә ия булырга тиеш.)

Билгеле булганча, илебездә яңа, социалистик җәмгыять төзү процессында әдәби хәрәкәтебездә дә зур үзгәрешләр, яңарышлар була килде. «Безнең юл» журналы «Яңалиф», «Атака» исемнәрендә дәвам итте, озак еллар буена «Совет әдәбияты» исеме астында чыгып килде. Беренче хикәям басылган чордан башлап, мин бу журнал битләрендә актив катнашып килдем. Күләмлерәк әсәрләремнән «Агыйдел», «Без-

нең авыл кешесе», «Балыкчы ялганнары» повестьлары, «Миңлекамал», «Тормыш җыры», «Хөррият» пьесалары, «Саф күңел» романы (I нче һәм II нче китаплары), шулай ук дисталәгән хикәя һәм мәкаләләрем иң башта шушы журнал битләре аша укучыларыма барып җиттеләр. «Казан утлары» үзенең 50 еллык гомерендә һәрвакыт әдәби хәрәкәтебезнең иң тулы күрсәткече булу белән бергә, язучы белән укучы арасында иң эшлекле арадашлык хезмәтен дә үтәп килде һәм килә. Без моңа шул кадәр ияләшкәнбез, көндәлек тормышыбызда һавага, суга һәрвакыт игътибар итеп тормаган кебек, шундый журналыбыз барлыгын да бик табигый һәм гади хәлгә санап йөрибез.

Юбилей уңае белән аның турында бер-ике авыз сүз әйтү өчен кулга каләм алып уйлана башлагач тоясың: никадәр зур байлыгыбыз бит ул безнең «Казан утлары»! Безнең өчен, язучылар өчен, һава белән су дәрәҗәсендә кирәкле зат бит ул! Аны алдырып өйрәнгән укучы өчен дә аңсыз тору кыен. Юбилей көннәренә хас гадәт буенча гына түгел, чын-ихлас күңелдән янып әйтәсе килә: яшә, озак еллар буена еракларга балкы, «Казан утлары»! Редакциянең портфельләре берсеннән-берсе әйбәтрәк әдәби әсәрләр белән һәрвакыт тулып торсын! Укучыларың саны елдан-елга арта барсын!

Зур булу белән бергә, бик реаль теләкләр. Шунысы әйбәт: аларны тормышка ашыру үз кулыбызда! Кадерен генә белик. Аны үзебез күрергә теләгән дәрәҗәдәге әдәби журнал итү өчен хәлебездән килгәннең барын да эшлик!

**Афзал Шамов**

# ЖУРНАЛНЫҢ БЕР НӨСХӘСЕ

Бөек Ватан сугышы елларында без, фронттагы язучылар, «Совет әдәбияты» журналының һәр санын бик сагынып, зарыгып көтеп ала идек. Безнең өчен бик кадерле кунак иде ул. Аның яңа саны килгән сәен көннәр күңелле бер бәйрәмгә әверелә иде дисәм дә, арттыру булмас.

Кызганычка каршы, журналны тәртипле рәвештә ала алмый идек. Хәрәкәттәге армиягә подписка юк иде. Бары бандероль белән генә килә иде ул безгә. Ул еллардагы журнал редакциясе коллективына һәм Язучылар союзы җитәкчеләренә рәхмәт, алар фронттагы татар газеталарын онытып бетермиләр, журналның яңа саннарын җибәргәләп торалар иде.

Шулай да 1943 елны журналны алдыруда шактый зур өзеклек булды. Тылга, каләмдәш иптәшләребезгә хатлар язып, ялынып, ялварып та алдыра алмаган чакларыбыз булгалады. Андый вакытларда журналның яңа санын гына түгел, хәтта күптәнге саннарын күрү өчен дә әллә ни бирергә әзер идек без.

Журналның чираттагы саннарын күрергә сусап йөргән шундый айларның берендә, әле дә хәтердә, сентябрьдә, хәзер Бөек Ватан сугышы тарихында «1943 елдагы Смоленск операциясе» дип аталган каты сугышлар барган көннәрдә, алгы сызыкта бер лейтенант миңа, сүз ара сүз чыгып:

— Безгә моннан бер ай чамасы элек «Совет әдәбияты» журналы килде,— диде.

Бу хәбәр мине бик кызыксындырды: «Аларга килгән, ә безгә юк».

— Кайсы саны?

— Май саны.

Бу санны күргәнем юк иде.

Мин сорашуымда дәвам иттем:

— Кемгә килә соң ул сездә?

— Мәхмүд Максудов дигән сугышчыга килгән булган.

Бусы инде минем өчен чамадан тыш гаҗәп хәбәр булды. Мин, лейтенантым янымнан китеп бармасын дигәндәй, аның портупеясыннан тотып алдым.

— Кем соң ул Максудов? Язучы Мәхмүд Максуд түгелдер бит? Капитан?

Егет гамьсез генә җавап кайтарды:

— Кем белгән аны.

Ә минем сорауларым артканнан арта бара иде: кайда ул Максудов? Кем булып хезмәт итә? Күргәнең бармы? Төс-бите, кыяфәте ничегрәк?

Дустым Мәхмүд Максудтан күптән хат юк иде. Аның тылдагы хәрби частьтан фронтка киткәнен ишеткән идем, ләкин кайсы фронтка икәнен белми идем. Шуңа күрә бу исем мине бик кызыксындырды. «Безнең фронттамы икән әллә?» — дип уйлап алдым мин.

Лейтенант бу юлы да сорауларыма күңелне канәгатьләндерерлек җавап бирмәде.

— Батальоныбызда андый офицер юк,— диде ул һәм шунда ук өстәп әйтеп куйды: — Хәер, кем белә аны? Бәлки, булгандыр да. Мондый каты сугышларда бүген киләләр, иртәгә китеп тә баралар. Күбесе дөньядан ук китә. Нишлисең, сугыш.

— Батальоныгызда булмаса, полкыгызда яисә дивизиягездә Максудов дигән офицер юкмы?

Егет батальондагы офицерларны гына белә икән.

Ахырда мин, Мәхмүд Максудовның кем икәнен, аның хәзер кайдалыгын полк яисә дивизия штабында ачыкларммын дип уйлап, соңгы соравымны бирдем:

— Ул журнал кайда соң? Миңа биреп тора алмыйсыңмы?

Кызганычка каршы, биреп тора алмый икән. Оборонада торганда журнал батальондагы татар сугышчылары арасында кулдан-кулга күчеп йөргән, аны аерым-аерым дә, җыйнаулашып та укыганнар. Ә хәзер ул күрше батальондагы татар сугышчыларында икән.

Лейтенантның әйтүенә караганда, сугышчылар аны бик кызыксынып, яратып укыганнар, хәтта ул татар сугышчылары арасында хәрби-политик тәрбия алып бару өчен кулланма булып та хезмәт иткән. Сугышчылар аны тылдан, туганнарыннан, әти-әниләреннән килгән хат кебек итеп укыганнар.

Эзли торгач, ул журналны мин күрше батальоннарның берсеннән таптым. Табуы җиңел булмады. Дөресен әйтергә кирәк: бик авыр булды. Каты һөҗүм сугышлары барган көннәрдә аерым сугышчыларны гына түгел, хәтта син күрергә теләгән офицерларны табуы да, алар янына бару да бик читен иде. Ике арада өзлексез ут астында тотылган, снарядлар, миналар белән актарылып, пулялар белән мыжлап торган территория ята иде.

Шулай да мин әлеге журналны табу бәхетенә ирештем. 1943 елда чыккан 5 нче санның бер нөсхәсе иде ул.

Гадәттәге нөсхә. Сугыш елларындагы начар сыйфатлы саргылтсу кәгазьгә басылган. Буявы шактый тонык. Хәреф хаталары да җитәрлек. Шулай да аның тышкы күренеше, торышы һәм язмышы кызык иде.

Тышлыгын ертып алганнар. Әлеге лейтенантның әйтүенә караганда, аның эчке ягы буш булган, ягъни аңа бернәрсә дә басылмаган. Кәгазь юклыктан йөдәгән сугышчылар моңа бик шатланганнар, шунда ук аны ертып алып, тылга, әти-әниләренә, туганнарына хат язганнар. Ике хатка җиткән, ике кешене бәхетле иткән.

Журналның текстлы өлеше беренче битеннән алып соңгы битенә кадәр тулысынча сакланган. Әмма ул, укыла-укыла, кулдан-кулга йөри-йөри, шул кадәр тузган, таушалган, күпереп, калынаеп киткән, аерым юллары хәтта танымаслык хәлгә җиткән иде,— кыскасы, иң бәхетле, иң укылган китап язмышын башыннан кичергән иде ул.

Сугышның тынып торган минутлары иде. Тынып торган дигәч тә, атышлар тәмам туктаган вакыт түгел, ә бераз басылып торган минутлары гына иде.

Мин күптән түгел генә немецлар ташлап качкан, әле һаман дары исе, үлем исе аңкып торган тәбәнәк бер землянкада журнал битләрен ашыгып-ашыгып актарырга,

кайбер урыннарын укырга керештем. Сугышчылар аны миңа, дөресе, бер сержант, вакытлыча гына бирел торды.

— Зинһар, иптәш капитан, ачы миңа кире кайтарып бирергә онытмагыз,— диде ул миңа, ялынган һәм үтенгән тон белән.— Бик кирәкле журнал ул... Миңа бик кирәк. Ротадагы татарлар, башкортлар, казакълар, үзбәкләр арасында агитатор мин. Аларга укыйм мин аны. Барысы да аңлый. Күргәнсез, татар халкының каян килеп чыгуы турында бик кызыклы мәкалә бар анда. Шигырьләр, хикәяләр дә бар... Очерклар да...

Чыннан да бу санда Х. Гыймадиның «Урта Идел буе халыкларының татар-монгол игосына каршы көрәше тарихыннан» дигән мәкаләсе бар иде.

Журналны озак актарып торырга насыйп булмады. Атышлар көчәйде. Егетем минем янга ашыгып йөгереп керде дә:

— Гафу итегез, иптәш капитан, журналны мин алып китәргә мәҗбүр булам,— диде.— Батальоныбыз хәзер кузгала. Җыеналар.

Ул журналга таба кулын сузды. Мин аңа каршы килмәдем, бирдем. Ул акланырга, миннән гафу үтенергә теләгәндәй:

— Бик кирәкле журнал шул ул,— дип кабатлады.— Безнең борынгы бабаларыбыз Идел буендагы башка халыклар белән бергә, бер сафта торып, монгол оккупантларына каршы сугышканнар икән. Бүген дә без...

Сержант әйтәсе сүзен әйтеп бетермәде, сөйләшеп торырга вакыты юк иде аның. Кадерле журналны противогаз сумкасына тыкты да йөгереп чыгып китте. Миңа да инде монда калырга кирәк түгел иде. Ашыгыч эшләрем, үтисе бурычларым бар иде.

Шул чак күңелемдә сакланып калган уемны әйтим: журналдан аерылу җиңел булмады миңа: якын дустымнан, кадерле иптәшемнән аерылган кебек хис иттем мин үземне.

Соңыннан билгеле булды: редакция чыннан да бу журналны көньяк фронтларның берсендә хезмәт итүче язучы Мәхмүд Максудка җибәргән булган икән (бу санда аның «Фәриднең хатлары» исемле очеркы да басылган иде), ләкин полевая почтаны күрсәткән цифрларның берсе ялгыш язылу аркасында ул әдип кулына барып кермәгән, ә бөтенләй икенче якка китеп, Калинин фронтындагы бер батальонга эләккән һәм шунда аның бик кызыклы язмышы башланган.

Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң, Совет Армиясе сафыннан кайткач, журнал редколлегиясенең бер утырышында мин бу вакыйганы иптәшләргә сөйләдем. Алар моны бик кызыксынып тыңладылар. Тик бер иптәшнең генә, сугыш елларында фронтларда чыгып килгән татар газеталары редакцияләренә журналның яңа саннарын җибәрү эше йөкләтелгән сотрудникның гына, кәефе бик китте, моны сөйләгән өчен миңа чынлап үпкәләде. Ул, үзенең хатасызлыгына бик нык ышанып, ачуланып:

— Әгәр анда сезнең полевая почталарыгыз адресны саташтырганнар икән, анда минем гаебем юк,— диде ул миңа.

Сүз шуның белән бетәр дип уйлаган идем мин, ләкин бетмәде. Редколлегия утырышында катнашучы өлкән язучыларның берсе, әлеге сотрудникка дусларча карап:

— Тукта әле, син нигә үпкәлисең моңа? — диде.— Афзал сине гаепләмәде бит, бары булган хәлне генә сөйләде. Әгәр тәптәнрәк уйлап карасаң, син моңа үпкәләргә түгел, ә шатланырга тиеш. Беләсеңме нигә? Син ялгышып җибәргән журнал алгы сызыктагы сугышчылар кулына барып кергән, аларны көрәшкә, батырлыкларга рухландырган, фашизмга каршы сугышкан, атакаларга барган, бөек Җиңүне даулаган. Син менә бу вакыйганың шул ягын уйлыйсыңмы, юкмы?.. Ни дигән сүз бу? Журналыбыз халык белән бергә бара дигән сүз түгелме соң? Ә син үпкәләгән буласың... Үпкәләргә түгел, ә моны сөйләгән өчен рәхмәт әйтергә кирәк.

Өлкән язучының, аксакалыбызның, сүзләрендә тирән фәлсәфи мәгънә бар иде. Чыннан да, журналыбыз халык белән бергә бара, аңа хезмәт итә, укучыларны ленинчыл рухта тәрбияли, аларны бөек коммунистик җәмгыять өчен көрәшкә өнди, чакыра.

...Бу кызыклы вакыйгадан соң инде бик күп еллар үтте, бик күп сулар акты. Шулай да журналыбызның әлеге укыла-укыла тузып, керләнеп, каралып беткән нөсхәсе, аның язмышы әле һаман күңелемдә, күз алдымда.

Равил Фәйзуллин

# ЖУРНАЛНЫҢ ҮЗ АРХИВЫН БУЛДЫРЫЙК

Бала чакта, без, малайлар, яр ягасына җыелып, кулларны каш өстенә куеп, озаклап, Камага хәйран калып карап тора идек. Мәгърур, тантаналы кыяфәттә ак пароходлар уза, җыйнак катерлар үтә, арлы-бирле җиңел көймәләр йөренә. Кайчак, Кама-Чулманны урталай яргандай итеп (ул чак сулар ул галәмәт җәелмәгән иде), сузаеп, озын-озын баржалар таккан буксирлар уза. Алар салмак бара, озак уза, чөнки йөкләре авыр, юллары авыр. Кайсы баржага күмер төялгән, кайсына бодай, кайсына агач, кайсына кавын-карбыз... Ә буксир тарта да тарта...

Мин үзебезнең «Казан утлары»н күп йөкләр сөйрәүче әнә шул буксирга охшатам. Ул — мәдәниятебезнең күп кырлы һәм күп санлы хаҗәтләрен хәл кадәри канәгатьләндереп баручы бердәнбер калын нәфис журнал. Төп вазифасы — укучыларны әдәби хәрәкәтебезнең торышын билгеләүчә әсәрләр белән таныштыру белән бергә, журналыбыз сәнгатьнең бүтән өлкәләрен дә кочакларга тырыша. Фәнни хезмәтләр, тарихи материаллар, театр, музыка, рәсем сәнгатьләренең үсеш тенденцияләрен чагылдырган мәкаләләр... Кыскасы, иҗтимагый, рухи тормышның көзгесе ул «Казан утлары».

Инде журнал белән шәхсән минем бәйләнешкә килгәндә, 10 елга якын эшлекле мөнәсәбәттә торабыз дип саныйм. Бу дәвердә журнал битләрендә байтак шигырем басылып чыкты. Алардан тыш, мәкаләләр белән дә катнашкалап киләм. Беренче шигырьләрем басылганнан алып бүгенге көнгә кадәр (шәт, киләчәктә дә шулай булыр дип уйлыйм) бу журналда басылуны бер сынау мәктәбе узу һәм зур дәрәҗә дип саныйм. Татар әдәбиятының үзеген тәшкил итүче язучыларның күпчелеге, мөгаен, бу журналны үсү мәктәбе дип таный торгандыр. Һәрхәлдә, соңгы ун елда әдәбиятка аяк баскан яшь язучылар өчен «Казан утлары» чын мәгънәсендә старт мәйданы, күтәрелү ноктасы булды. Бер генә мизгелгә «Казан утлары» юк дип фараз итик. Әкиятләрдәгечә күкне җиде кат дибез икән, ихтимал, рухи күгебезнең берничә каты җимерелеп төшәр иде. «Талантлы-канатлы» дибез икән, бу тәгъбирне белү генә җитми бит, канатлы икән, очарга да кирәк. Биеклек кирәк, күк кирәк!

Миңа үземә дә, вакытлыча гына булса да, бу журнал редакциясендә беркадәр эшләп алырга насыйп булды. Ул — редактор булып Р. Мостафин эшләгән вакыт, тиражы берничә мәртәбә үскән, журналның укучылар арасында бик нык популярлаша бару чоры иде. Төрле бүлекләрдә аз-маз эшләштергәләгәнгә күрә сотрудникларның эшләре дә беркадәр таныш. Бүлекләргә ул вакытта да җиңел түгел иде, хәзер язучылар күбәйгән, табигый, әсәрләр дә күбәя барган саен, эш катлаулана, әсәрләр, авторлар, ниһаять, укучылар алдында җаваплылык арта төшкән булырга тиеш. Алыйк, тәнкыйть бүлеген генә. Асылда, бу әдәби тәнкыйть бүлеге генә түгел бит, сәнгатебезнең барлык төрләрен барлап баручы, гомумән, әдәби-иҗтимагый фикер үсешен чагылдыручы бүлек. Журналның икенче яртысында вак хәреф белән басылган материалларның күләмен һәм эчтәлеген күздән кичереп, хисаплап карасаң, бүлек башкарган хезмәтне беркадәр чамаларга мөмкин. Әлбәттә, һәр бүлекчең үз спецификасы, үз мәшәкате, үз җаваплылыгы. Журналыбызның 50 еллык бу бәйрәме белән, күңелемдә йөрткән бер теләгемне дә әйтәсе килә: журналның чын үз архивын булдырырга иде! Мәдәниятка караган күпме кульязма керә редакциягә! Бик күп бит. Әлбәттә, бөтенесе басылып бетә алмый, күпмеседер кала, күпмеседер беркадәр үзгәртелә, кайберсе авторга кайтарыла, кайберсе, еллар үткәч, югала да торгандыр... Бер заман кемнәрдер эзләячәк, киләчәк буын рәнҗиячәк. Әйтик, 50 еллык бәйрәмдә журналның «Безнең юл»дан «Казан утлары»ның бүгенге 5 санына кадәр саннарның тулы комплектлары булсын

иде әле редакциядә. Күргәзмә оештыр идең, күрсәт идең, тотып, актарып кара идең! Ә бу бит әле хыялланыр нәрсә түгел, табигый булырга тиеш, элементар нәрсә. Кыскасы, бу юнәлештә, гомумән, әдәби мирасның кыйммәтен аңлау һәм аны барлау юнәлешендә безнең һәрберебезгә уйларга уй, эшләргә эш җитәрлек.

«Журнал миңа нәрсә бирде» дигән сорауга бик күп рәхмәтле сүзләр белән җавап бирергә мөмкин. Журнал сөенеп басарлык, укучылар яратып укырлык әсәрләр язсак, бу — безнең иң чын рәхмәтебез булыр. Бәйрәм уңае белән, редколлегия членнарын, редакция аппаратында эшләүче хезмәткәрләрне ихлас котлыйм, фидакарь эшләрендә уңышлар телим. Якын елларда журналның тиражы 100 меңгә җитсен. Шулай булсын, республикабызның бай тормышын хәзер зур саннар — миллионнар, миллиардлар билгели,



Габдрахман Әпсәләмов

# ҮТКӘН ЮЛЫ ЗУР, КИЛӘЧӘК ЮЛЫ ЯКТЫ

«Казан утлары»на ярты гасыр... Моны әйтүе генә ансат. Анда безнең искелек чоңгылыннан көрәштә калкып, яңага, коммунизмга омтылган гаҗәп матур, катлаулы, вакыты белән фаҗигале, җиңүләре белән искиткеч гүзәл тормышыбыз чагылган. Әгәр журналның озын юлын күзаллап, җыеп, җәелмичә әйтсәк, болай: журнал безгә өр-яңа татар совет әдәбиятын ачты, коммунистлар партиясе сызган ленинчыл туры юлдан алып барып, дөньяны танырга һәм яратырга өйрәтте, совет әдәбияты кемгә хезмәт итәргә, кемне җырларга тиешлеген күрсәтте. Журнал үзенең битләрендә уннарча, йөзләрчә татар совет язучыларын, шагыйрьләрен, драматургларын, әдәбиятчыларын тәрбияләде, алар, үз чиратларында, үз әсәрләре белән партиягә яңа кеше үстерергә булыштылар.

«Казан утлары»н мин үземә нәрсәдер биргән һәм үзем анда нәрсәдер бастырган өчен генә олыламыйм. Журнал безнең әдәбиятыбызның көзгесе, ул нык идея позициясендә торган, зур бурычларны хәл итәргә сәләтле, талантлы һәм бердәм иҗат коллективыбызны оештырды, туплады. Барыннан да элек менә шул нәрсә сөендерә.

Мин журналга бөек Ватан сугышы алдыннан килдем һәм аның аппаратында эшли башладым. Журналны халык никадәр яратканын сугыш елларында үз күзем белән күрдем. Бу хакта фронттан кайткач, «Кызыл Татарстан» газетасында «Совет әдәбияты» журналы турында «Солдат хатлары» дигән мәкалә дә бастырган идем. Гаҗәп ул хатлар! Куе урман эчләрендә хәрәкәт иткән безнең подразделениеләргә почтаны да самолеттан гына ташлыйлар иде. Бер вакытны почта капчыгы «битараф» җиргә килеп төшә. Безнең сугышчылар дошманның көчле уты астында аны үзләренә алып кайталар, аннары саз суында чыланган «Совет әдәбияты»ның һәр битен учак яктысында киптереп, солдатларга кычкырып укыйлар...

Димәк, журналда җан азыгы булган!

Тыныч елларда журналның авторитеты һәм тиражы тагын да артты, ул күп меңнәрчә кешеләрнең аерылмас юлдашына әверелде, укучы аның битләрендә һәрвакыт илнең йөрәк тибешен сизеп килде һәм әле дә журнал заман сулышы белән яши. Мондый журналга язышу үзе бер бәхет ул.

Мин үземнең барлык диярлек хикәяләремне, повесть һәм романнарымны — исемнәрен санап тормыйм — журналда бастырдым. «Күк күкрәр» исемле яңа романымны да анда бирергә уйлыйм.

Журналның үткәне зур булса, киләчәге тагын да яктырак, өметләрек.

## Рафаил Төхфәтуллин

# ЖУРНАЛ МИҢА — МИН ЖУРНАЛГА

Казан утлары» минем гомерлек юлдашым дисәм, һич тә арттыру булмастыр. Хәреф таный башлаганнан бирле аның бер генә санын да укымый калганым юк бугай. Дөрес, сугыш елларында аннан аерылып торырга туры килде. Ләкин 1945 елда фронттан кайткач, китапханәдә көннәр буе дөньямны онытып, журналның үзем югында чыккан саннарын укып утыруым бик хәтердә. Гүя бик сагынган якын дустымны очраттым да сөйләшеп-сөйләшеп һич кенә дә сүзләр бетми.

Шушы дустым-сердәшем минем үземне дә әдәбият мәйданына җитәкләде. Беренче хикәяләремне дөньяга чыгаруда шәфкатьле кулларын сузган журнал редакторлары Афзал ага Шамовка, Гази ага Кашшафка, ул вакытта редакциядә эшләгән Габдрахман ага Әпсәләмовка, остазым Гомәр ага Бәшировка олы рәхмәтләремнең иге дә, чиге дә юк.

Ул елларда журнал сотрудниклары Гариф Ахунов һәм Яхъя Халитов белән якыннан танышып, дуслашып китүем дә минем әдәбиятка якынаюымда аз роль уйнамады.

Журналда ни бастырдым? Беренче тапкыр анда «Сталинградлылар» дигән хикәям 1952 елда басылды. Шуннан бирле уңышлырак һәр хикәямә, һәр повестема журнал бик шәфкатьле төстә урын биреп килә. (Мәкаләләр белән дә чыккаладым.) Аларны санап тору кирәкмәстер. Ник дигәндә... 20 ел буе биргән «әдәби продукциям»нең күләме азрак шул әле. Журнал юбилеен әнә шундый күңел канәгатьсезлеге белән дә каршылыйм. Бәрәкәтле канәгатьсезлек булсын иде!

## Фатих Хөсни

# АНЫҢ ЯКТЫСЫНДА...

Кайчандыр Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Гали кебек мөхтәрәм әдипләребез редакциясендә, «Безнең юл» исеме белән чыгарыла башлаган бу журнал соңыннан берничә мәртәбә исемен алыштырды, редакторлары алышынды — берәүләре китте, икенчеләре килде, ләкин журнал үзе китмәде, дересрәге, без аңардан китмәдек, ул безнең өчен — татар язучылары өчен гел шулай безнең юл булып калуында дәвам итте. Әле дә шулай! Рус классикларыннан берсе, ялгышмасам Тургенев бугай, әйтә: «Без барыбыз да Гогольнең «Шинель»еннән чыккан кешеләр», ди. Шуңарга охшатып бүген без — әлегә исән булган татар язучылары бер авыздан диярлек әйтә алабыз: әйе, без шул бер юлдан — безнең юлдан килдек һәм шул юлдан килеп ялгышмадык шикелле...

Шәхсән, мин үзем әдәбиятка күп кенә борылмалы юллар үтеп, хаталар да ясаштыргалап, кайнаша-эзләнә кергән кеше. Элегрәк яшьләр матбугатында, пионер газеталарында кулымны сынадым, әмма үземнең чын әдәби язмышымны 1927 елда «Безнең юл» журналында басылган «Дөнья матур миңа» дигән шат рухлы шигырем белән башладым дип горурлык белән әйтә алам. Хәер, саный китсәң, күп алар. Ләкин укучыларга билгеле булган (минем шулай уйларга тәвәккәллегем җитә!) төп әсәрлә-

рем — «Йөзек кашы», «Гыйльмениса», «Минем тәрәзәләрем», «Язмыш шуклыгы» кебек үзем бик яратып язган повестьларым, «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел» кебек романнарым һәм күп санлы хикәяләрем бөтенесе шушы журнал битләрендә беренче укучыларын таптылар. Җәннәткә барып кергәнче иң элек сыйрат күпере аркылы үтәсе бар — дичи мифология шулай ди. Әлбәттә, без дә җәннәткә йөгереп кенә барып кермәгәнбездер, без алай изге бәндәләрдән түгел, безне дә тараганнардыр, безнең дә нервларыбызны бозганнардыр. Әдәбиятта шунсыз мөмкин түгел, шуның өчен редакция дигән «сыйрат күпере» бар, анда, уч иткән кебек, үтә тә төпченүчән, үтә дә ортодоксаль, гади телгә күчереп әйтсәк, үтә дә «каеш» кешеләрне утыртып куялар. О, беләбез инде без аларны, йөрәгебезгә үтмәсә, бу чаклы сузып әйтмәс тә идек! Ә бит начарлык теләп түгел, яхшылык теләп — укучыга, язучының үзенә, ниһаять, гомуми әдәби хәзинәбезгә яхшылык теләп шулай эшлиләр. рәхмәт төшкерләре. Шуны истә тотып, журналның бу тантаналы көннәрендә аларга — редакциядә эшләп киткән кешеләрнең элеккеләренә дә, хәзергеләренә дә чын ихластан язучы рәхмәте җиткерәсе килә. (Рәхмәтне хәзергеләренә күбрәк тә «ишәргә» булә, узганнары — инде узган, хәзергеләре белән алда әле маңгайга-маңгай очрашасы бар!)

Уен-муен калып торсын, ниһаять, менә без «Казан утлары» яктылыгына килеп чыктык. Шул игелекле юл, безнең юл, үз юлыбыз белән килеп чыктык. Журналда хәзер яңа, яшь көчләр эшли. Яшь көчләр дигән сүз, икенче төрле әйткәндә, яшь тешләр дигән сүз дә ул. Алар белән уен корып булмый, әйберең яхшы булса гына кил. Тулаем алганда, журнал, аның хәзерге торышы, утызынчы еллар, сугыш алды еллары белән чагыштырганда, күз генә тимәсен, сизелерлек яхшырды. Журналның тематик диапазоны киңәйде, басылган әсәрләрдә, вакыйга өстеннән койрык чәнчеп чабуга караганда, кеше күңеленә тирәнрәк үтәргә тырышу сизелә, журнал соңгы елларда күп кенә яшь каләмнәр тәрбияләп үстерде. Болары — шулай, боларын безнең кулдан инде, шәт, тартып алмаслар. Әмма борын чөяргә ашыкмыйк, шулай ук булып җитмәгәннәре дә юк түгел. Басылган кайбер әсәрләргә караганда, журнал редакциясендә утыручы «яшь тешләргә» кай очракта үткенлек, яхшы мәгънәсендәге «каешлык» җитешеп бетми. Темасы бөтенесен дә аклый, дип карау да бар кебек. Аннары журналның гомуми культурасын күтәрү, фактларга карата төгәллек, гыйльмилек критерием саклау, әдәби тел сафлыгына игътибарлылык, иҗтимагый тормышыбызның төрле өлкәләреннән төрлерәк каләмнәрне тарту кебек мәсьәләләрне дә көн тәртибенә куярга вакыттыр.

Ничек кенә димик, кай яктан гына килмик, без — татар язучылары — гел шул үзебезнең иялешенгән «Казан утлары» яктылыгына килеп чыгабыз. Аның нурлары өлегә күзне чагылдырырлык ук булмаса да, шулай да азып-тузып йөрмәүче без тәүфыйк ияләренә җитәрлек. Аның яктысында яшь бөреләр ачылганнан-ачыла бара, урта буын ир-егетләре мәйдан тота, безнең ише карт-коры, карт мәчеләр кебек, нигезгә сузылып ятып, сөякләрен җылыта. Ара-тирә, сырт йоннарын бик кабартмыйча гына, мыраулап та куйган булабыз.

## Әдип Маликов

# СИХОТЭ-АЛИН ТАУЛАРЫ АША

1945 ел, сентябрь башы. Бөек Тын океан киңлекләрендә тагын бер сугыш учагының яңа гына сүндерелгән чагы. Безнең Сахалин дивизиясе Тоэхара (хәзерге Южно-Сахалинск) шәһәренә килеп керде. Урман, тау араларында әле атыш тынмаган. Анда-санда качып йөргән самурай группаларын коралсызландырып, соңгы разведкадан кайтып кергән бер көндә, кулыма гранат сыман озынча

төргәк тапшырдылар. Мин аны сүтәргә ашыкмадым, башта печатенә, кире адресына күз төшердем: «Казан». Күңелемнән бер уй йөгереп узды: әллә басылды микән?

Чик буе землянкасында, окопта язылган күләмле беренче шигъри әсәрем — «Атаудагы хисләр» поэмасын шул елның маенда мин Казанга җибәргән идем. Бер бит чамасы сәлам хаты да яздым. Ә поэманың башында — түбәндәге юллар:

. . . . . . . . . . . . . .

Бир урныңны
ерак атаудагы
Солдат хисләренә, Казаным!

Кат-кат төрелгән ул «гранат»ны мин, дөресен әйтим, дулкынланудан калтырана-калтырана гына ачтым. Эченнән «Совет әдәбияты» журналы килеп чыкты. Редакторы — Газиз Иделле, диелгән. Журнал «2 нче Белоруссия фронтының татар сугышчыларыннан татар халкына хаты» белән ачылган. Хат астына генераллар, бик күп офицерлар, татар сугышчылары, шул исәптән, фронтовик-шагыйрь Шәрәф Мөдәррис, фронтовик-язучы Гамир Насрый кул куйганнар. Повестьтан өзек, фронтовик язучыларның хикәяләре, шигырьләре арасында минем беренче поэмам да бар иде. Хәтта тыгып җибәргән хатымны да басып чыгарганнар. Менә бит, шушы кадерле төргәк, төргәк эчендәге бердәнбер калын журналыбыз Сихотэ-Алин таулары һәм диңгезләр аша, сугыш юллары буйлап, ун мең чакрым еракльктагы атауга үзенең яшь авторын эзләп килгән! Мин үз гомеремдә, шул елларны истә тотканда, ике зур шатлык кичергәнмен икән: берсе — сугыштан исән чыгу, икенчесе — «Совет әдәбияты» журналының 1945 ел, 7 санын кулыма алу шатлыгы!

Шул вакыттан бирле журнал белән арамның өзелгәне юк. Барлык поэмаларым, күпчелек шигырьләрем, очеркларым «Совет әдәбияты» — «Казан утлары» битләрендә урын алып килделәр. Киләчәктә дә язмыш безне шундый шатлыктан аермасын!

## Әмирхан Еники

# «БЕЗНЕҢ ЮЛ» — «КАЗАН УТЛАРЫ»

Уйлап утырам... Беренче әйберем («Озын көй тыңлаганда» дигән нәсер иде ул) «Безнең юл»да басылып чыкканда миңа унҗиде яшь булган икән. Ә хәзер... Хәзергесен әйтеп тормаганда да була. Кыскасы, шул заманнан бирле кырык алты ел узып та киткән. Журналга исә менә илле яшь тулды. Димәк, без бергә картайганбыз?! Хәер, журнал картаямыни ул?.. Журнал яши дә яши, буыннардан буыннарга күчә-күчә яши, тик без генә олаябыз, китәбез, алышынып торабыз... һәм шулай булырга тиеш тә ул!

Егерменче елларның икенче яртысында мин «Безнең юл»да берничә хикәя һәм вак-төяк нәсер чыгарып өлгердем. Заманның бөрлык исемле язучылары катнашкан житди журналда басылырлык булгач, ул әйберләр шул чактагы таләпләргә азмыкүпме җавап биргәннәрдер инде, әмма хәзерге таләпләрдән чыгып караганда, алар бик зәгыйфь нәрсәләр, шуңа күрә мин аларны искә төшерергә яратмыйм да.

Утызынчы елларның башында булса кирәк, журнал исемен үзгәртте: ул «Атака»га әйләнде. Исеменә ияреп, эчтәлеге дә бик нык үзгәрде. Мин үзем «Атака»га катнаша алмадым — ул елларда инде әдәбияттан читкә киткән идем.

Аннары журнал исемен тагын алыштырды — «Совет әдәбияты» булып чыга башлады. Аның бу исеме озын гомерле булды, һәм минем дә яңадан әкренләп әдәбиятка кайтуым аның шушы чорына туры килә. Дөрес, сугышка чаклы мин аңардан һаман читтә идем әле, тик фронттан яза башлагач кына, ниһаять, аның бусагасыннан атлап кердем дия алам. Сугышның бу җәһәттән файдасы тиде: ул безне җыйды, туплады, берләштерде.

Соңгы егерме биш ел дәвамында инде мин журналның даими авторларыннан берсе булып танылдым дип әйтсәм, бу, шәт, мактанудан саналмас. Һәрхәлдә, барлык повестьларым һәм хикәяләремнең күп өлеше, шулай ук очерк-мәкаләләрем аның битләрендә басылып чыктылар. Билгеле, мин аңа бик ияләштем, төп иҗат йортым итеп карарга өйрәндем. Ләкин бу әле безнең арадагы мөнәсәбәт һәрвакытта тату-шома гына барды дигән сүз түгел. Нык кына тартышкан, бәхәсләшкән чаклар да күп булды. Әдәбият бик нечкә, бик четерекле нәрсә ул, бәхәс-тартышсыз җиңел генә «уткәреп» булмый аны... Хәер, бу кадәресе инде аның язучысына карап тә билгеләнә торгандыр.

Мин үзем җитлеккән әдәбият һәр җәһәттән дә бик төрле булырга тиеш дигән карашта торам. Һәр язучы, һәр шагыйрьнең үз дөньясы, үз йөзе булса гына талантлы һәм кызыклы әсәрләр туарга мөмкин. Менә безнең хөрмәтле «Казан утлары»быз, бай традицияле җитди журнал буларак, әнә шул төрлелекне идея бердәмлеге нигезендә куәтли һәм чагылдыра алса, ул киләчәктә дә әдәбиятыбызның чын көзгесе булып калыр дип ышанасы килә... Бик озын гомер телим мин аңа!



## Саҗидә Сөләйманова

# ПОЭЗИЯ МӘКТӘБЕ

«Казан утлары» минем өчен поэзия мәктәбе булды. Журнал битләрендә басылган шигырь-поэмалар — иң оста укытучылар. Ләкин иң кайгыртучан, иң таләпчән остазлар — журналның поэзия бүлеген алып баручылар.

Моннан ун еллар элек «Казан утлары» аша минем беренче шигырьләр көлтәсе дөнья күрде. (Аннан элек «Татарстан яшьләре»ндә бер-ике шигырем чыккан иде.) Бу эштә үземнең катнашым бөтенләй булмады. Шигырьләрне укып, киңәш бирүчеләр дә, журналга тәкъдим итүчеләр дә — поэзиянең үсеше белән чынлап кызыксынучы өлкән шагыйрьләр булды.

Әдәби тәнкыйтьтә «Сибгат чишмәсе» дигән сүз бар, ә менә «Сибгат иләге» дигән төшенчә бар микән? Бер вакыт журналга ике дистәдән артык шигырь җибәргәч, һәммәбез ихтирам итә торган Нури ага Арсланов: «Унөч шигыреңне сайлап алдым», дип җавап язган. Дөньяга тугызы гына чыкты. Бу хакта Нури абыйның хәтеренә төшергәч, ул: «Сибгат иләге нечкәрәк бит», диде. Шушы «нечкә иләк»кә эчтән генә күпме рәхмәт әйттем! Журналда ун ел буена кеше укырдай шигырьләрем чыгып килгән икән, үземә дә сизелмәгән четаклыкларны уткәрмәүче әлеге кыл иләкнең роле зур.

Журналның «иләге» нечкәрәк булган саен чын әдәбиятны сиземмәве көчлерәк. Аның аша төрле жанр, төрле стиль, формалар дөньяга чыга, юл таба.

## Риза Ишморат

# ЯРАТУ ХИСЛӘРЕ БЕЛӘН

«Казан утлары»... Казанның гына түгел, бөтен республикабызның, әдипләребезнең генә дә түгел, бөтен халкыбызның да уй һәм хисләре, гүзәл эшләре ялкын булып чагыла кебек бу журналда. Ана телебездә әсәр дөньяга килү белән аларны иң беренче булып бастырып чыгара торган әдәби журналыбыз халкыбызның тормышы, культурасы елдан-ел үсә барган кебек, ул да үсә, эчтәлеге белән дә, сыйфаты белән дә байый һәм яхшыра барды.

Журнал килүгә мин аны зур хөрмәт һәм ярату хисләре белән кулыма алам да бөтен эчтәлеге, анда кергән барлык материаллар белән танышып чыгарга ашыгам. Күп кенәсен бирелеп, дулкынланып укыйм. Үземнең дә әсәрләрем иң башлап шушы журналда басылганы («Шаулыйлар дулкыннар», «Давылга таба», «Үлмәс җыр», «Гөлзада» һ. б.) өчен генә түгел, ә бәлки әдәбиятны яратып укучы буларак кызыксындыра ул мине.

Мин журналны беренче еллардагы саннарыннан башлап, димәк, илле елга якын, өзлексез диярлек укып килүчеләрнең берсе. Шикләнмичә әйтә алам, тормыш һәм әдәбият белән танышуда, эстетик зәвык тәрбияләүдә, шулай ук язучы буларак үсә баруымда зур ярдәм итте ул миңа. Күп санлы әдипләребез белән якыннан танышу, аралашу, дуслашуыма сәбәп булды. Бүген «Казан утлары» журналының 50 еллык тантанасы көннәрендә редакциядә эшләүче, шулай ук анда элекке чорларда да эшләгән иптәшләрне һәм, әлбәттә инде, журналыбызның күрке булган барлык әдипләрне олы бәйрәмебез белән котлап, гади укучы буларак, аларга кайнар рәхмәтемне белдерәсем килә.

«Казан утлары»ның киләчәктә тагын да көчлерәк балкуын, аның битләрендә әдипләребезнең тагын да гүзәлрәк үрнәкләре барлыкка килүен телим.

## Эдуард Касыймов

# ЯШЬНӘП-КҮКРӘП ЯШӘ!

Еш кына «сүз илаһи бер кечкә ия» дибез...

Алай да күңелебезгә иң якын җаннарга — сине дөньяга китергән әнием белән әтиеңме ул яки сөйгән кызыңмы — артык матур һәм купшы сүзләр әйтүдән тыелабыз. Гадәтләнмәгән. Тартынабыз. Оялабыз. Әмма хикмәт әдәпнәзакәттә генә түгелдер. Иң олы, иң гүзәл һәм иң изге хисләр төптә, бик тирәндә йөрәк җылысы тирәсендәрәк сакланып калучанлыгындадыр... «Илаһи» сүзебез кайчакны шулай үтә мескен төстә егәрсез булып чыга...

Монда да шуңа охшашрак хәл. Ни әйтим телем белән, ни языйм каләмем белән?

Аны сагынып көтеп аласың. Менә инде ул, ниһаять, синең җылы кулларыңда... «Казан утлары». Нурларын мул сибә. Ләкин ашыкмыйсың. Иң әүвәл акрен генә битләргә керешәсең. Ә күңел талгын гына үз дулкыннарында тирбәлә бирә. Дулкыннар көчәя бара. Йотыласың... Сөендерерме, көендерерме?

Төрле чагы була... Ләкин һичкайчан битараф иттерми, гамьсез һәм вәемсыз хәлдә калдырмый.

Аңа инде илле яшь...

Әнә шулай вакыты белән чиксез куанычларга да, ачы хәсрәтләргә дә күндергәләп, хәтта кайчагында зәһәр тәтене белән күз яшьләрен чыгарткалап та, уенын-көлкесен дә онытмыйча... кыскасы, асыл егетләрчә, яшьнәп-күкрәп, дәртле яшьлекнең чәчәк аткан дәвере төсендә үзенең **йөз еллыгын** да каршы алса ла икән! Моны мин гап-гади укучы булып әйтәм, бу — минем иң сәмими һәм иң изге теләгем.

Ләкин журнал минем тормышымда иң ышанычлы һәм хөрмәтле юлдашым гына түгел әле. Ул — минем төпле киңәшчем һәм ныклы таянычым да... Журнал мине әдәби-иҗат юлына алып керде. Канатлар үстерде. Аның битләрендә хикәя, очерк яисә әдәби-гыйльми мәкаләләрем басылып чыгуы хакында әйтмим дә, нәкъ менә шунда минем зуррак, күләмлерәк әсәрләремнән «Гомер ике килми» романы, «Кояш көн дә чыга», «Бир кулыңны, дустым!», «Көмеш язулы кылыч», «Сорбонна профессоры һәм без» кебек повестьларым дөнья күрде. Инде менә «Томан аша» дигән романымның дәвамы **«Һаваларда тургай»** (башта «Кош — канаты белән» дип исемләнгән иде) романы да журнал ишеген ныклап шакыды. Шәт, озакламастыр, якын арада бу әсәрем дә хөрмәтле укучыларыма үзенең чын йөзен, асыл сыйфатларын ачып салырдыр.

Шулай, башкалабызда кабыздырылган уртак учагыбызга ара-тирә мин дә акыл сәләтем һәм йөрәгем кайнарлыгы биргән өлешне салып барам икән һәм аның ялкынын дөрләтүдә азмы-күпме булышам икән — моны мин, олы җаваплылык булуы өстенә, зур бәхетем дип тә исәплим.

## Атилла Расих

# ӘДӘБИЯТ МӘЙДАНЫНА ЮЛ АЧУЧЫ

Мин 1939 елны үземнең татар әдәбиятыннан башка яшәү алмавыма, аннан тормышымның бернинди дә мәгънәсе калмаячагына иман китереп, Кавказдан өйгә, Казанга, кайттым.

Исәбем әдәби эшчәнлегемне юмор һәм сатирага багышлау иде. Әзер темаларым да, бер-ике хикәям дә бар иде. Шулай кайту белән дип әйтерлек мин «Совет әдәбияты» редакциясенә киттем. Ул вакыттагы редактор Тәхфәт Имаметдинов шунда ук мине каршысына утыртып, хикәяләремне укып чыгарга кушты, һәм яратканлыгын белдереп, хикәяләрне якындагы саннарның берсендә бастырачагын әйтте.

Мин шул көннән бирле үземне әдәби журналыбыз «Казан утлары»ның зур мәсьүлиятле корреспонденты дип исәплим.

Юбилярыбыз үзенең яшәү дәверендә татар совет әдәбияты көчләрен туплау, әдәби хәрәкәткә дөрес юнәлеш бирү өлкәсендә күп тырышлыклар күрсәтте. Бүген актив һәм нәтиҗәле эшләп килүче әдәбиятчыларның күпчелеге беренче фатиханы шул журналда алдылар, шуның битләре аша киң мәйданга аяк бастылар, шунда чыныктылар, шунда үстеләр.

Минем үзем өчен дә әдәбият мәйданына юл ачучы шул ук безнең кадерле юбилярыбыз булды. Ул минем фронтта язган хикәяләремне укучыга оператив рәвештә җиткереп, миңа фашизмга каршы олы мәйданда каләм белән дә көрәшергә мөмкинлек тудырды. Ниһаять, сугыштан кайткач, фронтта язылган беренче повестемне («Бәхет орлыклары») мин шуның битләрендә бастырдым. Бу исә миндә олы формаларга мөраҗәгать итү кыюлыгы тудырды.

Ләкин, кызганычка каршы, бу вакыйгадан соң унбиш еллар чамасы мин журнал өчен «мәхәббәтсез үрдәк баласы»на әйләндем. Ул минем «Дустым Мансур»ны да, «Язгы авазлар»ны да һәм, гомуман, язган һәр әсәремне тибәрә килде. Ни хәл итәсең! Ситуация шундыйрак иде, күрәсең, ул чорда...

Минемчә, журналның йөзен редактор вазифасын үтәүче, әдәбият хәрәкәте өчен үтә җаваплы кеше, билгели. Юбилей көннәрендә мин редакторлар арасыннан аерата зур хөрмәт белән үземә дебют мөмкинлеге биргән Төхфәт Имаметдиновны, сугыш елларында хәрәкәттәге армиядән язган әсәрләремне тоткарлыксыз басып барган Гази Кашшафны, «Ике буйдак»ны укучыга җиткергән Газиз Мөхәмматшинны, «Ямашев»ка каршылык күрсәтмәгән Рафаэль Мостафинны рәхмәт әйтеп искә аласым килә.

Туганнарча кайнар ярату хисләре белән мин бердәнбер журналыбызны илле еллыгы көнендә тәбрик итәм, аңа бәхетле киләчәк, озын гомер телим.

## Барлас Камалов

# ОСТАЗ, АРАДАШЧЫ, ДУС

Бүгенге юбиляр — хәзер «Казан утлары» исеме белән чыгып килә торган әдәби журналыбыз — минем тормышыма ун яшьлек малай чагымда ук килеп керде. Мин аның битләреннән үзем аңлардай әдәби әсәрләрне һәм тәнкыйть мәкаләләрен кызыгынчы елның җәеннән башлап укый башладым. Шуннан бирле генә дә минем өчен күпме талантларның ничәмә-ничә яңа әсәрен ачты инде ул, күпме галимнең акыллы сүзен, әдипләрнең ялкынлы бәхәсләрен, әдәбиятсәнгать һәм культура яңалыкларын ирештерде. Бәхетемә дип әйтим, институтта укыганда һәм аннан соңгы елларда миңа аның чыга башлаган көненнән алып дөнья күргән һәммә саны белән танышып чыгу насыйп булды. Кыскасы, мин аның илле еллык эшчәнлеге һәм тарихы белән нигездә таныш.

Шуңа күрә дә, журналыбызны олылап, **остаз** дип атыйм. Мин анда басылган бик күп әсәрләр, теоретик мәкаләләр, дискуссияләр аша әдәби осталыкка өйрәндем дип исәплим. Һәрхәлдә, «Казан утлары» әдәби мәктәбемдәге хөрмәтле укытучыларның берсе булды, шулай булып кала бирә.

Журналны мин бер дә икеләнмичә **арадашчым** дип тә олылыйм. Илебездә яшәүче халыклар теленнән, Көнбатыш һәм гомумән бөтендөнья әдәбиятыннан күпме әсәрләр белән таныштырды ул безне! Ярты гасыр буена укучыга тәкъдим ителгән мондый үрнәкләрне саный китсәң, исемлеге су буе булыр иде! Мин белмәгән телләрдән мин сокланып укырлык әсәрләр биргән икән, моннан да шәп арадашчыны кайдан эзләмәк кирәк?!

**Дус** дип атавымның да сәбәбен аңлатыйм. Тормышыңдагы барлык хәлләрне иң якын дустыңа гына яшерми сөйләп була. «Казан утлары» да, укучыларны җан дустыдай якын итеп, аларга бик-бик күп нәрсә сөйли. Язучыларның иҗат җимешләрен бирү белән генә чикләнми, ил һәм дөнья хәлләренең иң мөһимнәрен хәбәр итү белән генә дә канәгатьләнми, бәлки язучыларның иҗади кредоларын ачкан диалоглар һәм монологлар бирә, укучыны әдәби белемләндерү юнәлешендә көчен кызганмый, тормыштагы күп санлы проблемалардан читләшмәскә тырышып җан ата.

Автор буларак, мин «Казан утлары» журналында 1953 елда басыла башладым. Беренче адымнарым аерым китапларга карата тәнкыйть мәкаләләре язудан гыйбарәт иде. 1959 елның февралендә журнал битләрендә минем «Үр менгәндә» повестем басылды. Өченче ел һәм былтыр «Казан утлары»нда минем «Күршеләр» һәм «Ялыкмаслар» дигән повестьларым дөнья күрде. Һич яшерми әйтим: бу — зур куаныч. Әсәр журналда басылдымы — аны күп санлы укучылар гына түгел, хәтта язучыларыбызның да һәммәсе диярлек укый. Димәк, дары бушка шартламаган булып чыга. Ә «Казан утлары»ның тиражы хәзер сөенеп бетә алмаслык!

Ярты гасырлык бәйрәмен иткән көннәрдә журналыбызга уңышлар, иҗади кыюлык телим. Яңадан-яңа талантлы каләм ияләрен ача барсын ул!

**Гамил Афзал**

# ЖУРНАЛ МИҢА НӘРСӘ БИРДЕ

Бу сорауга бер-ике сүз белән генә җавап биреп котылып булмый, бертекләбрәк сөйләргә кирәк. Мин Магнитогорск шәһәрендә 1936 елда ук «Габдулла Тукайдан да уздыра торган» шагыйрь булырга кирәк дип, кәгазь тырмарга тотынган идем. Язарга теләк зур, талант чамасыз, әзнепә өчәр шигырь әтмәллим, тик ни турында язарга, ничек язарга икәне турында уйлап та караган юк, шигырь юлларының очлары рифмаланса, шагыйрь булырга шул җиткән: шалтырый-калтырый, ялтырый, тагы ни кирәк.

Бер дәфтәр шундый шигырьләр язу белән, әтәчләнеп, олы шагыйрьләр белән бәхәсләшәсе килә: син кем дә мин кем, янәсе. Тик шигырьләрне беркайда да басмыйлар. Еллар үтә тора. Калын-калын кулъязма китаплар языла, ә тәкәббер Казан талантны танымый. Тәкәббер Казанга үч итеп, язам да язам. Ә Шәрәф Мөдәррис, Җәвад Тәрҗеманов, Зәки Нурилар җиде кат күктә алла белән сөйләшәләр.

Бик соңыннан булса да аңладым: ул чагында мин Ә. Ерикәй, С. Хәким, Ш. Мануур шигырьләренең бик алама вариантларын язып йөргәнмен икән.

Сугыш башланганда калын-калын дүрт кулъязма китабым бар иде инде. Сугыш елларында көненә 12 шәр сәгать эшләгәндә дә, конторадан чыгарып түккән кәгазьләрне, иске чертежларны җыеп, шулардан дәфтәр тегеп, шигырь яздым.

Сугыштан соңгы елларда миңа Г. Иделле, Ә. Камал язып җибәргән рецензияләр һәм «Совет әдәбияты»ннан килгән «каләмегез өметле генә күренә, ләкин...» дигән хатлар мендәр калынлыгы җыелды. Шунысы сөенечле, уңыш теләп, кайнар сәлам җибәрәләр иде.

Йөз шигырь язып берсе дә басылмаган чагында, рәнҗеп һәм усалланып, йөз дә беренче шигырьне язарга тотынырлык өмет һәм ныклык булмаса, шигырь язам дип йөрмә дә икән. Бер дәфтәр начар шигырь язу белән, әдәбиятның түренә кереп, аяк бөкләп утырырга тырышу кирәкми икән.

Унтугыз ел тырышканнан соң гына мин әдәбиятка килдем.

Башкортстанның Шәрип авылында каты авырып, «миннән булмас, ахрысы, инде үлсәң дә ярый» диебрәк шикләнә башлаганда, 1955 елның ноябрь аенда «Совет әдәбияты» берьюлы тугыз шигыремне бастырып чыгарды. Шуннан мин терелдем, аякка бастым, урамга чыктым. Журнал миңа киң юл бирде, нык канатлар бирде, биек трибуна бирде, тырышкан ташны яра икән дигән ышаныч бирде.

Мин биек трибунадан халык белән сөйләшә башладым, адымым ныгыды, тавышым көрәйде, җиргә каты басып йөреп була, колач салып йөзеп була, кадерен белеп эшлә дә эшлә генә.

Журналда барлыгы 156 әсәрем басылып чыкты, әле чыгасылары күп, язасылары күп, тимернең кызган чагы, алда өмет зур.

«Казан утлары»н 50 еллык юбилее белән кайнар котлыйм, аңа зур тиражлар, талантлы авторлар телим! Укып исләрең китәрдәй романнар, пьесалар, хикәяләр (кибәк түгел), ялкынлы поэмалар, энҗеләрдәй шигырьләр елга булып агып килүен телим. Берсеннән-берсе гүзәл шедеврларның кайсын алданрак басарга белми редакторлар аптырасыннар! Амин.

**Газиз Иделле**

# УЛ ЕЛЛАРДА

1945 елның башы иде. Берничә айлар «Ватан намусы өчен» исемле фронт газетасы редакциясендә эшләп кайткач, партиянең Татарстан өлкә комитеты мине «Совет әдәбияты» журналына редактор итеп билгеләргә булды. Башта, нишләргә белми, аптырабрак калдым: риза булыргамы, юкмы? Шундый зур һәм җаваплы эшне башкара алырмынмы?.. Дөрес, бу эш миңа шактый таныш танышын. Төрле газета редакцияләрендә, шулай ук радиода эшләгәнем бар. Аннары 1929—30 елларда «Безнең юл» журналы редакциясендә дә эшләп алган идем. Тик секретарь булып кына һәм анда да әле Гомәр Гали кебек зур белемле, тәҗрибәле редактор кул астында. Ә хәзер менә үземә җаваплы редакторлык вазифасын йөклиләр. Булдыра алырмынмы?.. Шик-шөбһәләремне өлкә комитетында эшләүче иптәшләргә дә сөйләдем. Алар, булышырбыз, диделәр. Шулай кирәк, диделәр. Күндерделәр.

## I

Мин редактор булып эшли башлагенда, сугыш инде Германия җирендә, Берлинга якынлашып бара иде. Безнең гаскәрләр меңнәрчә километрларга сузылган фронт буйлап гел алга ыргыла, немец фашистларын, аларның үз ояларында тукмап, тез чүктерер көннәр якынлашып килә иде.

Әмма сугыш тудырган кыенлыклар әле һәркайда нык сизелә иде. Һәм безнең журнал эшендә дә.

Редакциянең портфеле утә ярлы. Кая инде ул, бүгенге кебек, роман һәм поэмаларның, хикәя һәм очеркларның айлар-еллар буе чират көтеп ятулары... Журналның һәр санын туплау үзе бер зур проблема иде ул елларда. Язучыларның күбесе фронтта, алардан сирәк-мирәк кенә шигырьләр, кыска очерклар килгәли. Тылда калган язучылар бик тырышып эшлиләр, югыйсә, ләкин алар бик аз, бармак белән генә санарлык. Ә ай саен чыгып килә торган калын журнал материалны кочагы-кочагы белән йотып кына тора. Редакция аппаратында без нибары өч кеше: Фатих Хөсни, Әнас Камал һәм мин. Шундый шартларда журналның чираттагы санын хәзерләргә керештек.

Миңа редакторлык хезмәтемне бәхетле саннан, журналның бөек җиңүгә багышланган саныннан башлап җибәрергә туры килде. Минем кулда «Совет әдәбияты»ның моннан 27 ел элек чыккан шул бишенче саны. Эчке бер дулкынлану белән аның саргаеп беткән битләрен актарам. Менә беренче битләр. Анда Верховный Башкомандующийның 1 Май приказы: «Быел Ватаныбыз халыклары Беренче май көнен Ватан сугы-

шының җиңү белән тәгалләнүе шартларында каршылыйлар... Кызыл Армия, немец империализмының оясы Көнчыгыш Пруссияне, Померанияне, Бранденбургның күп өлешен һәм Германиянең башкаласы Берлинның төп районнарын алып, Берлин өстенә Җиңү байрагы кадады»...

Шунда ук 9 Майга — бөек җиңү көненә багышланган тарихи документлар: СССР Халык Комиссарлары Советы Председателенең халыкка мөрәҗәгате (анда безнең какшамас тимер көчләребез удары астында фашистик Германиянең тез чүгүе, тәмам җиңелгәнлеген рәсми тануы һәм берсүзсез капитуляция игълан итүе турында сөйләнә), аның Кызыл Армия гаскәрләренә һәм Хәрби-диңгез флоты сугышчыларына тәбрик приказы һәм Кремльдә Кызыл Армия гаскәрләре командующийлары хөрмәтенә 24 майда үткәрелгән мәҗлестә ясаган чыгышы. Болары — журналның беренче битләрен бизәп торган рәсми материаллар. Шуларга татар язучыларының бөек җиңүгә багышланган ялкынлы җырлары һәм шигырьләре, публицистик мәкаләләре ялганып китә: «Җиңү җыры», «Онытылмас көннәр», «Сукты безнең изге сәгать», «Тоткач Мәскәүләр якаң» (Г. Тукайга ияреп), «Фронт юлында», «Җиңү бәйрәме»... Фатих Хөснинең «Апрель» һәм Гази Кашшафның «Ашыгыч нәтиҗә» исемле кечерәк күләмле хикәяләре. Һәр икесе сугыш темасына багышланган, һәр икесендә совет кешеләренең уй-тойгылары, шатлык һәм хәсрәт хисләре чагыла. Фронтовик язучы Гамир Насрыйның «Гыймади абзый Берлинда» дигән очеркы, исеменнән үк күренгәнчә, шул чорның иң актуаль мәсьәләләрен кузгата. Редакциянең башкорт шагыйре Хәниф Кәрим белән дә элемтәсе бар икән. Аның «Кое янында» исемле новелласында сугышчыларыбызның онытылмас батырлыклары да, дошманның йөрәкләрне тетрәткеч ерткычлыгы да оста каләм белән тасвирланган. Билгеле, хәзер мин санаган материаллар белән генә журнал чыгарып булмый. Алар бик аз. Җитәрлек әйбер туплаганчы, безгә әле тагын күп борчылырга, тырышып эзләнергә туры килде.

...Алда бер тапкыр телгә алып узган идем: журнал редакторы итеп билгеләнгәнче мин партия өлкә комитеты командировкасы белән берничә ай фронт газетасында эшләп алдым. Шул чагында, фронт газеталарында басылган иң яхшы әсәрләрне сайлап, «Җиңү юлы» исемле бер җыентык төзегән идек. Р. Ишморатның әлеге китапка кергән «Мирза Билаловның разведкага баруы» исемле очеркын журналда да урнаштырырга булдык. (Җыентыкта ул «Висла буенда» дигән исем белән басылган.) Шул көннәрдә генә рус язучысы Лев Никулинның «Бер уч туфрак» исемле хикәясен укыган идем. Интернациональ дуслык темасына багышланган бу әсәр уңай тәэсир калдырган иде. Редакция портфелендә бүтән әйбер булмаганлыктан, аны тиз генә татарчага тәрҗемә итәргә керештем. «Правда» газетасының хәбәрчеләре Б. Горбатов һәм М. Мержанов җиңелгән Германия вәкилләренең капитуляция актына кул куюларын үз күзләре белән күреп торганнар. Аларның «Капитуляция» исемле тарихи репортажларын да журналның шушы чираттагы саны өчен тәрҗемә иттем.

Дәрҗия Аппакова өч хикәя тәкъдим итте. Ул — танылган балалар язучысы. Хикәяләре дә балалар турында, балалар өчен. Ләкин ул чагында махсус балалар журналы юк. «Пионер каләме»н сугыш мәльгун туктатты. Бер аны гына да түгел. Хәтта үзәктә чыга торган күп кенә журналлар да вакытлыча туктап торды. Безнең «Совет әдәбияты» исә республикабызда сугыш елларында да туктаусыз чыгып килгән бердәнбер журнал иде. Редколлегия членнары белән киңәштек тә, әйдә, балаларыбызны да бер куандырыйк дип, ул хикәяләрне журналның чираттагы санына урнаштырдык. Алга сикереп булса да әйтеп үтим: Дәрҗия Аппакованың кулы-аягы җиңел булды. Шуннан соң безгә балалар өчен язылган әсәрләр күбрәк килә башлады. «Балалар әдәбияты» дигән яңа бүлек ачып җибәрдек һәм аңа һәр санда даими урын биреп бардык. Журнал саннарын актарып, санап чыктым: ике ел эчендә генә дә бу бүлек буенча 29 авторның балалар өчен язылган 59 әсәре урнаштырылган икән. Ләкин әйбер һаман җитми. Редакция папкаларын тагын бер тапкыр бергәләп актарып чыктык. Нәкый ага Исәнбәтнең «Тукайның соңгы басмасы турында» дигән зур гына тәнкыйть мәкаләсе табылды. Кат-кат укып чыктык. Бик кыю һәм үткен язылган. Кимчелекләрне бик дөрес һәм урынлы тәнкыйть иткән. Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның иҗади мирасына тирән ихтирам һәм тулы җаваплылык белән карарга өнди торган кыйммәтле, файдалы мәкалә. Аны да журналыбызның шушы бишенче санына урнаштырырга кирәк дигән фикергә килдек. Шулар янына тагын Р. Раимовның «Татар телендә беренче социал-

демократик газета» исемле публицистик мәкаләсен, Әнәс Камалның атаклы композиторыбыз Салих Сәйдәшев турындагы, Ә. Еникинең шул араларда вафат булган зур артистыбыз Шакир Шамильский турындагы мәкаләләрен һәм Гафинең (Ф. Хөснинең әдәби псевдонимы — Г. И.) Абдулла Алиш әкиятләре турындагы рецензиясен дә өстәгәч, журналның бу тарихи май санына материал туплау эше, ниһаять, тәгәлләнде. Шул эчтәлек белән без аны укучыларыбыз хөкеменә тапшырырга булдык.

Урамда яз. Урамда май. Урамда бәйрәм. Бөек җиңү бәйрәме!

Сукты безнең изге сәгать,
Килде якты көн бүген;
Безнең бөек җиңү даны
Нурландырды ил күген,—

дип җырлый шагыйрьләр.

## II

Шуннан соңгы көннәр, элеккеләренә охшамаган, тыныч көннәр булып, шатлыклы елмаюлы, көләч көннәр булып, сугыш яраларын төзәтү көннәре булып килә-китә тордылар. Сугышчылар да әкренләп тыныч тормышка, төзелеш фронтына кайта башлады. Әле шинелен дә салып өлгермәгән сугышчан дуслар, каләмдәшләр белән күрешү-үбешү ешайды.

Фронттан Әхмәт Фәйзи кайтып төште. Элеккечә үк көр күңелле, җор телле, тик бераз уйчанрак бугай. Яңа иҗат планнары белән рухланып йөри. Болай ул Мәскәүдә яши иде. Хәзер бераз Казанда торырга чамасы бар. Сугыш вакытында гаиләсе дә монда күченеп килгән иде. Күп вакытын Матбугат йортында үткәрә. Безнең редакциягә кереп утыра. Эшебез, хәлләребез белән кызыксына. Шунда ук, буш урын булса, утырып эшли дә: яза, сыза, төзәтә. Татиздатта аның «Дулкыннар ни сөйлиләр» исемле шигырьләр җыентыгы басылырга хәзерләнә, ул хәзер күбрәк шул мәшәкать белән йөри, шуның белән мәшгуль. Безгә дә булыша. Теге яки бу кульъязманы, бигрәк тә шигырьләрне укып, үзенең фикерен әйтә.

Казан урамнары буйлап, күкрәгендәге орден-медальләрен чыңлатып, сугыштан авыр яралар алып кайткан Әсгать Айдар йөри. Редакциядә еш була. Аның «Солдат моңы» исемле повестен редакцияләүне нәшрият миңа тапшырган иде. Журнал өчен шул әсәрдән зур гына бер өзек сайлап алдым, аны да әлеге 5 санга ук кертеп җибәрдек.

Очерклары, кыска хикәяләре белән сугышка кадәр үк танылып өлгергән Гариф Галиев кайтты һәм журналның актив авторларыннан берсе булып китте.

Хәбәрсез югалганнар исемлегендә йөргән шагыйрь Нәби Дәүли кайтты. Әсирлектә күп җәфа чиккән икән. Баштарак бераз читкә тибәрелеп йөртелсә дә, элеккечә нык ихтыярлы булып, үзенең намусы сафлыгына ышанган хәлдә, әдәбиятта урынын-исемен саклап кала алды. Журналның 1947 елгы 2 нче санында аның «Ана», «Солдат фронттан кайтты» исемле шигырьләре басылды. Соңыннан үзенең «Яшәү белән үлем арасында» исемле повесте белән ул тагын ялтырап-үсеп, күренекле әдипләребез сафына килеп басты.

Кайту!.. Инде еш ишетелә һәм күңелләргә бик хуш килә торган бу сүз әдәбиятта да чагыла башлады.

«Бер катлы кечкенә ак пароход үзенең очлы борыны белән Агыйделне урталай ярып бара. Ул... юан морҗасыннан бер туктаусыз ап-ак төтен йомгаклары бөрки-бөрки, Әҗәкүл пристанена якынлашып килә иде... Дошман явыннан Мәскәүне саклаган, Берлинны алу сугышында үлмәс дан казанган атаклы укчы полкның автоматчысы рядовой Хәснетдин Кадыйров, пароход койрыгына чыгып, Агыйдел буйлары өчен генә хас булган тип-тигез киң болыннарга, болын өстен бизәп көзгедәй ялтырып яткан вак-вак күлләргә, күл читләренә үрелеп-үрелеп үскән бөрлегән, карлыган һәм шомырт агачларына, ара-тирә күзгә чагылган көмеш яфраклы ялгыз усакларга» сокланып карап фронттан өенә кайтып бара. Бу юллар Гамир Насрыйның, үзе кайтып өлгерер-өлгермәс дигәндәй, безгә язып биргән «Кайту» исемле кыска хикәясеннән алынды (8 сан.

1945 ел). Алга таба бу тема башка күп кенә фронтовик язучыларыбызның иҗатында киң урын алыр. Риза Ишморатның «Кайту» исемле пьесасы бер Татарстанда гына түгел, аннан читтә дә озак еллар шаулап барыр... Ә әлегә алар яңа кайта гына башладылар, әкренләп, аз-азлап...



Сугыштан соңгы еллар тарихка илебез, халкыбыз тормышында яңадан-яңа уңышлар җулап алу еллары булып кереп калдылар. Явыз гитлерчылар җимергән, талаган, яндырган, бөлгенлеккә төшергән өлкәләр һәм республикалар, шәһәрләр һәм авыллар, завод-фабрикалар, колхоз-совхозлар яңадан торгызылды, экономикабыз, культурабыз, тормыш-көнкүреш шартларыбыз күзгә күренеп яхшыра, күтәрелә, ныгый барды. Тарихта тиңдәше булмаган авыр сугышта дошманны тар-мар итеп, җиңеп кайткан кыю солдатларыбыз тыныч төзелеш фронтында да үзләренең батырлыкларын бик ачык күрсәттеләр. Автоматларын яңадан каләмгә алмаштырган әдипләребез дә шул батырлар сафында булды.

Әмма сугыш китергән бәла-казалар, югалтулар онытылмады һәм онытылмас та. Күп корбаннар алып китте ул. Миллионнарча кешеләребез Ватанны азат итү өчен алып барылган изге көрәштә башларын салдылар. Күп кенә әдипләребез дә. Муса Җәлилебез хәбәрсез югалды (ул елларда безгә шуннан артыгы билгеле түгел иде). Фатих Кәримебез сугыш бетәр алдыннан гына, Кенигсбергны штурмлаганда батырларча һәлак булды. Нур Баян да сугыш кырыннан кайтмады — Ватан өчен көрәштә корбан булды. Гадел Кутуй... Инде сугыш та беткән иде. Сугыш кырында фашист дошманны җиңдө, әмма каты авыру аның күзләрен мәңгегә йомдырды. Кутуйның кабере еракта, Польша җирендә... Тагын ничаклы яшь талантлар! Аларның үлмәс исемнәре — Тукай клубы янындагы мәрмәр тактада һәм меңнәрчә укучылар йөрәгендә.

Казандагы зиратларның берсендә, гади генә кабер ташында шундый сүзләр укыганым хәтеремдә: «Кеше үлә, диләр, дөрес түгел, ул тик инде безнең янәшәдә генә булмый». Югалту кайгысын басу теләге белән әйтелгән бу сүзләр олы шәхесләргә, әдәбият-сәнгать әһелләренә карата бигрәк тә туры килә. Сөекле Мусабыз үлмәс җыр булып яңадан терелеп кайтты. Изге сугышта батырларча һәлак булган барлык өлкән һәм яшь әдипләребез халкыбыз йөрәгендә, үлмәс исем булып, мәңге саклаңыр...

Кабат журнал саннарын актара башлыйм.

**Текә таулар, киң елгалар аша**
**Мин көрәшче булып атладым,**
**Россиям!**
**Ләкин йөрәгемә**
**Башка якын иләр тапмадым.**

Бу — Нур Баянның «Илем, сиңа!» исемле шигыре. Әле үзе исән чакта, Венгриядән язган һәм журналның 1945 елгы санында басылган. Сугышның беренче көненнән үк шинель киеп, Ватаныбызны дошманнардан сакларга киткән бу шат күңелле лирик шагыйрь солдат булып та, политработник булып та, хәрби газета редакторы булып та озын юл үтте. Якын дусты Гази Кашшаф белән гел хат алышып тора иде ул. Фронт шартларында язган шигырьләр дәфтәрен дә, саклап тоту өчен, аңа җибәргән (басар өчен түгел, чөнки аларны әле ул камилләштерәсе булган). Менә Г. Кашшафның зур мәкаләсе һәм шул дәфтәрдән берничә шигырь:

**Борчылмагыз, мине белгән дуслар,**
**Шат җырчыгыз сезне онытмас.**
**Бер кайтыр ул, якты кояш сыман,**
**Дошманнарны җирдән корыткач.**

*(4 сан, 1947 ел)*

Әйе, борчылып көттек без аларны. Әйе, ул да кайтты. Кояш сыман якты шигырь булып. Туган авылына да кайтты — шул колхозның исеме булып...

1945 ел, 7 сан. Гадел Кутуй исеме кара рам эчендә алынган. Республикабызның партия-совет оешмалары җитәкчеләреннән, әдәбият-сәнгать эшлекләреннән 49 кеше кул куйган некролог... Художник эшләгән рәсеме... Кыю, батыр караш, үткен күзләр... Шундый ир-егетебезнең үлгенә ышанасы да килми һәм ышанмыйбыз да! Барыбыз бертавыштан: «...Ул үзенең иҗаты белән, санап бетергесез гүзәл эшләре белән безнең арада яши, безнең белән бергә социалистик Ватаныбызны ныгыту, көчәйтү, үстерү эшендә катнашып бара», дибез. Шул санда ук Гази Кашшафның «Гадел Кутуй» дигән мәкаләсен һәм Кутуйның сугыш кырында язган, матбугатта беренче тапкыр игълан ителә торган «Ханҗәр» исемле хикәясен укыйбыз.

Күңел тагын үткәннәргә әйләнеп кайта.

1946 ел, 6 сан. Гадел Кутуй. «Сагыну»... Бу нәсер үз вакытында радио аша тапшырылган иде. Хәзер генә матбугатта игълан ителә. Шунда ук «Туган ил» исемле шигыре. Бер генә ел элек «Кызыл Армия» исемле фронт газетасында басылган булган. Һәр икесендә туган илгә мәдхия җырлау, аны сагыну, аның иминлеге өчен көрәшкә омтылу хисләре.

**И туган ил, и матур ил,**
**Калдың бездән еракта,**
**Калсаң да бездән еракта,**
**Күңелдә син һәрчакта,—**

ди шигырендә. «Сагындым, бик сагындым сине, туган ил! — ди нәсерендә.— Мин горур атлыйм. Чөнки мин чит илдә әсир булып түгел, җиңүче булып йөрим. Миңа һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык. Ләкин берсенә дә керәсем килми минем. Мин ата-бабам нигез корган илемдәге изге йорт турында уйлыйм һәм шунда тизрәк кайтып керер өчен Берлинга ашыгам». Әйе, ул шулай гел безнең белән бергә яши, ашыгып-атлап гел алга бара, үзенең онытылмас хикәяләре, шигырьләре, дан казанган «Тапшырылмаган хатлар»ы белән яңа җәмгыять төзүдә, яңа кеше тәрбияләүдә катнаша...

* * *

**Үлем турында уйлама,**
**Илең турында уйла.**
**Илең турында уйласаң,**
**Гомерең озын була.**

Гел кабатлана торган, күптән күңелләргә, йөрәкләргә кереп урнашкан гаҗәеп көчле һәм тирән мәгънәле шигъри юллар. Фатих Кәрим юллары, аның үзен дә озын гомерле иткән, үлемсез шагыйрь иткән юллар!

1945 ел, 7 сан. Фатих Кәрим истәлегенә багышланган сәхифәләр. Мирсәй Әмирнең «Шиңмәс гөл» исемле мәкаләсе, Гали Хуҗиның «Синең гомерең — илең өчен яну», Сәлих Баттталның «Син кем идең?» исемле шигырьләре...

Фатих Кәрим сугышка кадәр үк киң танылган, күренекле шагыйрьләребездән берсе, унга якын китап авторы. Бик күп ялкынлы шигырьләренә өстәп, «Җиденче мич», «Тавышлы таң», «Аникин» кебек поэмалар иҗат итеп өлгергән иде. Сугыш кырында исә аның таланты яңадан үсеп, киңәеп, тирәнәеп китте. Искиткеч авыр шартларда чын сәнгать әсәрләре тудырды. «Идел егете», «Гөлсем», «Партизан хатыны» «Үлем уены» исемле поэмалар, «Язгы төн», «Разведчик язмалары» кебек повестьлар бирде. Болар бит төннәрен, ял вакытында, кәгазьне прикладка куеп, шәм яктысында яки ай яктысында язылган иҗат җәүһәрләре!

**Сине, Фатих, җую кайгыбыздан**
**Мин атнага еллык картайдым.**
**Ничәнче төн менә йокысыз мин,**
**Алып киттең бөтен тынгымны:**
**Бер колдыз ким хәзер минем өчен,**
**Ут камаган уем-тойгымны...**

Бу юллар Гали Хуҗиның «Синең гомерең — илең өчен яну» дигән 16 гына юллык шигыреннән алынды. Шигырьне укыйсың да, шул кадәр дулкынланган-тетрәнгән шагыйрь моның белән генә калмас, дип уйлыйсың. Шулай булып чыга да. Шулай бер вакыт фронт газетасында Гали Хуҗи белән бергә эшләгән драматург Ш. Зәйни безгә хат җибәрә: «Г. Хуҗи Ф. Кәрим турында зур поэма язарга кереште,— дигән.— Билгеле, Гали сезгә ул турыда язмый да торгандыр, ул аны сер итеп тотарга тырыша. Аңа хат язганда, «бик ышанычлы чыганакларга таянып» дип, бу турыда әйтсәгез бик шәп булыр иде!..» Чыганак, чыннан да, бик ышанычлы булды. Күп тә узмый, редакциягә Гали Хуҗидан «Гражданин, солдат, шагыйрь» исемле зур поэма килеп төште. Зарыгып көтелгән әсәр. 8 бүлектән торган зур күләмле, йөрәк ялкыны белән язылган поэма. Редакциядә аны һәммәбез дә бик дулкынланып укыдык. Фатих Кәрим образына лаеклы иҗат җимеше иде ул. Һәм аны журналның чираттагы санына (2 сан, 1946 ел) урнаштырдык. Шунда ук Фатих Кәримнең «Шакир Шигаев» исемле пьесасы. Фатих Кәримнең соңгы әсәрләреннән берсе. Анысын шагыйрьнең тормыш иптәше Кадрия Ишукова китерде. Бик тиз укып чыктым. Камил эшләнгән әсәр дип булмаса да, Ватан сугышын, аның батыр кешеләрен, аларның омтылышларын һәм төрле язмышларын, канлы көрәшнең кырыслыгын, дошманның єрткыч йөзен чагылдыру ягыннан мәгълүм кыйммәте шиксез. Автор аны тагын камилләштерә башлаган, ләкин төгәлли алмаган. Бу турыда без Кадрия ханым белән киңәшләштек. Пьесаны журналда бастырып чыгару өчен редакцияләүне ул миңа ышанып тапшырды.

Гази Кашшафның «Ул көрәш моңнарын җырлады» исемле мәкаләсе дә бик дулкынланып язылган һәм ул шагыйрьнең портретын тулыландырып тора.

Шулай итеп журналның бу санында Фатих Кәримгә багышланган материалларга шактый зур урын бирелде.

> **...Син үлмәдең, шагыйрь, яшисең,**
> **Синең гомерең — илең өчен яну,**
> **Ә җырларың — гомер чәчәгең;**
> **Безнең йөрәктәге ялкынлану —**
> **Бу синең дә җирдә яшәвең,—**

дип тәмамлана Гали Хуҗи поэмасы һәм ул шагыйрьнең үлмәс исемен тагын да югарырак күтәрә.

## III

Габдрахман Әпсәләмов, Афзал Шамов, Әдип Маликов, Абдулла Әхмәтләрдән хатхәбәрләр һәм әдәби материаллар хәзер Көнбатыштан түгел, ә Ерак Көнчыгыштан (Маньчжуриядән, Кореядән, Сахалиннан) килә башлады. Көнбатышта тар-мар ителгән фашистик Германиянең Көнчыгыштагы хәрби союзнигы — Япон самурайлары бар иде бит әле. Ниһаять, аларга да чират җитте.

Көнбатышта сугыш тәмамланып дүрт ай вакыт узганнан соң, безнең батыр гаскәрләребез Ерак Көнчыгышта да тынычлык урнаштырдылар. Авыр һәм каты сугышлардан соң, Япониянең каршы торуы сындырылды, ул басып алган җирләребездән кире алып ташланды, һәрьяктан чолганып алынган Япония үзен җиңелгән дип таныды, коралын ташлады һәм капитуляция актына кул куярга мәҗбүр булды. Без язучыларыбызның бу фронтларда катнашулары белән дә хаклы рәвештә горурлана алабыз.

Журналның август саны өчен материалларны туплап бетергән идек инде. Шул чак японнарны җиңүгә бәйле тарихи документлар килеп төште: Верховный Башкомандующийның Ерак Көнчыгыштагы җиңүләребезгә багышланган приказлары һәм халыкка мөрәҗәгате. Аларның урыны — журналның беренче битләрендә. Ләкин бу зур җиңүгә карата әдәби материал да кирәк бит! Ансыз ничек инде журналны чыгарырга кирәк?!. Бу мәсьәләдә, коткарса, Әхмәт Фәйзи генә коткара инде, дигән карарга килдек.

Шундый бик ашыгыч шигырь сорап мөрәҗәгать иткәч, ул башта каушабрак та калды бугай. Гадәттәнчә, ыһым-ыһым дигән булды, сүз дә бирмәде, бөтенләй баш та тартмады. Курам — уйлана бу. Ярый. Икенче көнне тагын сорыйм. Юк. Җилкәләрен җыера, барып чыкмый әле, янәсе, теманы тотып алып булмый... Үзара фикер алыша-

быз, темага төрле яктан килеп карыйбыз. Көнчыгышта яңа җиңү бит. Безнең Ерак Көнчыгышыбыз күгендә кояш тагын иртәрәк калкып күтәрелә башлады диган суз. Шул үзе генә дә менә дигән матур образ була ала ич. Ә ул һаман, ашыктыруга да карамастан, булмый бит, булмый әле, дип йөри. Тагын берничә көн үтте. һәм «булмый, булмый» дип йөргән Әхмәтебез, бактың исә, беренче көннән үк яза башлаган икән. һәм менә безнең алда әзер шигырь! Шигырь генәме әле, 208 юллык бөтен бер поэма!

| | |
|---|---|
| **Күтәрелә кояш,** | **Кешенең мең еллык** |
| **Күтәрелә кояш,** | **Тантанасын котлап** |
| **Күтәрелә кояш,** | **Күтәрелгән иң-иң** |
| **Бөек. Җылы. Көчле.** | **Якты салют төсле,—** |

дип башлана ул поэма һәм тарихи вакыйгалар Фәйзичә лирик та, кырыс та алымнар белән тасвир ителеп, түбәндәге юллар белән тәгәлләнә:

| | |
|---|---|
| **Безгә дуслык төеп,** | **Җиңү байрагыдай** |
| **Юмарт нурын коеп,** | **Кояш күтәрелә,** |
| **Безнең өскә, илнең** | **Кояш күтәрелә,** |
| **Бөек түтәленә,** | **Кояш күтәрелә.** |

*(Август. 1945. Казан)*

Минем шәхси китапханәмдә Әхмәт Фәйзинең бер китабы бар. Үзе исән чакта, 1954 елда басылып чыккан иң тулы җыентыгы. Анда шагыйрьнең барлык шигырьләре, поэмалары, пьесалары, юмористик шигырьләре һәм балалар өчен язган әсәрләре урнаштырылган диярлек. Бик матур, зур фоторәсеме дә бирелгән. Җыентыкның исеме дә «Күтәрелә кояш». Аны миңа үзенең автографы белән бүләк итеп бирде:

*«Газиз,*
*Бу җыентыкның исеме синең заказ белән язылган шигырьнең исеменнән алынган. Бергә эшләгән чакларның истәлеге итеп, сиңа тәкъдим итәм.*
*1. III. 55. Автор».*

Бу — минем еш кулга ала торган иң кыйммәтле, истәлекле китапларымның берсе.

## IV

8 нче санны шулай типографиягә төшереп җибәрдек. Әмма аның артыннан барасы 9 сан белән нишләргә инде?.. Шигырьләр, мәкаләләр булыр да, алары бар да. Ләкин алар, бердән, күләм ягыннан күп урын сорамыйлар. Икенчедән, төп материал, гомуми кагыйдә буларак, проза әсәрләре булырга тиеш бит: хикәяләр, повестьлар, романнар! Ә алар юк һәм якын араларда булу ихтималы да күренми. Язучы иптәшләр, дуслар белән очрашу-сөйләшүләрдән бу безгә бик ачык билгеле. Язалар, әлбәттә, кайчандыр булыр алар. Ә хәзергә — теләсәң нишлә, юк! Шундый вакытта үзеңне, ничектер, трибунага чыгып та, әйтер сүзең булмаганнан, халык алдында аптырап тик басып торучы кеше хәлендә калган кебек хис итәсең.

Шул араларда гына республикабызда пьесалар өчен уткәрелгән конкурс йомгаклары игълан ителгән иде. Өлкән драматургыбыз Нәкый ага Исәнбәтнең «Сәхибҗамал Волжская» исемле драмасы икенче дәрәҗә премия белән бүләкләнде (ялгышмасам, беренче премияне алучы булмады бугай). Ул аны Сәхибҗамал ханым Гыйззәтуллина-Волжская шәрәфенә һәм татар театрының кырык еллыгына багышлап язган. Әсәр белән тиз генә таныштык. Ошады.

Төп образ үзенең бөтен тулылыгы, зур мәртәбәле таланты, сокланырлык гүзәллеге, ул чорга хас булганча, башыннан кичергән бөтен авырлыклары һәм аларны кыю җиңүчән горур табигате, кыскасы, бөтен тормышын театрга, сәхнәгә багышлаган фидакарьлеге белән гәүдәләндерелгән. Әсәрдә, әлбәттә, шул чор, шул даирә кешеләре дә җитәрлек күрсәтелгән. Драма 5 пәрдәлек, бик озын итеп язылган. Күләме ягыннан тулы ике пьесалык. Әле артык та булмаса. Сәхнәгә куйганда ул, әлбәттә, кыскарыр, артык урыннары төшереп калдырылыр. Нәкый аганың башта шулай бик озын

итеп яза торган гадәте бар иде аның. Шуңа күрәдер, ахры, бу драма текстын ул «Әдәби вариант» дип тә атаган. Бәс, шулай да булгач, ул үзеннән-үзе безнең әдәби журналга керәм, дип сорап тора ич. Һәм ул журналыбызның үзәк урынын алып та куйды. Драмага эпиграф итеп Тукайның күренекле артисткага багышланган мәгълүм шигыре алынган:

**Күр, ничек иртә кояш чыкса, җиһанга нур тула,**
**Һәр күңелләр нурланадыр, чыкса Гыйззатуллина.**
**Бу икәүгә тәңре биргән бертигез зур мәртәбә:**
**Берсе үйның күк йөзендә, берсе үйның сәхнәдә.**

Эпиграф белән янәшә Сәхибҗамал Гыйззатуллинаның 1911 елда төшкән бик матур рәсемен дә урнаштырдык. Журналның һәрбер санында диярлек юмор бүлегендә катнашып килүче өлгер «Гафи»ебезнең (Ф. Хөснинең) мактау каләменнән дә читтә кала алмады «Сәхибҗамал»:

**Пәрдә ачтык.**
**Чыкты килеп «Миңлекамал»,**
**Җеннекамал, Җимлекамал, Җиллекамал,**
**Мин дә менә кабат кайттым сезгә, диеп**
**Килә атлап сәхнә кызы «Сәхибҗамал».**

Кыскасы, безнең өчен зур байлык булды бу «Сәхибҗамал». Лакин...журналның матур әдәбият бүлеге өчен бердәнбер байлык диярлек. Тагын проза әсәрләре кирәк. Ә алар юк. Нишләргә? Вакыт көтми бит. Әнәстән сорыйм, кая, редакциягә килеп тә басылмыйча калган материалларыңны актарып карыйк әле, шулар арасыннан эшкәртеп булса да файдаланырлык берәр хикәя килеп чыкмасмы, дим. Берәмтекләп, җентекләп карап чыгабыз, укыйбыз... Юк, монда да юанырлык әллә ни күренми. Тагын, тагын актарабыз. Шунда Г. Әпсәләмовның «Егетнең егете» исемле хикәясенең кульязмасы килеп чыкмасынмы. Бу яшь фронтовик язучы белән мин беркадәр таныш иде. Аның «Төньяк балкышы» исемле хикәяләр җыентыгын кызыксынып, яратып укыган һәм аңа язган рецензиям моннан элегрәк журналда басылып та чыккан иде. Алып, бик җентекләп укып чыктым. Хикәя асылда батыр ефрейтор Әсрар Хәмидуллин — берниндиКыенлыклар-куркынычлар алдында да каушап калмыйча, сугышчан бурычны җиренә җиткереп үти торган кыю егет турында. Әсәрдә сугыш эпизодлары да, Хәмидуллинның батырлыгы да укучыны җәлеп итәрлек, тетрәтерлек дәрәҗәдә тасвирланган. Гәрчә үзенең стиль алымнары белән Әпсәләмовның моңа чаклы чыккан әсәрләреннән беркадәр аерылып торса да, һич яраксызга чыгарырлык хикәя дип тапмадым мин аны. Бигрәк тә безнең хәзерге кытлык хәлебездә. Җыелышып тагын бер тапкыр укып чыктык. Ярый, барә бу, дигән карарга килдек. Бер пьеса һәм шушы кечкенә хикәя янына тагын проза әсәрләре кирәк бит әле. Мәскәүдә күптән түгел генә А. Степановның «Порт-Артур» исемле тарихи романы басылып чыккан иде. (Укучылар һәм киң җәмәгатьчелек аны хуплап каршы алды, соңыннан ул Дәүләт премиясенә дә лаеклы булды.) Исеменнән үк күренгәнчә, ул көннәрдә роман бик актуаль яңгырый иде. Укучыларыбызны, әлбәттә, аның белән дә таныштырырга кирәк. Романнан зур бер кисәкне сайлап алдык. Әнәс Камал аны бик тиз тәрҗемә итеп китерде. (Бер уңайдан әйтеп үтик инде: ул елларда, гомумән, рус совет әдәбияты үрнәкләре белән укучыларыбызны таныштыру тәҗрибәсе даими төстә алып барыла иде. Журнал битләрендә М. Горький, М. Лермонтов, А. Чехов, К. Симонов, А. Фадеев, Н. Погодин, И. Франко, А. Твардовский, А. Сурков, В. Маяковский, С. Михалков, Н. Некрасов, Л. Никулин, М. Исаковский, С. Борзенко, С. Маршак, В. Величко, В. Катаев, М. Пришвин һәм башка язучыларның әсәрләре басылган.)

Журналның фәнни өлешен эшләргә ярдәм итүчеләр дә табылды. Бу очракта хөрмәтле Мөхәммәт ага Гайнуллин белән Латыйф ага Җәләйне күз алдында тотып әйтүем. Аларның һәр икесе журналыбызның публицистика һәм тәнкыйть-библиография бүлегендә күркәм урын алдылар. Бай әдәбият тарихыбыз белән бөтен нечкәлекләренә кадәр тирәнтен таныш булган һәм аны туктаусыз өйрәнүеч дәвам иттереп килгән Мөхәммәт ага күренекле классикларыбыздан Заһир Бигиевнең тууына 75 ел тулуга карата язылган зур мәкаләсе белән катнашты.

Карт галим, тел белгече Латыйф Җәләй яңа яза башлаган иптәшләрнең шигырьләрен тикшереп, мәкалә язды. Андый шигырьләр ул елларда Татиздат каршында оештырылган консультация бюросына килә иде. Л. Җәләй ага аларны шуннан алып, бик җентекләп тикшергән. Журналда бик файдалы, төпле, конкрет мисалларга бай күзәтү белән чыкты.

Тарихи датага багышланган тагы бер мәкалә бар икән: аны полководец М. И. Кутузовның тууына 200 ел тулуга карата профессор Н. Коробков язган. Элек-электән әдәбиятыбызның төрле жанрларында актив эшләп килүче Фатих Хөсни бик тиз генә бер рецензияне язып өлгертте: Әхмәт Фәйзинең яңа гына басылып чыккан «Дулкыннар ни сөйлиләр» исемле шигырьләр җыентыгы турында. Уңышларына да югары бәя биргән, кимчелекләрен дә читләтеп үтмәгән. Ә. Фәйзи үзе дә канәгать булып калды шикелле. Һәм, ниһаять, бәхет тагын елмайды — фронтовикларыбыздан ике хат килеп төште. Менә ике зур сугышта катнашкан карт солдат, минометчик Госман Бакиров. Аның белән без айлар буе Беренче Украина фронты газетасы редакциясендә бергә булган идек. Үзе бик тыныч, игелекле профессия кешесе ул — укытучы! Мөләем, югары культуралы, тыйнак өлкән агабыз. Ул әле һаман солдат шинелен салмаган, җиңүче — азат итүче батыр булып, Европа илләрендә йөри. Безгә ул Австриядән кыска гына очерк-репортажын җибәргән. Ахырына «Вена. Август. 1946» дип куйган. Исеме дә «Венада һәйкәл». Шәһәргә штурм ясаганда батырларча һәлак булган совет сугышчылары һәм офицерлары хөрмәтенә мәһабәт һәйкәлне ачу тантанасы тасвир ителгән.

Ә яшь шагыйрь һәм солдат Гыйлемдар Рамазанов Германиядән «Галя» исемле бер шигырь җибәргән. (Хәзер ул — Башкортстанның күренекле шагыйрьләреннән берсе, атаклы әдәбият галиме, зур җәмәгать эшлеклесе.) Ул елларда Гыйлемдар Беренче Украина фронты частьларының берсендә хезмәт итүче сугышчы иде. Беренче тапкыр без аның белән Польшада очрашкан идек. Ул — редакторыбыз Риза Ишморатның электән танышы — газета редакциясенә килеп чыккан, хәбәрләр, шигырьләр китергән иде. Бер төн кунып та китте. Төрле темага әңгәмә күп булды, һәркайсыбызга кызыклы эпиграммалар язып калдырды. Ул чакта ук шагыйрь иде, бөтен торышы-йөреше белән шагыйрь иде. Ничектер сабыр холыклы да, азрак оялчан да кебек, япь-яшь егет булып хәтердә калган... «Галя» исемле шигырен яратып укыдык. 36 юллык шигырьдә, немец шәһәре Нойштадтка барып кергәч та, Галя исемле украин кызын азат итүен сугыш ялкыны белән өртелгән лирик тонда, бик җылы-реаль итеп җырлаган Гыйлемдар:

**Хуҗа качкан, хәзерләгән ашын,**
**Талап җыйган малын калдырып.**
**Бер кыз чыкты миңа каршы,**
**Йөгерә-йөгерә җитез талпынып.**

**Шушы минут өчен үткән юл да,**
**Аккан кан да, тир дә җәл түгел,**
**Ирек алды тагын азмы коллар,**
**Коткарылды күпме яшь гомер...**

## V

Шулай, көннәр, айлар бер-бер артлы үтә торалар. «Совет әдәбияты» да бер-бер артлы укучылар кулына юнәлә. Хәзер журналның чираттагы саннарына материал туплау эше дә әкренләп җиңеләя башлады. Мирсәй Әмир, Гариф Галиев, Мөхәммәт Гайнуллин, Хәсән Хәйри, Гали Халит, Ибраһим Нуруллин үзләренең яңа язган хикәяләрен, очеркларын, мәкаләләрен редакциягә китерә торалар. Журналга турыдан-туры бәйле булган, бик якын торган Гази Кашшаф, Фатих Хөсни, Кави Нәҗми, Таҗи Гыйззәт, Әхмәт Ерикәй, Әхмәт Фәйзи, Әнәс Камал иптәшләр үз әсәрләре белән журналны тәэмин итәләр. Фронттан кайткан Атилла Расих «Бәхет орлыклары» исемле маҗаралы повестен китерде. Кызыклы, мавыктыргыч әсәр. Ул журналда дүрт санга бүленеп басылды (1946 ел, 5, 6, 7, 8 саннар). Госман ага Бакиров укучыларыбызны үзенең бик җанлы һәм тормышчан итеп язылган «Сугышчы көндәлеге» белән, Шәйхи Маннур «Казан кызы» поэмасы белән таныштырды. Гариф Гобәй сугыш елларында балаларыбызның зур эшләргә сәләтле булуларын күрсәткән «Заман балалары» исемле романын язып бетерде һәм аның зур бер өлеше журналыбызның ике санына бүленеп басылды.

Утлы-канлы сугышларда корал белән дә, калем белән дә катнашып, исән-сау әйләнеп кайткан Ибраһим Гази, Афзал Шәмов, Нури Арсланов, Зәки Нури, Идрис Туктар, Шәреф Мөдәррис, Абдулла Әхмәт, Мөхәммәт Садри, Гали Хуҗи, Мәхмүт Хөсәен, Самат Шакир, Нур Гайсин һ. б. хөрмәтле әдипләребез журналның һәрбер санында яңа әсәрләре белән катнаша башладылар. Шактый еллар Казаннан читтә яшәгән язучы Габдрахман Минский Бакудан үз тавышын ишеттерде: ул чик сакчылары гаскәрләре сафында хезмәт иткән, Бөек Ватан сугышында катнашкан. Чик сакчыларының бик авыр да, мавыктыргыч һәм маҗаралы да хезмәтеннән бер мөһим эпизодны тасвирлаган «Эзләр» исемле хикәясе шулай ук журнал битләрендә үз урынын алды. Яңа тема. Оста гына язылган да.

Гомәр Бәширов әрмый-талмый «Намус» исемле романын язып ята, журналда аерым өзекләрен бастырды. Шул өзекләрдән чыгып кына хөкем йөрткәндә дә, сугыш елларындагы авыл тормышын, колхозчыларның фронт өчен фидакарь хезмәтләрен, аларның эчке дөньяларын, сөенеч-көенечләрен киң колач белән, чын художникларча тасвирлап бирә торган кыйммәтле бер роман туып килүен чамаларга мөмкин иде.

Габдрахман Әпсәләмовтан күп кенә яңа әсәрләр алдык: «Маньчжур язмалары», «Корея хикәяләре». Аларны да укучылар яратып кабул иттеләр, кызыксынып укыдылар. Бер заман үзе дә кайтып төште һәм редакциябезнең җаваплы секретаре булып, бик сагынган эшенә баш-аягы белән чумып китте. Фронтка шул редакциядә эшләгән җиреннән киткән иде бит ул. Сибгат Хәким кайтты, журналның поэзия бүлеген аңа тапшырдык. Инде шактый тәҗрибәле булган бу ике яшь әдип журналның эшен яхшыртуга, басыла торган әсәрләрнең сыйфатын тагын да күтәрүгә күп көч куйдылар, үз иҗат җимешләре белән дә укучыларыбызны еш кына шатландыра тордылар. Сибгатнең кыска, әмма тыгыз эчтәлекле шигырьләре, Габдрахманның фронт һәм тыл кешеләрен оста сурәтләгән хикәяләре журналыбызны бизи торган материаллардан санала иде. Габдрахман нәкъ шул елларны (1947) «Ак төннәр» исемле повестен язып, башта журнал аша укучылар хөкеменә тапшырды. Бу аның хикәяләрдән киң полотнолы романнарга таба уңышлы бер адымы булды дияргә ярый. Сибгатнең мәшһүр «Фазыл чишмәсе» дә журнал битләреннән чылтырап ага башлап, киң дөньяга таралды.

Шаулаган «Миңлекамал» авторы Мирсәй Әмир «Тормыш җыры» пьесасын язды, зур уңыш белән театр сәхнәләрендә куела башлады, шул пьеса һәм Мирсәй тарафыннан тәрҗемә ителгән «Мылтыклы кеше» (Н. Погодин), Таҗи ага Гыйззәтнең «Изге аманәт» драмасы шулай ук сәхнәләрдә куелып кына калмадылар, ә безнең журнал битләрендә дә күренекле урын алдылар.

Кырык алтынчы елга чыккач, штатыбыз да бераз тулыландырылды, тиражыбыз да беркадәр артты. Моңарчы журнал 8195 данә тираж белән басыла иде, хәзер ун меңнән артып китте. Бүгенге белән чагыштырганда, бик бәләкәй тираж, әлбәттә. Алай да без шундый аз гына үсүгә дә шатланып йөрдек. Ул елларда юрганның кыскалыгы да артык сузылырга ирек бирми иде (кәгазь җитешмәү, каты лимит!) Аның каравы, алдагы бик куандыргыч перспективалар да ачык күренә иде инде. Шундый шартларда безнең редакция коллективы тагын да күтәренкерәк дәрт белән эшли иде.

Бу кыскача истәлекләрне тәмамлап, шуны әйтим: ике елдан артык эшләү дәверендә, яхшысы да яманы да дигәндәй, төрлесе булгандыр инде, әлбәттә. Хәзер, бүгенгедән торып, ул чордагы эшебезгә янә кайтып карау, бәя бирү сыман уйлануларымда канәгатьләнү, шатлану хисләре белән бергә, ара-тирә үкенү-көенү кебек нәрсәләр дә күңелдә чагылып китә. Аларны шул чорның мәгълүм авыр шартларына гына сылтап калу, әлбәттә, дөрес булмас иде. Журналны төрле яклап тагын да яхшырту юнәлешендә теге я бу чараларны үткәрергә теләп тә булдыра алмаган чаклар да («дәрт бар, дәрман юк»), сәләт, белем җитмәү аркасында җибәрелгән аерым кимчелекләр дә булмады түгел. Җитәкче оешмалар аларны үз вакытында күреп-кисәтеп, төзәтә дә тордылар, ярдәм итеп килделәр. Без ул күрсәтмәләрдән, эшлекле конкрет тәнкыйтьләрдән һәрчак тиешле сабак алырга тырыштык. Кыскасы, әгәр ул чорда (1945—46—47) журналның һәрбер санын укучыларыбызны Ватанга, партиягә бирелгәнлек рухында, патриотизм, интернационализм, коммунизм рухында тәрбияләүгә буйсындыру өчен көчебезне, сәләтебезне аямый эшләдек һәм мәгълүм дәрәҗәдә моңа ирештек тә дисәм, редколлегия члennарының да, редакция аппараты хезмәткәрләренең дә уртак фикерен әйткән булырмын дип ышанам.

Илдус Ишморатов

# ДАВЫЛ АЛДЫННАН

*Ленин маршруты буйлап сәяхәт*



„1900 елның июнь аенда Владимир Ильич әнисе һәм апасы белән Надежда Константиновна янына Уфага бара. Юл уңаенда ул Нижний Новгородка туктала, анда социал-демократларның киңәшмәсен үткәрә, газета чыгаруда аларның катнашуы турында килешә. Нижний Новгородтан юлын Идел, Кама, Агыйдел буйлап пароходка утырып дәвам итә».

Юлбашчы биографиясеннән бу юлларны укыганнан соң, мин Ленинның сәяхәте белән кызыксынып киттем. Чыннан да, Ильич Уфага барган чакта Татарстанны буеннан-буена үрап узган бит.

Идел, Кама, Агыйдел буйларында ниләр күрде икән ул?! Нинди уйлар уйлап узды икән?!

Шул сорауларга җаваплар эзләп, Ленинның бу сәяхәте турында язылганнарның барысын да укып чыктым, архивларда казындым, тарихчылар, туган якны өйрәнүчеләр белән сөйләштем. һәм, ниһаять, үзем дә шушы маршрут буйлап сәяхәткә чыгарга уйладым.

Июнь ае. Кояшлы көн. Каршыга искән йомшак җил битне иркәли. Утыз яшьлек Ильич үзеннән-үзе күз алдыма килеп баса, аның ул вакыттагы рухи халәтен тойгандай булам.

Минем сәяхәтем Горький шәһәреннән башланды. Нижний Новгород. Минин, Добролюбов, Горький шәһәре!

Шәһәрнең истәлекле урыннары белән тарихчы К. Н. Хамов таныштырып йөрде. Элек елларда Илья Николаевич эшләгән ир-егетләр гимназиясе бинасында Ульяновларның мемориаль квартира-музеен оештырырга тырышып йөргән көннәре икән аның. Илья Николаевич һәм Мария Александровна турында шул кадәр тәфсилләп сөйләде К. Н. Хамов, аларның бирелгәге тормышы һәм эшчәнлеге безнең күз алдында үткәндәй булды.

Менә мин хәзер теплоход палубасында басып торам. Гаҗәеп мөлаем йөзле, олы яшьтәге ханымның борынгы Кремль тирәсендә Идел яры буйлап акрын гына йөрүе күз алдыма килә. Аның бер ягында — улы, икенче ягында — кызы. Мария Александровна, мөгаен, балаларына ничек итеп бирелдә, бу шәһәрдә Илья Николаевич белән тормыш корып җибәрүләрен сөйли торгандыр, ә, бәлки, кечкенә Анютаның яисә Сашаның шуклыкларын искә төшерәдер...

Соңгы вакытларда тикшеренүчеләр, архив документлары нигезендә, Илья Николаевич Ульяновның әтисе Нижний Новгород губернасы крестьяны булганлыгын ачык-

ладылар. Илья Николаевич, мөгаен, бу турыда Мария Александровнага да әйткән булгандыр. Ә Владимир Ильич белдеме икән? Әгәр белгән булса, әлбәттә, бу тирәләр аның күңеленә тагын да якынрак булгандыр... Шуларны уйлый торгач, Чабаксарга килеп җиткәнебезне дә сизми калганмын. Чувашстан башкаласы! Бу республика да Ульяновларга бәйле уйларга алып кереп китә. Илья Николаевич чуваш халкын агарту өчен күп эш эшләгән. Билгесез бер художникның картинасын искә төшерәм. Уң кулына акбур тоткан Илья Николаевич кара такта янында чуваш балаларына нәрсәдер аңлатып тора. Уйларым зирәк карашлы, мөлаем йөзле кеше — Советлар Союзы космонавты Андриян Николаев белән очрашуга килеп җитә дә, күрсә икән Илья Николаевич чуваш халкының бүгенге казанышларын дип куям.

Владимир Ильичның әтисе истәлеген чуваш халкы рәхмәт хисе белән хәтерендә саклый. Чувашстан университеты аның исемен йөртә, университет студентлары һәм укытучылары аның музеен оештырганнар.

Илья Николаевич чувашларга гына түгел, татарларга, мордваларга да ярдәм иткән. Чүпрәле, Буа, Тәтеш районнарында ул ачкан мәктәпләр әле дә бар. Тәтеш янындагы Илья Николаевич ачкан Кошки-Тимбай авылы мәктәбе узган ел 100 еллык юбилеен үткәрде...

Чувашлар яши торган бу урыннардан узган Мария Александровна, Анна Ильинична һәм Владимир Ильичның исләренә, мөгаен, якын танышлары Николай Охотников төшкәндер.

— Синең Коля Охотников дигән дустың шушы тирәдән түгелме? — дип тә сорагannардыр әле анасы яки апасы Владимир Ильичтан.

— Юк, ул Чистай өязеннән иде,— дип җавап биргәндер Ильич.— Тик шунысы кызганыч: кыенлыкта, ач-ялангач яшәп, сәламәтлеген югалтты, бик яшьли үлеп китте. Югары белем алырга, Яковлевның мәгърифәтчелек эшен дәвам иттерергә бик тә хыялланган иде ул...

Каһәр төшкән самодержавие строе күпме яхшы кешенең гомерен кисте! Владимир Ильич шундый кешеләрдән үзе өчен бик якыннарын — Н. Г. Чернышевскийны, әтисен, абыйсы Александрны, Николай Федосеевны, Анатолий Ванеевны шул чакта хәтереннән кичергәндер...

Минем күз алдыма Анна Ильинична үзенең истәлекләрендә сурәтләгән күренеш килеп баса.

«Без барлык көннәрне палубада үткәрдек,— дип яза ул.— Володяның күңеле бик күтәренке иде, ул елгадан һәм яр буе урманнарыннан бөркелеп торган саф һаваны рәхәтләнеп сулады. Кечкенә пароходның өске буш палубасында төнгә кадәр сузылган әңгәмәләребез хәтердә... Әнкәй, арып, каютага төшеп китә торган иде. Анда-санда күренгән пассажирлар да инде юк. Палуба хәзер икебез өчен генә, һәм тын елга, йокыга талган яр буйлары эчендә конспиратив әңгәмәгә беркем дә комачау итми иде. Владимир Ильич гомум рус газетасын оештыру планы, аның партия төзү өчен нигез булып хезмәт итәчәге турында тәфсилләп, мавыгып сөйләде».

Әйе, Владимир Ильичның эшләре бу вакытта уңышлы гына бара. Шушенскоеда сөрген срогын тутырып кайтканнан соң, ул, Псков шәһәренә урнашып, политик эш җәелдереп җибәрә. һәм нәтиҗәдә чит илдә зур яшерен газета — «Искра»ны чыгару мәсьәләсе инде тәмам хәл ителә.

Чит ил паспорты кесәдә. Алда «Искра» газетасының агентлар челтәрен оештыру бурычы тора. Аның Уфага барышы да шул максат белән. Әмма анда барырга рөхсәт алу өчен әнкәсе Мария Александровнага күпме көч куярга туры килгән! Менә ул үзе дә Володясын озатып килә. Озакламый Казан!.. Анда да Владимир Ильичның социал-демократлар белән очрашып сөйләшәсе бар. Әмма бик зур саклык күрсәтергә кирәк, жандармнар берни дә сизәрлек булмасын!

Казан каласы Ульяновлар семьясы өчен аеруча истәлекле шәһәр. Бигрәк тә Владимир Ильич өчен. Аның тормышындагы бик әһәмиятле вакыйгалар шушы кала белән бәйле: университетта уку, 1887 елда атаклы 4 декабрь сходкасына катнашу, беренче кулга алыну, сөргенгә сөрелү, сөргеннән кайткач, Маркс хезмәтләрен өйрәнү. Әйе, бу революциягә беренче адым, алда торган давыллы вакыйгаларның башы.

1890 елда да Владимир Ильич, Петербургка барышлый, Казанга тукталып, алты көн торган. Менә хәзер нәкъ ун ел үткәч, 1900 елның 11 июнендә ул тагын Казанда.

— Моннан киткәндә яшь егет идем, ә «картлач» булып кайттым,— дип тә шаярткандыр әле Владимир Ильич, Петербургта иптәшләре биргән кушаматны искә төшереп.

Бу юлы Владимир Ильич Казанда тагы да азрак тора. Нибарысы бер тәүлек тә берничә сәгать. Бу юлы биредә аның кемнәр белән очрашуы әлегә билгесез. Әмма шунысы бәхәссез: ул монда элемтә урнаштыра һәм газета өчен тагын бер хәбәрче пункты булдыра.

Казандагы туганнарына да кереп чыкмыйча калмагандыр, университет яныннан узарга, Кремль тирәсендә йөрергә дә вакыт тапкандыр ул.

...Казанда Ульяновлар «Якимова һәм уллары җәмгыяте»нең «Владимир» дигән пароходына утыралар. Пароход 12 июньдә кичке сәгать биштә кузгалып китә...

Шул замандагы Казанны күз алдыма китерергә тырышам. Тар урамнар. Төтен, тузан сеңеп каралып беткән йортлар, завод трубалары. Сәләмә эшчесезләр, грузчиклар, сукбайлар төркеме, сәүдәгәрләр, кырык тартмачылар, мещаннар, күкрәкләрен киергән полицейскийлар...

Ә хәзер күз алдымда — куәтле порт краннары, гранитка төренгән тигез яр буйлары, соңгы елларда үсеп чыккан таныш кварталлар, күп катлы йортлар, җәмәгатьчелек биналары, пассажирларның бәхетле елмаюлары. Әнә шәһәр уртасында университетның физика факультеты бинасы, болытларга ашып, җәйге кояш нурында ялтырап, бөтен Казанга ямь биреп тора. Әйе, Казан яшәргән, чагыштыргысыз матурланган. Калкулык өстенә урнашкан Кремль һәм башка истәлекле биналар шәһәрнең борынгы үткәнен сөйлиләр.

...Казаннан Кама Тамагына кадәрге юлда Ульяновлар, әлбәттә, Кокушкинода үткәрелгән күңелле көннәрне дә искә төшергәннәрдер. «Җәй көне Иделгә чыгасы иде. 1900 елның язында син һәм Анюта белән бергә ничек әйбәт йөзгән идек!» — дип, соңрак Лондоннан әнкәсенә язган хатында да, мөгаен, Владимир Ильич нәкъ менә шушы араны искә төшкәндер.

Бөек елга буйлап йөзгәндә, Владимир Ильич яраткан шагыйре Н. А. Некрасов сүзләрен дә кабатлагандыр:

**«Волга! Волга! Безнең җиребезне,**
**Баскан чаклы халык кайгысы,**
**Язың ташыган чиксез суың белән**
**Син дә кырны баса алмыйсың.**
**Кайда халык, шунда ыңгырашу...»**

Идел диңгезенең иң киң җире. Уң якта, еракта-еракта, офык суга килеп тоташкан урыннан да арырак Антоновка авылы калды. Элек бу авылның исеме Бездна булган. 1861 елда Антон Петров җитәкчелегендә анда крестьян восстаниесе күтәрелә. Ульяновлар бу вакыйганы да искә алганнардыр...

Бу сәяхәткә чыгар алдыннан мин 1900 елда басылган Казан газеталарын актарып утырдым. «Волжский вестник» газетасының бер санында безнең як крестьяннарының хәле турында кызыклы гына материалга юлыктым. «1899 елның җәендә Казан губернасы, Лаеш өлкәсенең Чаллы кыры тирәсендәге рус булмаган ярлы крестьяннарга һәм кешеләргә ярдәм турында кыскача отчет» дип исемләнгән бу мәкалә.

«Харьковта миңа,— дип яза автор,— ураза вакытында Казан губернасы ярлылары өчен дип әзерым кешеләр һәм медицина җәмгыяте тарафыннан хәергә җыелган 265 сум 15 тиен акча тапшырдылар. Ярдәмгә мохтаҗ кешеләр яшәгән урынны билгеләү минем үз иркемдә иде. Мин... татарлар яши торган Чаллы кыры дип исемләнгән төбәкне сайладым. Анда сигез ел элек каты ачлык булган. Бу тирәләрне XIX гасырның башында зур урманнар каплап алган булган. Урман эчендәге аланнарда, болыннарда иген иккәннәр... Бу тирәктә 14 авыл: берсе рус авылы, дүртесендә керәшен татарлары яши, сигезе татар авылы, бер авыл катнаш. Аларның үзәге — Кадрәк Чаллысы дигән авыл. Ул безнең нәселдән килгән морза имениесе, элек морза биләмәсе булган, хәзрәт авылы дип йөртелгән.

Безнең кешеләрнең төп эше — җир эшкәртү, вакыты белән урманчылык, йөк ташу белән дә шөгыльләнәләр. Әмма безнең як — караңгы як, эш хакы бик аз төшә. Дәваланыр урын юк. Земство шифаханәсенә кырык чакрымлап барырга кирәк.

Кадрәк Чаллысына мин чәршәмбе көнне килеп төштем. Тирә-яктагы авылларда зоңгелә авыруы таралган һәм ярдәм сораучылар бик күп иде.

Хөкүмәт бүлеп биргән ярдәм айның ике атнасына гына җитә. Күп балалы гаиләләр, онны күршеләреннән алып торып, бурычка батканнар. Акча эшләр урын юк, житен, киндер һәм яшелчә корылыктан көеп беткән. Булган кием-салым байларга, сәүдәгәрләргә заклад салынган. Болыннар, чәчү җирләре буп-буш. Исән калган терлек-туар кыштан бик ябык чыккан. Күренеп тора: Харьковтан алып килгән акча бик аз, ә нужа зур...»

Әйе, Владимир Ильич Идел — Кама буйлап Уфага сәяхәт кылган чакта татар крестьяннары, Россиядәге барлык хезмәт кешеләре кебек үк, ач-ялангач яшәгәннәр. Күптән түгел миңа әлеге газетада исеме аталган авылларда булырга туры килде. Бу авыллар хәзер Балык Бистәсе районына керә. Авыл кешеләренең тормышы иркен. Ачлык, корылыкны хәзер анда белмиләр дә. Колхоз һәм совхозларның һәрберсе хәзерге заман техникасы белән тәэмин ителгән. Һәр елны гектардан 20—25 центнер уңыш җыеп алалар. Мәктәпләр, китапханәләр, клублар, культура сарайлары, больницалар, электр, радио, телевизор, газ...

Мин шуларның барысын хәтергә төшердем дә уйлап куйдым: әгәр күрсә икән шуларны хәзер... Юк, Ленин турында әйтмим. Ул, әлбәттә, нәкъ менә шулай булачагын белгән, бөтен көчен, бөтен гомерен халыкларны шул якты тормышка чыгаруга багышлаган. Мин әлеге отчетның авторы турында әйтәм. Ул мондый үзгәрешләрне үз күзе белән күрсә дә, ышанмас иде кебек...

Алда — Чистай шәһәре. XX гасыр башында ул иске бер сәүдәгәрләр шәһәрчеге булган. Аның Ульяновларны кай ягы белән кызыксындыруын әйтүе дә кыен хәзер. Язучы Г. Успенский 1888 елны Себергә барышлый монда тукталып, шәһәрне Россиянең гадәти бер караңгы почмагы дип атый. Ә А. П. Чехов 1880 елның апрель аенда Сахалинга сәяхәте вакытында туганнарына болай дип яза: «Кама буйлап йөзәбез, кай тирәләр икәнен тачып та булмый. Чистай тирәләре булса кирәк. Яр буйларының матурлыгы да күзгә күренми, җәһәннәмдәге кебек салкын».

Менә Алабуга. Борынгы шәһәр. Ул — кавалерист кыз, язучы Надежда Дурова һәм рәссам Иван Иванович Шишкин белән атаклы. Патша хөкүмәтеннән Иске Мултан дигән удмурт авылы крестьяннарының күпме җәфа күрү вакыйгалары искә төшә. Шул сәяхәттән дүрт-биш ел элек кенә булып үткән суд процессы бөтен Россиягә шаулаган. Танылган язучы В. Г. Короленко аларны яклап мәкаләләр язып чыга.

1895 елдан 1897 елга кадәр барган бу процесс нәтиҗәсендә удмурт крестьяннарының гаепсезлеге ачыклана. Удмурт халкына пычрак ату һәм җирләрен басып алу нияте белән полицейскийлар һәм карагруһчылар аларга яла яккан булып чыга.

Әйе, Идел — Кама буйлары Ульяновларга патша хөкүмәтенең вак милләтләргә кыргыйларча мөнәсәбәте турында күп нәрсә сөйләгәндер. Шулай булмый мөмкин дә түгел, бу һәркемгә күренеп тора: әнә Алабуга өязендә күбесенчә татарлар яши, ә ул Вятка губернасына карый. Чабаксар, Царевококшайск өязләре исә, чуваш һәм мари халыклары җирләре булса да, Казан губернасы составына кертелгән. Бу махсус рәвештә, милләтләрнең бердәмлеген бетерү өчен эшләнгән бит...

В. И. Ленин 1920 елда Татарстан автономияле республикасы оештыру турындагы декретка кул куйганда, мөгаен, бу тирәләрне хәтеренә төшергәндер. Бу якларның киләчәген күз алдына китергәндер. Әнә алар, Ленин идеяләренең җимешләре: тиз йөрешле теплоходлар, нефть вышкалары, югары вольтлы электр үткәргеч мачталары, яңа шәһәрләр, булачак автогигант корылмалары! Каманың һәр ике як яры да яңара, яшәрә! Ирекле кешеләрнең чиксез ихтыяр көче, киң колачлы омтылышы әкиятне чынга әверелдерә!

Кама автомобиль заводы. Бу гигант завод корылмалары ике миллион ярым квадрат метр җирне били. Төзелешнең масштабы һәм тизлеге буенча хәзергә кадәр әле дөньяда моның тиңе булганы юк. Ә автозавод шәһәре тиздән зурлыгы буенча Татарстанда икенче шәһәр булачак. Андагы биналар, андагы йортлар, квартиралар хәзерге заманның барлык таләпләренә җавап бирерлек. Киләчәк шәһәре, коммунизм шәһәре!

Химиклар шәһәре Түбән Кама, ГЭС төзелеше. Чаллы яныннан үткәндә, мин шуларны уйлап горурландым. Минем уйларымны гармун тавышы бүлдерде. Гармун

тавышын ишеткәч, ашыга-ашыга палубага чыктым. Яшь кенә кыз кулындагы тальян гармун Кама буйлары турында сөйли. Аның янына утырышкан шундый ук яшь кызлар, яшь егетләр, гармунга кушылып, җырлап җибәрделәр:

Акчарлаклар оча уйнап
Агым су өсләрендә.
Син җылы бирдең, туган як,
Иң якты хисләремә.
Кама буе — туган як,
Гөлләр үсә торган як.
Гүзәллеге күңелләрдән
Җырга күчә торган як.

Җыр тавышы тын елга өстеннән еракларга, яр буендагы урманнарга тарала. Җыр яңа хисләр, яңа уйлар уята. Уйларым шул ук бер нәрсәгә — бу якларның үткәне һәм хәзерге көненә кайтып кала.

Уң кулда — Минзәлә районы җирләре. Күптән түгел мин газета заданиесе белән бу район колхозларында йөргән идем. Түбән Тәкермән авылында җитмеш яшьлек Салихҗан ага Ризванов миңа менә нәрсәләр сөйләде:

— Кигән киемебез киндер тукымадан өйдә тегелгән күлмәк-ыштан иде,— диде ул.— Кичен, эштән арып кайтып, өс киемебезне дә салмыйча, урынга ава идек. Бердәнбер бәйрәмдә — сабан туенда гына күңел ача идек. Яшьләр өчен мунчадан башка җыелып күңел ачу урыны юк иде. Иртәдән үк карап йөри торган идек — бүген кем мунча яккан. Мунчага җыелышып, чыра яктысында карта уйный, әкиятләр сөйләшә идек. Үзебезнең авылдан һәм якын-тирәдәге авыллардан тыш башка дөнья барлыгын да белми идек без. Хәер, авылда бер кеше — Бәдретдин агай — газет алдыра иде. Дөнья хәбәрләрен авыл халкы бары тик Бәдретдин агайдан гына сорашып белә ала иде...

Ә хәзер...

Хәзер Минзәлә дәүләт театры, йөзләрчә үзешчән коллективлар авыл кешеләренә культура хезмәте күрсәтә. һәр авылда — культура йортлары, китапханәләр... Колхоз авылы кешеләренең культура ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен аларда бөтен мөмкинлек бар.

Менә бу шат күңелле кызлар белән егетләр Минзәләгә ел саен үткәрелә торган традицион музыкаль фестивальгә баралар икән...

Теплоход, Каманы сулда калдырып, яшел тугайлар, болыннар, тирәкләр уртасында талгын гына аккан Агыйделгә борылды. Җырларда җырланган матур Агыйдел буйлары. Минем бала чагым биредә үтте. Сабый чагымның онытылмас истәлекләре шушы гүзәл елга белән бәйле. Әти белән печән чабулар, яңа гына чабып алынган хуш исле печәнгә күмелеп, шалаш эчендә йоклаулар, кичке учак янында олыларның, бигрәк тә маякчы агайның, сөйләгән тылсымлы хикәятләре.

Без, балалар, йокыдан соң тора идек. Кояш инде шактый күтәрелгән була иде. Әтиләр инде эшләп арыган. Чәй эчә-эчә ял итәләр. Без аннан-моннан гына капкалыйбыз да болынга йөгерәбез, җиләк җыябыз. Аннары көймәдә йөрибез. Менә борылышта пароход күренә. Пассажирларга кул болгыйбыз, пароход узып киткәч, ул калдырган дулкыннарда тирбәләбез...

Зур тарихи вакыйгаларның, онытылмас истәлекләрнең шаһите ул Агыйдел сулары! Атаклы сәяхәтчеләр, Пугачев һәм Салават Юлаев каһарманнары, гражданнар сугышы батырлары, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Салих Сәйдәшев...

Ләкин бу тирәләрдән Ленин узган булуын бала чакта башыма да китермәгән идем.

Минем бабаларым — әни ягыннан да, әти ягыннан да — Агыйдел буенда гомер иткәннәр. Берсе ишкәкче, икенчесе балыкчы булган. Аларның кайсы да булса, әлбәттә, Ульяновлар семьясы утырган пароходны күргәндер, карашы белән озатып калгандыр...

Владимир Ильич Уфада ике мәртәбә булган. 1900 елның февралендә Ленин Шушенскоедан сөрген срогын тутырып кайта. Себердән кайтышлый үтелгән зур шәһәрләрнең иң беренчесе Уфа була. Бирedә ул ике көн тора. Россиянең үзәктәге шәһәрләренә кайтырга рөхсәте булмаган Надежда Константиновнаны урнаштыра ул бирегә. Социал-демократлар белән очрашырга да вакыт таба. «Тәрәзәләрне ачып җибәргәч, бөркү бүлмәгә кояш нурлары уйнап торган, хәл керткеч саф һава бөркелеп тулгандай булды»,— дип искә алалар В. И. Ленинның беренче килүен Уфа большевиклары...

Менә ул июнь аенда тагын Уфада. Биредә Владимир Ильич социал-демократлар белән берничә киңәшмә үткәрә.

Уфада истәлекле урыннар бик күп. Әмма мин һәр көнне иртән тору белән ямьле Агыйдел буйларына юнәләм. Биек яр буйлап сузылган бакчада йөрим. Еракта калган июнь көннәрен күз алдыма китерәм. Бу сукмаклар буйлап кайчандыр утыз яшьлек Ленин йөргән, дим. Кайсы урын аеруча ошады икән аңа?..

Уфада озак еллардан бирле яшәүчеләр Владимир Ильичның тау башындагы бакчага — губернатор бакчасына килгәләве турында сөйлиләр. Ул, әлбәттә, борынгы крепость башнялары торган калкулыкка да менгәндер. Хәзер Салават Юлаев һәйкәле торган биеклектән ул, дуслары һәм туганнары белән бергә, табигать күренешләре белән хозурланган, дип сөйлиләр...

Шулай яр буйлап йөри торгач, бу тирәләр миңа ничектер таныш кебек тоелды. Минем бу күренешләр турында кайдадыр укыганым бар бит. Әйе, бар. Лениннан укыганым бар. Аның 1902 елда чыккан китабында түбәндәге сүзләр язылган:

«Без, күмәкләшеп, кулга-кул тотынышып, текә һәм кыен юлдан атлыйбыз. Безне һәрьяклап дошманнар чолгап алган һәм безгә, һәрвакыт диярлек, аларның уты астында барырга туры килә».

Әйе, бу гомумиләштерелгән революцион көрәш картинасының реаль күренеше Уфада булып чыкты. Социал-демократлар белән очрашулар, киңәшүләр, патша шымчыларыннан качып, Агыйдел буенда үткәрелгән. Ә алар, Ульяновның биредә нинди эш белән шөгыльләнергә тиешлеген яхшы белеп, аны бик нык эзәрлекләгәннәр, шымчылардан текә сукмаклар буйлап, кулга-кул тотынышып качарга туры килгән...

Владимир Ильич Уфада ике атнадан артык тора. Аннары, поездга утырып, Подольскига кайта. 16 июльдә шуннан чит илгә китә.

1900 елның декабрендә Лейпцигта Ленин «Искра»сының беренче саны чыга.

## Марсель Зарипов

# ТЫЛСЫМЛЫ НУР



Бөек Октябрь революциясе булып, йөз ел үткәннән соң җирдә нинди тормыш булачак? Шул турыда төрле прогнозюрамалар әйтелгән бер китап бар. «2017 нче елда» дип атала ул. Анда бер хирургның безнең заманда эшләгән врачлар турында үзенең хезмәттәшенә язган хаты да басылган. Хатта мондый сүзләр бар: «Клиникаларда авыру кешенең организмындагы барлык үзгәрешләрне ачык итеп күрсәтеп тора торган интроскоплар булмаган. Кешенең эчке әгъзаларын күрсәтә алырдай берданбер нәрсә рентген аппараты төшергән тонык рәсем генә булган...»

Кызык бит, әйеме? Казандагы врачларның белемен күтәрү институты рентгенологларының эше белән мин үзем дә әнә шул сүзләрне укыгач кызыксынып киттем бугай.

Гадәттә, рентгенологларга рәхмәт әйтеп язган хатлар килеп тормый, читтән аларны туган көннәре белән дә котламыйлар, бәйрәмнәрдә чәчәкләр дә китермиләр. Гадәткә кермәгән! Бу уңайдан медиклар үзләре дә беркадәр елмаеп һәм аянып та: «Хирург ялгышса, рентгенолог гаепле, операция бик әйбәт чыкса, хирургны тәбрикләрләр»,— диләр. Чыннан да шулай бит. Рентгенологның кызыл ут кына яна торган караңгы бүлмәсен кешеләр рәтләп күрә дә алмыйлар. Оста куллы хирурглар кешенең сүнгән йөрәген алып аның урынына яңаны куялар, баш миендәге чикләвек төше кадәрле генә шешне кисеп алалар. Рентгенның зарарлы нурларыннан кургаш алъяпкыч белән ышыкланып, тере организмның эчендә ниләр барлыгын күрүче, врачларга нишләргә кирәклек турында дөрес киңәш бирүче кешеләрне исә бик аз искә алалар.

Кафедрадагы дежур сестра профессор Фәйзуллинның өстәленә «бүгенгеләр» дип, хатлар китереп куйганда, Мидхәт ага бу хатларда, рәхмәт әйтүдән бигрәк, каты авырудан газап чиккән берәр кешенең гозере, ата-аналарның зур кайгысы, сабый балаларның фаҗигасе турында язылганлыгын белеп тора. «Ярдәм итегезче, доктор! Коткарыгыз, зинһар»,— диләр алар.

Луганск шәһәреннән менә мондый бер хат килгән: «1964 елдан бирле инде мин каты авырып, урын хастасы булып ятам. Врачлар минем авыруыма төрлечә диагноз куеп карадылар, ләкин хәлем елдан-ел начарлана бара. Мәскәүдә Боткин исемендәге клиник больницада эшләүче иптәшләр сезгә язып карарга киңәш иттеләр...»

Икенче бер хатның тышына Фергана штемпеле басылган.

«Хөрмәтле профессор иптәш. Сездән бик үтенеп сорыйбыз: улыбызны ничек дәваларга кирәклеге турында киңәш бирә алмассызмы? Безнең аны укытасыбыз, саусәламәт кеше итәсебез килә».

Өченче хатны язган кеше якында гына яши. Ак халатыңны салып, институттан чыгасың да трамвай юлы белән барып, мәйдан аша гына узасың. Адреста әйтелгән йорт шунда гына.

«Хөрмәтле профессор! Мин сезне белмим, сез дә мине белмисез. Ләкин мин сезне күрү белән үк таныр идем, ник дисәгез, минә хәзер сезнең фоторәсемегез минем каршымда тора.

Хөрмәтле Мидхәт Харисович, менә сигез ел инде мин эпилепсия авыруыннан җәфа чигәм. Бик үтенеп сорыйм — авыруымны ачыкларга ярдәм итегезче. Минем эшем — авыр булса да кызыклы эш, бик яратам мин аны. Әгәр миннән, «Бәхетеңне нидән табасың?» дип сорасалар, мин: «Эшемнән»,— дип җавап бирер идем».

Мондый чакта авыруга ярдәм итәргә тиешле кеше нәрсә хис итә? Врачның авыруга ярдәм итәргә баруы, кешегә яхшылык эшләүдән дә бигрәк, аның профессиональ бурычы, хезмәт вазифасы түгелмени?

Мондый чакларда Фәйзуллин тиз генә плащын, эшләпәсен кияр иде дә вокзалга, аэропортка ашыгыр яисә җәяүләп мондагы авыру янына йөгерер иде. Ләкин күрше аудиториядә генә аны врачлар, Урал, Идел буе, Кавказдан килгән хезмәттәшләре көтә. Алар институтка рентген диагностикасы эшен өйрәнергә, кеше организмында нинди үзгәрешләр булуын күрә белергә килгәннәр, аларны инде өч кенә авыру көтми, меңләгән авыру көтә. Әйтик, зур бер корабның капитаны бер кешене коткару өчен йөзләгән, меңләгән пассажирны куркыныч астына куя аламы?

Тормышта әнә шулай икенең берсен сайларга туры килә торган очраклар еш була. Фәйзуллин яшь кеше түгел инде, яше аның алтмыштан узган, ул инде, күңелендә туган кызгану хисенә бирелеп, шундук чыгып йөгермәскә күптән өйрәнгән. Ул хатларны конвертларына кире салып, элеккеләре янына куя. Аннары бер таблетка кофеин эчеп җибәрә. Кечкенә сәдәф чаклы гына бу таблетка тонусны күтәрә, авырая башлаган гәүдәне җиңеләйтә. Профессор чак кына үзенең йөрәк тибешен тыңлый, бераз хәл кергәнен көтеп тора да шуннан соң аудиториягә таба атлый. Йөзе аның җитди, тыныч. Өстәлендә: «Ярдәм итегезче, доктор!» дип гозерләп язган хатлар калган дип уйламассың да.

Врачларның кешелекле булырга тиешлеге турында күп ишеткән, күп укыган кайберәүләр әйтерләр: «Хатны уку белән авыру янына йөгермәгән, лекция укырга кереп киткәнмени?» — диярләр, хәтта профессорның үзенә әйтеп язулары да ихтимал. Ә менә мин үзем бу хакта киресенчә уйлыйм: профессор Фәйзуллин өчен, Казан рентгенологлары өчен яшәү һәм хезмәтнең иң зур мәгънәсе әнә шул лекция укуда, үз эшеңә башкаларны да өйрәтүдә, үзләренең дә камилләшә баруларында. Аңлашылып җитмиме? Алайса аңлата төшик. Беренчедән, Фәйзуллин ярдәм сораган бер авыру янына барып, аны терелтер дип кем әйтә ала? Медицина ул кадәр үк көчле түгел бит әле! Профессор шул рәвешчә йөреп, уңлаган, йөзләгән авыруны терелтә алса да, дәваланырга тиешләр аннан әллә ничә тапкыр күбрәк бит. Хикмәт берәүләрне генә терелтүдә түгел, бик күпләрне дәвалап сәламәтләндерүдә.

Мидхәт ага Фәйзуллинга хәзер алтмыш ике яшь. Аның белеменә, эш квалификациясенә күрә зур дәрәҗәсе бар, тормышы да яхшы. Кешегә тагы ни кирәк? Уйлап карасаң, булганы белән генә канәгать түгел икән кеше. Кырык ел буена врач булып эшләү, фәнни эш башкару дәверендә аның терелмәс дип каралган авыруларны да терелтерлек итеп искиткеч дөрес куйган диагнозлары, үзеннән уздырган шәкертләре, авыл больницаларында да, башка клиникаларында да врачлар кулыннан төшми торган белешмә китаплары, чит илләрдә басылып чыккан фәнни хезмәтләре бар, ә ул әле һаман да бер нәрсә өчен борчыла: практиклар яңа авыруларны дәваларга өйрәнеп җиткәнче, медиклар аларның яңадан-яңаларын эчә торалар, ди.

«Нигә ул кадәр көч җитмәстәй эшкә омтылырга? Бөтен авыруларны да терелтү мөмкин эшмени?» — дип, Фәйзуллинның бу фикеренә каршы килергә мөмкин. Ләкин ул, кеше һәрвакыт зурга омтылырга тиеш, дип карый. Күп вакыт уйлаганыңның бер өлешен генә тормышка ашыра аласың. Зур эшнең бер өлеше — шактый күп инде ул, ә кечкенә эшнең бер өлеше — бик кечкенә. Фәйзуллин кеше организмындагы бөтен эчке хәлләрне күрсәтә торган тылсымлы нур белән мавыгып, рентгенолог булып киткәч, ул иң зур максатка ирешергә — авыруларны төп-төгәл белергә, хирург һәм

терапевт та, окулист һәм онколог та рентген төшергән рәсем буенча кешенең эчендә нинди авыру барлыгын белеп, дөрес дәваларлык диагноз куярга омтыла.

Моннан кырык ел элек аның никадәр кыю омтылышлы булганлыгын, үз алдына гаҗәп зур бурыч куйганлыгын күз алдына китерү өчен мондый бер нәрсәне әйтеп китик: дөньяга атаклы рентгенолог доктор Рейнберг соңгы көненә хәтле үзендә ашказаны рагы булганлыгын белмәгән. Күренекле врачлар Склифоссовский, Валь, Грубе, Бильрот та Пирогов та рак шеше барлыгын таба алмыйлар. Беек хирург үләренә 26 көн кала гына үзенә-үзе дөрес диагноз куя. Үзенең гомерлек эше итеп рентгенологияне сайлаганда профессор Фәйзуллинның үз алдыча нинди зур максат куйганлыгы инде аңлашылса кирәк.

Хәер, ул елларда ук Фәйзуллин профессор булмый әле, бер завод больницасында фельдшер булып кына эшли. Иртән ул университетка медицина буенча лекция тыңларга йөгерә, кичләрен Казандагы бердәнбер рентген аппаратында эшли. Казандагы баш сөяге һәм баш мие авыруларын өйрәнә торган рентгенокраниология мәктәбе әнә шул яшь фельдшер Мидхәт Фәйзуллин эшләгән беренче аппараттан башланган дип әйтә алабыз.

Зур теләк, омтылышларга бирелеп хыялланырга безнең кайсыбыз яратмый икән? Ләкин андый хыялларны көндәлек тормышның күңелсез бертөрлелеге басып китә, якты теләк, омтылышлар ничектер сүрелеп кала. Шулай яши торгач, сизми дә каласың: гомерең узып та бара икән инде, хыялларың алсу бер томан гына булган икән. Сугышка хәтле үк әле искиткеч оста хирург профессор Гусынин рентген эшендә яхшы белгеч булып танылган Мидхәт Фәйзуллин төшергән рәсемнәрне карый да аның белекле аңлатмаларын тыңлаганнан соң: «Кешенең тәнен кисәр өчен әллә ни баш кирәкми. Иң мөһиме — кай төшне ничек кисәргә икәнен белү»,— ди, институттагы хирург ассистентына дип билгеләнгән вакансияне рентгенологка бирдертә.

Менә шул рәвешчә Фәйзуллин зур фән дөньясына кереп китә. Аларда мондый бер эш бүленеше бар. Рентгенолог-практикның эше — аппаратта яхшы, ачык рәсем төшереп, шуңа аңлатма бирү. Шуннан калганы инде — дәвалаучы врачлар эше. Рентгенолог-галим өчен исә иң мөһиме — эчке әгъзаларның рәсемдәге сурәтен өйрәнү, кеше организмындагы нормадан аз гына тайпылышларның да сәбәпләрен ачыклап белү.

Илебездә башка рентген диагностикасы кафедраларындагы кебек, Казан галимнәре дә хәзерге заман медицина фәненең бөтен өлкәләре белән шөгыльләнәләр. Әмма институтка барыннан да бигрәк рентгенокраниология дигән өлкә — баш сөяге һәм баш мие авыруларын белү системасы — дан китерә. Бу система союзда беренче буларак эшләнә.

«Фән ул — без» дип, гыйльми эшнең күмәк эш икәнлегенә басым ясап Виктор Гюго әйткән бугай. Кызганычка каршы дип әйтикме, әллә бәхеткә каршымы — тормыш бу фикернең дөреслеген раслап бетерми, хәзерге заман фәнендә галим кешенең «үзем» дигәне дә зур урын тота әле.

Баш капкачы һәм бит сөяге зарарлану турында беренче хезмәтен Фәйзуллин сугыш елларында яза. Ул вакытта Мидхәт ага башы ярылган сугышчыларны дәвалый торган госпитальдә бүлек мөдире булып эшли, баш сөяге зарарлануының бөтен организм функциясе белән бәйләнешен анализлый, меңләгән авыруны тикшерә. Боларның һәркайсы медицина фәненең бик күп якларын тирәнтен белүне сорый. Фәйзуллин ал-ял белми эшли, ике елда диссертациясен язып бетерә.

Ул чагында әле Мидхәт ага бик зур максатларны күздә тотмый, хәрби врач эшенең хәзерге заман медицина фәненә бәйләнешен дә күреп бетерми, диссертациясен яклаудан да баш тарта. Вакыты ул түгел — сугыш заманы. Казандагы медицина институтының ректоры С. В. Курашов аны бик каты тиргәп ташлый.

— Диссертацияңне хәзер үк якла! Сугыш булса соң! Сугышта медиклардан тагы да күбрәк эш сорыйлар — кешеләрне терелтеп аякка бастырырга кирәк,— ди.

Фәйзуллин докторлык диссертациясен кырык сигезенче елда яклый. Берәүләр өчен андый эш иң зур максат булса, икенчеләргә арырак китү өчен бер баскыч кына. Доктор булганнан соң, Фәйзуллин ничә ел фельдшер, авыл врачы, зур госпитальнең рентгенологы булып эшләү дәверендә җитәрлек тәҗрибә, акыл туплаганлыгын һәм моңарчы әле уйларга да кыймаган гыйльми эшкә керешергә кирәклеген аңлый. Әл-

бәттә, сүз әлеге шул баш сөяге, баш мие авырулары турында бара. Йөрәк, ашказаны, бавыр, бөер, аяк-куллар кешенең анатомик әгъзалары гына булса, баш мие, доктор Амосов әйтмешли, акыл, уй, хис-тойгы савыты. Фәйзуллинның, аның хезмәттәшләре һәм шәкертләренең хезмәтләрен монда гына санап, әйтеп бетерерлек түгел. Бу хезмәтләр кечкенә авыл больницаларында һәм зур шәһәр клиникаларында эшләүче меңләгән врачларның кулларыннан төшми торган белешмә китабына әверелгән.

Докторлык даныи күтәрү җиңел эш түгел. Артист, спортчы, талантлы язучы һәм художниклар — эшләгән эшләре, кешеләргә шатлык, ләззәт бирүләре белән танылалар, ә врач кешегә, дәвалаган, терелткән өчен рәхмәт яудырудан бигрәк, аңа зур өмет баглап, каты авырулы кешеләр килә. Казан рентгенологлары кулында тылсымлы нур барлыгын күбрәк авырулар, дәвалаучы врачлар белгән саен, кафедраның эше дә арта гына бара. Институттагы консилиумнарга катнашырга, поликлиникаларда консультация бирергә, авылларга барып кайтырга, рентген аппараты белән эшләгәннән соң, утырып язарга — фән белән шөгыльләнергә кирәк. Бер ел эчендә кафедра гади клиника врачлары гына ярдәм итә алмый торган ун меңләгән авыруны тикшерә.

Бервакыт клиникага врачлар «терелтмәслек» дип тапкан авыру кызны салалар. Ул бернинди бәхетсезлеккә очрамаган: моңарчы бер тапкыр да авырганы булмаган, спорт белән шөгыльләнгән, ишкәк спортында өч ел буена республиканың чемпионы булып килгән. Моннан ярты ел элек, ярышта оттыргач, бик нык борчылган. Спорттагы уңышсызлыгы әнә шулай тормыш фаҗигасенә әйләнеп киткән. Кайсы поликлиникага барса да, врачлар берни әйтә алмыйлар, әнисе аны заманында Вишневский белән бергә эшләгән атаклы врачларга да алып барып күрсәтә — барыбер файдасы булмый.

Кафедрада төзелгән системаның — авырулар «энциклопедия»сенең менә кайчан кирәге чыга! Рентгенологлар практикада очрамый торган бер хәлне — баш мие усеч-тесе шешен табалар. Нишләргә? Операция ясаргамы? Операциядән кеше үлмәс, исән калыр дип кем ышанып әйтә ала? Әллә рентген нурында тотаргамы? Кешене үтерми, бәлки терелтә торган гына итеп ул нурның чамасын ничек билгеләргә? Тәвәккәлләп, авыруны рентген нуры белән дәваларга булалар. Беренче сеанс сизелерлек үзгәреш китерми. Өч айдан соң дәваны кабатлыйлар, ә бишенче сеанстан соң инде авыру кыз аягына баса, стенага тотына-тотына атлап китә. Кабер якасына баскан кыз ике елдан соң, кафедрага килеп: «Миңа гаилә корырга мөмкинме?» — дип киңәш сорый.

Фәйзуллин шушы хәл турында Будапештта халыкара конгресста сөйли. Аның бу докладын шул арада ук Венгриядә һәм Германия Демократик Республикасында бастырып та чыгаралар.

Казан рентгенологлары эшендәге мондый мисалларны дистәләп, хәтта йөзләп тә китерергә мөмкин булыр иде.

Егерме ел үткәннән соң, без әлеге чемпион кыз белән очраштык,— хәзер ул олы гына хатын булган инде. «Казан рентгенологларына берәр төрле дәгъвагыз юкмы?» — дип сорадым мин аннан. Ул гаҗәпләнеп кулларын селекте дә:

— Ни сөйлисез! Алар үнҗиде елга минем гомеремне озайттылар. Хәзер улым Андрюша җиденче классны тәмамлый, кызым Лариса дүртенчедә укый. Икенче бер бала бар — ирем эчә. Менә аны да рентген нурында тотып алырга иде»,— диде.

Рентгенологларны да, шахтерлар кебек, пенсиягә илле яшьтән чыгаралар. Берәр авыруга катлаулы операция ясаганда хирург өчен нинди куркыныч булуы мөмкин? Авыруның исән калу-калмавы бар, аннары... авторитетын-дәрәҗәсен төшерүе дә ихтимал. Медицина — бик нечкә, бик катлаулы нәрсә белән — кеше организмы белән эш итә торган фән, шуңа күрә кешеләр врачның ялгышу ихтималын да аңлыйлар. Рентгенолог, авыру кеше белән бергә, үзе дә тылсымлы нур астына керә, үзенә дә күпмедер микъдар нур сеңдерә. Әлбәттә, әллә ни күп түгел, көненә рентгенның меңнән унҗиде өлеше генә. Кеше өчен ул зарарлы түгел, аны сабый бала да тоймый. Әмма ул бер тапкыр гына булмый бит, ике, өч, ун, йөз, мең мәртәбә кабатлана.

Профессор Фәйзуллинга илле яшь тулган көнне зур хезмәтләре өчен рәхмәт белдерәләр, мактау грамотасы бирәләр. Шушы чиккә җиткәч инде ул уйлана кала. Сәламәтлегенә начарланганнан, һәр лекциягә кергәндә кофеин эчәргә туры килгәннән генә түгел.

Аның төп эшеннән башка әдәби иҗат белән дә шөгыльләнәсе килә — сугыш вакытыннан бирле язылып бетмәгән пьесасы бар, берәр сәгать пианино уйнап аласы иде. Мидхәт ага музыканы бик аңлый, бик ярата. Алар әле малай чакларында ук энесе белән Сәйдәшевнең үзе янына барып музыка дәресләре алып йөргәннәр. Фәйзуллинга профессор дәрәҗәсе бирелгәч, энесе әйтә: «Аның докторлык чамасы турында әйтә алмыйм, әмма ул ярыйсы ук яхшы музыкант»,— ди. Энесе аның танылган композитор булды: милли культурабызның энҗесе саналган «Башмагым» музыкаль комедиясен язды, йөзләгән җыр, романс иҗат итте, ә Мидхәт ага рентгенолог булып калды. Һәркемнең сәләтенә күрә эше. Ул, бик теләсә дә, бишкә бүленә алмый. Көн саен, «Ярдәм итегезче, доктор!» дип гозерләп язылган хатлар алып торганда, пианино уйнап, пьеса язып утырып буламыни?!

Бер карагандa сәер дә кебек. Профессор, аның хезмәттәшләре һәм шәкертләре күбрәк эшләгән саен (алар инде алты монография, йөзләгән журнал мәкаләсе язганнар, төрле авыруларга диагноз кую буенча зур белешмә булырлык өч махсус җыентык чыгарганнар), үз-үзләренә таләпчәнлекләре арта бара. Безнең заман кешеләргә авыруны байтак китерә шул, врачка күренергә чират торалар, һәркемнең үз авыруы. Аларның берсен дә «иртәгәгә» калдырып булмый, врач аның авыруын бүген ук белергә, бүген ук дәваларга тиеш: аңчары соң булуы бар. Үлемнең үз эшен медицинадан алданрак эшләгән очраклары күпме?

Әлбәттә, эшләгән эшеңнән канәгать булып, боларның берсен дә күрмәскә, күз йомарга да мөмкин. Киресенчә дә эшләргә була: моңарчы эшләгәннәреңне онытып торып, ярдәмгә мохтаҗ авырулар турында, врачтан тырышлык, фидакарьлек сораучылар турында гына да уйларга мөмкин. Казан рентгенологлары — әнә шундый кешеләр, алардагы югары профессиональ һәм гражданлык активлыгының, үз-үзләренә искиткеч таләпчән булуларының нигезендә әнә шул омтылыш ята. Алар иң зур уңышларына да гади бер эш итеп, кечкенә генә җитешсезлекләренә исә зур бер кимчелек итеп карыйлар. Әгәр профессор Фәйзуллинның кулына бер бит кәгазь биреп, үз-үзегездән зачет алыгыз — плюс, минус билгеләре куегыз, дисәк, ул үзенә минус билгеләрен күбрәк куяр иде.

Минемчә, Мидхәт ага минуслар ягына иң элек эшнең вак-төяк якларын оештыра алмавын теркәп куяр иде. Аның үз уенча, бу як — алар эшендә иң зур кимчелек. Көндәлек тормышта тегесен-монысын юнәтеп остарып беткән берәр администраторга юк кына эш булып күренә торган нәрсә фән кешеләре өчен башкарып чыга алмаслык бер мәсьәлә булып тоела. Менә һәр көнне иданнәрне балавызлап ялтыратып торырга кирәк — техничкалардан шуны эшләтеп булмый: өстәмә акча түләгез, диләр. Күпме тырыша торгач, үзләре теләгәнчә итеп уку-өйрәнү лабораториясе җиһазладылар — өр-яңа аппаратлар куйдылар, үзе ачыла, үзе ябыла торган пәрдәләр эшләттеләр, ә менә экран булмады — завхоз биш метр ак киндер юнәтә алмады. Фән эше ул тоташ тәҗрибәләрдән тора, аның берсе уңышлы чыкса, меңе уңышсыз була. Кафедрага этләр белән бик күп тәҗрибә ясарга кирәк. Эт булдыру өчен дүшәмбе көн җиткәнне, берәр эчкеченең баш төзәтү өчен акча юнәтергә дип, урамнан Сәрбайны тотып китергәнен көтәргә туры килә...

Кафедраның эшенә бәя биргәндә профессор, һичшиксез, үзенең шәкертләренә, фән белән янып йөрүче аспирантларына плюс билгесе куяр иде. Бу мәсьәләдә инде Мидхәт ага бөтенләй икенче кеше, хәйләсен дә белә, осталыгы да җитә... Кафедраның хәзерге доценты Исмәгыйл Галимовны ул нерв авырулары ординатурасыннан алган. Рентген диагностикасы методларын үзләштергән невропатолог — алтын кадр бит ул! Ә менә кафедрада андый штат юк. Ректоратта: «Нишлисең бит, андый урын каралмаган»,— дип кенә җавап бирәләр. Шуннан соң Фәйзуллин Мәскәүгә, туп-туры министрның үзенә хат яза. Аспирант-невропатолог урынын ул булдыра, тик үзенә шелтә дә ала. Икенче тапкыр үзеннән өлкәннәрне узып эш йөртмәсен, янәсе. Шелтә алу бигүк күңелле хәл булмаса да, Фәйзуллин бик шат. Һәр шелтә бәрабәренә берәр рентгенолог-галим булдыра барырга бик риза ул.

Илдус Хәбибуллин белән эш башкачарак килеп чыга — моңарчы ул бөтенләй икенче кафедрада укый, соңыннан гына Фәйзуллин янына күчә.

— Мине аласызмы? — дип килә ул.

— Мин сезне бөтенләй белмим бит,— ди профессор.

Хәбибуллинны ике ел «өйрәнгәннән» соң, аңа балаларның баш миендәге үзгәрешләрне тикшерергә тема тәкъдим итә. Гыйльми советта теманы раслаганда «башкарып чыга алырмы?» — дип шик белдерәләр. Фәйзуллин, аспирантны яклап, «башкарып чыгар», ди. Соңыннан ул бу шәкертенең искиткеч тырышлыгын, эш сөючәнлеген күреп үзе дә шакката. Хәбибуллин өч ел буена кулыннан аппаратны төшерми: җәй көннәрендә җилкәсенә күтәреп, кыш көннәрендә чана белән тартып суд эшендәге медицина экспертизаларына алып йөри һәм нәтиҗәдә тирән эчтәлекле зур хезмәт яза. Марс Михайлов авыл больницасында хирург булып эшли, кафедрага лаборант булып эшкә керә, диссертация яклый...

Фәйзуллин үз шәкертләре өчен вакытын да кызганмый, үзе җитешә алмаганга, аларга эшләргә дип үз идеяләрен дә бирә. Шәкертләре дә Мидхәт аганың яхшылыгына яхшылык белән кайтаралар — аның җитәкчелегендә ал-ял белми эшлиләр. Кафедрада «эшләдем» димиләр; галимнәр, ассистентлар, аспирантлар, техниклар, лаборантлар һәм нянялар да һәрвакыт: «Эшләдек»,— диләр. Алар үз институтларында уздырылган Бөтенсоюз конференциясенә бергәләп доклад язалар, бергәләп Сочига, Таллинга семинарларга барып, врачларны баш мие авыруларын таба белергә өйрәтәләр. Башта алар үзләре кеше авыруының серенә төшәргә өйрәнәләр, аннары бүтәннәрне өйрәтәләр...

Галишер Нәвои әйткән: «Гыйлем эчмәк — энә очы белән кое казымак», дигән. Бәлки, мин ялгыша да торганмындыр, минемчә, бу сүзләр бәрыннан да бигрәк медицина фәненә карый. Башка фәннәр өйрәнә торган нәрсәләрне системага салырга, аларның уртак серен, ачкычын табарга мөмкин әле. Ә менә кешедәге авыру белән алай эшләп булмый, чөнки бер үк авыру төрле кешедә төрлечә килеп чыга. Фәйзуллинның үз хезмәтләре, шәкертләренең эзләнүе кеше авыруын өйрәнә торган фәндә, бәлки, энә белән төрткән бу эз, нокта гына булыр, ләкин шунсы да мәгълүм — ноктадан башламаганда кыска гына бер сызыкны да сызып булмый.

Соңгы тапкыр без Мидхәт ага Фәйзуллин белән аның кафедрасында сөйләшеп утырдык. Мин аңардан: «Медицина фәнен тагы бер илле елдан соң ничегрәк итеп күз алдына китерәсез? — дип сорадым.— Кайберәүләрнең юраууларына караганда, ул чагында инде врачлар рентген аппараты төшергән тоныкрәсемнәр белән генә эш итмәсләр, алар кулында кешенең бөтен эчке әгъзаларын күрсәтә торган интроскоплар булачак бит...»

— Фантазия турында нәрсә дип әйтик? Алай ансат кына егерме беренче гасырга күчеп, егерменче гасыр турында өстән торып фикер йөртү күңеллесен күңелле дә, тик прогнозлар әйтүгә карап кына авыру кешенең хәле җиңеләймәс. Аңа: «Ике меңенче елны көт инде, дип әйтеп булмый бит»,— диде профессор.

Башта мин медицинада сай йөзүем өчен гафу үтендем, аннары капыл гына болай дип сорадым:

— Ул баш миен дәвалап азапланганчы, алыштырып куел кына булмыймы? Бөерне, йөрәкне алмаштыралар бит. Дөньяда инде унлап кеше икенче кеше йөрәге белән ике елдан артык яши.

Профессор елмаеп куйды:

— Хыял, хыял!..— диде.— 1968 елда дөньяда 101 кешенең йөрәген алмаштырганнар, ә 1969 елда — 17 генә. Йөрәк ул тәндәге канны куа торган насос кына, ә баш мие — кеше ул үзе дигән сүз. Кеше үлгәннән соң йөрәк биш минут яши, ә баш мие шундук үлә. Андый операцияләрне ясарга мөмкин булганда да аннан да зуррак кыенлыклар килеп туачак. Больницадан кеше бөтенләй икенче кеше булып чыгачак. Әйтик, хирург кеше скальпель тота белмәс, математик-кибернетик иң ансат мәсьәләне дә чишә алмас. Ул гына да түгел, намуслы кеше әшәке җанлыга, батыр кеше куркакка, җаны-тәне белән фәнгә бирелгән галим вак бер карьеристка әйләнер. Хикмәт кемгә нинди кешенең мие туры килүендә. Анысы әле киләчәк эше. Ә менә без, хәзер врачлар кешенең баш миен алыштыра алырлармы-юкмы? дип фараз кылып утырганда кешеләр авырып яталар...— Фәйзуллин, фикерен йомгакларга җыенгандай, беравык уйланып торды да аннары әйтте:— Без рентгенологларга менә хәзер үк инде нәрсәдер эшләргә кирәк. Әйтик, без куя торган һәр диагноз якынча гипотеза гына булмасын, абсолют дөрес булсын. Бу нәрсә иртәгә дә, берсекөнгә дә, врачлар кешенең баш миен алмаштыра башлагач та кирәк булачак...

Халит Кумысников

# ТЫЙНАК КЕШЕ, СӘЛӘТЛЕ АРТИСТ

Бүгенге артист, бүгенге сәнгать кешесе... Ул ничек уйнарга, нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Иң элек — талантка, әлбәттә. Монысы бәхәссез. Ләкин талантлы булу гына җитми. Актер тагын әле заман сулышын тоя белергә тиеш. Бер-берсеннән аерылгысыз шушы ике сыйфат хәзерге чор артистының йөзен билгели дә инде. Һәм Татарстанның атказанган артисты Фатих Кульбарисов нәкъ шундый сәхнә эшлеклеләреннән санала.

Кульбарисовны мин егерме елдан артык беләм, аның иҗатын өзлексез күзәтеп киләм. Кыен һәм сикәлтәле юл үткән артист ул. Байтак еллар буена режиссерлар аңа игътибар биреп җиткермәделәр, аңа күп вакыт эпизодик рольләр белән канәгатьләнергә туры килде. Дөрес, эпизодик рольләрне дә кемдер уйнарга тиеш. Кульбарисов та андый рольләрдән баш тартмый, әлбәттә, ләкин артык дәртләнеп, энтузиазм белән уйный да алмый. Аның эрерәк образларга тотынып карыйсы килә, кызык һәм мавыктыргыч итеп уйныйсы килгән геройлары була. Артист үз энергиясен тулы көченә файдалана алмавы, кызыклы һәм үзенчәлекле фикерләренең тормышка ашмавы өчен борчыла...

Ә инде үзенә ошаган рольне Фатих дәртләнеп, җиренә җиткереп өйрәнә. Төннәр буе эшли, туктаусыз эзләнә, уйлана. Яраткан роле өчен гаҗәеп буяулар, төгәл детальләр таба. Соңыннан тамашачы аның оста уйнавын, интеллектуаль артист булуын күреп куана. Фатих үзе исә тыйнак кеше. Кайчак котлауларны да бик коры гына кабул итә, хәтта канәгатьсезлек тә белдерә. Аныңча, бу рольдә әле күп нәрсә табылмаган, роль тиешенчә эшләнмәгән, шулай булгач, кешеләр күңелне генә күрергә тырышалар, дип уйлый.

Кайсы гына пьесада уйнамасын, Кульбарисов һәрвакыт үз персонажларыныңурынын дөрес табарга тырыша. Аның геройлары бер вакытта да берсен-берсе кабатламыйлар, бер-берсенә охшамыйлар, аларның һәркайсы драматург ачкан билгеле бер эпоханың, теге яки бу конкрет даирәнең вәкиле булып күз алдына баса. Сәхнәдә Кульбарисовка карыйсың да, автор фикерен ничек шул кадәр дөрес аңлый һәм аны шундый тулы гәүдәләндерә ала икән бу кеше дип гаҗәпләнәсең.

Нәкый Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясендәге Розенберг образын искә төшерик. Әсәрдә фашист идеологы Розенберг белән патриот шагыйрь Муса Җәлил очрашкан күренеш бар. Ике дөнья, ике система капма-каршы килә. Аларның һәркайсы үз карашының хаклыгына инана һәм шул карашын расларга тырыша. Бер якта — хисләргә бирелүчән, нечкә күңелле әсир шагыйрь, икенче якта — каты бәгырьле гитлерчы. Әгәр бу кешеләрнең беренчесендә (М. Җәлил ролен Ф. Хали-

тов уйнады) кайнар кан ярсыса, икенчесе үзен тыныч һәм салкын тота. Озын буйлы, ябык гәүдәле Розенберг бөтенләй диярлек хәрәкәтсез, шуңа да мәет кебек күренә. Кульбарисов башкарган бу рольдә без бернинди ясалмалык сизмибез. Ул тамашачыны ышандырырлык образ тудырган, рольнең сәнгатьчә гәүдәләнешен тапкан. Ничек соң ул рольнең бөтен нечкәлекләренә, аның асылына төшенә алган?



Фатих Кульбарисов актерлык сәнгатенең гыйльми ягын студиядә укыганда өйрәнә, ә академия театры спектакльләрендә уйнау теорияне практика белән бәйләргә мөмкинлек бирә. Аның театрдагы беренче укытучысы Кәшифә Тумашева була. Ә Кәшифә апа үзе — А. В. Луначарский исемендәге театр сәнгате институтында күренекле педагоглар А. Д. Попов һәм А. А. Андерстан укыган кеше. Укытучыларыннан өйрәнгәннәрен Кәшифә Тумашева студиядә укучы яшьләргә бирергә тырыша. Ул Фатихның актерлык йөзе формалашуга да көчле йогынты ясый.

...Булачак артист Фатих Кульбарисов актерлык сәнгате серләрен беренче чорда, ничектер, авыррак үзләштерә. Сәхнәдә ул җанлы характер тудырырга кирәклеген белә, әмма ничек итеп үзеңә шул характерга әверелергә, аның яңача гәүдәләнешен табарга, ничек рольгә керергә? Ул әнә шуларны белми. Роль өстендә эшләүне ул әле текстны ятлаудан һәм персонажның тышкы кыяфәтен бирүдә генә дип уйлый. Болай уйлаганда, сәхнәдә уйнау җиңел шикелле. Костюм киеп, грим сөртәсең дә, сәхнәгә чыгып, ятлаган сүзләрне сөйлисең. Яшь артистка хәтта кайбер артистларның роль өстендә эшләүнең кыенлыклары турында сөйләүләре дә аңлашылып җитми. Алар аңа юри, кыланып кына сөйлиләр шикелле тоела.

Әмма күзәтүчән табигатьле Фатих репетицияләрдә кайчакта тәҗрибәле артистларның да рольгә керә алмый азаплануларын күрә. Фатих тегеяисә бу актерның роле спектакльдән спектакльгә байый, тәгалләнә баруын һәм, ниһаять, артистның иҗат шатлыгыннан балкып китүен күрә. Ә менә үзенең андый шатлык кичергәне булмый әле. Нишләп болай соң? Бәлки, аның сәбәбе репетицияләргә шулай җиңел караудандыр, үз-үзеңнән читкә китә алмаудадыр?.. Ә Касыйм Шамил, Габдулла Уральский, Зәйни Солтанов, Хәлил Әбҗәлилов кебек артистларны сәхнәдә танып та булмый, алар сәхнәдә бөтенләй башка кешегә әвереләләр. Мәсәлән, Касыйм Шамил «Шәмсекамәр» спектаклендә сукыр суфи ролен башкара. Тамашачылар алдында бер нәрсәгә дә исе китмәгән тыныч йөзле суфи утыра. Әмма кирәк чакта аның йөзе бик тиз хәрәкәткә килә: көйләп дога укыганда хәтта аның битендәге миңе дә селкенә. Касыйм Шамил үз героеның характерын бирүдә бик төгәл детальләр һәм дөрес буяулар таба. Аның образлары бер вакытта да бер-берсен кабатламыйлар. Бу зур художник Фатих Кульбарисовның артист булып формалашуына уңай тәэсир итә. Шулай ук күренекле сәхнә остасы Зәйни Солтанов иҗаты да аңа нык тәэсир итә.

Утызынчы елларда Татар академия театры тирәсендә бик күп талантлы иҗат көчләре туплана. Шулар арасында Хәлил Әбҗәлилов бигрәк тә аерылып тора, һәм ул яшь артист Фатих Кульбарисов иҗатына да билгеле бер йогынты ясый. Әбҗәлилов сәхнәдә үзенең һәрбер хәрәкәтен бик җентекләп уйлый, текстны ул эчке кичереш аша сөйли һәм сәхнәдә гаҗәеп үзенчәлекле образлар тудыра торган артист була. Шуңа күрә дә Фатих аның иҗатын җентекләп өйрәнә, аның иҗат лабораториясенә үтеп керергә омтыла. Аның иҗаты, әнә шулай, иң яхшы сәнгать осталарының бай традициясе йогынтысында үсә.



*Ф. Кульбарисов «Җилкәнсезләр» спектаклендәге Батырхан ролендә.*

«Хуҗа Насретдин» спектакленнән хан сараендагы күренешне искә төшерик. Бу спектакльдә хан ролен Н. Гайнуллин, Хуҗаны Хәлил Әбҗәлилов, ә вәзир ролен, сәләтле артист М. Илдар үлгәннән соң, Фатих Кульбарисовка уйнарга туры килә.

Яшь артист үзенең партнерлары дәрәҗәсендә уйнау өчен күп көч куя. Ул томана һәм тар карашлы Зәйнәгыйны — үз вәзирен табарга омтыла. Әгәр Әбҗәлиловның Хуҗасы һәм Гайнуллинның ханы һәр нәрсәгә бик тиз җавап бирүчән, җитез һәм үткен акыллы кешеләр булса, Кульбарисовның вәзире шуларның киресе. Актер бу образны тулыландыра торган ышандыргыч детальләр һәм буяулар эзли. Хан белән Хуҗа бер-берсен ярты сүздән үк аңлыйлар икән, Зәйнәгый исә аларны аңларга тырыша, ул акыллы баш булып кыланган ахмак кыяфәтендә сурәтләнә. Вакыйгаларга ул соңга калып кына төшенә. Вак нәрсәләргә дә бик зур мәгънә бирә, югары даирә кешеләренә охшарга тырышып, үзен гаҗәеп эре тота. Аның килеш-килбәте бик мәһабәт, ул һичкайчан ашыкмый, сүзен өзеп-өзеп, җай гына сөйли. Шул ук вакытта артист аның тышкы ясалмалыгына басым ясый. Шулай итеп, Кульбарисов бу спектакльне әдәби яктан бик җентекләп эшләнгән тулы канлы образ белән баета.

Фатих Кульбарисов Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр» спектаклендә (режиссеры Ш. Сарымсаков) аеруча зур уңышка ирешә. Вакыйга 1910 елда Казанда бай сәүдәгәр Нуретдин йортында бара. Бик көяз һәм ыспай киенгән хыялый авантюрист Батырхан бу өйдә бик еш була. Баштарак ул аз сүзле, тыйнак табигатьле, нәзакәтле кеше булып күренә. Батырхан үз милләтенең «чәчәк атуы» турында һәм зур акча турында хыяллана. Аның өчен татар пролетариаты һәм татар буржуазиясе дигән төшенчәләр юк, бары тик милләт кенә бар. һәм менә героебызның патриотик тойгыларын сынау сәгате җитә. Беренче бөтендөнья сугышы башлана. Кульбарисов-Батырхан ялтырап торган хәрби мундирдан. Ул үз милләтен яклап сугышка китәчәк, дошманны җиңгәнче көрәшәчәк һәм герой булачак.

Әмма Батырхан өчен көтелмәгән хәлләр булып ала. Илдә Октябрь революциясе җиңә. Батырхан контрреволюцион комитет лидерына әйләнә. Ул үзен милләтнең бөек бер вәкиле итеп саный, урындык һәм өстәлләрдән баррикада корып, мөселманнарны Советларга каршы көрәшкә чакыра. Хәзер инде бу «оста» ораторның элеккеге тыйнак холыклы Батырхан булуына ышануы да кыен. Хәзер ул үзен бөтен милләт башында, хөкүмәт башында хис итә. Милләтне саклау өчен көрәшергә кирәген аңлатырга тырышып, бүлмә буйлап йөренә башлый, әле урындык өстенә менеп баса, әле өстәлгә сикереп менә. Ахырда ул, милләтнең җиңеләчәген исенә төшереп, үз-үзен белештерми үксеп еларга тотына. Артист һәр яңа күренештә үз героеның характерын ача бара, аның принципсызлыгын, рухи яктан бушлыгын фаш итә.

Батырхан — соңгы картиналарда да шундый ук мәсләксез кеше. Менә ябыккан һәм йончыган Батырхан ак армия белән Себергә чигенә. Дөрес, кайвакыт Батырхан яңа авантюра турында да хыяллана, әмма бу хыял аның йөрәгендә пыскып кына кала. Батырхан инде үзенең дан казана алмаганлыгына төшенә. Хәзер ул бер генә нәрсә турында хыяллана: менә йокыга таласы иде дә йөз елдан соң гына уянасы иде. Артист үз героеның эчке бушануын, аның инде тормышка битараф каравын бик дөрес бирә: ул инде бөкрәеп төшкән, йөзе таушалган, тавышы тоныкланган, хәрәкәтләре сүлпәнләнгән.

Спектакльнең финалында, куркынып, тирә-якка карана-карана, Батырхан килеп керә. Аның карашы әле бер нәрсәгә, әле икенчесенә юнәлә. һәр кешене ул үзенең дошманы итеп күрә. Сүзләре бәйләнешсез, буталчык, үзе һаман әле ниндидер зур планнар турында сөйләнә. Батырхан образын иҗат иткәне өчен, 1958 елда Фатих Кульбарисовка Тукай премиясе бирелә.

Кульбарисов иҗат иткән тагын бер образга тукталып үтәсе килә. Моннан берничә ел элек Академия театры Т. Гыйззәтнең «Чаткылар» драмасын сәхнәгә куйды. Фатих анда элеккеге патша армиясе солдаты Тимай ролен башкарды. Баштарак без карышуны белми торган, кыюсыз һәм сүзсез бер крестьянны күрәбез. Әмма илдә революцион хәрәкәтләр көчәю белән бергә, әкренләп Тимай образы да ачыла бара. Артист крестьян характерының үсешен, аның патша палачлары белән көрәшүнең кирәклеген аңлый башлавын зур осталык белән, тамашачыны ышандырырлык итеп бирә алган.

Тимай стихиячел рәвештә массаларның җитәкчесенә әверелә. Моның белән актер яңа кеше тууын күрсәтә һәм бу образ безгә ирексездән Әбҗәлилов иҗат иткән Биктимер образын хәтерләтә. Тимай да, Әбҗәлиловның Биктимере шикелле үк, үсештә, эволюциядә бирелә. Кульбарисов элекке солдатның эчке кичерешләренә зур игътибар бирә. Аның Тимае — олы җанлы, йомшак күңелле кеше. Әмма элекке солдат тигезсезлекне күреп сыкрый. Ул инде изүчеләргә каршы көрәш җиңү белән бетәргә тиеш дип уйлый. Без анда тышка бәреп чыгарга торган яшерен көч барлыгын тоябыз. һәм Тимай ул көчне басып кала алмый. Ул кызының тапланган намусы өчен, изелгән крестьяннар өчен, халык өчен дошманга каршы көрәшкә күтәрелә.

Фатих Кульбарисов сәхнәдә уйлый, үзе башкарган персонаж характерының дөреслеге белән тамашачыны ышандыра белә. «Дошманнар» спектаклендәге Яков Бардин образында ул тирән психологик кичерешләрне бик оста бирә. Зур эчке культуралы булган артист Ф. Кульбарисов җир өстендә үзенең артыклыгын аңлаган кеше хисләрен бик тирән һәм оста итеп ача алган. Яков фабрикантлар арасында кала алмый, шул ук вакытта ул үзен эшчеләрдән аерып торган бусаганы да атлап чыга алмый. Шундый каршылыклар эчендә үз-үзенә урын тапмаган Яков бу дөньяны ташлап китә. Ләкин андый финалга ул тормыш турында бик күп уйлаганнан соң гына адым ясый.

Кульбарисов сәхнәдә һәрвакыт уйлый һәм аның уен белергә тырышу тамашачыны да Кульбарисов геройларын дулкынландырган проблемалар хакында уйланырга мәҗбүр итә. Шуңа күрә дә В. Лавреньтьев пьесасы буенча куелган «Ата хакы — таңре хакы» спектаклендәге коточкыч авыру Максим образы ахырга кадәр серле булып кала. Кульбарисов героеның авыруы турында хәтта үзе дә онытып тора. һәм дөрес эшли. Максимның авыру



*Ф. Кульбарисов — Тимай бабай.*



*«Ата хакы — тәңре хакы». Тамара— Ш. Әсфәндиярова. Максим — Ф. Кульбарисов.*

кеше икәнлеге беленсә, тамашачы аны кызгана башлар иде. Актерның ул геройны кызганыч хәлгә куясы килми. Аның Максимы үзен бик батыр тота, һичкайчан ыңгырашмый. Һәм безгә, залда утыручыларга, аның коточкыч авыру икәнен белгәч, ничектер уңайсыз булып китә. Максим кешеләрне бик ярата, һәркемгә яхшылык эшләргә тырыша. Ул бик ихтирамлы, киң күңелле, көчле ихтыярлы кеше. Шундый кешенең үлүе бик кызганыч. Ләкин шул ук вакытта мондый көчле кешенең замандашы булуыбыз белән без горурланабыз да.

«Инде китмә» спектаклендә Кульбарисов гражданнар сугышында командир булган, зур тормыш сынаулары үткән, хәзер инде олыгайган кеше ролен башкара. Режиссер П. Исәнбәт һәм Ф. Кульбарисов бу геройның характерын ачу өчен гомум кешелеклелек сыйфатларын табарга тырышалар. Күп кенә башка персонажлары шикелле үк, Кульбарисовның бу герое да акыллы, интеллектуаль һәм бик игътибарлы кеше. Ул бик тыйнак, әмма юмордан, киң күңеллелектән дә мәхрүм түгел. Ул тамашачының күңелен үзенә тарта, мәхәббәт казана.

Фатих Кульбарисов тормышта башкалардан аерылып тормый. Хәтта, киресенчә, андый тыйнак артистны сирәк очратасың. Әмма ул кешеләр белән бик тиз аралаша, уртак тел таба, үзен бик гади тота. Ә инде сәхнәдә Кульбарисов бөтенләй икенче кешегә әверелә. Сәхнәдә очраткан саен, без анда нинди дә булса кызыклы яңалык табабыз. Чөнки ул сәхнәдә уйлана, бик мөһим проблемаларны хәл итә. Менә ни өчен аның образлары тормышчан була, менә ни өчен ул безне гел мавыктырып, өметләндереп тора.

Рафаэль Мостафин

# УКУЧЫ ҺӘМ ЯЗУЧЫ

Кешеләрнеке кебек үк, китапларның да үз язмышлары була. Аларның бер ишеләре кулдан-кулга йөри, өзлексез укыла, икенчеләре исә, тузан җыеп, еллар буе китапханә киштәләрендә ята. Әйе, төрле китапны төрле язмыш көтә...

Бала чакта без яхшыны яманнан шактый ансат аера идек. Әгәр китап җитәрлек таушалган, аның битләре тишелеп-ертылып, ә тышы әче камырдан пешергән коймак кебек күперен, майланып беткән булса, бу инде тәгаен гәнә кызыклы китап дигән сүз. Әгәр дә китап, кеше кулына кермичә, ер-яңа килеш куйган урынында торэ икән, андыйны укып азапланырга да кирәкми, барыбер рәтле булмаячак.

Әле хәзер дә, китапханәләрдә булганда, күп тапкырлар яңадан төпләнгән, юка кәгазь белән битләре ябыштырылып беткән китапларны мин аерым бер хөрмәт белән кулга алам. Алар меңнәрчә укучыларга рухи азык һәм эстетик ләззәт биргән, гомерләрен намуслы хезмәт белән уздырган эшчән китаплар...

Әмма ничек белергә: кайсы китап укыла, ә ниндие, файдасыз йөк булып, китапханә киштәләрен биләп ята? Бер Татарстан китап нәшрияты гына да ел саен йөздән артык матур әдәбият китабы чыгара. Аларны нинди язмыш көтә? Еш кына без моны белмибез, дөресен генә әйткәндә, артык кызыксынмыйбыз да. Аның өчен укучыларның фикерен өйрәнергә кирәк. һәм бу эшне системалы төстә бөтен республика күләмендә алып барырга вакыт. Шунсыз безнең тәнкыйть әдәби әсәрләрне бәяләүдә субъективизмнан котыла алмаячак. Матбугат битләрендә булсын, төрле киңәшмәләрдә булсын, бу хакта күп сөйләнде.

Шулай да була бит, тәнкыйтьче: «...фәлән язучының фәлән әсәрен укучы гаять җылы каршылады» яки «бу әсәрне халык аңламый, бу халыкка кирәксез әсәр», дип яза. Әмма нәрсәгә, нинди мәгълүматларга таяна тәнкыйтьче? Еш кына бер нәрсәгә дә таянмый. Әгәр без чын мәгънәсендәге фәнни тәнкыйтьне, төгәл мәгълүматларга нигезләнеп фикер йөртә торган җитди тәнкыйтьне үстерергә телибез икән, статистика мәгълүматларыннан курыкмаска тиешбез. Югыйсә, укучы исеменнән, халык исеменнән эш йөрткән булып, тәнкыйтьченең үз көчсезлеген генә яшереп калуы мөмкин.

Ун еллар элек «Комсомолец Татарии» газетасы үз укучылары арасында бер анкета бастырып таратты. Анда: «Үзегез яраткан бер татар прозаигының һәм бер шагыйрьнең исемен атагыз», дигән сорау да бар иде. Рус укучыларының иң зур күпчелеге Г. Әпсәләмов белән С. Хәким исемнәрен атады [1]. Мондый эш кайбер язучылар арасында ризасызлык уятты. Татарстан язучылар союзында уздырылган җыелышларның берсендә шагыйрь Нәби Дәүли: «Бу сан-

[1] 1971 елда шуңа охшаганрак бер анкета Украина республикасында да уздырылган икән. Күп кенә башка мәсьәләләр белән бергә, социологлар Украинада (рус язучыларыннан тыш) СССР халыклары әдәбиятыннан кайсы язучының аеруча популяр булуын ачыкларга теләгәннәр. Бишенче урынны тагын Г. Әпсәләмов әсәрләре алган.

гатьне мыскыллау. Микъдар күрсәткечләре әдәбиятта житди роль уйный алмый. Мондый анкеталар җәмәгатьчелекне бутый гына»,— дип чыкты. Шундый катгый чыгышлардан соң республикада укучылар фикерен өйрәнү бөтенләй диярлек туктал-ды. Шуның аркасында безнең тәнкыйть объектив характердагы бик мөһим мәгълүматлар чыганагыннан мәхрүм калды.

Республикада укучы фикерен өйрәнү мәсьәләләрен яңадан җанландырып җибәрәсе иде. Бу юлда вакытлы матбугат органнары (шул ук «Казан утлары» журналы) файдалы һәм зур эш башкара алырлар иде. Китапханә эшчеләре дә актив ярдәм итәрләр дип уйлыйм. Менә шул чагында инде без, һич икеләнмичә, үз фикеребезне әйтә алыр идек. Бу китапны халык, чыннан да, яратып укый, аны массовый тираж белән чыгарырга кирәк; менә бусын исә чыгармый торганда да ярый, дияр идек. Хәзергә андый мәсьәләләр күбрәк чама, интуиция белән хәл ителә. Шуның аркасында еш кына тонналарча кәгазь әрәм була, меңнәрчә сум дәүләт акчасы җилгә оча, әлай гына да түгел, хезмәт ияләрен коммунизм рухында тәрбияләү эшенә күпме зыян килә. Кулларында төгәл мәгълүмат булмаганлыктан, тираж билгеләү мәсьәләсендә сәүдә оешмалары да: «Артып калганчы, җитми калсын», дигән принциптан чыгып эш йөртәләр. Китапка теләсә нинди очракта да сатылып бетәрлек иң кечкенә тираж бирергә тырышалар. Нәтиҗәдә меңнәрчә укучылар үзләренә кирәкле, файдалы китапларны күрми калалар. Ә. Кәримуллинның «У истоков татарской книги» исемле монографиясе белән, мәсәлән, нәкъ шундый хәл килеп чыкты. Аны нибары 1000 данә тираж белән чыгаралар. Ә ул ике көндә сатылып бетә, гади укучыларны әйткән дә юк инде, китапны хәтта белгечләр дә алырга өлгерми кала. Кыскасы, укучы фикерен фәнни нигездә, системалы төстә өйрәнү — тормыш үзе көн тәртибенә куйган мәсьәлә. Аны тиешенчә юлга салмый торып, без матбугат эше белән бәйле күп нәрсәләрне уңышлы хәл итә алмаячакбыз.

* * *

Ярар. Бу мәсьәлә уңай хәл ителде, безнең кулда теләсә кайсы авторның ничек укылуын күрсәткән төгәл саннар бар, дип фараз кылыйк. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсен билгеләү өчен бу гына җитәме? Юк, билгеле. Кино сәнгатен өйрәнүчеләр төгәл саннар белән эш итәләр. Һәр яңа фильмны күпме тамашачы карый — теркәлеп барыла. Баксаң, әсәрнең чын әдәби кыйммәте белән аны караган тамашачылар саны арасында зур гына аермалар яшәп килә икән. Юк кына мелодрамалар, өстән-өстән генә эшләнгән җиңелчә комедияләр чын сәнгать югарылыгындагы этаплы фильмнарга караганда күбрәк тамашачы җыялар икән.

Шундыйрак хәлләр турында «Театр» журналы да борчылып яза. Драматургиядә хәтта «кассовый спектакль»ләр дигән махсус термин да барлыкка килгән. Әдәби кыйммәте әллә ни зур булмаган, әмма халыкны нык җәлеп итә торган әсәрләрне шулай атыйлар икән. Димәк, Нәби Дәүлинең сүзләрендә күпмедер хаклык та бар. Укучы фикере һәм әсәрнең чын әдәби кыйммәте, аларның үзара мөнәсәбәте һәрьяклап җентекләп өйрәнүне сорый торган шактый катлаулы мәсьәлә икән. Аны хәл иткәндә бер чиктән икенче чиккә ташланулар булмаска тиеш. Ә бездә алар, кызганычка каршы, бар әле.

**Чиккә ташлануның беренче төре.** Кайбер язучылар: «Мин бит тәнкыйтьче өчен язмыйм, укучы өчен, халык өчен язам. Әгәр әсәрләремне халык укый икән, тәнкыйть ничек кенә сукмәсен, һич исем китми»,— дип акланырга тырышалар. Беренче карашка шактый дөрес күренгән бу фикернең бер йомшак урыны бар: әсәрнең укылу дәрәҗәсе белән аның әдәби кыйммәте арасында һәр очракта да тулы тәңгәллек булмаска мөмкин.

Урта кул беллетристика югарылыгында язылган булсалар да, шпионнар турындагы китапларны ябырылып укыйлар. Әдәби кыйммәте чамалы булган детективлар да миллионлаган тиражлар белән басыла. Шәхси күзәтүләремнән чыгып, шикләнми әйтә алам: бездә, мәсәлән, Ә. Давыдовка караганда, М. Хөсәен шигырьләре күп тапкыр популяррак. Ә бит иҗатының тирәнлеге, сәнгатьчә көче ягыннан Ә. Давыдов бер башка югары тора. Шунда ук икенче бер факт искә төшә. Соңгы елларда бер төркем укучылар Эдуард Асадов дигән урта кул, хәтта баналь бер шагыйрьнең әсәрләрен ябырылып укый башладылар. Шул ук вакытта Л. Мартынов, Е. Винокуров, Д. Самойлов кебек күренекле совет шагыйрьләре укучыларның шактый аз өлешенә мәгълүм. Сәеррәк хәл, билгеле, ләкин нишлисең... Әгәр без сәнгать әсәрләренең кыйм-

мәтен билгеләгәндә популярлыкны төп критерий итеп алабыз икән, ул чагында гаҗәп парадоксаль хәлләр каршында калуыбыз бар.

Китапханә эшчеләренең фикеренә карагында, соңгы еллар татар прозасының иң популяр әсәре Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романы икән. Ләкин, моңа карап, аны сәнгатьчә эшләнеше ягыннан да иң камил әсәр дип буламы? Минемчә, юк. Иң элек әлеге популярлыкның сәбәпләрен ачыкларга тырышып карыйк.

Нурихан Фәттах әсәрен бабаларыбызның борынгы тормышына багышланган беренче тарихи роман дияргә була. Романда Болгар иле мөстәкыйль дәүләт булып яшәгән чордагы вакыйгалар тасвирлана. Халкыбыз тарихының бу чоры турында фәнни чыганаклар аз. Аның каравы, төрле легендалар һәм риваятьләр шактый күп сакланган. Миңа калса, Н. Фәттах күбрәк шул легендаларга таяна, халыкның узганын шактый матурлап, идеаллаштырып һәм шигърилаштереп бирә, нәтиҗәдә шул чорның чын социаль каршылыклары бөтен тирәнлегендә ачылмый кала. Үткәнне, борынгы вакыйгаларны тасвирлаганда, ул күбрәк татар әдәбиятындагы романтик традицияләргә (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы, Курмашиның «Таһир-Зөһрә»се һ. б.) таяна. Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында әлеге роман тикшерелгәндә, чыгыш ясаучыларның берсе бик хаклы рәвештә: «Н. Фәттах авантюрага корылган мәхәббәт романнары эзеннән киткән», дигән иде.

Н. Фәттах романының көчле яклары да, кимчелекләре дә нәкъ шуның белән аңлатыла. Автор вакыйгаларга бай мавыктыргыч сюжет кора алган, шуңа ул укучыны киеренкелектә тота, аны үз артыннан ияртә ала. Минем күп тапкырлар «Әтил суы ака торур» романы әкият шикелле укыла дип сөйләүчеләрне очратканым бар. Бу, күрәсең, дөрес фикердер.

Инде әсәрнең йомшак якларына килгәндә, иң элек шул нәрсә күзгә ташлана: романтик хикәяләү алымы тарихи чынбарлыкны бөтен тирәнлегендә һәм киңлегендә иңләргә мөмкинлек бирмәгән. Романның беренче бүлекләре ифрат төгәл тотып алынган детальләре, җанлы һәм тормышчан образлары, оста тасвирланган тормыш күренешләре белән хәтердә кала. Әмма алга таба романның төп герое үзенең социаль сыйфатларын югалта, теләсә нинди хәлләрдән, теләсә нинди авырлыклардан ансат чыга торган әкият персонажына әйләнә. Шуның аркасында образның социаль яңгырашы нык кими. Тотыш инде аерым бер халыкның, аерым бер кабиләнең вәкиле булудан бигрәк, ниндидер әкият батыры булып кала.

Н. Фәттах яратып, мавыгып укылырлык роман язган. Әмма ул тарихи әсәргә тотынган һәр автор алдына куела торган төп бурычны башкарып чыга алмаган: әсәрдә ерак үткәндәге тормышның тулы һәм тирән панорамасы ачылмый. Шуңа күрә бары укылу факты гына автор файдасына сөйли торган хәлиткеч аргумент була алмый әле.

**Чиккә ташлануның икенче төре.** Кайвакыт, киресенчә, укучы фикере гомумән исәпкә алынмый, аны санга сукмаска, читләтеп узарга тырышу тенденциясе сизелә. Читкә ташлануның икенче төре әнә шуннан гыйбарәт.

С. Рафиковның «Тын елга буенда» романын «Казан утлары» журналында басылганчы укырга туры килмәгән иде. Укыгач, гаҗәпләнеп, аптырап калдым. Романның әдәби сыйфаты түбән, эпизодлары җансыз һәм озыннар, фабуласы таркау, әсәрдә тапталган ситуацияләр, схематик образлар тулып ята. Аңа журналда ни өчен шул кадәр урын бирелгәндер, аңлашылмый. Күрәсең, темасының актуаль булуы, проблемаларының яңалыгы кызыктыргандыр инде. Мин байтак танышларымнан әлеге роман турындагы тәэсирләрен сорап карадым. Алар арасында төрле һөнәр кешеләре: инженерлар, эшчеләр, укытучылар, колхозчылар, төзүчеләр бар иде. Сораган берсе, гаепле кеше сыман, җавап бирергә кыенсынып калды. Берсе дә әсәрне ахырга кадәр укып чыга алмаган икән. Нигә, дип сорыйм. Күңелсез, диләр. Күңелсез... Шушы бер сүз теманың актуальлеген дә, проблемаларның мөһимлеген дә, авторның изге максат белән көнтөн тырышып утыруларын да — һәммәсен юкка чыгара. Чыннан да, әгәр атмый икән, мылтыкның юан көпшәле булуыннан ни файда? һәм әгәр тәмсез икән, ашарга ярамый икән, ризыкның файдалы витаминнарга бай булуыннан ни куаныч?

Илленче еллар ахырында драматургия мәсьәләләренә багышланган кайбер мәкаләләрдә драматург тамашачы җырын җырламаска тиеш, ул аларны тәрбияләргә, үстерергә тиеш, кебек фикерләр күп кабатланды. Бирелә дереслек бар иде үзе. Тик аның практик нәтиҗәсе генә әллә ни шәп булмады. Кайбер драматурглар тамашачы фикере белән гомуман санашмый башладылар. Тамашачы исә, үз чиратында,

театрга йөрүдән туктады. Күптән түгел миңа бер театр белгече белән бәхәсләшергә туры килде. «Х. Вахит «кассовый» әйберләр язарга сәләтле драматург кына бит ул. А. Гыйләҗев менә, чыннан да, зур, актуаль мәсьәләләр күтәрә. Ләкин тамашачы аның әсәрләренең тирәнлеген аңламый, шуңа да әсәрләре озак бармый», ди бу. Һәрберсе үзенчә кызыклы булган бу ике драматургны сөзештерү кирәксез эш, минемчә. Әгәр Х. Вахит сәхнә законнарын шәп белә, комедиячел ситуацияләр таба, тамашачыны киеренке хәлдә тота, үз артыннан ияртә ала икән, бу начар сыйфатмыни? Инде еш кына аның әсәрләренә тормышчан тирәнлек, зур иҗтимагый мәсьәләләр күтәрү, безнең чынбарлыкның яңа, кызыклы якларын чагылдыру җитми икән, бусы бөтенләй башка мәсьәлә. Моның өчен аны тәнкыйтьләргә кирәк. А. Гыйләҗев, чыннан да, һәр әсәрендә зур мәсьәләләр кузгатырга омтыла, аның әсәрләрендә яңа фикер була. Ләкин аңа күтәргән мәсьәләләрен сәхнә телендә тамашачыга җиткерерлек, тамашачының игътибарын тотып торырлык осталык җитми. Бусы, драматург буларак, А. Гыйләҗевнең көчсез ягы. Дөрес, әсәрдән-әсәргә ул бу кимчелеген җиңә килә. Әгәр без совет драматургиясенең иң яхшы әсәрләренә, Н. Погодин һәм А. Арбузов, К. Тинчурин һәм Т. Гыйззәт пьесаларына мөрәҗәгать итсәк, тирән фикерләрнең тамашачыга зур осталык белән җиткерелүен дә күрербез. Димәк, кызыклы, яңа эчтәлек үзенә лаек яңа формадан башка яши алмый. Драматург шуңар омтылырга тиеш.

Спектакль — тамашачы өчен, китап — укучы өчен чыгарыла. Мылтык «атмый» икән, язучының көче файдасызга сарыф ителгән дигән сүз. Әсәрнең популярлыгын, укылу дәрәҗәсен бердәнбер критерий итеп алырга ярамый, дидек. Әмма аның белән бөтенләй хисаплашмау шулай ук дөрес булмас. Хәтта укучылар массасының фикере зур, авторитетлы белгечләрнең фикерө белән туры килмәгән очракларда да уйларга кирәк: һәрвакытта да әлеге **авторитетлар** гына хаклымы икән әле?

Моннан берничә еллар элек Татарстан язучылары союзы каршындагы проза секциясе утырышында Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» исемле яңа романы тикшерелгән иде. (Утырышта сөйләнгән сүзләрнең кыскача эчтәлеге «Казан утлары» журналында басылды, теләгән кеше таныша ала.) Тикшерүдә күренекле прозаиклар һәм тәнкыйтьчеләр катнашты. Чыгыш ясаучыларның күбесе романдагы җитди кимчелекләр турында сөйләде. Әсәрдәге аерым күренешләрнең артык төче, сентименталь характерда булуын әйттеләр, Гөлшәһидә образының идеаллаштырылып бирелүен билгеләп үттеләр, романдагы күп кенә башка кимчелекләрне күрсәттеләр. Мин дә чыгыш ясадым, шулай ук күбрәк тәнкыйть иттем. Ул фикерләремнән мин әле дә кире кайтырга җыенмыйм. Әмма аннан бирле узган еллар хәзер безне бу әсәргә бераз башкарак күзлектән карарга мәҗбүр итә. Соңгы 6—7 ел эчендә «Ак чәчәкләр» әдәбиятыбызның иң популяр әсәрләренең берсенә әйләнде. Ул башка телләргә тәрҗемә ителде, миллионнарча тираж белән «Роман-газета» битләрендә басылды. Әсәр әле һаман яратып укыла, аның буенча әдәби бәхәсләр, укучылар конференцияләре уздырыла, «Гөлшәһидә җыры» халыкның иң яраткан җырына әйләнде. ЗАГС хезмәткәрләренең сөйләвенә караганда, яңа туган кызларга Гөлшәһидә исемен куярга теләүче ата-аналар саны арткannan-арта бара, ди.

Роман нигә бу хәтле популяр булып китте соң?.. Мин еш кына шул турыда уйланам, әлеге популярлыкның сәбәпләрен эзлим. Хикмәт, күрәсең, безнең үз зәвыкларыбыз белән киң катлау укучылар массасының зәвыклары арасындагы аермададыр. Г. Әпсәләмов (бу хакта аның үзенең дә берничә тапкыр ачыктан-ачык язганы бар) иҗат практикасында аңлы рәвештә үткенәйтү алымыннан файдалана, кешеләрдәге уңай якларны да, начар сыйфатларны да юри күпертеп, үстереп сурәтли. Тискәре геройларны ул бөтен әшәкелеге, гариплеге, ямьсезлеге белән бирә. Уңайны исә, очраклы, йомшаграк сыйфатлардан чистартып, пьедесталга бастыра.

Реалистик сәнгать әсәрләренә куела торган таләпләрдән чыгып, гадәттә, без моны кимчелек дип бәялибез. Ләкин һәр очракта мәсьәләгә конкрет төстә якын килә белү кирәк. Сүз Г. Әпсәләмов әсәрләре турында барганда, кешедәге яхшы һәм начар якларны юри үткенәйтеп сурәтләүне язучының иҗат алымына хас бер үзенчәлек дип карарга тиеш булабыз. Мондый алым үзенең тамырлары белән татар әдәбиятының романтик традицияләренә барып тоташа, димәк ки, аның яшәргә шулай ук хакы бар.

В. Маяковский, яхшы һәм төрле шагыйрьләр күбрәк булсын, дигән. Без бу җөмләнең беренче яртысын ешрак кабатлыйбыз,

ә икенче яртысы турында азрак уйланабыз. Әйе, язучылар төрле дә, яхшы да булырга тиешләр. Чөнки укучы да төрле бит. Кайбер укучыларның зәвыгын ошатмаска, тәнкыйть итәргә мөмкин, әмма аның белән санашмаска хакыбыз юк. Шул ук вакытта «Ак чәчәкләр» романын, Г. Мөхәммәдова кебек («Казан утлары» журналы. 1971 ел. 12 сан), тоташ мактау да урынсыз эш. Әйе, ул популяр роман, укучылар аны яратып укый. Менә шуңа күрә дә, Г. Әпсәләмов иҗат алымының яшәргә хаклы булуын раслау белән бергә, без аның кимчелекләрен дә күрсәтергә бурычлы.

Совет кешеләренең гүзәл образларын тасвирлаулары, түбән җанлы, вак кешеләрне хурлык баганасына терәүләре белән, аның романнары, һичшиксез, файдалы эш башкаралар. Ләкин тормыш гаять катлаулы, аны Әпсәләмов әсәрләрендәге калыпларга гына сыйдырып булмый. Әшәкелек аяк астында күренеп ятмый, начар кешеләр чын йөзләрен күрсәтмәскә, яшеренеп калырга тырышалар. Безнең көннәрнең уңай геройлары да пьедесталда гына басып тормый. Алар безнең кебек үк кешеләр, безнең арада, безнең белән яшиләр. Яхшыны начардан аеру өчен тормышны ныклап өйрәнергә, кешеләрне якыннан белергә кирәк. Әгәр без укучыларны чыннан да хөрмәт итәбез, аларның зәвыкларын тәрбияләргә телибез икән, шуларның һәммәсе турында да укучыларга сөйләргә тиешбез. Әмма бу эшне саклык белән, партия өйрәткәнчә, такт белән эшләргә кирәк. Г. Әпсәләмоаның «Ак чәчәкләр» романына мин аеруча киң тукталдым, чөнки бу роман һаман укыла, басыла тора, бүгенге әдәби хәрәкәттә катнаша, кыскасы, актив тормыш белән яши. Шулай булгач, безнең бу әсәр турындагы элекке фикерләребез шул көенчә, бернинди үзгәрешсез кала алмый, яңартылуга, камилләштерүгә мохтаҗлар.

Укучы, тамашачы фикере белән һичшиксез санашырга кирәк дигән тезисны раслау өчен, тагын бер мисал китерәсем килә. Өч ел элек «Ленфильм» киностудиясе Казанда «Моабит дәфтәре» исемле нәфис фильмның премьерасын оештырды. Без бу фильмны, Мусаның якты образын экранга чыгуын, шул хәтле көткән идек, фильмның йомшак һәм җитешсез якларына күз йомарга, аларны гафу итәргә дә әзер идек. Шуның тәэсире булгандыр, безнең матбугат фильмны бик зурлап каршы алды, аңа ифрат зур реклама оештырды. Газета битләрендә картинага әллә ни кадәр урын бирелде, фильм турында дистәләрчә уңай рецензия басылды (шулар арасында минеке дә бар иде). Дөресен әйтергә кирәк, «Моабит дәфтәре» болай зәвык белән эшләнгән фильм иде. Ләкин күп кенә уңай яклары һәм өстенлекләре булуга да карамастан, фильмны тамашачы кабул итмәде, күп тә тормый, ул экраннардан төште. Күрәсең, герәшче шагыйрьнең халык күңелендә туган мәхәббәт образы фильмдагыдан үзгәрәк, көчлерәк, өстенрәк булган. Безнең мактап язган рецензияләребез дә, артист П. Черновның шәп уены да хәлне үзгәртә алмады. Хәзер менә, киресенчә, без үзебез үзгәрергә, фильм турындагы элекке карашларыбыз турында тагын бер кат ныклап уйланырга тиешбез. Хакыйкать шуны таләп итә. Әле Н. Г. Чернышевский ук, иң гадел һәм туры судья — вакыт, һәм без карашларыбызны аңа карап дөресли барырга тиеш, диган иде. Бик урынлы сүзләр. Тормышта шулай да була, кайвакыт сыек, шактый йомшак эшләнгән очраклы әсәрләр вакытлыча бик популяр булып китә. Ләкин вакыт сынавы аша, халык сынавы аша бары чын сәнгать әсәрләре генә уза ала. Татар совет әдәбиятының вакыт сынавын уңышлы узып, халыкның мәңгелек мәхәббәтен казанган әсәрләре аз түгел. Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» һәм М. Гафуриның «Кара йөзләр»е, Ш. Камалның «Акчарлаклар»ы һәм М. Әмирнең «Агыйдел»е, К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е һәм М. Файзинең «Галиябану»ы, һ. Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» һәм «Мокамае», М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре» һәм Ф. Кәримнең фронт лирикасы, Х. Туфан һәм С. Хәким шигырьләре, Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» һәм Г. Бәшировның «Намус»ы... Саный китсәң, күп алар. Ул әсәрләрнең һәркайсы халкыбызның тирән мәхәббәтен казанды, һәм аларның шундый зур популярлыгы чын әдәби кыйммәтләре белән аз гына да каршылыкка керми.

* * *

...Шул рәвешчә, бер чиктән икенчесенә ташланмый гына, без укучы фикерен өйрәнергә һәм аңа сак караш булдырырга тиеш. Бу бик мөһим мәсьәлә. Совет власте елларында без әдәбиятны аңлый һәм бәяли белә торган укучылар массасы тәрбияләдек. Мондый укучы башка бер илдә дә

юк. Төрле киңәшмәләр һәм съездлар вакытында миңа чит ил язучылары белән очрашырга туры килгәне бар. Безнең илдә әдәбиятка, язучыларга булган зур игътибарны күреп, алар гаҗәпләнәләр. Чит ил кешеләре Россияне бер дә юкка гына «иң күп китап укучы ил» дип йөртмиләр бит.

1967 елда мин ГДРда булып кайттым. Шулай бервакыт Берлинда немец язучыларының мәҗлесендә булырга туры килде. Сүз иярә сүз чыгып, әңгәмә куерып китте. Әңгәмә барышында мин шуны аңладым, алар татар халкы, аның үткәне һәм бүгенгесе турында бик аз беләләр икән. Арадан берсе татар халкының грамоталылык дәрәҗәсе ничә процент дип сорады. Мин бездә бу мәсьәлә күптән хәл ителде, укый-яза белмәгән кеше бөтенләй юк, дидем. Фикеремне дәлилләү өчен, бездәге китаплар, газета-журналлар, аларның тиражлары турында сөйләп киттем. «Казан утлары» исемле айлык әдәби журнал 57 мең данә тираж (хәзер аның тиражы 87 меңнән артып китте) белән чыга дигәч, алар гаҗәпләнеп, бер-берсенә карашып куйдылар. 5 миллион халык арасында калын әдәби журналның шундый зур тираж белән таралуына һич ышанасылары килмәде. (Аларның «Яңа немец әдәбияты» исемле, безнеке шикелле үк журналлары ул чагында 17 мең данә тираж белән чыга иде. Ә ГДРда 17 миллион халык яши.) Бездәге китапларның, бигрәк тә шигырь китапларының тиражы шулай ук алардагыдан зуррак булып чыкты. Татарстан районнарында уздырыла торган әдәбият атналыклары, колхозларда, совхозларда, культура сарайларында, клубларда, уку йортларында үткәрелә торган очрашулар, конференцияләр турында сөйләгәч, арадан берсе:

— Андый укучы өчен тырышсаң да ярый,— дип куйды.

Кызганычка каршы, без үзебез менә шушы гади, карап торышка бик гадәти хакыйкатьне бәяләп бетермибез әле. Язучыларны ярата һәм ихтирам итә торган, аларның һәр язганын укып бара торган укучыларга ашык-пошык эшләнгән, түбән сыйфатлы әсәрләр тәкъдим итү — зур хиянәть. СССР Язучылар союзының әдәбият-сәнгать тәнкыйте мәсьәләләренә багышлап уздырылган пленумында тәнкыйтьче язучыдан зур көч куеп эшләүне таләп итәргә тиеш диелде. Безнең тәнкыйтьчеләргә еш кына әнә шундый таләпчәнлек җитми.

Аннан соң, укучыларның таләп һәм зәвыклары да өзлексез үзгәреп тора. Хәзер инде үз әдәбиятыннан башканы белми торган укучы азаеп бара. Русча грамоталылыкның киң таралуы, рус һәм дөнья әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә итү һәм, ниһаять, радио һәм телевидениенең киң җәелүе шуңа китерде ки, татар укучысының аң-белеме, культура дәрәҗәсе бик нык күтәрелде.

Шулай бер вакыт Татарстанның иң ерактагы авылларының берсендә олы яшьтәге шагыйрьнең иҗатына багышланган кичәдә катнашырга туры килде. Ул үзенең иң гади укучыларга исәп тотып язылган юмористик шигырьләрен укыды. Ә укучы, баксаң, ул уйлаганча ук гади түгел икән инде. Дөрес, болай аны тыңладылар, ләкин искитмичә тыңладылар, әдәплелек йөзеннән генә тик утырдылар. Шул чагында миңа ул шагыйрь бик кызганыч тоелды. Халыкка нәрсә дә ярый дип уйлап йөреп, күпме ялгышкан ул.

Әйе, укучы үзгәрә, аның зәвыгы үсә, дөньяга, әдәбиятка карашы да киңәя бара. Әле кичә генә кайбер тәнкыйтьчеләр Әмирхан Еники «камерный» язучы, ул бер төркем интеллигенция өчен генә яза дип йөриләр иде. Хәзер аның язганнары иң популяр әсәрләр рәтендә йөри. Әле кайчан гына бер төркем яшьләрне формализм белән мавыгуда, халыкка аңлашылмый торган шигырьләр язуда гаепли идек. Бүген исә шундый язучылардан Р. Фәйзуллин, Р. Харисов, Р. Гатауллиннар яшьләрнең яраткан шагыйрьләренә әйләнеп баралар.

Әдәбиятның киләчәге өчен кайгыртканда, без укучылар белән бәйләнеш мәсьәләсен истән чыгара алмыйбыз. Коммунистлар партиясе безне гел искәртеп килә: сәнгатьнең илһам чыганагы, иҗади уңышларның сере — халык тормышы белән тыгыз бәйләнештә.

Туфан Миңнуллин

# БЕЗ «ТЕАТР» УЙНЫЙБЫЗМЫ?

Моннан ике ел элек Татарстан язучылар союзы балалар әдәбиятына багышлап махсус җыелыш уздырган иде. Ул җыелышта, башка жанрлар белән берраттан, балалар драматургиясе турында да сүз барды. Кызганычка каршы, авыз тутырып сөйләрлек уңышларыбыз юк иде, күбрәк зарланырга туры килде. Балалар драматургиясенә күз салсак, бүген дә хәлнең әллә ни үзгәрмәгәнен күрәбез. Ул һаман да элеккеге урынында — бүтән жанрлар әдәбият мәйданында туп типкәндә, читтәнрәк карап тора.

Нилектән алай? Сәбәбе нидә?

Бу кечкенә мәкаләдә мин балалар драматургиясенә төпле диагноз куярга, аңа менә шундый дарулар эчертегез, дип рецепт язарга җыенмыйм. Тик шушы жанрга хөрмәтле бер кеше буларак, эчне пошырып йөргән кайбер мәсьәләләргә генә тукталып узарга телим. Сүзне саннардан башлыйк. Соңгы алты-җиде ел эчендә унбишләп авторның балаларга адресланган илледән драма әсәре дөнья күргән. Карап торышка бу аз түгел. Әмма шул илле исәбенә бер пәрдәле пьесалар, скетчлар, интермедияләр дә кергәнен исәпкә алсак, әллә ни күп тә түгел. Кызганычка каршы, шул азның да шактые пешеп җитмәгән, түбән сыйфатлы әсәрләр. Алар бүгенге көн таләпләренә җавап бирә алмыйлар.

Төп җитешсезлекләрнең берсе, минемчә, бүгенге балаларга, замана балаларына әйтерлек яңа сүзебез, үз сүзебез булмауда, тема тарлыгыннан котыла алмауда. Еллар буе бер почмакта биибез, иске көйгә биибез. Шуның нәтиҗәсендә бертөсле — игезәк пьесалар туа, теләсәк-теләмәсәк тә штамп барлыкка килә. Бүгенге балалар драматургиясендә иң киң таралган темаларның берсе — дуслык темасы. Тегеләй дә әйләндерәбез дуслыкны, болай да әйләндерәбез. Хәлбуки, әллә кайчан әйтелгән фикерләрне кабатлаудан, вәгазь укудан уза алмыйбыз. Билгеле, өлкәннәр әдәбиятында мәхәббәт мәңгелек тема булган кебек, балалар әдәбиятында дуслык та мәңгелек темаларның берсе. Ләкин без аны киңәйтергә, фәлсәфи югарылыкка күтәрергә омтылмыйбыз. Заман үзгәрә, кешеләр үзгәрә дибез, ләкин әлеге кешеләр исәбенә ни өчендер балаларны кертергә онытабыз. Алар да үзгәрә бит, картлар әйтмешли, җиде класс бетереп туалар. Безнең олы яшьтәге мәктәп балаларына багышланган пьесаларыбызда исә дүрт-биш яшьлек балалар арасында булә торган дуслык сурәтләнә: «Уенчык ватканыңны дустыңа сылтама», «дустыңның начар гадәтен яшереп калдырма», кебекләр. Шулай ук «хезмәт сөй, намуслы, вөҗданлы, тәртипле, тыйнак бул, алдашма» дигән вәгазьләр дә вакланып бирелә, пьесадан пьесага күчеп йөри. Әгәр Шамил Рәкыйповның Фаикъ исемле звено вожатые: «Пионер ул намуслы була. Һәрвакыт, һәр җирдә», дип әйтә икән, Идият Абдулловның укытучысы:

«Колхоз милкенә кул салу, ялганлау, гаебеңне яшерү — бик начар эш», ди. Миргалим Харисовның дружина советы председателе шуңа өстәп: «Данны урлап алып кына булмый. Бу — пионер намусына тап төшерә», дип куя. Боларны бит хәзер пионерлар гына түгел, октябрятлар да белә. Нигә шушы тапталган хакыйкатьне әйтер өчен генә пьеса язарга? Ныклап уйлаганда, бәлки, шул ук фикерләрне икенче төрлерәк, бүгенге укучының йөрәгә кабул итәрлек, әдәбирәк иттереп әйтеп буладыр. Әнә Әхсән Баянов үзенең «Васыять» исемле драматик поэмасында андый юлны тапкан бит. Антыңа турылыклы бул, дип коры сүз кычкырттырмаган, шул фикерне образлы итеп әйтә алган. Һәм шуңа күрә әсәр истә кала. Хәер, анда да пионер вожатые килеп чыгып: «Куркакларга, ялагайга — иң зур хурлык!» — дип әйтмичә түзә алмый. Күрәсең, кирәксә-кирәкмәсә дә лозунг ташлау, күптән билгеле нәрсәләрне кат-кат туку безнең каныбызга сеңгән. Тырышып-тырмашып шуны балаларга йоктырабыз. Нәтиҗәдә, редакцияләргә балалар кулы белән язылган җансыз пьесалар, шигырьләр һәм хикәяләр агыла. Димәк, тема сайлаганда, укучыларга таныш, тапталган темалардан качарга, аларның «башын бутарлык», уйландыра торганнарын табарга тырышырга кирәктер. Иске темаларга тотынган очракта да аны ачып бирүнең яңа формаларын эзләргәдер. Ул укытучының: «Гали, класста тәртип бозарга ярамый», дип әйтүеннән бераз гына аерылып торсын иде.

Бер уңайдан, балалар драматургиясендә «наивность» дигән нәрсәгә тукталып үтмәкче булам. «Наивность»ны ничегрәк тәрҗемә итәргә белмәдем. «Русча-татарча сүзлек»тә күп төрле мәгънәсе аңлатылган. Иң ошаганы «балаларча фикер йөртү» дигәне булса да, ул да мин теләгән мәгънәне бирми. Мисал китереп карыйк. Шамил Рәкыйповның шактый ук уңышлы язылган «Шамакай килә» пьесасында хәйлә, мәкер, әләк, көнчелек, иренчәк дигән әшәке көчләр кешеләрне аздыру турында хыялланалар. Хаттабыч картны алдап, куәт җыеп алалар да эшкә тотыналар. Һәм зуп-зур чит ил туристларын бөгеп салалар: талаштыралар, көнләштерәләр, сугыштыралар. Ә бәп-бәләкәй совет малайларына якын да килә алмыйлар. Югарыда әйтелгәнчә, туганда ук җиде класс бетереп туган балаларга капитализмның череклеген шушы рәвешчә аңлатуны «наивность» дими ни диярсең. Яки Госман ага Бакировның «Безнең матуркайлар» дигән өч пәрдәлек пьесасын алыйк. Пионерлар сыер фермасын шефлыкка алырга булалар. Артта өстерәлгән ферма, алар килеп булышуга, алга сикерә, ал да гөл була. Кире Хикмәтулла шунда ук уңай якка борыла. Ялкау кыз Фәүзия ялкаулыгыннан ваз кичә, тәүбә итә.

Пьеса дәвам итә, төзәлеп барган Фәүзия тагын ялгыша: сыерларын ташлап шәһәргә китәргә җыена, чемоданнарын күтәреп машинага утыра. Шул чак пионерлар йөгереп килеп: «Син сава торган сыерның шундый матур бозавы бар, шуны ничек ташлап китәсең», дип әйтәләр. Фәүзия эри дә төшә. Бозавым белән саубуллашып чыгыйм дип фермага кереп китә дә шуннан торып кала. Шәһәр турында уйламый да. Билгеле, мондый «наивность»ка укучы ышанмый. Хәер, автор да бит укучыга ышанмый, аны бишек баласына саный, катлаулырак итеп язсам аңламас, дип курка. Мондый мисалларны башка пьесалардан да шактый китерергә мөмкин. Кем белә, бәлки, шушы «наивность», укучыңа ышанмау безнең темаларны арзанайта, ваклыйдыр да. Ләкин драматурглар онытмасыннар иде: балалар бездән акыллырак. Бу — күптән билгеле хакыйкать.

Әдәби осталык турында берничә сүз. Әдәби осталык дигәндә мин драматургның осталыгын күз алдында тотам. Әллә миңа гына шулай тоела, нигәдер кайберәүләр өчен пьеса язу бездә җиңел эшкә санала. Ни өчендер алар ике, өч кешене (балалар өчен язганда — аю белән бүрене) очраштырып сөйләштерүне пьеса язу дип уйлыйлар. Һәр жанрның кебек, драма әсәренең дә үзенчәлеге бар. Әмма кайбер иптәшләр шушы аксиоманы онытып җибәрәләр бугай. Иң өстә яткан мисалны алыйк. Әгәр язылачак әсәреңне пьеса дип атыйсың икән, син сәхнәнең элементар законнарын белергә тиешсең. «Пионер сәхнәсе»нең өченче санында Рифкат Исмәгыйловның «Еллар үткәч...» исемле бәләкәй пьесасы басылган. Сигез битле бу әйбер ике күренеш һәм прологтан тора. Ниләр генә юк анда?!. Прологта: «Авыл, янган һәм җимерелгән йортлар тирәсендә окоплар», «фашистлар оборонасы». Күренешләрдә: болдырлы өй, рәшәткәле алма бакчасы. Прологтагы 19 яшьлек солдат күренешләрдә өлкән яшьтәге абзыйга әйләнә. Уннан артык катнашучы. Сәхнәдә ничек уйнамак кирәк бу әйберне? Һич башыма сыйдыра алмыйм. Яки балалар өчен күп әйберләр язган, калын-калын китаплар чыгарган Җәвад Тәр-

җемановның «Шуктуган»ын тикшереп карыйк.

Әкият-пьеса менә диган темага язылган. Яшьтән үк эшләргә өйрән, картайгач җайсыз ул, олылар җилкәсен кимермә, диелгән. Бер уңайдан урмандагы кош-корт, җәнлекләрнең гадәтләре дә язылган. Димәк, укучы табигать белән дә таныша бара. Менә шушы фикерләрне, авторның түбәндәге искәрмәсе буенча, тамашачыга җиткерергә кирәк: «Җәй айларында пионерлагерьларда бу пьесаны турыдан-туры урман аланлыгында күрсәтергә була. Мәктәп һәм авыл радиоузелы аша тапшырырга да мөмкин. Ул чакта бернинди декорация кирәк булмаячак». Ә, минемчә, җәй айларында да, кыш айларында да күрсәтергә мөмкин түгел аны. Чөнки ул драма әсәре түгел, анда драма элементлары юк. Беренчедән, әсәр дилбегә буе озын. Автор җәнлекләр турындагы мәгълүматларны җыйган да, диалогларга бүлгәләп, драма әсәре дип укучы алдына салган. Аны: «Менә монысын үзем язып алдым — шигъри калыпка салдым», дип тәмамлаган. Ләкин һәрбер шигъри калыпка сыйган әйбер драматургия калыбына сыймый бит. Ыштыр аякка чолгар, шарф муенга урар өчен. Һәм пьесаны урамда да, урманда да уйнап булмый. Аның өчен бары тик сәхнә кирәк. Радиоузел аша тапшырып буладыр, бәлки. Ләкин монысы инде башка жанр. Сәхнәне белмәү, аңламау күп пьесалардагы диалогларда аеруча нык сизелә. Алар — җансызлар, корылар. Шуңа күрә әсәрләрдә әйтелгән акыллы сүзләр дә үзләренең вазифаларын үти алмыйлар, истә калмыйлар. Хәер, җансыз диалоглар характерларның төссез булулары нәтиҗәсендә туа. Кайбер пьесаларда Галине Галиядән, аюны мәчедән аеруы шактый читен. Әйсә еш кына әзер характерлар белән эш итәбез. Ялкау малайлар бертөсле, мактанчыклар бертөсле. Алдан ук киштәләргә тезеп куелган. Шуннан алабыз да пьесаларга чәпибез. Мәсәлән, Нур Гайсинның Мохтәры өенә кайтып керә, портфелен диванга атып бәрә, аннан пальтосын һәм бүреген салып диванга ташлый да әбисенә: «Әби, алып куй», ди. Җәвад Тәрҗемановның Әмире тышкы ишектән керә, сумкасын диванга ыргыта, аның өстенә пальтосын һәм баш киемен ташлый да: «Әби, аш әзерме?» ди. Миргалим Харисовның Фәрданәсе бүлмәгә керә дә сумкасын атып бәрә. (Бу әсәрләрне укыгач, исемә төште: Туфан Миңнуллинның үз Азаты да китапларын атып бәрә икән.) Гөлшат Зәйнашеваның Тансыгы бераз икенче төрлерәк — ул портфелен аркасына аскан, тик фуражкасын футбол тубы итеп тибеп уйный. Болары, беләсездер, тискәре геройлар.

Уңайлары нишли? Ул хакта алданрак әйтеп үттем. Беренчедән, аларның берсе дә диярлек гади пионер түгел. Кайсы пионер вожатые, кайсы звено вожатые, кайсы отряд советы председателе... Бер-берләренә шундый охшаганнар, билләһи, бер кеше язса да бу чаклы ук булмас иде. Тискәре геройлар, бер-берләренә охшатып, бүрек ыргытышалар. Вожатыйлар, алай ярамый, дип әйтәләр дә тискәре геройлар бердәм елап җибәрәләр яисә «больше алай эшләмим», дип тәүбә итәләр. Әдәби ел йомгакарының берсендә Роберт Батуллин бу хакта сөйләгән иде. Ул анда проза жанрына анализ ясады. Димәк, бу чирдән бүтән жанрлар да интегә икән.

Кайбер очракларда без, язучы буларак, нәни укучыларыбыз алдында җаваплылык хисен онытып җибәрәбез. Начар әсәр бастырып, тәрбия эшенә никадәр зыян китерүебезне аңлап җиткермибез. Нур Гайсин, мәсәлән, балаларга өчәр пәрдәле ике драма әсәре биреп ялгышкан. «Ялгышу» һәм «Югалган макет» пьесалары җиңел кулдан язылганнар, бер-берсеннән исемнәре белән генә аерылып торалар, эчпошыргыч озыннар. Идият Абдуловның «Алма вакыйгасы» да, вакыйга булмау сәбәпле, ун юлда бетәргә тиеш иде, ә ул, ни өчендер, бер пәрдәгә сузылган. Заманында балаларга яхшы-яхшы пьесалар бүләк иткән Абдулла Әхмәткә дә, бәлки, «Сагыну» исемле драмасын бастырырга кирәкмәс иде. Һәрберебез өчен билгеле хакыйкать: балалар өчен язылган әсәрләр тормышчан булырга тиеш. Бала күңеле ясалмалылыкны кабул итми. «Ярамаганмы почык борыннарга», дип язу җинаять.

Артык мавыгып китеп, җитешмәгән якларга күбрәк тукталдым бугай. Кайбер иптәшләр: илле әсәр арасыннан бер дә рәтле-юньле нәрсә таба алмадыңмыни, диярләр. Бар, билгеле. Нәкый Исәнбәтнең «Былтыр кысты» диган әкият-пьесасы оста язылуы белән аерылып тора. Роберт Батуллинның, Гөлшат Зәйнашеваның драма әсәрләре уңышлы. Гәрәй Рәхим «Тигезсезләр илендә» исемле кызыклы гына әкият иҗат иткән. Ләкин болар гына аз, бик аз.

Нишләргә соң? Эшләр хөрти, хәлләр мөшкел, дип елап утырыргамы? Әллә күрмәмешкә, белмәмешкә салынып, булганы белән канәгатьләнеп яши бирергәме?

Балалар өчен махсус чыга торган «Пионер сәхнәсе»н тәрҗемә әсәрләре яки өлкәннәр өчен язылган пьесалар белән тутырыргамы? Әллә балалар драматургиясен мәйданга чыгара алырлык көч-куәт табылырмы? Минемчә, безнең язучыларыбыз, балалар театры белән җитәкчелек итүче иптәшләр, газета-журнал, нәшрият редакцияләре бердәм алынса, шиктый эш эшләп булыр иде. Әлегә, дөресен әйтергә кирәк, балалар өчен драма әсәрләренең куктән төшкәнен көтеп ятабыз.

Казанда курчак театры яши. Балалар өчен бердәнбер профессиональ театр ул. Ләкин бу театр татар телендә ике елга нибары бер спектакль чыгара. Чагыштыру өчен, өлкәннәр театрына күз салыйк. Дүрт дәүләт театры елына оригиналь әсәрләр буенча эшләнгән җиде-сигез спектакль әзерли. Балалар өлкәннәрдән әзмени бездә? Аларның эстетик зәвыгын тәрбияләү мәһим чара түгелмени? Күп төрле җыелышларда театр, драматургия турында сүзләр сөйләнә, карарлар чыга. Ә соңгы алты-җиде елда мин балалар театры мәсьәләсе күтәрелгәнне хәтерләмим. Ул хакта кем борчылырга тиеш? Янә килеп, өлкәннәр театры ара-тирә булса да балалар өчен спектакльләр чыгарса, начар булыр идемени! Киләчәктә үзләренә зәвыклы тамашачы әзерләрләр иде. Андый чакта, гадәттә, куярлык пьесалар юк дигән аклану ишетәсең. Юк дип әйтү җиңел, булдыру турында уйларга иде. Драматургияне бары тик театр гына тудыра. Ниһаять, телевизор экраннарына карасак, анда да балалар өчен татар телендәге тапшырулар еш кына информацияләргә кайтып кала. Анда-санда әкият укыла укылуын. Ләкин йөз меңләгән нәни тамашачы анда-сандагыга канәгать түгел. Мәсьәлә шулай ук телевидениедән күрсәтерлек драма әсәрләре булмауга кайтып кала. Һәрхәлдә, шулай диләр.

Җыеп әйткәндә, олылар «театр уйнаганда» балаларыбыз «боз ялый». Бик уйнарлар иде — дәрт тә бар, дәрман белән фәрман юк.

# ЗАМАН РУХЫНДА

Әдәбият һәм тормыш. Аларның үзара бәйләнеше, бер-берсенә йогынты ясавы — әдәби тәнкыйтьнең игътибар үзәгендә торган төп проблема. Соңгы вакытта тәнкыйтькә игътибар артты, тәнкыйть турында партия съезды трибунасыннан бик мөһим сүзләр әйтелде. Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында: «Марксистик-ленинчыл традицияләрне үстерә барып, совет әдәбият-сәнгать тәнкыйте идея ягыннан бәяләүләрнең тегәллеген, социаль анализның тирәнлеген эстетик таләпчәнлек белән, талантка, нәтиҗәле иҗади эзләнүләргә сак караш белән бергә кушарга тиеш», диелә.

Тәнкыйть — әдәби күренешләрне тормыш дөреслеге белән чагыштырып, тикшереп карый торган, заманның эстетик рухына таянып эш итә торган гаять көчле корал. Аңа игътибар һәм хөрмәт белән карамау мөмкин түгел.

Әдәби иҗатның җаваплы һәм шактый авыр өлкәсе булган тәнкыйть бер вакытта да профессиональ тәнкыйтьчеләрнең генә эше булмады, бу өлкәдә һәрчак әдәбиятның үзен иҗат итүчеләр — язучылар, шагыйрьләр, драматурглар актив эшләп килделәр. Татар әдәби тәнкыйте дә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов кебек зур сүз осталарының бу өлкәдәге әйбәт традицияләрен дәвам иттерә. Бүгенге тәнкыйтьне күренекле язучыларның актив катнашыннан, аларның әдәбият һәм тормыш, герой һәм заман, әдәби форма һәм осталык турындагы уйлануларыннан башка күз алдына китереп булмый. Чөнки әдәби тәнкыйть — безнең уртак эшебез, гомум хезмәтләребезнең җимеше ул.

Күптән түгел әдәби процесс, әдәбият һәм тормыш турында уйлануларга багышланган яңа бер китап чыкты. Аны күп еллар буе әдәби хәрәкәтнең үзәгендә торган күренекле каләм осталарының берсе — Мирсәй ага Әмир язган[1].

Беренче карашка бу китап вакытлы матбугатта, һәртөрле стенограмма, беркетмәләрдә генә сакланып кала торган язмалардан җыелган корырак бер җыентык тәэсирен калдырырга мөмкин. Чөнки аңа зур булмаган рецензияләр дә, теге яки бу әдәби вакыйгага багышланган рәсми чыгыш яки речьләр дә, әдәби портретлар да, хәтта пародия, әдәби фельетон, иптәшләрчә шаярулар рәвешендә язылган әйберләр дә кергән. Куанычка каршы, әлеге шик китапның эченә кереп китү белән бик тиз җуела, укучы аны мавыгып укый башлый. Һәм китап һәркемне кызыклы, катлаулы бер дөньяга — әдәбият дөньясына әйдәп алып кереп китә.

«Үзебез турында» исемле бу китап оста художник, зур әдип кулы белән язылган. Анда кайнап торган әдәби тормыш, җанлы әдәби процесс, заман рухы һәр бит саен үзен сиздереп, укучыны дулкынландырып тора. Әдәбият турында автор сүз остасы — язучы теле белән, иста калырлык картина һәм детальләрдә сөйли. Әдәбиятның бүгенге торышы, андагы күренешләр, вакыйгалар һәм хәлләр М. Әмир китабында зур таләпләрдән — партия һәм халык күзлегеннән, заман рухыннан чыгып, югары һәм иң мөһиме гадел үлчәү белән үлчәнә. Дөрес, авторның кайбер бәхәсле фикерләре, бәяләүләре дә бардыр. (Тере организм, җанлы процесс белән эш иткәндә, бу котылгысыз хәл.) Ләкин аның күпчелек күзәтүләре ышандыра, уйландыра, фикер уята.

Заман рухы, тормыш сулышы. Китапның һәр бите шушы хисләр белән сугарылган. Менә җыентыкны ачып җибәргән «Алга карап» исемле мәкалә. Анда партия съезды

---

[1] Мирсәй Әмир. Үзебез турында. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, чыгышлар. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1971 ел.

делегаты булган язучының ихлас тойгылары чагыла:

«Съездлар Сараеның иң гүзәл чагы, архитектура сәнгате үрнәге сыйфатында форма һәм эчтәлеге ягыннан тулы мәгънәсендә ачылган чагы, әлбәттә, съезд көннәрендә була торгандыр. Тоташ пыяла стена аша аның кулуарларында кайнашкан меңнәрчә кешеләр, тыштан ук күренеп, сине тизрәк эчкә тарталар... Аска таба да, өскә таба да өзлексез йөреп торган баскыч-эскалаторлар сине йөзләрчә, меңнәрчә кешеләр белән бергә үз стихияләренә тартып алып кереп китәләр...»

Һәм шунда ук бүгенге әдәби хәрәкәттәге кайбер ямьсез күренешләр турында борчылып уйланулар:

«...Бездә бит әле, өстән генә караганда идея ягыннан бәйләнер җире юк кебек күренсәләр дә, чынлап караганда әдәби брак булган түбән сыйфатлы китаплар: шигырь җыентыклары, хикәяләр, сәхнә әсәрләре һаман чыга торалар. Дөрес, әдәбият дөньясы гел шедеврлардан гына тормый... Ләкин бер үк автор әдәби кыйммәтләре бер үк дәрәҗәдә түбән әсәрләрен бер-бер артлы тәкъдим итә икән һәм картайганчы шул дәрәҗәсеннән күтәрелү мөмкинлеге күренми икән, аларны шома гына үткәреп торуның кемгә кирәге бар?»

«Үзебез турында» исемле китап менә шундый сөйләшү, әңгәмәләшү стилендә, укучы белән бергәләп уйлану рухында язылган. Шушындый гади әңгәмәләшү, гадәти хикәяләү телендә автор шактый катлаулы һәм мөһим мәсьәләләр: социалистик реализм методының төп принциплары, әдәби стиль, дереслекне, чынбарлыкны ничек аңлау, новаторлык һәм традиция, ирекле шигырь проблемалары кебек үзенчәлекле темаларга иркенләп сөйләшә. Бер урында язучы, СССР Язучылары съездының йомгаклары турында сөйләп, анда алган тәэсирләр белән уртаклаша да, татар совет әдәбияты өчен хас проблемаларга тукталып уза («Социалистик реализмның тантанасы» исемле мәкалә). Ә икенче очракта проза әсәрләрендә заман рухы, драматургиядәге уңай герой турындагы бәхәсләргә карата үз фикерен әйтә («Драматург һәм уңай герой», «Заман рухы мәсьәләсе»). Бу мәкаләләрдәге фикерләр әле дә искермәгән, алар әле дә эстетик фикернең, әдәби тәнкыйтьнең игътибар үзәгендә торалар.

М. Әмирнең бу китабына Татарстан язучыларының съездларында ясаган докладлары, төрле фикер алышулар вакытында ясаган чыгышларыннан өзекләр дә кергән. Аларда җанлы әдәби процесс, әдәбиятның бүгенге проблемалары ачык чагыла. Бу характердагы мәкаләләрдә хәзерге татар совет әдәбиятының күзгә күренерлек һәрбер күренешенә һәм теге яки бу дәрәҗәдәге әһәмиятле әсәрләренә бирелгән бәя дә киң катлау укучыларны кызыксындырырлык. Шунысы әйбәт: язучы шактый гадәти, рәсми булган җыелыш һәм утырышлар турында да образлы теп белән, үзенчә бер җанлылык, ягымлы юмор белән сөйли. Әдәби ел йомгаклары турындагы бер җыелышта ул, мәсәлән, шулай ди:

«...Бу җыелышны, бәлки, язучылар өчен үзенә күрә уңыш бәйрәме дип карарга да булыр иде. Ләкин безнең алай дип атыйсыбыз килми. Чөнки, билгеле булганча, һәр бәйрәмнең үзенең мәҗлес түрендә утыручы геройлары була, гадәттә купчелек тәшкил итә торган урталары була, шулай ук ишек төбеннән уза алмаганнары да, ишекнең тышкы ягында ук калганнары да, хәтта, искечәрәк итеп әйтсәк, гает көнне «мәчет астына» ябылырга тиешле намазныязсыз, уразасыз гөнаһ ияләре дә була.

Язучыларны без алай бүлә алмыйбыз».

Авторның социалистик реализм әдәбиятының уңай герое, әдәби осталык, халыкчанлык, тарихи роман, әдәбият гыйлеме һәм әдәби тәнкыйть проблемаларына багышланган күзәтүләре һәм уйланулары да бүгенге әдәби хәрәкәт өчен бик актуаль яңгырыйлар. Заманыбызның алдынгы кешесе образын иҗат иту өчен, ди язучы, «бик намуслы рәвештә булса да, өстәл янында утырып эшләү генә җитми. Аның өчен коммунистик төзелешнең алдынгы сафында булырга, тормышның көрәшнең эчендә кайнарга, заманыбызның актуаль мәсьәләләрен хәл кылучы кешеләрне үз күзең белән күреп белергә генә түгел, алар белән бергә үзең дә шул көрәштә катнашырга кирәк». Бик хак сүзләр.

М. Әмир әдәби осталыкны әсәрнең темасыннан, аның идея эчтәлегеннән аерып йөртергә омтылыш тенденциясенә кискен каршы чыга. Язучы әдәби тәнкыйтьтә аерым әсәрләргә бирелгән бәхәсле бәяләргә карата да үз фикерен әйтә килә.

Соңгы еллар татар совет әдәбияты үсешендәге әһәмиятле вакыйгалар һәм күренешләр турында сөйләгәндә, М. Әмир язучыларның өлкән, урта һәм яшь буын вәкилләре иҗат иткән әсәрләргә бәя бирү белән генә чикләнми, әдәби процесс проблема-

ларын, хәл ителгән һәм әлегә хәл ителеп бетмәгән мәсьәләләрне дә кыю күтәрә. Бу җәһәттән бүгенге әдәбиятта халыкның тарихи-революцион үткәнен чагылдырган эпик әсәрләр, атап әйткәндә, тарихи роман проблемасы, халыкның иң яхшы сыйфатлары, гореф-гадәтләре, традицияләре һәм романтик герой турындагы фикерләр игътибарга лаеклы. Өлкән буын язучыларның әдәбиятка керткән зур өлешен лаеклы билгеләү белән бергә, автор яшь әдәби көчләрнең эзләнүләре, беренче уңышлары һәм кайбер кимчелекләре хакында да төпле фикерләр әйтә.

«Үзебез турында» китабының зур гына өлешен әдәби остазларга һәм каләмдәш дусларга — замандаш язучыларга багышланган фикерләр, язмалар, истәлекләр, чын йөрәктән әйтелгән сүзләр алып тора. Бу бүлек хаклы рәвештә бөек Тукай турындагы тирән ихтирам һәм олы мәхәббәт сүзләре белән ачылып китә:

«Һәр елны язның иң матур чагында, табигатьтәге бөтен тереклек дәртләнеп уянганда, агачлар яфракка бөреләнгәндә, киң күңелле яз кояшы күктән көлеп карап торганда, кешеләр хезмәт, дуслык бәйрәменә — Беренче майга хәзерләнгәндә шушы һәйкәл янына җыелу безнең язучылар һәм әдәбият сөюче барлык хезмәт ияләре арасында әйбәт бер гадәткә кереп китте. Чөнки язның бу матур көнендә табигать безгә сөекле шагыйребезне — Габдулла Тукайны бүләк итте, һәм бу көнне без изгегә саныйбыз».

Г. Тукай, Г. Ибраһимов, һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи кебек, татар әдәбиятының даны, мактанычы булган язучы һәм шагыйрьләргә багышланган кечкенә истәлек һәм мәкаләләрдә зур горурлык, тирән хөрмәт һәм рәхмәт хисләре тупланган. Аларның күпчелегендә үлемсез классик язучылар һәм замандаш-каләмдәшләр җанлы, ягымлы кешеләр булып күз алдына басалар. Аларның һәрберсенә авторның үз мөнәсәбәте, үзенчә карашы һәм үзенең шәхси хисләре бар. Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Фатих Кәрим белән очрашулар турындагы җылы истәлекләр күренекле язучыларның портретларына җанлы детальләр өсти.

Әдәби остазлар турында сүз алып барганда автор укучылар белән рус әдәбиятының корифейлары Лев Толстой, Антон Чехов, Иван Тургенев, Максим Горький хакындагы фикерләре белән дә уртаклаша.

Китапта шулай ук язучының замандаш һәм каләмдәш дуслары Гомәр Бәширов, Ибраһим Гази, күренекле башкорт әдибе Сәгыйт Агиш һәм XIX йөздә татар авыллары һәм татар халкы вәкилләрен үз иҗатында чагылдырган латыш художнигы Карл Гун турында бик җылы язылган мәкаләләр һәм истәлекләр бар. Ул мәкалә һәм истәлекләрдә автор Г. Бәширов һәм И. Гази иҗатындагы халыкчанлык, заман рухы турында җентекләп сөйли, укучыларны татар халкы вәкилләренең образларын тудырган латыш художнигы К. Гун белән таныштыра, якын дусты С. Агишның истә калырлык портретын тасвирлый. Мирсәй Әмир башкорт каләмдәшенең характерлы сыйфатларын бик оста тотып алган. Автор «бу кечкенә гәүдәле, һәрвакыт терекөмеш кебек хәрәкәтчән кешенең, колакка әз генә катырак булса да, бик күпне ишетүен, күзгә әз генә чамалырак булса да, бик күпне күрүен һәм ишеткән-күргәнен тыңлап туймаслык итеп сөйләп бирү осталыгын» гаҗәп ышандырырлык итеп күз алдына бастыра.

«Шаян тәнкыйть» дигән соңгы бүлектә язучы, әдәби фельетон, пародия жанрында чыгыш ясап, укучыларны елмаерга мәҗбүр итәрлек язмалар урнаштырган.

Шулай итеп, М. Әмирнең яңа китабы тирән игътибар белән, бер тын белән укыла. «Үзебез турында» — ул әдәби хәрәкәт, бүгенге татар совет әдәбияты турында уйлануларга корылган, уйландыра һәм куандыра торган китап. Әдәбият сөюче һәр укучы бу китапта үзе өчен күп фикерләр, яхшы рухи азык табар.

**Гыйлемдар РАМАЗАНОВ,**
**филология фәннәре докторы.**

## Хәкимҗан Халиков

### Яңгыр хәбәрчеләре

Кара кыйгач канатлы
Сап-сары бер кош болар.
Чыр-чу килеп үзләре
Юкка пыр-пыр очмыйлар,
Шундый сизгер кош болар!

Яңгыр килеп бераздан
Яумасынмы бик шәплəп.
Марат балык тота дип,
Тормады ул иләклəп —
Койды гына чиләклəп.

Менә нигә бу кошлар
Чыр-чу килгәннәр икән.
— Яңгыр килә, яңгыр! — дип,
Хәбәр биргәннәр икән...
Кайдан белгәннәр икән?

### Ничек тизрәк үсәсе?

Сез ничектер, их, дим мин,
Ничек тизрәк үсәсе?
Моряк Илгиз абый кук
Ничек дөнья гизәсе?
Тельняшка да, бушлат та
Киеп карыйм өстемә.
Үзем һаман кечкенә,
Үсеп булмый һич кенә.

Белмим, әллә еларга,
Әллә инде көләргә.
Су да эчәм көн саен,
Су сипкәндә гөлләргә.
Яңгыр яуса, урамнан
Кайтып керәм кич кенә,—
Ә мин һаман кечкенә,
Файдасы юк һич кенә.

Апам кебек, бер көнне
Үзем җыйдым урынны.
Исе китте әнинең:
«Карагыз,— ди,— улымны,
Хәйран, нинди зур үскән,
Нәни иде кич кенә!»
Аңламый бит һич кенә,—
Мин бит буйга көчкенә...

## Нигә?

Юл буенда ялгыз каен
Уйга чумган нигәдер.
Яшенен дә әйтер идем,
Нигә шуңа тиядер?!

Ә карт каен... елый, мескен,
Карап җәйге урманга.
Яшен суга микән аны
Әллә ялгыз булганга?

## Белми диеп йөр менә...

Энем минем әлегә
Укымый да, язмый да.
Биш тә тула бит инде
Шушы елның язында...

Китап алып утырсам,
Үзе һаман янымда.
Йотып барган, күрәсең,
Шул чагында барын да.

Әйткән идем: «Язарга
Өйрәтимме, Әхмәт?» — дип,
Күптән беләм дигәндәй,
Язып куйды: «Рәхмәт»,— дип.

**Радик Исаев**

# КҮРӘЗӘЧЕ



Саумысыз, Галия,— диде яшел эшләпәле бер агай, урамнан үтеп барган ханымга баш иеп.

— Исәнмесез,— диде Галия каршында елмаеп торган иргә.— Гафу итегез, мин сезне танымыйм бит...

— Ә мин сезне таныйм,— диде эшләпәле кеше.— Сезгә хәзер утыз ике яшь. Дөресме? Май заводында бухгалтер булып эшлисез. Иптәшегез нефтьче инженер, әле командировкада...

— Әллә бер-бер хәл бармы? Зинһар, тизрәк әйтегез? — диде Галия, хафаланып.

— Юк. Курыкмагыз. Мин моны сезне белүемне аңлату өчен генә әйттем. Кичәгенәк сез складтан бик әйбәт ит алгансыз икән. Анда Нина Сабировна дигән танышыгыз бар. Ул сезгә суыткыч табып бирергә дә вәгъдә иткән. Шулай бит.

— Белдем мин сезне,— диде Галия, авыр сулап.— Сез — следователь. Нина Сабировнаның берәр ялгышлыгы булгандыр. Мин сезгә берни дә әйтәчәк түгелмен.

— Мин әле сезнең шәһәргә ни өчен чыгуыгызны да беләм. Сезгә кофта кирәк. Универмагта сатучы булып эшләгән кызкай яхшы кофта табып бирергә вәгъдә иткән,— дип тезеп китте эшләпәле агай.

— Сез күрәзәче түгелдер бит? — диде Галия ачу белән.

— Күреп торасыз, түгел. Кичә кер югансыз. Бүген йөреп кайткач, идән юганнан соң, аш салырга исәбегез бар. Аннан Галина Андреевнаны чакырып, дүрт яшьлек кызыгыз Светлананы детсадка урнаштырырга исәп тотасыз.

— Белдем үзегезне. Сез безнең йортта торасыз,— диде Галия кинәт.

— Юк,— диде таныш булмаган кеше.— Мин бөтенләй бу шәһәрдән түгел.

— Хәтерләдем. Без Сочида очрашкан идек бит әле. Сез мине Сафа исемле егеттән көнләдегез. Иптәшегезгә хат язам, дидегез. Шулаймы? Әллә семья бозарга дип килдегез инде, ә? Ир булуыгызга әйтер идем, шуны да сер итеп саклый алмагач...

— Гафу итегез! Мин ул кеше түгел. Сезне дә гомеремдә беренче тапкыр күрәм,— диде агай, үзе уңайсызланып кызарды.

— Соң, алайса боларны кайдан беләсез? — диде Галия, аптырап.

— Теләсәгез сезне дә өйрәтәм.

— Өйрәтегез?!

— Без унбиш кенә минут элек бер трамвайда утырып килдек. Сез саргылт чәчле бер ханым белән дөньягызны онытып сөйләшә идегез. Мин сезнең арттагы утыргычта утырдым. Менә шул. Әле хәтердә калганнарын гына әйттем.

# ПЕРЕКУР



Эш бүре түгел, эш урманга качмас, егетләр, перекур ясап алыйк,— ди Сабит эш башлар алдыннан. Наряд алгач та перекур ясарга онытмый. Көндезге ашны да ярты сәгатьлек перекур белән көтеп ала.

Бер чак без аның белән авариягә чыктык. Поселокның электр корылмасы ватылган иде. Ун минутлык эшне Сабит перекурлары белән бер сәгатькә җиткерде.

— Тизрәк бул, меңләгән квартира утсыз тора бит,— димен тегеңә.

— Ашыкма. Ашыгу шайтан фигыле ул, туган. Перекур...

Эшне бетереп кайтырга гына чыккан идек, Сабит урам уртасында бозга таеп егылды. Шул кадәре нык төште, хәтта йортның тәрәзә пыялалары зыңлады.

— Аягым сынды,— диде ул көч-хәл белән.— Йөгер скорый пумочка!

— Тукта, уйлашыйк, перекур ясыйк, ашыгу шайтан фигыле, бәлки сынмагандыр әле аягың,— дидем.

## Георгий Ладонщиков

### Кысыр хәсрәт

«Аталар һәм балалар»
Проблемасын язган ул,
Гомер буе куерткан.
Шул кадәрле мавыккан —
Буйдак булып калган ул,
Өйләнергә оныткан!

### Өйрәтә

Тәҗрибәле бер Акбай
Ничек дөнья көтәргә
Өйрәткән, ди, баласын:
Яхшы белеп үс, дигән,
Кемгә койрык болгыйсын,
Кемгә өреп каласын.

### Сәбәбе...

Баш ваталар заводта:
Ни сәбәп, ни хикмәт бар,
План тулмый нилектән?
...Аракыны күп сатып
Шәп үтиләр планны
Күршедәге кибетләр!

### Ди...


Берәү роман язган, ди,
Бастырып чыгарган, ди,
«Укысалар — харап!..» ди,
Барсын сатып алган, ди.

### Зар

«Эшең консыз, тупас эш,
Культурасыз, яман эш!»
Теш врачыннан шулай
Зарланды... йолкынган теш.

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ тәрҗемәләре

«Казан утлары»н «Чаян» дусларыбыз котлый




Л. НАСЫЙРОВ рәсеме

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЭДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Партиябезнең XXIV съезды совет әдәбияты һәм совет сәнгате ирешкән казанышларга югары бәя бирде. Шуның белән бергә, съезд әдәбият-сәнгать әһелләре алдында торган мөһим мәсьәләләрне дә кузгатты. Бу бик аңлашыла. Илебез алга барган саен, әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдәге роле, әһәмияте күтәрелә бара. Иҗат кешеләре алдына куела торган таләпләр дә нык арта. Съезд материалларыннан ачык күренгәнчә, әдәбият-сәнгать өлкәсендәге казанышлар һәм кимчелекләр күп кенә дәрәҗәдә әдәбият-сәнгать тәнкыйтенең торышына бәйле. «Шик юк ки,— диде Л. И. Брежнев,— әгәр дә безнең әдәбият-сәнгать тәнкыйте партия линиясен тагын да активрак үткәрсә, таләпчәнлекне такт белән, художество кыйммәтләрен иҗат итүчеләргә игътибарлы мөнәсәбәт белән бергә бәйләп, зуррак принципиальлек белән чыгыш ясаса, совет әдәбияты һәм сәнгатенең уңышлары тагын да зуррак булыр, ә кимчелекләре тизрәк бетерелер иде». Съезд тәмамланып күп тә узмады, КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары басылып чыкты. Ул карар әдәбият-сәнгать өлкәсендә XXIV съезд билгеләгән программаны тагын да үстерә, дәвам иттерә.

Партия съездыннан һәм Үзәк Комитет карарыннан соң, илдәге әдәби хәрәкәт активлашып, бермә-бер җанланып китте. Моны безнең татар әдәбияты мисалында да бик ачык күрергә мөмкин. 21—22 февральләрдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында уздырылган зур җыелыш та шул турыда сөйли. Дөрес, әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышлар бездә элек тә начар үтми иде. Быел исә ул аеруча җанлы, аеруча эшлекле төстә узды.

Җыелышны Татарстан язучылар союзы идарәсенең председателе Зәки Нури ачты. Артык зур булмаган кереш сүзендә ул җыелышта катнашучыларны бер ел эчендә иҗат ителгән яңа әсәрләр белән таныштырды, татар язучылары алдында торган бурычларга тукталды. Шуннан соң докладчыларга сүз бирелде. 1971 елда басылып чыккан проза әсәрләре турында Рафаэль Мостафин, шагыйрьләр иҗаты турында Равил Фәйзуллин, сәхнә әсәрләре турында Аяз Гыйләҗев, әдәби тәнкыйть турында Нурихан Фәттах, Татарстанда яшәүче рус язучылары иҗаты турында Вячеслав Воздвиженский, очерклар турында Малик Хәмитов, балалар әдәбияты турында Шамил Рәкыйпов сөйләде. Докладлар нигездә төпле һәм тирән фикерле, кыю һәм туры сүзле булды. Докладчыларның күбесе әдәби әсәрләргә зур, җитди таләпләр югарылыгыннан торып бәя бирде.

Фикер алышуларны өлкән әдибебез Мирсәй Әмир башлап җибәрде.

— Быелгы докладларның һәммәсе дә нигездә уңай фикер калдырды,— диде ул.— Бездә язучыларга карата бик күп ташлама ясала. Шуның нәтиҗәсендә әдәби әсәрләрнең сыйфаты түбәнәя. Быелгы докладчылар бирәүгә дә ташлама ясамадылар.

Алга таба Мирсәй ага А. Гыйләҗев һәм Н. Фәттах докладларындагы аерым тезислар белән бәхәскә керде.

Гази Кашшаф соңгы елларда әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр язган хезмәтләр хакында сөйләде, яшь тәнкыйтьчеләр тәрбияләү белән бәйләнешле мәсьәләләргә тукталды, соңыннан докладлар турындагы тәэсирләре белән уртаклашты.

— Докладлар миңа да ошады,— диде Фатих Хөсни.— Кайнар, җанлы, бәхәс кузгата торган докладлар. Миңа аеруча Равил Фәйзуллинның докладлы ошады. Ул гражданлык хисе, борчылу, ярату белән сугарылган. Рафаэль Мостафинның гадел тәнкыйтеннән дә яхшы тәэсир калды. Шамил Рәкыйпов докладында балалар әдәбиятын тоташ документальлеккә әйләндерергә тырышу тенденциясе сизелде. Бу дөрес тенденция түгел...

Фатих Хөсни шулай ук докладлардагы аерым фикерләр белән килешеп җитмәвен әйтте.

СССР Язучылар союзы вәкиле Вил Ганиевнең чыгышы нигездә тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган иде. Ул тәрҗемәчеләр алдында торган бурычлар турында сөйләде, тәрҗемә китапларында очрый торган кимчелекләргә тукталды. Лидия Григорьева шулай ук тәрҗемә мәсьәләләре турында сөйләде. Ул татар язучыларын тәрҗемә итү эшенә күбрәк җирле авторларны тартырга кирәк, диде. Тәрҗемә эшенең торышына, тәрҗемә итү өчен әсәрләр сайлау мәсьәләсенә шагыйрь Нәби Дәүли дә кагылып узды. Шулай да аның чыгышы күбрәк әдәби тәнкыйть мәсьәләләренә багышланган иде.

— Без Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы»н, Мирсәй Әмирнең «Батыр малаен» укып үстек,— диде «Ялкын» журналының җаваплы редакторы Роза Хафизова.— Бүген балаларда патриотизм хисләре тәрбияли торган мондый әсәрләр аз языла. «Ялкын» журналы аларга бик мохтаҗ. Балалар пьесалар сорый. Ә бездә, журналда, алар өчен

язылган драма әсәрләре юк. Өлкән язучыларыбыз балаларны онытмасыннар иде.

Җыелышта катнашучылар өлкән шагыйребез Шәйхи Маннур чыгышын да игътибар белән тыңладылар.— Үзәк Комитет карары бик вакытлы чыкты,— диде ул.— Әгәр тәнкыйть үз алдына куелган бурычларга җавап бирә алмаса, диелә карарда, әдәби үсеш тиешле югарылыкта була алмый. Шул фикерләрне истә тотып, без үзебезнен әдәби хуҗалыкны тагы бер кат карап чыгарга тиешбез. Бөтен уңышларны таныган хәлдә, безнең шактый кимчелекләребез дә бар. Яшьләр арасында гына түгел, өлкән язучылар арасында да үз иҗатларына җавапсызрак караучы иптәшләр очрый.

Алга таба Шәйхи Маннур әдәби халтурага каршы көрәш мәсьәләләренә тукталды.

— Сәнгатьнең барлык тармаклары да әдәбияттан башлана,— диде Татар академия театрының баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов.— Театр да әдәбияттан башланган. Татар әдәбиятының күп гасырларга сузылган бай традицияләре бар, шуңа күрә театры да элек-электән көчле булган. Без шул традицияләрне дәвам иттерергә, тагын да үстерергә тиешбез.

Хәсән Сарьян «Идел» альманахының эш планнары һәм авторлары турында, Барлас Камалов Язучылар союзы каршындагы проза секциясенең эше, Туфан Миңнуллин бүгенге сәхнә әсәрләре һәм театр тәнкыйте, Бакый ага Урманче матур әдәбият әсәрләренең теле турында сөйләде. Докладлар буенча фикер алышуларда шулай ук Әхсән Баянов, Баян Гыйззәт һәм Мөсагыйт Хәбибуллиннар катнашты.

Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Мөдәррис Мусин катнашты һәм чыгыш ясады. Ахырдан Татарстан язучылар союзы идарәсенең 1972 елга эш планы карап тикшерелде, КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарын тормышка ашыру буенча конкрет чаралар билгеләнде.

## ОРГАН МОҢНАРЫ

28 февраль республикабызның музыка сөючеләре өчен чын мәгънәсендә бәйрәм көн булды. Консерваториянең актлар залында Казанда беренче тапкыр орган концерты бирелде.

— Коммунистлар партиясе, совет хөкүмәте,— диде СССРның халык артисты, композитор Нәҗип Җиһанов әлеге тантананы ачканда,— музыкабызны үстерү турында даими кайгыртучанлык күрсәтәләр. Бу көчле музыка коралы Татарстан хезмәт ияләренең рухи тормышын тагын да баетыр. Композиторларыбыз бу музыкаль инструментта уйнау өчен яңа әсәрләр иҗат итәрләр.

Беренче концертта, орган музыкасының классик композиторлары иҗат иткән әсәрләр белән бергә, татар композиторы Н. Җиһановның «Республикам минем» исемле кантатасы да башкарылды. Тамашачылар концертта башкарылган һәр әсәрне көчле алкышлар белән каршыладылар.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

8 февральдә Татарстан язучылар союзы каршындагы проза секциясенең чираттагы утырышы булды. Анда өч яшь прозаикның 1971 елда китап булып чыккан яңа әсәрләре (Лирон Хәмидуллинның «Дала иртәсе» һәм Мәгъсүм Хәбибуллинның «Кискеч җыры» исемле повестьлары, Миргалим Харисовның «Ватан нидән башлана» исемле хикәяләр җыентыгы) тикшерелде. Утырыш эшлекле һәм шактый киеренке төстә узды. Мактаудан бигрәк, тәнкыйть сүзе күп әйтелде. Докладчы Х. Сарьян да, фикер алышуларда катнашкан язучылардан А. Гыйләҗев, А. Шамов, Ә. Еникиләр дә нигездә яшь прозаикларның әсәрләрендәге тел кытыршылыкларына, кимчелекле якларга тукталдылар.

* * *

3 мартта Язучылар союзы каршындагы драма секциясенең чираттагы утырышы булып узды. Анда Нәби Дәүлинең «Соңгы сәгатьтә» исемле пьесасы укып тикшерелде.

## СССРның 50 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАП

Башкортстанның Илеш районында СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышланган әдәби атналык уздырылды. Гаять җылы, күтәренке төстә узган кичәләрдә ике тугандаш халыкның бер төркем язучылары, артистлары чыгыш ясады. Атналыкта катнашучылар арасында Татарстаннан Х. Сарьян, Р. Гатауллин, Татарстан АССРның атказанган артисты Г. Рәхимкулов һәм җырчы Ф. Сөләйманова, Татарстан язучылары союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросы хезмәткәрләре М. Шәймөхәммәтов белән М. Шиһапов һәм башка иптәшләр бар иде.

* * *

Республикабызның нефть районнарында яшәүче язучылар Г. Афзал, С. Сөләйманова, С. Кальметов, яшь шагыйрь Р. Вәлиуллин Башкортстанның Бәләбәй районында булып кайттылар. Алар катнашында клубларда, уку йортларында, эшче яшьләрнең тулай торакларында үткәрелгән очрашулар СССРның 50 еллыгына багышланды.

Яшьләрне тәрбияләүдә күрсәткән хезмәтләре өчен, ВЛКСМның Бәләбәй шәһәр комитеты Татарстан кунакларын Мактау грамоталары белән бүләкләде.

* * *

Татар язучыларыннан Р. Харисов, С. Сөләйманова, Г. Рәхим, Х. Сарьян, Р. Миңгалимов, М. Маликова, М. Газар һәм Л. Хәмидуллин Куйбышев шәһәрендә үткәрелгән әдәбият бәйрәмендә катнаштылар.

СССРның 50 еллыгына багышланган бу бәйрәм чын мәгънәсендә халыклар дуслы-

гының тантана итуен күрсәткән бәйрәм булды. Язучыларыбыз Идел буендагы ин зур өлкә үзәкләренең берсе булган бу шәһәрнең «Звезда» клубында, Дзержинский исемендәге Культура йортында, Металлургләр культура сараенда үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәләрдә катнаштылар, В. И. Ленин исемендәге металлургия заводы цехларында эшчеләр белән очраштылар.

Әлеге кичәләрнең икенче бүлегендә Куйбышев шәһәрендәге татар эшче яшьләренең һәм шәһәр вузларында укучы студентларның «Ялкынлы яшьлек» эстрада ансамбле концертлар бирде. Ансамбльгә инженер Илгиз Колючов һәм Куйбышев исемендәге медицина институтының 4 курс студенты Шамил Саттаров җитәкчелек итә.

Татар әдәбияты бәйрәмен ике мең ярымнан артык тамашачы карады.

* * *

Февраль аенда Минзәлә дәүләт драма театры коллективының Удмуртия башкаласы Ижевскида СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышланган гастрольләре булып узды. Театр күршеләребезгә Ә. Баяновның «Һәйкәл», Х. Ибраһимовның «Башмагым», З. Шаһиморатовның «Хәят», Р. Ишморатның «Хикмәтле Сәйфи», Ю. Әминовның «Кеше күнеле» һәм рус драматургы А. Салынскийның «Мария» исемле әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләрен күрсәтте.

* * *

Алма-Ата театрларында СССРның 50 еллыгына багышланган фестиваль бара. Аны, татар композиторы Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясен сәхнәләштереп, М. Ауэзов исемендәге казакъ драма театры башлап җибәрде. Тамашачылар спектакльне гаять жылы каршыладылар.

## УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ АТНАЛЫКЛАР

Күптән түгел Татарстанның Югары Ослан районында рус әдәбияты атналыгы уздырылды. Анда Т. Журавлев, С. Радзиевская, Н. Орешина, М. Зарецкийлар катнашты.

* * *

Татар язучыларыннан Г. Минский, Б. Камалов, Ә. Баянов, М. Фәйзуллина, Г. Рәхим, Ф. Шәфигуллиннар республиканың Балык Бистәсе районында йөреп кайттылар. Алар колхозларда, совхозларда, мәктәп укучылары янында булдылар. Китап укучыларны бүгенге татар әдәбиятындагы яналыклар белән таныштырдылар, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Февраль аенда яшь шагыйрьләр Ф. Сафин, Р. Вәлиев, Ә. Гадел, журналист Р. Хисмәтуллин Түбән Кама районы эшчәннәре һәм мәктәп укучылары белән очраштылар. Очрашулар вакытында шагыйрьләр яңа әсәрләрен укыдылар, бүгенге татар әдәбияты ирешкән уңышлар турында сөйләделәр.

* * *

16 февральдә яшь прозаик Вакыйф Нуруллин Казан театр училищесы студентлары белән очрашты. Автор «Күпер чыкканда» повестеның язылу тарихы турында сөйләде, студентларның күп санлы сорауларына җавап бирде.

* * *

18 февральдә Дөбьяз культура йортында В. Нуруллинның «Күпер чыкканда» повесте буенча укучылар конференциясе уздырылды. Конференцияне, кыскача кереш сүз сөйләп, укытучы Р. Закирова ачты. Әсәр буенча фикер алышуларда М. Сабитова, С. Лотфуллина, Х. Зарипов, Т. Гатауллина, З. Гыйбадуллина һәм В. Саттаровалар катнашты.

Конференциядә автор үзе дә катнашты, укучыларның сорауларына җавап бирде.

* * *

1 мартта Казан авыл хуҗалыгы институтында Рафаэль Мостафинның «По следам поэта-героя» исемле китабы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Китап буенча фикер алышуларда уннан артык кеше катнашты. Аларның барысы да әсәрне яратып укулары турында сөйләде. Конференция эшендә автор үзе дә катнашты.

* * *

3 мартта Казанның Актерлар йортында Рафаэль Мостафинның иҗатына багышланган тематик кичә уздырылды. Кичәдә автор «По следам поэта-героя» исемле китабын ничек язуы турында сөйләде. Татарстанның атказанган артистлары А. Арсланов, Э. Җәләлетдинов, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Н. Сабитовская, җырчы В. Гыйззәтуллина катнашында концерт бирелде. Тамашачылар «Сәйяр» вокаль-инструменталь ансамбль чыгышын да жылы каршылады.

## ШАГЫЙРЬ АРХИВЫ

Татарстан АССР Дәүләт музееның матур әдәбият бүлеге елдан-ел байый, зурая бара. Күренекле шагыйребез Шәйхи Маннур күптән түгел музейга Мифтах Вәдүтнең шәхси архивын тапшырды.

Бөек Ватан сугышы елларында вакытсыз һәлак булган бу яшь шагыйрьнең архив материаллары арасында, аерым китап булып чыккан шигырьләреннән тыш, «Сәхифәләр» исемле кульязма шигырьләр дәфтәре, төрле елларда туганнарына, каләмдәш дусларына язган хатлары, фоторәсемнәре бар.

## «ЙОЛДЫЗ ТАПКАН ЕГЕТ» ЧУВАШ ТЕЛЕНДӘ

Күптән түгел Чуваш китап нәшрияты Кави Латыйповның очучы-космонавт Андриян Николаев турындагы «Йолдыз тапкан егет» исемле повестен 10 000 тираж белән чуваш телендә басып чыгарды. Әсәрне чуваш теленә күренекле чуваш язучысы Владимир Ухли тәрҗемә иткән.

## ТАРИХЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Тугандаш Башкортстан республикасының башкаласы Уфада Көньяк Урал һәм Идел буе тарихчыларының беренче конференциясе үткәрелде. Конференциядә Уфа, Мәскәү, Казан, Ульяновск, Свердловск, Новосибирск, Оренбург, Чиләбе югары уку йортларының укытучылары, фәннитикшеренү институтларында эшләүче галимнәр, музей һәм архив хезмәткәрләре катнашты, аларның 60 тан артык докладлы тыңланды.

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының директоры, тарих фәннәре докторы, профессор М. Мөхәррәмовның «Тарихи чыганак буларак, 1917 елгы татар вакытлы матбугаты» дигән темага ясаган докладлы тыңлаучыларда зур кызыксыну тудырды. Шул ук институтның өлкән фәнни сотрудникгы М. Сәйдәшева конференциядә катнашучыларны Татарстан хезмәт ияләренең бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинга язган хатлары белән таныштырды. Тарих фәннәре кандидаты С. Алишевның докладлы Пугачев хәрәкәтенә бәйләнешле материалларны анализлауга, Казан дәүләт университетының өлкән укытучысы, тарих фәннәре кандидаты М. Усмановның чыгышы төрки телләрне өйрәнү мәсьәләсенә багышланган иде.

Көньяк Урал һәм Идел буе халыкларының тарихын өйрәнү эшен тагын да киңәйтү һәм аны координацияләү максаты белән, Уфа шәһәрендә Көньяк Урал һәм Идел буе тарихчыларының комиссиясе төзелде. Аның составына Казаннан тарих фәннәре докторы, профессор М. Мөхәррәмов кертелде.

## ГЕНЕРАЛ ЧАНЫШЕВКА 80 ЯШЬ

Шушы елның февраль аенда татар халкының батыр улы, республикада Совет властен урнаштыру һәм аны ныгыту эшенә зур өлеш керткән күренекле революционер, гражданнар сугышы һәм Бөек Ватан сугышы ветераны, отставкадагы генерал-лейтенант Якуб Чанышевка 80 яшь тулды.

25 февральдә Казан шәһәренең Офицерлар йортында атаклы генералыбызның олы бәйрәменә багышланган тантаналы кичә уздырылды. Аны, кыскача кереш сүз сөйләп, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Кадыйрова ачты. Тарих фәннәре докторы, профессор М. Мөхәррәмов кичәдә катнашучыларны Якуб Чанышевның революцион эшчәнлеге һәм зур тормыш юлы белән таныштырды. КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев КПСС өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм ТАССР Министрлар Советының тәбрик хатын укыды.

Юбилярны шулай ук Советлар Союзы Герое И. Г. Кобяков, Горбунов исемендәге авиация заводы слесаре В. П. Ларионов, отставкадагы генерал-майор Ф. Булатов, Татарстан язучылар союзы партия оешмасы секретаре Г. Минский, Татарстан художниклар союзы идарәсе председателе Х. Якупов, Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы ветераннары советы председателе Х. Төхфәтуллин һәм башкалар котлады. Кичәдә юбиляр исеменә килгән тәбрик хатлары һәм күп санлы телеграммалар укылды.

## ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ


25 февральдә Казан шәһәренең Актерлар йортында Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисты Зәйни Солтанов, Татарстанның атказанган артисты Бари Тарханов, артист Шакир Шамильский, Татарстанның атказанган артисткалары Мәрьям Сульва һәм Нәфига Арапоьаларны искә алу кичәсе үткәрелде. Артистларның тормышы һәм иҗат эшчәнлекләре турында доклад белән Хәким Сәлимҗанов чыкты. Кичәдә артистларның замандашлары үзләренең истәлекләрен сөйләделәр.

## ЭШЧЕ ХӘБӘРЧЕЛӘР КИҢӘШМӘСЕ

Февраль урталарында КПССның Чаллы шәһәр комитетының утырышлар залына «Социалистик Татарстан», «Советская Татария», «Коммунизм байрагы» һәм күп тиражлы «Кама таннары» газетасының хәбәрчеләре җыелды. КамАЗ төзелешендә социалистик ярышны яктырту буенча эшче хәбәрчеләрнең һәм журналистларның бурычлары турында доклад белән КПССның шәһәр комитеты секретаре П. М. Столяров чыкты. Киңәшмәдә, эшче хәбәрчеләрдән, производство алдынгыларыннан тыш, «Камгэсэнергострой» идарәсе партком секретаре А. И. Архипов, КПССның Татарстан өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Н. И. Демидов иптәшләр чыгыш ясады. Эшче хәбәрчеләр киңәшмәсендә «Социалистик Татарстан» газетасының редакторы Ш. Хамматов, «Советская Татария» газетасының редакторы А. И. Клименков, «Коммунист Татарии» журналының редакторы Ш. Вәлиев катнашты.

# АККОШЛАР

**ФАСЫЙЛ ӘХМӘТОВ** көе  **РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН** җыры






Көзләрдән соң язлар килми,—
алда — салкын, ак кышлар.
Китәсез дәмени,
китәсез дәмени,
китәсез дәмени, аккошлар?

Әллә ничек үтте яшьлек,
соң очрашты язмышлар.
Хушлашырга безгә
иртәрәк бит әле,
иртәрәк бит әле, аккошлар!

Бездә әле бу дөньяга
күңел тулы алкышлар.
Китәсез дәмени,
китәсез дәмени,
китәсез дәмени, аккошлар?

*Хөрмәтле укучылар!*

Журналыбызның 7 нче санында Шамил Бикчуринның **«Каты токым»** һәм Нәзир Сәфәровның **«Каргышлы һәм өметле көн»** әсәрләренең ахырын укырсыз.

Нәби Дәүлинең **«Тимәгез минем Гөлзадама!»**, Гамил Афзалның **«Халык белән очрашу»**, Нигъмәт Ихсановның **«Давылда»** исемле хикәяләре урнаштырыла.

Шулай ук Сезгә Әхсән Баян, Равил Фәйзуллин, Фәния Чанышева, Рәшит Гәрәй, Флера Гыйззәтуллина шигырьләрен тәкъдим итәбез.

**СССР төзелүгә 50 ел тулу** уңае белән белорус әдәбияты үрнәкләре игътибарыгызны җәлеп итәчәк.

Әдәби тәнкыйть бүлегендә Малик Хәмитов һәм Вячеслав Воздвиженский мәкаләләре, яңа китапларга рецензияләр бар.

Әдәбият тарихы белән кызыксынган укучыларыбыз Әхмәт ибне Фазланның **«Идел буе болгарларына сәяхәт»**ен укырлар.

Гөлсем Мөхәммәдованың **«Киев вакыйгасе»** дигән хезмәте Галимҗан Ибраһимовның Киевтагы революцион эшчәнлеге турында сөйли.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210